# Казан утлары

ИЮНЬ № 6
1965

# Казан утлары

АЙЛЫҚ ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИҚ ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ

*ҚЫРЫҚ ДҮРТЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА*

ИЮНЬ **6**

ҚАЗАН 1965

# Бу санда:

## РОМАН, ПОЭМА, ХИКӘЯЛӘР, ШИГЫРЬЛӘР


Г. Мөхәммәтшин. Дулкыннар. Хикәя . . . . . . . . . 3
Х. Камалов. Туган җирдә. Эскизлар . . . . . . . . . . . 14
Ә. Еники. Корьәнхафиз. Хикәя . . . . . . . . . . . . 27
Ш. Маннур. Муса. Роман . . . . . . . . . . . . . . 39
Р. Гәрәй. Яңа шигырьләр . . . . . . . . . . . . . 74
И. Салахов. Күкчәтау далаларында. Романнан өзекләр . . . . 75


## БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ


М. Фәйзуллина. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . 119


## НУР БАЯННЫҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ


З. Мәҗитов. Илнең туры улы . . . . . . . . . . . 122


## БӨЕК ҖИҢҮГӘ 20 ЕЛ


И. Гази. Истә калганнарым . . . . . . . . . . . . 125


## Г. ХАЛИТКА 50 ЯШЬ


Х. Госман. Тынгысыз илле ел . . . . . . . . . . . . 129


## СОВЕТ ВЛАСТЕНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА


Г. Галиев. Землемер баганасы. Очерк . . . . . . . . . 131
Р. Надиев. Борынгы шәһәрнең икенче яшьлеге. Очерк . . . . 141

---

К. Гыйрфанов. С. Рәмиев турында кайбер истәлекләр . . . 148
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 157


***Редакциягә килгән кульъязмалар кире кайтарылмый.***

---


Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана 19, Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 52. Редакция «Казан утлары».*

*Газиз Мөхәммәтшин*

# ДУЛКЫННАР

Хикәя

Көн кичке якка авышса да, һаман кыздыра. Бөркү. Биек камышлар, куе таллар белән капланган борылмадан кинәт кенә ялтырап килеп чыккан Ык өстендә дә, мал таптап бетергән яланда да, яландагы җәйләүдә дә тавыш-тын юк. Көндезге савым узган, сөтле бидоннар паромга төяп аръякка чыгарылган. Шуңа күрә җәйләүдәгеләр брезент палаткаларга, такта вагоннарга таралып ял итә.

Паром туктый торган күпердә, кулына кармак сабы тотып, Салих утыра. Ул өстенә куыш эчләрендә, кибән төпләрендә ауный-ауный керләнеп беткән сары майка һәм аңа иптәшкә ике балагының да тез күзләре тишек иске чалбар кигән. Кара чәчләре чуалып киезләнгән, битен-ияген шундый ук кара куе сакал баскан. Салих, күпер субаена агым китереп сылаган калкавычын бөтенләй исеннән чыгарып, күзләрен Ык аръягындагы тауларга текәгән дә уйга баткан. Аның уйлары Ык суы кебек тын һәм салмак ага.

«Нәрсә ул яшәү?» — дип сорый үз-үзеннән Салих һәм, кашларын җыера-җыера уйланып утырганнан соң, сүзенең хаклыгына бөтен рухы белән инанган кешеләрчә, салкын кан белән генә үзенә җавабын да бирә. Яшәү — көрәш, дөньяда яшисең икән, өзлексез көрәшергә кирәк. Бу — хакыйкать. Ләкин ни өчен көрәшергә? Менә шушы сорауга җавап табуы Салихка әллә нишләп кыен, буталчык кебек тоела.

Дөнья — бер. Дөнья — адәм балаларының бөтенесе өчен дә уртак бишек. Тик бу гомуми дөнья эчендә бик күп вак «дөнья»лар да яши ич. Аларын кая куясың! Һәр кешенең үз мөхите, үзе өчен генә аңлаешлы «бәләкәй дөньясы» бар. Нәрсәгәдер омтылганда, анык максатыңа ирешү өчен көрәшеп, өзлексез хәрәкәт эчендә яшәгәндә ул да синең белән хәрәкәт итә, көрәшә... Ә Салих соңгы вакытларда бернигә борчылмый йокымсырап яши башлады, һәм аның үз дөньясы да Салих белән бергә йокымсырады, тынды. Салихка шунлыктан бөтен кешеләр өчен уртак зур дөнья да шау-шуыннан, алга чабуыннан туктап калгандай тоела башлады. Салих үзе моны бик яхшы сизә, әмма борчылмый. Аның үз фәлсәфәсе бар. Чөнки болай җанга да, тәнгә дә рәхәт. Мәшәкать әз, тыныч. Ә бит кешеләр шуны аңламыйлар. Мисал өчен еракка барасы юк, мисал — кул астында. Җәйләүдәге кызларны кара! Ярты кружкә сөт өчен дөнья беткәндәй ах-ух килеп, төнне-көнне белми тызылдап-бызылдап йөриләр. Җыелышлар җыялар, киңәш-табыш итәләр, көлешәләр, әрләшәләр. Бер ише егетләр кара таңнан кара төнгә чаклы басуда җир сөрә. Шулай да ардым-талдым дими, ястык-мендәр турында уйламый. Шәмгә ут элдерүгә, дәфтәрләрен итек кунычына кыстырып, мәктәпкә йөгерә. Икенчеләре, ачуың да бер килмәгәе, бишегеннән төшкән көненнән алып картайганчы укый. Күз нурын коя-коя, нервысын бетерә-бетерә интегә. Ахыр килеп галим була, академик. Өченче

төрле хыялый башлар айга аяк басарга чамалап, теш кайрап йөри. Дүртенчеләре... Һи, санап бетерерлекмени, чут-чамасына чыгарлыкмени аларның!.. Ләкин бу тырышулар, җәфаланулар ахыр чиктә гомер буе бөртекләп җыйган белемеңне үзең белән ияртеп җир куенына кереп яту һәм туфрак булу өчен генә бит! Менә кай ягы кыен аның — фани дөньяның. Дөрес үк уйланып җитмәгән...

Кояш, урыныннан күчеп, Салихның кулбашларын һәм чалбар тишекләреннән пеләш баш шикелле ялтырап күренеп торган тез капкачларын яндыра башлады. Менә яр читенә пырылдап сиртмә койрык төште. Озын койрыгын көянтәдәй атындыра-атындыра, йөрәгенә чыдаша алмаган кеше төсле әрле-бирле йөгерергә тотынды. Болын буеннан велосипедында җилдереп почтальон малай узды. Елганың теге ягындагы печән кибәненә, канатларын салмак кына кагып, җәйге муллыкта симергән ялкау чәүкә кунды. Салихка «чәрр!» дип сәлам бирде. Җавап алмагач, безгә барыбер, дигәндәй, канат астыннан борча эзли башлады.

Салих, уйларына бирелеп, боларның берсен дә күрмәде. Һавада кинәт гөрелте тавышы ишетелгәч кенә, йокысыннан куркып уянган кеше төсле сискәнеп, өскә карады. Анда Актаныштан Минзәлә ягына самолет үтеп бара иде...

Салих кармагын судан тартып чыгарды. Кармактан каралҗымяшькелт озын кыраша ычкындырып күпергә ыргытты. Суалчанына төкергәләп кире салды да тагын дөньясын онытты, уй җепләрен әүвәлгеләренә ялгап җибәрде.

Менә ул, Салих, көтүче. Бүген таң атканчы ияр өстеннән төшмәде. Күрәнле ерганак буенда төн чыкты. Җәйләүгә сыерларны иртәнге савымга гына алып кайтты. Ашык-пошык бер кыерчык икмәк ашап, ярты чүмеч сөт эчте дә куышка кереп ауды. Төш житкәнче үлек шикелле йоклады. Кайсы ягы белән ятса — шулай торды. Кич тагын ияргә менәр, төнге көтүгә чыгар. Көн саен шулай, ай буе, җәй буе. Төнлә көтү, көндез йокы. Юри генә үзгәрсен, ялгышып кына бүтән төрле булсын икән! Көннәр төннәрне куып, тегермән куласасы шикелле җай гына әйләнә дә тора.

Ул, көз житкәч, көтүне фермага алып кайтыр. Элекке шикелле салам парландырырга керешер. Кыш буе ферма тыкрыгын таптар. Март бураннарында сырынды өстеннән таң саен яңа сукмак салып узар. Өч-дүрт пар бияләй, бер пар киез итек туздырыр. Ык язгы ташуларыннан арып, кире үз ярларына кайтып сыенгач, болыннар ачылгач, тагын җәйләүгә чыгар. Менә шул. Күңел өчен генә дә, бер генә дә яңалык юк. Бөтенесе — яшәп, күреп, туеп беткән нәрсәләр. Әйтергә кирәк, көннәр генә түгел — еллар да куласа төсле әйләнеп тора. Аны бүтәнчә итәргә көч-куәт житми. Таллык уртасында, балтырган, юа арасында яткач, ниләр генә кыландырсаң да, әлеге дә баягы — сыртына артыш таягы, дигәндәй шул көтүче Салих булып каласың инде. Анысы гына житмәсә, хатыны ташлап качкан карт егет Салих булып.

Теллерәк кызлар турыдан ярып, йөзгә бәреп тә әйтә: ир булган ирне хатын-кыз ташлап китми — чат ябышып ята, ди. Кем тикшереп йөргән дә кем төбенә төшкән — бәлкем, дөрес әйтәләрдер.

Салих көрсенеп куйды. Чыбыркы, чалгы, сәнәк сабы тота-тота тимердәй каткан бармаклары белән җилкә чокырын кашыды. Шул чакта аның нәкъ борыны турысында әллә ничек кенә бөҗән пәйда булды. Кәтүк җебе белән асып куйгандай бер урында бөҗелдәп җанны үртәп тора башлады. Салих аны кулы белән читкә селтәп җибәрде. Бөҗән бөҗлавы тынуга, колга өстеннән уйнаклый-уйнаклый куышып ике күбәләк очып үтте. Бу нәрсәкәйләренә хәтле парлы-парлы бит, чукынган, ачуың ничек килмәсен, дип мыгырданды Салих, ә син кеше башың белән түмгәк өстендә кыңгыраеп торган челән төсле ялгызың дөнья көт. Хатының киткәч — ни хәлләр итәсең. Башны ташка орып

йөрәккә җиңеллек килми. Баш ярылыр — таш калыр, бар кырганың шул булыр.

Салих көсләрне әрли-әрли (тагын алдаганнар) кармагына суалчан кигезде. Төшкән шәпкә, калкавыч суга чумды һәм «пылт» итеп калкып та чыкты. Ләкин бөтерелә-бөтерелә бер адым агарга өлгермәде — тагын күздән югалды. Салих, алабуга комсыз ахры: килгән шәпкә йота, дип кармак сабын тартты. Гаҗәпкә каршы, чирәм өстенә кармакны бик саран ала торган кашык буе чурагай килеп төште. Койрыгын җиргә бәрә-бәрә дөнья бетереп чабаланырга тотынды. Салих аны саңагыннан эләктереп кармактан ычкындырды һәм суга манчып кер чайкагандай чайкап алды да чиләккә җибәрде.

Шулчакта сукмакта зәңгәр күлмәкле бер кыз күренде. Ул, кәрзин тоткан ягына янтая төшеп, тиз-тиз атлап Салих янына килде. Кәрзинен шыпырт кына үлән өстенә куйды да аяк очларына басып Салихка якынлашты. Кулындагы үлән сабагын аның шәрә җилкәсендә йөртә башлады. Салих җилкәсен җыерды. «Чебен» алай да китмәгәч, кулы белән шапылдатып алды. Кыз көлеп җибәрде һәм күлмәк итәген рәтләп Салих янына утырды.

— Йоклап киткән дип торам.

— Ә-ә, син икәнсең, шайтан кызы, — диде Салих та көлемсерәгәндәй итеп, — ни чыкса — синнән чыга.

— Эләгәме?

— Юк. Бер исәр чурагай капты.

— Балык төптә шул хәзер, салкында. Чишмә чыккан урыннарны эзли.

— Беләм. Кәҗәсе өчен түгел — мәзәге өчен утырам. Вагонда күңелсез, торасы килми, туйдырган. Син үзең ни майтарып йөрисең?

— Чайкыйсы керләрем бар иде. Аннан соң, бик эссе. Чумып чыксаң да ярый.

Тын калдылар. Салих тәмәке төреп кабызды. Кыз күлмәк итәген сыпырып алды, үз уйларына үзе көлемсерәп куйды. Бит очлары уймактай чокырланып, йөзе тагын да сөйкемлеләнеп, матураеп китте.

Кызның исеме Фаягөл. Чәчләре сары, күзләре зәңгәр, бит алмалары, иреннәре алсу. Сүз өчен кесәгә керә торганнардан түгел — телгә дисеңме, эшкә дисеңме — чаяның чаясы. Әллә шуңа күрә инде, әллә башка берәр сәбәптән Салихның күзенә ул бүтән кызларга караганда ешрак чалына шикелле. Ул кайчакларда аның исемен юри үзгәртеп, Чаягөл дип дәшә һәм төнлә көтүдә йөргәндә: «Бирсә дә бирә икән ходай төрле төсләрне бер кешегә өеп, буяуларын кызганып тормый икән. Ә бу салават күперенең үзен кемгә бирер икән дә, кайсы җүнсез егетнең бәхете хәттин ашыр икән? Безнең ише картларга гына насыйп яр булып чыкмады. Безгә насыйп ярлар, әгәр әниләреннән туган булсалар, кайларда адашып йөри торганнардыр», — дип пошынып уйлана һәм караңгы талларга карап көрсенә. Көрсенә дә, үрелеп-үрелеп тә буе җитмәгәч, йөземнәр пешмәгән әле, аларны ашасаң ашказаныңны бозарсың, дип бакчадан чыгып киткән төлке шикелле: «Зәңгәр күзле, сары чәчле — әллә ничек шунда, безнең як халкына охшамаган ла ул», — дип, үзен юатып куя.

Фаягөл кинәт:

— Чиртә, чиртә!.. Тарт инде тизрәк!.. — дип кычкырып җибәрде. Салих уйларыннан айнып кармагын тартып чыгарды. Ләкин кармак, Фаягөлнең үкенеченә каршы, буш иде.

— Кычкырып балыкны куркыттың. Кармак салганда кем тавышлана, — дип мыгырданды Салих.

— Кычкырма дигән була! Төш күреп утыра да... Аннары кешегә сылтый...

— Нибуч көпә-көндез төш күрерсең. Минем урында эшләп кара әле. Җәй буена хет сыңар төн йокы тигәне бармы миңа?..

— Безне уйнап йөриләр дип беләсеңме? Сөтне аны савуы түгел — эчүе генә җиңел.

— Ансын белә-әм! — диде Салих, нигәдер төксе генә итеп.

Фаягөл аның тавышындагы үзгәрешне әллә сизмәде, әллә сизеп әһәмият бирмәде, субайга маймыч шикелле борынын төртеп йокымсыраган калкавычка күз салып алды да тагын сүз катты:

— Кай көннәрне билнең, кулбашларның сызлавына чыдар хәл калмый, бармакларны язып булмый. Вагон сәкесенә кереп егылыр идең дә кыймылдамый-нитми рәхәтләнеп ятыр идең. Ләкин Ык буенда гармун тавышы ишетелүгә сикереп торасың. Әйбәт киемнәреңне киясең. Ник дисәң, уйныйсы-шаярасы килә, күңел күтәрәсе килә. Уен-көлкесез тормыш — тормышмени ул!. Яшәдең ни, яшәмәдең ни!.. «Уйнамагач та көлмәгәч, бу дөнья нигә ярый», — дип тәк томалдан җырламыйлар шул.

Фаягөлнең күзләре уйчанланып, моңсуланып китте. Ул «артымнан йөргән егетләр күп, арысландай батырлары, һуш китмәле матурлары да бар, ләкин нишлим, нишлим — сине сөясем, синнән сөеләсем килә, мәхәббәтсез тормыш — тормышмени ул!» дип әйтергә теләгән иде. Ләкин тыелып калды. Кирәкмәс, дип уйлады, ул сүзләр теләсә кайда кычкырып әйтелә торган сүзләр түгел. Хисләр дә, мәхәббәт хисләре дә изге — аларны уйламыйча түгәргә ярамый...

— Уйнагыз, шаярыгыз! Сезне тыйган кеше бармы әллә, — диде Салих һаман караңгы чырай белән. — Шуның өчен дә яшьләр. Яшь чак — тиле чак бер генә була. «Яшь гомерләр ике килми, сулар үргә акса да», — дип тә җырлыйлар бит.

— Ә син үзең яшь түгелмени?

— Түгел... Бәхетсезлегемә каршы.

— И илаһым!.. Әллә картаеп та киттеңме?

— Ие... кызганычка каршы.

— И-и, менә агай! Алайса ничә яшьтә инде син, бабыкай?

— Егерме алтыда, үскәнкәй. Дүрт ел үттеме — утыз тула. Аннан инде дүртенче дистә китә дигән сүз. Кырыкны ваклый башладыңмы — илле, илле артында алтмышы көтеп тора.

Фөягөл вак ташларен кояшта елтыратып көлеп җибәрде. Ул, куллары белән җиргә таянып, гәүдәсен әз генә артка ташлап, гөнаһсыз балаларча рәхәтләнеп көлде. Салих аңа җәлт кенә күз салып алды. «Чибәр чая гөл, чибәр!»

Фаягөл, көлүеннән туктап, күлмәгенең кай төшеннәндер кульяулык алды. Яшьле күзләрен сөртә-сөртә, һаман да «пырх-пырх» итеп, Салихның уйларына җавап биргәндәй әйтеп куйды:

— Кара син, мин бит чыннан да синнән җиде ел соң туганмын, бабыкай. Тик син юкка уфтанасың. Кызгандырырга тырышып. Кеше төсле генә түгел. Ташла шул «карт-карт» диюеңне, мескенлегеңне. Оят кирәк әзрәк. Самогоны беткән чуаш шикелле йөрисең.

— Җитәр, кызый!.. Чая дигәч тә син тагын... Ник телеңә салынасың?..

— Пошмас бәндә булганга. Билләһи дип әйтәм, — ачуың килмәсен, — синең ишеләргә санаторий ни дә, крематорий ни — барыбер. Турысын әйткәнгә үпкәләмә — көлмәк итәгеңә ут капса да торып сүндермәссең син: пожарниклар килеп су сиптерүен көтеп ятырсың...

Кыз чуерташ алды да аны ачу белән Ык өстенә бәпчетеп җибәрде. Таш, дүрт-биш мәртәбә сикереп, аръякка җиткәндә генә суны кистереп төпкә чумды. Салих: — «Балыкларны качырып бетерәсең, тиле кызый», — дип сукранып куйды.

— Тота алмаган балыгыңа..., — диде кыз.

Тагын тынлык урнашты. Шулчак су читендәге яшел төнбоек өстенә төнбоек төсле үк яшел сыртлы бәләкәй бака баласы үрмәләп менде. Тамак астын дер-дер калтыратып, шар күзләрен ачкалап-йомгалап егет белән кызга карап торды. Куркыныч юклыгына, күпер өстендә озын таяк тотып утыручы кешенең үзенә тимәслегенә ышангач, батыраеп китеп, баш очында безелдәп торучы черкигә сикерде. Әмма, кызганычка каршы, аны эләктерә алмады, «чулт» итеп сырты белән суга егылып төште. Ап-ак шәрә корсагын кояшта ялтыратып, аякларын әле җыерып, әле язып ни булганын аңлый алмыйча бертын аңгыраеп ятты да, аңлагач, оятыннан тиз генә төпкә чумып юк булды.

Фаягөл дә, Салих та ул мескенкәйнең көпә-көндез хур булуын күзәтеп утырганнар икән. Кычкырып көлеп җибәрделәр. Көлүдән башта Салих туктады, һәм аның чыраена шунда ук тагын җитди кырыслык йөгерде. Ул башын борып Фаягөлгә карады. Ачуы килүен яшерепнитеп тормыйча, төксе генә тавыш белән:

— Тә-әк. Пошмас җан, күлмәк чабуың яна башласа да сүндерергә иренеп ятырсың, дисеңме! Ә син моны, иптәш прокурор, нидән чыгып, нәрсәгә нигезләп әйтәсең әле? Һәм алай дияргә кем сиңа хокук, права бирде? — дип сорады.

Фаягөл икенче таш алып су өстенә бәпчетеп җибәрде.

— Нидән чыгып әйтәмме? Менә нидән чыгып әйтәм, Салих. Чын егет кулында ут уйната, кылны кырыкка яра, диләр. Син дә шулай бит. Мин белгәннән бирле син гел эштә. Кулларыңда ут уйный. Мин сине гел эштә генә күрәм. Тынгысыз син, кырмыска кебек. Ә бүтәнгә... Бүтәнне күрмисең... Әллә ничек шунда. Бер нәрсәгә дә исең китми, ахры. Ә бу бит, беләсең килсә, бик куркыныч нәрсә. Кешене бөгеп төшерергә, үзенең колы итеп бөтенләй җиргә егарга, бетерергә может. Элек нинди матур җырлый идең, баяныңны нинди оста уйный идең. Таң алдыннан урам буйлап сыздырып кайтканда без, ник икәнен үзебез дә аңламыйча, елап уяна идек. Ә хәзер җырың да ишетелми, баяныңны да уйнамыйсың. Ни булды сиңа? Мөгаззәмә апа шулай сүндереп киттеме синең күңел утыңны? Ник йөрәгең йоклады синең, җаның ник йоклады?

Салих, шаккатып:

— Йөрәге йоклаган кеше үлә, — дип кенә әйтә алды.

— Җаны йоклаган кеше дә шуннан артык түгел. Тере мәет белән бер. Бүтәннәргә андыйлардан нинди файда да нинди зыян! Сөт тә, йон да юк.

Салих җилкәсен кашып алды һәм «черт» итеп суга төкерде. Ләкин бу усал телле кызның нинди максат белән мондый төртке сүз башлавын, тел төбен бераз сизенгән шикелле тоелса да, бөтенләй үк аңлап бетермәгән иде. Шуңа күрә аптыраганрак һәм ачулырак иде. Шуны кызга сиздермәс өчен ул шәрә тезенә уч төбе белән шапылдатып сугасуга:

— Мин үз йөрәгемне иртәме-соңмы барыбер аңлармын. Сезне төшенүе кыен. Әйт әле менә: син үзең чәчәк кебек яшь чагыңны нигә чебенчерки мыжлап торган куыш эчендә заяга уздырасың? — дип сорады.

— Эшлим.

— Ни өчен?

— Кешеләр өчен.

— Мин укытучы түгел, син дә укучы түгел. Такта янында җавап бирмибез. Дәреслек буенча сөйләвең монда бик үк килешеп бетми бетүен дә — ләкин ярар. Чөнки, ник дисәң, мин үзем син килеп әрләргә керешкәнче нәкъ шундыйрак уйлар белән баш вата идем. Бу фани дөньяда тырышыргамы, көрәшергәме, әгәр шулай итәсең икән, инде ни өчен көрәшергә дә, ни өчен тырышырга?! Киләчәкне без барыбер күрмибез, төзибез генә.

— Бүтәннәр күрер.

— Кем соң ул «бүтән»? Мин аны белмим һәм беләчәк тә түгелмен. Үзем бәхетле итәр өчен арып-талып эшләгән ул кешемне күрергә тиеш бит инде мин. Аңа хакым бардыр бит?..

— Син, Салих, әллә ниләр сөйлисең бүген. Тәмам буталып беттең. Иртә белән сөт урынына карга мие эчмәгәнсеңдер бит?

— Син, кызый, боргаланма. Әйтә алсаң — турысын әйт. Үзең ничек уйлыйсың?

— Мин ул киләчәк буын кешесен күрәмме-юкмы — бу минем өчен вак мәсьәлә. Ул кем булса да — миңа барыбер. Мин бүген аларның берсе өчен генә түгел — бөтенесе өчен эшлим.

— Әйдә, укы лекцияңне, кызый, укы... Мин бүген аның өчен көтү көтеп йөргән кеше, киләчәк кешесе, ул бәхетле җәмгыятьтә бәхетле булып яшәрме?

— Әлбәттә.

— Димәк, синеңчә, коммунизмда бернинди кайгы-хәсрәт булмаячак?

— Әлбәттә.

— Юк! Ул чакта да кайгы-хәсрәт булачак. Моңа минем иманым камил.

— Син ни сөйлисең? — диде Фаягөл, аптырабрак. — Кайдан алдың бу сүзләрне, кайдан килеп телеңә керде алар?

Салих кармак сабын күпер өстенә ташлады да Фаягөлгә борылды. Үзе дә сизмәстән аның кулларыннан алды. Йөзе, кырыслыгын югалтып, уйчанланып китте.

— Кайчак үз фикерем дә була минем, Фаягөл. Коммунизмда машиналар, төрле роботлар булыр, гомумән, техника, автоматика бик нык үсәр, дибез. Әмма анда эшләүче кешеләр синең белән минем шикелле үк кешеләр ич. Йөрәкләре дә безнеке шикелле калачак. Хәзерге кешенең бөтен тойгылары, хисләре аларның йөрәкләрендә дә булыр. Йөрәк хисләрен, уйлау, фикерләү сәләтен бернинди заман да машина яки автомат белән алыштыра алачак түгел. Бер генә мисал: коммунизм кешеләре дә, нәкъ без курыккан төсле, үлемнән куркырлар. Яшәвен бездән озаграк яшәрләр, ләкин дөньядан нәкъ хәзерге шикелле китәрләр. Үлем үзе генә йөрми, үлем кайгы-хәсрәт, күз яшьләре ияртеп йөри. Газиз ата-аналарын, сөекле балаларын югалткан кешеләр кайгырмаслар, еламаслар, янмаслар-көймәсләр дисеңме? Янарлар-көярләр. Чөнки кеше йөрәге, йөз еллар, мең еллар үтсә дә, үзгәрмәс, һаман шул кеше йөрәге килеш калыр. Шатлана да белер, кайгысын да күтәрә белер...

Салих, Фаягөлнең кулларын җибәрде дә, үз урынына борылып утырып, дулкынланудан тирләгән маңгаен кул аркасы белән сыпырып алды, ашыгып тәмәке кабызды. Фаягөл Салихны авызын ачып тыңлап торды. Менә кайчаннан бирле өс-баш дигән нәрсәгә тамчы да әһәмият бирмичә, ертык-пыртык киеп, бөтен дөньясына үпкәләгәндәй башын аска иеп, җимерек күз-каш белән берәүгә дә дәшми уйланып йөрүче бу кешенең кинәт дөрләп китеп бик күп сөйләп ташлавы һәм аның сүзләрендә соңгы елларда ишетелмәгән, әле хәзергә бик үк аңлашылып та бетмәгән нindидер хаклык яңгыравы Фаягөлне аптыраткан һәм куандырган иде...

Ык буендагы камышлы күлләрнең кайсынадыр балыкчылар ау салды ахры, выртлавыч белән «вырт-вырт» итеп балык мутарга тотындылар.

Бу тавыш Фөягөлне уйларыннан айнытып җибәрде. Ул әкрен генә:

— Ә мәхәббәт?.. Мәхәббәт ничек булыр?.. Мәхәббәт үлгәннәрне дә терелтә диләр бит? — дип сорады.

— Төрлесе була, — диде Салих, аңа карамый гына. — Мәхәббәт үлене терелтә, терене үтерә.

Кыз аңа тиз генә каршы төште:

— Юк!.. Ул дәвердә инде тереләрне үтерә торган мәхәббәт дөньяда яшәмәс. Үзе үләр. Синең сүзеңә ышанмыйм, ышанасым килми. Мәхәббәт кешеләргә бары тик шатлык кына китерер. Аларның гомер юллары матурлар. Бәхеткә, таң йолдызы шикелле юл күрсәтеп, яктыртып торыр. Көрсез, саф мәхәббәт, көнләшүләрдән, төрле түбәнлекләрдән чистарган чын мәхәббәт кешеләрне кешеләр өчен әллә нинди, күз күрмәгән, колак ишетмәгән батырлыклар эшләргә өндәп торыр.

— Җүләр кызый! Яшь син. Телең акылыңнан алда йөри. Шуңа күрә күңелеңә килгәнне телең әйтә дә бирә. Ул чакта, значит, халыкның бөтен эше, бөтен мәшәкате бетә дә, гыйшык-мыйшык тотышып, кети-кети уйнап ятарга гына кала инде, ә?.. Шулаймы?

Кыз ярсый башлады. Кашлары дулкынланып урыныннан купты, бит урталары кызарып янарга тотынды.

— Түгел! Син уйлаганча түгел! — диде ул, ашыгып. — Мәхәббәт — иҗат чишмәсе. Дөрес мәхәббәт бер чакта да эшкә комачауламый.

— Дөрес мәхәббәт!? — дип сорады Салих, гаҗәпләнеп. — Анысы нинди була тагын?

— Дөрес була, чын, — диде Фаягөл, тиз генә аңлата алмавына уңайсызланып. — Сөйгәнең өчен, әгәр кирәк булса, эһ! тә итми җаныңны бирерлек...

Салих, башын аска иеп, көрсенеп куйды.

— Эх чая, чая гөл! Беркатлы кызый! Мәхәббәте хакына минут та уйламыйча, син әйткәндәй, җанын ярып бирергә торган чибәр кызлар, батыр егетләр хәзер юкмы әллә? Таһир-Зөһрәләрне элек кенә яшәгән дисеңме? Хәзер дә бар алар. Күп. Һаман күбәяләр. Тик, кызганычка каршы, монда безнең тирәдә, безнең өчен түгел. Еракта — башка бәхетлеләр өчен...

Кызның зәңгәр күзләренә гаҗәпләнү чыкты, ул:

— Син әйткән «ерак» кайда соң? «Бәхетле» дигәнең кемнәр? — дип сорады.

— Улмы? Ул «ерак» дигәнем Казан, Мәскәүише гөрләп торган шәһәрләр. Караңгы төндә дә шушы көн шикелле ялт итеп торган киң урамнар, матур парк-бакчалар. Мәрмәр сарайлар, институтлар, университетлар, театрлар, кинолар, тагын мең төрле әллә нәрсәләр. «Бәхетлеләр» дигәнем шул бакчаларда киенеп-ясанып көлешә-көлешә гүлят итеп йөрүче чибәр кызлар, ак күлмәкле, чиста тәнле — профессор булырга укучы егетләр. Завод-фабригында җиде-сигез сәгать эшләп кайтканнан соң, төзәнеп-бизәнеп ял итүче шәһәр кешеләре... Аларның син омтылган мәхәббәткә һәм гыйшыклы уйнарга урыннары да бар, вакытлары да җитәрлек.

Фаягөлнең күзләрендә баягы гаҗәпләнү әкренләп югалды, алар уйчанланып киттеләр.

— Ә безнең вакыт юкмы? — дип сорады ул, сагышлы тавыш белән, әкрен генә.

Салих үз сүзләренең эзсез калмавын, Фаягөлгә тәэсир итүен күреп эченнән куанып алды. Ләкин куанычын тирәнрәк яшерде, тышка чыгармады. Гадәттәгечә тыныч күренергә тырышып, кызга җавап кайтарды:

— Ә безнең, Фаягөл сеңелкәем, андый подручкем гүлятләргә чынлап торып бөртек тә вакытыбыз юк. Шәһәр халкы, син уйлама, культуралы яшәргә генә түгел — культуралы ашарга да ярата ул. Синең белән минем ише кешеләр, шәһәр халкы күзен ачып иртән торуга, аның өстәленә җылы булки белән куе сөт һәм дә кефир-мефир ише нәмәкәйләр әзерләп куярга тиешбез.

— Ә урын? Син бит әле яшьлек хисләре өчен урыннар да юк дисең?

— Әйттем. Артыңа әйләнеп кара, тирә-ягыңа... Минем сүзгә ышанырсың. Елның ел буена якты дөнья чырае күрмә, иртән эш диеп ян, кичен эш диеп көй. Син әйтәсеңме инде, мин әйтимме — бер үк балык

башы — тирес арасында сыер җилене тартып яшәп ничек күңел күтәрелсен! Мәхәббәт дип ничек йөрәк җилкенсен! Мәхәббәт дурак түгел ул: мондый урыннарны җир буе җирдән әйләнеп үтә.

Салих тагын тәмәке кабызды. Ләшберди башлаган әрекмән белән ябылган калай банка төбендәге суалчаннарны туфрагы-ние белән су өстенә селтәп җибәреп, кармак җебе урарга кереште. Фаягөл, тезләрен кулмәк итәгенә тыгып, җайлап утырды һәм күзләрен ерактагы яшел урманнарга текәде. Урман читендәге юлдан машина үтте бугай: ул урында урманны каплап, бөтерелә-бөтерелә каралҗым тузан болыты күтәрелде.

Шулчакта күперчектән ун-унбиш адым читкә каяндыр килеп чыккан тәкәрлек кунды. Мөгезен бик дәһшәтле тырпайтып куйды да йомшак кондырак арасына бер күмелеп, бер калкып, җәйләүгә таба чапты. Ык уртасына, күкрәге белән һава ярып, туп шикелле атылып акчарлак төште. Су чупылдады. Акчарлак, күз ачып йомганчы, кашык сабы озынлыгы ялтыр балык эләктереп, кире һавага омтылды.

Аларны тын гына күзәтеп утырган кыз көлеп җибәрде һәм, әллә инде сабый чакларын искә төшереп: «Тәкәрлек, тәкәрлек! Тәңкәң булса миңа бир! Акчарлак, акчарлак! Акчаң булса миңа бир!» — дип кычкырды. Ләкин шунда ук җитдиләнеп Салихка карады.

— Концертлар, парклар юк дисең... Кояш чыккан чакта әнә теге яшел камышларның таң җиленнән әкрен генә шаулап, серләшеп утыруын ишеткәнең бармы?.. Мин тыңладым. Күп тапкырлар. Камышлар моңы, акчарлак тавышы минем күңелемә барлык музыкалардан матуррак булып ишетелде. Камышлар пышылдавын тыңлый-тыңлый, менә шушы болын буйлап ничәмә-ничә таңнарда ничәмә-ничә тапкырлар үттем мин. Салкын чык табаннарымны куыра иде, артымнан яшькелт сукмак, әле генә үзем салган юеш сукмак, сузылып кала иде. Кеше күңеле ни телидер — белүе кыен, кеше күңеле — томан, диләр. Ләкин таңгы чыкларны коя-коя барган юеш сукмагымны син әйткән паркларның комлы юлларына үлсәм дә алыштырмас идем мин. Чын әгәр, ант итеп әйтәм... Безнең яклар!.. О-о, безнең якларның, Ык буйларының матурлыгы!.. Шушы табигать эчендә, шушындый көндә яшь-яшь егет бөтенләй имансыз булса гына борынын салындырып, кара коелып утырыр. Йөрәк урынында таш булган кеше генә ник туганына үкенеп яшәр...

Фаягөл читкә борылды һәм тыңлаусыз бармаклары белән чәчләрен рәтли башлады. Салих аның чая икәнен бик күптән белсә дә, болай килешле итеп, укытучылар шикелле бәйләнешле итеп сөйләвен беренче тапкыр ишетә иде. Шуңа күрә ул башта, күзләрен челт-челт йомып, аптырап, соңга таба гаҗәпләнеп утырды. Кыз камыш дигәндә камышларга карады, акчарлак дигәндә, күзе белән әллә кайчан очып киткән акчарлакларны эзләде. Ул үзенең җиңелә башлавын, Фаягөлнең, балачага итеп санга сукмый йөргән сары чәчле кызның, аның таш күңелен эретеп өстенлек ала башлавын сизде. Тик аның сүзләрен аста калдырырлык каршы сүзләр (хәер, андый сүзләрне әйтергә ул бик үк теләми дә шикелле иде инде) тапмады. Шуңа күрә телен тешләп бер җавапсыз калмас өчен генә:

— Ямь юк монда, ямь, — дип куйды.

— Тормыштан ямь табар өчен, беренчедән, аны аңлый белергә һәм күрә, таба белергә кирәк...

— Икенчедән... — диде егет, кызның сүзен бүлеп, ирония ишетелеп торган тавыш белән.

— Икенчедән, — дип дәвам итте кыз, — икенчедән, тормыштан ямь табар өчен үзең ямьле булырга кирәк.

— Мин тормышны аңлый белдем — тормыш кына мине аңламады, — диде Салих, тагын көрсенеп. — Ә ямем юклыгын мин беләм...

— Аны кайдан алдың?.. Нишләп синең ямең булмасын, ди?..

Бу гади сорау, нишләптер, Салихның күңел түрендә моңа кадәр тын гына йокымсырап яткан яшерен хисләрен кузгатып җибәрде. Таш курчакныкыдай зәңгәр күзле шушы кызга әз генә эч серләрен әйтәсе, бераз күңелен бушатасы килеп китте. Ул әле моңарчы берәүгә дә кычкырып та, пышылдап та чыгармаган серләрен ничектер искитмәгән төс белән, җиңел генә әйткәндәй әйтте дә бирде:

— Ямьле кешене хатыны ташлап китми.

— Шуңа дисеңме?

— Шуңадыр инде...

— Дөрес түгел! Мөгаззәмә апа үзе ата ялкау булды. Тир түкмичә, тузан йотмыйча яшәргә теләде. Анда да күмәч кенә ашап. Сыерыгызны да юньләп сава белми иде бит ул. Ярты сөтен калдыра иде. Шуның белән мескен хайванны көтүгә чыгара иде.

— Аларын алла белә...

— Алла түгел — мин беләм. Шәһәргә таюы синең аркадамы әллә? Черки күп, яши алмыйм, дип үзе кылтаеп йөргән. Шәһәр җүләр түгел — эш яратмаганнарны ашатмый. Ул ялкаулыгы белән бик үк романтикалый алмыйдыр әле.

Салих тагын тиз-тиз тәмәке тарта башлады. Фаягөл, ни әйтер икән, дигәндәй, аңа карап куйды да, эндәшмәгәч, уйчан гына өстәде:

— Иреннән аерылган хатын — канаты каерылган хатын, диләр дә диюен... Тик мин аны кызганмыйм. Ул үз канатын үзе каерды.

— Аларын халык белми шул, — диде Салих су өстенә карап. — Бер ярамаган гадәт бар: семья таркалдымы, ирне сүгәләр. Ә ире түгел — хатыны әшәке булып чыкса!.. Унау аерылышса, шуның бишесе хатыннары аркасында түгелме әллә? Шулай бит?.. Ә бездә бернәрсә булдымы — шалт ирнең маңгаена. Тоталар да шуны гаеплиләр. Аннан соң бөтенесе синнән читләшә, исерек адәмнән качкандай кача. Элекке дусларың ташлый, хатын-кызларны әйткән дә юк — алары бөтенләй дошман күрә башлый. Берәү дә яратмый. Менә шундый тормышта ничек яшәмәк кирәк, ничек күңел күтәрелсен!..

— Бөтенесе дошман күргәндәй тоела гына. Ә сине кем дошман күрсен. Ни өчен?.. Ю-ук!.. Сине бөтенесе якын итә, дус, иптәш күрә... Әйтсәм-әйтим инде: сине хәтта яратып йөрүчеләр дә бар. Чын әгәр. Бер кыз...лар ярата сине...

Салих күңелсез генә көлеп куйды.

— Син инде бигрәк... Арттырам дигәч тә... Кем яратсын мине!

— Яратканның яхшысын-яманын тикшереп тормыйлар. Яраткан яхшы булып күренә, — диде Фаягөл әкрен генә.

— Нишләп минем бер дә очратканым юк соң ул кызны?..

— Акча янчыгын югалткан бай шикелле гомер буе җиргә карап йөргәч... Тирә-ягыңа, якты дөньяга бер күтәрелеп күз салмагач...

— Җүләр кыздыр ул...

— Монсын мач китердең. Җүләр, бик җүләр. Шыр тиле булмаса, башын-күзен сакал баскан, йөрәгенә мүк үскән бер боек җан өчен, тилебәрән орлыгы ашаган кебек, шул гомердән бирле тилереп йөрмәс иде...

Салих Фаягөлнең тавышында әлегә чаклы ишетелмәгән рәнҗү белән үкенү тойгылары сизеп аптырап китте. Шунда аның күкрәген рәхәт яндырып эчке бер дулкын узды. Егет кызның сүзендәге тирән мәгънәне әкренләп аңлый башлады һәм гаҗәпләнеп тә, куркып, оялып, куанып та аңа карады. Кыз башын аска иеп, салам очы тешләп утыра иде. Аның күкрәге еш-еш күтәрелә, кызышкан бит алмаларын тагын да матурайтып шәфәкъ алсулыгы йөгергән иде.

— Фаягөл!.. — диде Салих, бөтен хисен, бу кызга булган бөтен якынлыгын үзе дә сизмәстән тавышына кушып. — Чая, чая гөл!.. Син...

Шул вакытта Фаягөл кыр кәҗәсе җитезлеге белән урынынnан сикереп торды. Кулмәк итәгенең бөгәрләнгән урыннарын сыпыра-сыпыра, тыныч әйтергә тырышып:

— Синең баяның кайда? — дип сорады.

Салих, сүзнең һич көтмәгәндә бөтенләй икенче, ят темага күчүенә гаҗәпләнеп, каушап төште. Зиһенен җыеп, шактый вакыт торгач кына:

— Баян!.. Нинди баян? — дип сорады.

— Баяныңны алып киләсеңме?.. Җәйләүгә.

Салих әз генә уйланып торды да кыю итеп:

— Киләм! — диде.

— Бүген кич... уйнарсыңмы?

— Уйнармын! — дип кычкырды Салих. — Чукынсын, син әйткәч уйнармын!..

— Әйбәт күлмәгеңне киярсең. Мин аны алып килдем. Юарга.

— Нинди күлмәк? Кайдан алдың? — диде Салих, аптырап.

— Кайдан булсын, мендәр астыңнан, — диде Фаягөл әз генә елмаеп, әз генә шелтәләп. — Җә, майкаңны бир!

— Майканы?.. Минем... шушы сары майканымы? — диде егет, тагын да ныграк аптырап.

— Әйе инде. Сары дигән була. Беләүләнеп каткан бит. Төсен аерып булмый. Бер очтан аны да юып, үтүкләп бирим. Җә, сал инде!

Салих, командир боерыгын үтәгән солдат шикелле, ашыгып майкасын салды. Фаягөл аны кәрзингә ташлады да тиз-тиз атлап таллар артындагы басмага китте. Салих шәрә тезләрен һәм шәрә корсагын Кама аръягындагы зәңгәрсу таулар өстенә барып җиткән кояшка ялтыратып, бу хәлләргә гаҗәп-хәйран булып һәм әз генә миңрәүләнеп, утырган урынында утырып калды. Һәм ул, кыз керләрен юып бетереп киптерергә элгәнче һәм чәчләрен рәтли-рәтли каршысына килеп басканчы, бу көнгә хәтле башына кермәгән рәхәт уйларын уйлап, әледән-әле үзалдына елмаеп утырды. Фаягөл:

— Уфф... Су керәбезме? — дигәч:

— Керәбез, әбизәтилне керәбез! — дип чамасыннан арттырыбрак кычкырып җибәргәнен үзе дә абайламый калды. Шунда ук тишек чалбарын салып атты. Кара сатин трусиктан гына калып, кызның чишенгәнен көтә башлады.

— Кара, күзләре шакмак кебек... Читкә борылып тор — күлмәкне салам, — диде Фаягөл, Салих борылды. Фаягөл тиз генә күлмәген салды да йөгереп килеп ярдан суга сикерде. Бераздан Ык уртасында аның башы күренде. Ул, битен-күзен каплаган сары чәчләрен сыпырып, Салихка карады да, аның аягы белән комлы төпне сак кына капшыйкапшый әкрен генә эчкә керүен күргәч, түземсезләнеп:

— Курыкма!.. Күпердән башың белән чум!.. Акчарлак ясап! — дип кычкырды.

Алар бик озак, тәмам арып беткәнче, рәхәтләнеп коендылар. Икесе бөтен Ык өстен шаулатып, көлешә-көлешә үрдәкле уйнадылар, каршы ярга чыгып тал араларыннан кара бөрлегән җыеп ашадылар, былтыргы кибән урыннарыннан юа эзләделәр, яр тишекләреннән җиде кысла, бер шамбы тоттылар. Кыслалардан, кыса дип, Фаягөл курыкты. Шуңа күрә аларны тоту белән кире җибәрә бардылар. Ә шамбы кызның кулыннан үзе шуып төшеп китте. Паром күпере өстенә беренче булып арган-талган, әмма түбәсенә һич истә-оста юк чакта үзе ишелеп төшкән бәхеттән һәм шатлыктан авызы ерылган Салих чыкты. Аның артыннан Фаягөл йөзеп килде. Кулларын өскә сузып:

— Я инде, тартып ал! — диде.

Салих үрелеп аның кулларыннан тотты. Кызның матур муенына, купальнигы өстеннән әз генә күренеп торган зур ак күкрәкләренә, аларны аерган матур уентыга карап бер мизгелгә башын югалтты.

Күпер өстенә күтәрелгәч, аларның күкрәкләре бер-берсенә сизелерсизелмәс кенә кагылып китте. Салих күзләрен йомды. Тәнендә кузгалырга иткән ләззәтле һәм газаплы ят тәләкне куып тиз генә кызның кулларын җибәрде.

Фаягөл сөлге белән сөртенгәннән соң:

— Борыл, киенәм! — диде.

Салих сүз тыңлаучан бәләкәй бала шикелле тагын читкә борылды. Эченнән генә көлеп, кызык та бу кызлар халкы: ни гомер су кердек, бөрлегән җыеп йөрдек. Анда карарга ярый, ә чишенгәндә — киенгәндә — ярамый, дип уйлап куйды. Фаягөл керләрен җыеп кәрзингә тутырды.

— Кипкәннәр дә. Хәзер кайтып үтүклим, — диде.

— Рәхмәт инде сиңа! — диде Салих.

— Рәхмәт — әйтүеңә рәтләп. Кич баяныңны онытма!

— Онытмыйм инде, онытмыйм, Фаягөл!..

Фаягөл зәңгәр күлмәген җилфердәтә-җилфердәтә җәйләүгә кайтып китте. Ни булды соң әле бу, дип уйлады Салих, шәрә корсагында бармакларын биетеп, иртән дөньяда яшисем килми иде — хәзер бала-чага шикелле җүләрләнеп көләм дә торам, көләм дә торам. Мәхәббәт шулай давылландырамы кеше күңелен? Җан өрәме, әллә нинди олы эшләргә өндиме, киләчәккә чакырамы?.. Мөгаен... Шушы ак йөзле, зәңгәр күзле, алсу иренле салават күпере шаштырып киттеме? Чынлап шашаммы? Әллә карт башымнан гашыйк буламмы? (Салих сакал баскан ияген шытырдатып ышкып куйды.) Ә нишләп карт булыйм мин!.. Кырынырга, чистарынырга кирәк бүген. Көне нинди матур... Җәйләү дә шәп төштә безнең. Курорт бу. Казан халкы ялга дип безнең якларга килә... Фаягөл, чая гөл!.. Чукынсын, чыгам бүген кичке уенга, сыздырам баянны.

Кояш бәләкәй ак болыт астыннан чыкты. Болыт күләгәсе Ык өстеннән шуышып узып, каршы ярдагы таллар арасында эреп югалды.

Салих күпердәге чиләген алды да андагы чурагайны Ыкка җибәрде. Чиләктә азапланып яткан чурагай, үзенең ирекккә чыгуын аңламый торды. Аңлап алгач, койрыгы белән суга бәреп, эчкә — тирәнгә кереп китте. Ул төштә су өстенә түгәрәк дулкыннар таралды.

Җәйләүдә радиола уйнатып җибәрделәр. Җәйләү өстенә, ямьле Ык буйларына Фәридә Кудашеваның искиткеч йомшак, саф һәм ягымлы тавышы таралды:

Таң алдыннан Агыйделнең
Дулкыннары бик салкын,
Яшь йөрәкнең дулкыннары
Нигә икән бик ялкын...

Салих моңа чаклы яраткан җырчысының тавышында таш күңелле кешеләрне генә түгел — ташның үзен үксетерлек моң ишетә иде. Ләкин ул бүген бу җырда сагыш тулы моң түгел — күңелнең иң тирән, иң яшерен хисләрен кузгатырлык куаныч һәм бәхет авазы, ир йөрәген эшкә һәм көрәшкә җилкендерә торган чакыру, өндәү тавышлары ишетте. Гаҗәпкә калып, җырны тыңлый башлады.

Март, 1965 ел.

*Хисам Камалов*

# ТУГАН ҖИРДӘ

*(Эскизлар)*

## ИКЕ ӘЛМӘТ

Әлмәт тирәкләре мине күргәч
Таныган күк шаулап куйдылар;
Иске Әлмәттә йөрим уйга чумып,
Яңа Әлмәткә тарта тойгылар.
Истәлекләр мине эзәрлекли,
Үкенүләр килә эземнән,
Монда үткән бүлеген мин гомернең
Сызып ташлый алмыйм үземнән...
Үткән яшьлек тарта иске Әлмәткә,
Хәзергесе тарта — Яңага,
Яңа белән иске тартышалар,
Аркан тартышкандай мәйданда.
Әле бусы сөйри үз ягына,
Әле тегесе. Яңа көчлерәк:
Тәки мине тартып алып китте
Яңа йортлар ягына өстерәп.
Стеналар — соргылт. Чупай ташы,
Пычкы эзе төшкән аларга;
Һәрбер ташта тигез, нечкә сырлар
Кырыс бизәк өсти калага.
Бу ташларда кемнең кул җылысы?
Кем тирләре аккан бу төштә?
Тәрәзләрдә кемнең елмаюы
Балкып китә, кинәт нур төшсә?
Ул төзүче үзе ничек икән,
Тапты микән бәхет бу эштән?
Булгандыр бәхетсез чаклары да:
Башкаларга бәхет төзешкән...
Гомер дәфтәремнең һәрбер битен
Мин актарып йөрим: хаталар
Укытучы кызыл кара белән
Төзәткәндәй ярылып яталар...
Әти, укы, диде — мин карыштым,
Иптәш малайларны тыңладым,
Олылар сүзен сүз итмисең яшь чак,
Шуңа күрә, ахры, уңмадым...
Уку — читен,
Эшне сайладык без,
Эш тә майлы ботка түгелне
Аңлап кына килгән чакта кинәт
Сугыш уты башка үренде.

Кайсыбыз кая иптәш малайларым:
Суслонгерга, туры фронтка,
Кайсыбыз барды рейхстагка кадәр,
Кайсыбыз калды мәңге шул утта.
Шулар рухы әллә тарта, Әлмәт,
Әллә тарта туган туфрагым,
Сиңа кайтам, бәхетем киреләнеп,
Сүрелгәндә тормыш учагым.
Сиңа, Әлмәт, ут алырга кайтам,
Гайбәтләрдән качып, я бүтән
Мине күрәлмәүче дус-дошманнан,
Бурычлардан синдә ял итәм.
Диңгезләрдә йөзгән пароходка
Моллюскалар ябыша, шулардан
Чистарттыру өчен һәр судноны
Кертәләр бит төче суларга.
Шулай мин дә ябышкакларымнан
Арынам бары синең суыңда...
Юк, рәсемгә төшәр өчен кайтмыйм,
Мут шагыйрьдәй, төзелеш фонында!

Гүзәл йортлар. Менә бакчалысы,
Ашъяулыктай бакча, ә шунда
Кыярларга кемдер су сибәме?..
Тукта, таныш чалым кашында.
Бу Гафаров иптәш түгелме соң?
Әйе, шул-шул, ничек бирешкән!
Теге чорда райком түрәсе иде,
Шул хәлгәме инде ул төшкән?
Эш өстендә килә иде. Бер мәл
Лобогрейка белән урабыз,
Тамак ач, тик горурлык бар бездә,
Сер бирмәскә иткән булабыз.
Көн-төн эштә... Ә ул килеп безне
Эттән алып этка ташлады.
Безнең алда колхоз сөте белән
Умырып-умырып күмәч ашады.
Авызыбызга сулар килде безнең,
Түзәлмичә атка кизәндем,
Без кузгалдык арыш урдырырга —
Ә ул калды ашап көзәндәй.
Шул чагында аны китаптагы
Бай шикелле итеп күрдем мин,
Берсен-берсе бетереп ташлый торган
Үчле уйлар уйлап йөрдем мин...
— Сез Гафаров агай түгелме соң? —
Ул, сипкечен куеп, борылды.
Төймә кебек күзләреннән миңа
Бер салкынлык килеп орынды.
Ул таныды мине, үзен көчләп,
Хәле мөшкел ахры, — шуңарга!
Постан төшкәч очрау кыен да соң
Сине белгән таныш, дусларга.
Урындыкка дәште...
Aклангандай
Үз хәленең асылын аңлата.

Мондый чакта кеше бүтәннәрне
Гаепләргә күбрәк ярата.
Гафаров та шулай. Китте тезеп,
Ул фәрештә диеп торасың.
Мин-минлеге каты яраланган,
Сүзләреннән ләкин тоясың:
Сагына һаман үзенең бояр булып
Йөрүләрен теге заманда!..
Түрәлекне сөя, әй, бу кеше!
Бармы икән әллә канында?!
Аннан әйтә: — Ә сез, яшьләр, әле
Күп нәрсәне аңлап җитмисез.
Беләсеңме Ньютон спирален?
— Беләм, беләм, шуннан ни дисез?
— Кабатлана-кабатлана гына
Алга бара тормыш... юк чара!..
— Теге чаклар кабат килер диеп,
Итәсеңме шуңа ишарә? —
Ул дәшмәде. Өмет, мәкер белән
Елмайды тик миннән көлгәндәй,
Мине әйдәп ачык сөйләшүгә,
Әйтә куйды күп сер белгәндәй:
— Ул съездлар ай-ай... шул вакытта
Инфаркт булды миңа — чак калдым...
Хе-хе-хе-хе, сине күзәтеп барам,
Үзең дә бит... шактый нык яндың?!
— Ләкин бер дә эчемә ачу җыеп
Мин посмадым. Ни бар — качуда?!
Ә «спираль» — синең бәлаң, ташла!
Агу сипмә инде ачудан.
Ник яшерергә? Властьлы сезнең брат
Нишләгәнен хәтта тоймаган:
Шахмат пешкасы итеп кешене
Күп язмышлар белән уйнаган.
Шул гаделме? Кан, яшь коеп инде
Эшләмиләр матур, хак эшне.
Әшәкелек — әшәкелек чәчә,
Ә гаделлек тудыра намусны!..
— Кызыл авыз, тормыш әле сиңа
Үз күзләрен бирер, үз башын,
Семьяң булсын менә... — Кулын селти,
Чытып шунда йөзен һәм кашын.
— Әй, абыкай, икейөзлелекне
Яшәү авырлыкка япсарма,
Сиңа булган картлык хөрмәтен дә
Шундый сүзләр белән таптама.
Яшь булсам да, тормыш миңа үзенең
Лаеш шулпаларын эчерде,
Мин әшәке хыянәт ачысын да,
Дуслык шатлыгын да кичердем.
Тик анда да кеше кайгылары
Булды миңа һаман зур кайгы,
Берәрсенә килгән зур бәладән
Җилкәләрем минем янтайды.
Күкерт кебек кабынып китте теге,
Чәнчү өчен бер сүз тапмый ул:
— Әтиең дә, мескен, каудар иде,

Алмагачтан алма... һаман шул!..
Һәм мин киттем яңа Әлмәткә менеп,
Кәефем килде — ачуын китердем,
Малай чакның күңелдәге үчен
Шулай итеп, ахры, бетердем.

... Тормыш бит ул очрашулар белән,
Аерылулар белән туп-тулы:
Урам чатын борылганда, баксам,
Лира килә миңа туп-туры.
Икебез дә кинәт каушап калдык,
Ут шикелле булып кызардык,
Яшь, гөнаһсыз чакта безнең дуслык
Түгел иде дәшми узарлык.
Бөгелмәдә бергә укып йөрдек,
Икебез дә горур шул чаклы:
Лира инде укытучы кызый,
Мин фронттан, үзем таяклы.
Сез бит һич тә тиң түгелләр, диеп,
Әнисе әйтеп торган аңа гел.
Җырдагыча: тиң түгеллеген дә
Күреп сөя иде яшь күңел.
Мин оялчан, кимсенүчән идем,
Шул киртәне җиңә белмәдем.
Башта мин сайларга хаксыз дидем,
Сөю дәгъвә итеп йөрмәдем...
— Син акыллы идең, Лира, миннән!
Исеңдәме, яздым бер хат та.
Хисләреңне бора белә идең
Исәп белән теләсә кай якка.
Ә мин белми идем. Әле һаман
Үзләштерә алмыйм шул «фәнне».
Ышанасыңмы, мин яшь түктем качып
Син кияүгә чыккан ул көнне!
— Әй, үткәнне искә алма инде!
Көнче булды Фатих һәм эчте:
Әгәр берәү миңа карап узса,
Ала иде, янап, чәнечке.
Көнләде синнән дә, Вахиттан да... —
Лира тынды... Барысы аңлашыла —
Шулай сиздем, хисләр урынын, ахры,
Били барган ачы тәҗрибә.
Ул үзгәргән, сер бирмәскә тырыша,
Горурлыгы бик нык һаман да:
Ирен мактап ала, үкенгәндәй
Эч серләрен әйтеп салганга.
Сөйләгәннән артык белгәнемне
Сизенә дә, тагы яшерми:
— Тик Вахитка чыкмавыма үкенәм,
Ә шулай да әйбәт яшим мин.
Хатын-кызда җайлашу бик көчле,
Йомшаклыктан ләкин түгел ул!
Болай торабыз да, мәхәббәт юк,
Аның урынын алган күнегү.
Миннияр, син мине гаепләмә,
Кичерергә тормыш өйрәтте.

Ә класста дөньям оныттам мин,
Шул дәвалый минем йөрәкне.
Син уйлама, мин бәхетсез түгел,
Бәхет кешенең һәрчак үзендә!..

Лира туктый. Сүзе дәвамыдай
Ясалма нур балкый күзендә.
Һәм ул китте. Кош канаты кебек
Нейлон пыльник калды елкылдап.
Ә йөрәгем...
Калды сулкылдап.
Тук-тук аяк тавышы йөрәгемне
Сандалларга салып суккандай
Итте!
Китте!
Әйдә инде юлы уң булсын!
Әйдә инде шулай онытылсын!

Йөрим.
Тирәк яфраклары шаулый,
Коелгандай чыңлап вак акча.
Болконында кемдер гармун сыза...
Әлмәт киче шулай таңгача.
Мин кафега кердем, шунда кинәт
Килә алмый торам һушыма:
Иске таныш — Сөмбел, чертежчы кыз,
Көлә-көлә килә каршыма.
Түгәрәк йөз! Ник кимсенә икән
Юк дип миндә тышкы чибәрлек?..
Саф акылы, җитдилеге белән
Бик күпләрне җәлеп итәрлек.
Ул тормышын сөйли, эчендәге
Шатлыкларын, сөйли кайгысын.
Ялганламый. Утырмыйсың уйлап
Кайсы калька, чын дип кайсысы.
Үз-үзеннән һич канәгать түгел,
Зарлангандай тоела тормыштан,
Бу бөек хис, — канәгать булмау хисе, —
Бирелгәндер, ахры, тумыштан.
Без аңарга килдек... өстәлендә
Эскизлары яңа Әлмәтнең,
Киләчәге калькаларда әле,
Очрашуны шул да ямьләтте.
Шәһәр төзү серен сөйли, сөйли,
Ә аннары күчә шәхсигә:
— Бар нәрсәм бар: эшем, тоткан урыным,
Квартирым. Ә соң бу нигә? —
Дим кайчакта, ялгышымны тоям,
Эзләнгәндә күңел нәрсәдер,
Шундый ахмак уйлар килә икән!
— Эзләнмәсә күңел — бәсәрер.
Акыл сату тоеп минем сүздә,
Тирән итеп Сөмбел көрсенде:
— Сөйләү эштән җиңел булгангамы,
Әй сибәбез генә без сүзне!..

Без фәлсәфә сатып утырганда,
Харис килде — аның абыйсы,
Дустым минем фронт елларыннан,
Ә таушалган малай ярыйсы.
Ай-ваема карамыйча, мине
Алып китте үзенә кунакка.
«Нахальный»да тора икән Харис,
Шәһәр читендәрәк, бер якта.

Бу «Нахальный» поселогы менә.
Андыйлар бар һәрбер шәһәрдә.
Ә кешеләр бигрәк әйбәт икән,
Үзең әйбәт булсаң әгәр дә.
Дустым Харис шунда яшәп ята,
Ярата шул бераз кәгәргә,
Кәгүен ул законный дип саный:
— Эш шундый бит, брат, гамәлдә.
Эчем яна. Шуңа яна, дустым:
Без урманда трасса ярабыз
Бульдозерлар белән! Агачларны
Кубарып алып читкә салабыз.
Күпме байлык һәлак итәбез бит,
Күздән яшем атыла кайчагын:
Шәмдәй матур каеннарны изә
Бульдозерның авыр пычагы.
Кайда хаклык? Чыбык кискән өчен
Кеше шундук судка бирелә.
Бу вәхшилек булмый нәрсә инде?
Я моны соң ничек диергә?.. —
Кояш ашап яргаланып беткән,
Кирпеч кебек йөзе Харисның,
Күз кабагы аның салынып төшкән,
Ул бик эшчән насел варисы.
Тәмәкесен конфет кебек суыра.
— Чыдап булмый шундый эшләргә.
Нәчәлниккә бардым... Яңалык, ди,
Шулай тоела йомшак кешеләргә!
Нәчәл бик күп, казна исәбенә
Юмартлыкта барсын уздыра,
Халык байлыкларын «акыллы баш»
Халык исеме белән туздыра.
Саклап тоту — ул саранлык түгел,
«Кызыл!» диеп кашың сындырма,
Барлыгым шул, ләкин мин бүтәнчә
Була алмыйм, ниләр кылдырма!
Ничек кенә хатын иләмәде,
Тормыш та нык кына сугарды,
Җаным һаман «кызыл!» Миңа һаман
Бар нәрсәдән хаклык югары!
Хет яманла мине, начар диген,
Күңелем акка көнем ак минем,
Туган җирнең һәр нәрсәсен җәллим,
Бар ла шундый начар як минем!.. —
Кул бирә ул тагын, бармаклары
Чәерләнгән, янган чырае.
Бу тормышны
Җилкәсендә илтә

Тик шундыйлар гына мөгаен!..
... Харис — ялга, ә мин тәнгә чыктым:
Факел хоры яна тауларда:
Факел тотып гүя туземецлар
Чыккансыман филләр ауларга...

... Икенче көн Харис эштән кайтты.
Әй сусаган серге бу күңел.
Ә фикерләр безнең бик килешә,
Бер сөйләшү — үзе бер гомер.

Харис сөйли: — Бездә музейларга
Куярлык бер кызык адәм бар.
Түрәләрне шундый ярата ул,
Бар түрәләр — аңа аллалар!
Һәм ул әйтә: «Түрәләрдән башка
Яши алмас идем, чын әгәр!
Кемнәр мине эшкә кушар иде,
Эш бармаса, мине кем тиргәр?!
Тиргәве дә аның файда гына,
Шул файданы тоеп тик торам,
Түрә әгәр миңа бер елмайса,
Салган кебек булам йөз грамм!
Кушмыйча мин берни эшли алмыйм.
Өйдә эшлим хатын кушканга,
Кайберәүләр җиңел яши дия,
Санап мине әрсез куштанга!
Мин баш түгел, башкаручы гына,
Мин кечкенә кеше, миңа ни,
Берсе килә, берсе китә — түрә, —
Минем кыйбла һич тә үзгәрми.
Башкаручы, мин гел буйсынучы,
Ай-яй авыр, нишлим, язмыш шул!..»
«Ташла, адәм, черек фәлсәфәңне,
Тире саклау — яшәү түгел ул!
Әнә кошлар, сөйрәлүчеләр бар,
Син әйтәсең, мин кеше, дисең,
Кеше булгач, кеше кебек яшә,
Сөйрәлүче булып яшисең!» —
Дим мин аңа, ә ул ачуланмый,
Ачуы килми аның берникә.
Хет хатынын алып кит син шунда,
Икенче көн сиңа кул бирә...

... Харислардан киттем буровойга,
Тантанага шунда очрадым,
Илсур дустым каршы алды мине
Бик сагынып, җәеп кочагын.
Буровойга фотограф килгән
Төшерергә рабкор помбурны,
Бар буровой халкы шау-гөр килеп,
Әзерлиләр шуңа Илсурны.
Кайсы кигезә яхшы бүреген аңа,
Кайсы бирә салып пальтосын,
Кайсы шарф бәйли,
Галстук тага,
Кайсы рәтли иңен, якасын.

Фотограф илтеп бастыра аны
Бер начәлнең «ЗИМ»е кырына
Һәм төшерә...
— Елмай, елмай! — ди ул,
Илсур елмаялмый.
Фотографның кәефе кырыла.
Тирләп бетә Илсур елмаялмый,
Каушап калган кебек сәхнәдә.
Һич елмаймый торган егет шул ул,
Теге ышанмас инде әйтсә дә!
Елмая ул шунда — аварияне
Вакытында җиңеп чыгалса,
Ял көннәре кайчак урамнарда
Берәр сылу кызга очраса...

Елмаерлык түгел бүген эше,
Энә өстендә гүя утыра,
Скважина бер аждаһа кебек,
Бар цементны йотып тик тора!
Пирамидадагы мылтыклардай
Тезелгәннәр «шәмнәр» бер мәлгә,
Растворлар түгелеп күл-күл ята,
Сөт түгелгән кебек идәнгә...
Илсурлар бит тәки тегәлләде...
Короттажлар килде. Бер агай
Сыңар куллы — эшне оештыра;
Шау-гөр килә тагы буровой.
Агай — үткен,
Скважинаның ул
Тиз төшенә кәефен — шалт та шолт.
Холкын белеп гел өйрәтеп тора,
Фокусниктай күзе — ялт та йолт.
Ток ялгады,
Җир «дерт» итте кинәт,
Зыңлап куйды вышка кыл кебек,
Скважинаның юан тамагы да
Укшый башлый кинәт буылып.
Тамагыннан менә су ургыла,
Ташу суыдай кызгылт. Җыела
Бар егетләр, карап тора алар:
Су карала бара, куера.
Һәм әйләнә соргылт агынтыга, —
Нечкә генә, тузбаш еландай.
Җир тартыша, дер-дер килә, гүя
Зур мамонтны сөңге яргандай.
Кан киткәндәй шуннан нефть ага,
Мамонт каны кебек төсе дә.
Бу гадәти бер эш кенә бары,
Шаккатмыйлар моңа берсе дә.
Ә егетләр кайсы кая ава
Кече әбәт ашап алырга,
Сыңар куллы абый якмыш ашый,
Термоста бар чәе «салырга».
Ашап туйгач ләкин амин тота,
Битен сыпыра сыңар уч белән...
Юк, ышанып түгел, тик икмәкне
Зурлап кына, аны мин беләм!

## ЗАВХОЗ ЗИННУР

Малайларны Зиннур бик ярата,
Ә үзенең улын тагын да.
Малаена алма тоттыра да,
Сөйләп ташлый миңа барын да:
— Өйләндем дә малай көтеп йөрдем,
Тапмый хатын, тапмый, уңмаган,
Шундый чакта менә, уйлап кара,
Хатыныннан кем суынмаган?
Суына башладым шул,
Кантордагы
Кызларга да күзем төшкәли,
Елмаялар, эретерлек итеп,
Күрә алар җанны үтәли.
«Зиннур абый!» диган булып кайсы
Өзелеп китә... каушап каласың,
Прожекторга эләккән самолеттай,
Уңны, сулны белми барасың.
Ә шулай да күңел тартмады бит,
Вөҗдан килеп, кисә башлады.
Шул чак хатын менә малай табып,
Переворот ясап ташлады.
Бу малайдан, белмим, нәрсә чыгар,
Бик кечкенә әле, шулай да,
Әнисеннән бизеп барган чакта
Тойгыларны борды уңайга.
Хатынның да хакы артты, телим
Яхшы ягын гына күрергә.
Малай мине аңа бәйләп куйды,
Ычкынмаслык итеп гомергә.
Ул коткарып калды җимерелүдән
Ике җанны, безнең семьяны,
Кайтарды ул матур вакытларны,
Җылытты ул салкын ояны.

## ӘЛМӘТ ПЕЙЗАЖЫ

Анда, монда биек краннар
Зур кулларын күккә сузганнар.
Тимер кран корыч беләген
Күтәргән дә бирә кирәген
«Дошманының». «Дошман» һаман бар —
Шалтырап торган такта бараклар.
Бер зур кран барак сыртына
Әй селтәнеп бирә һәм тына.
Ә бараклар ябышкан җиргә,
Ташбакадай әкрен чигенә.
Ул бараклар калган әз генә,
Төкәнми бит нәфсе тиз генә,
Кеше омтыла һаман әйбәткә,
Әкияттәгедәй матур Әлмәткә.
Шуңа күрә корыч краннар,
Баракларга сугыш ачканнар.

Һөҗүмгә алар әнә баралар,
«Бараклар шәһәрен» алалар,
Җимерәләр аны, теталәр,
Яңа йортлар салып китәләр.

Бер кырыйда ята торбалар,
Юан-юан бүрәнәләрдәй,
Торба өстеннән чаба малайлар,
Өйдән чыккан яшь бәрәннәрдәй.
Әй тотынды яңгыр, малайлар
Төрле якка, әй, сугылдылар,
Чыбыклагач яңгыр сыртларын
Торбаларга кереп тулдылар.
Торбаларны яңгыр зыңлата,
Малайлар шат бу ят авазга,
Башын сузып кайсы торбадан
Тамчыларны җыя авызга.

## ТАНЫШ АБЫЙ

Дәшеп алды мине таныш абый,
Килеп төшкәч, бүген өлкәдән,
Себерләрдә йөреп, безнең якта
Булалмаган иде күптәннән.
Искә төште кинәт бер вакыйга,
Үзе кызык, үзе аяныч,
Ачуланма, абый, ачуланма,
Мин бәләкәй чакта булган эш:
Алтынчыда мин укый идем,
Әле озак мин белми йөрдем:
Тормыш нәрсә? Нәрсә мәшәкать?
Кеше үзе була ничә кат?
Кешеләр нигә берсе-берсенә
Дошманлашып кайчак үчегә?
Укытучы безгә ни әйтсә,
Шул төп закон иде, гадәтчә.
Ул көрдә дә бер көн тын торды,
Китапларны аннан ачтырды.
— Күрәсезме, — диде, — шул биттә
Бер рәсем бар, матур, әлбәттә,
Хәзер инде халык дошманы,
Бу китаптан сызыгыз аны.
Әй очындык без бик моңарга:
Безгә булсын фәкать сызарга,
Шытыр-шытыр итеп сызабыз,
Бетергечләр белән бозабыз,
Каләм белән күзенә төртәбез,
Аркылы-торкылы сызып тетәбез.
Ләкин укытучыга ни булган,
Күзләренә гүя су тулган!
Ул яшерә бездән карашын,
Ә йөзендә кайгы карасы.
Шул чагында синең рәсемне
Сызганмын мин, абый, гафу ит!
Абый көлә һәм селти кулын:
— Әйдә, аны искә төшермик!

Сөенә-сөенә икәү йөрибез
Әлмәт урамнарын тутырып;
Аның җаны һәр яңалыкны
Сусагандай эчә йотылып.

## ЯНГАН ЙӨРӘК

— Сез кайларда хәзер бораулыйсыз?
— Бораулыйбыз, дускай, кайда да.
Бүген генә менә малай туды,
Барсы да бит безнең файдага!
Тик факеллар гына бушка яна,
Йөрәк әрни, әрни көн дәген,
Берәр җирдә әллә пожармы дип,
Уянып китәм менә төннәрен.
Горгазларга бардык,
Имза җыеп,
Гәзитләргә язып карадык,
Сүзләр, вәгъдә... тик шуңардан бүтән
Бернәрсәгә ирешә алмадык.
Һаман вәгъдә... Вәгъдә белән генә
Күпме инде менә яшибез?
Без үлгәчтен булыр әле диеп,
Тешне кысып кайчак дәшмибез!
Вәгъдә бит ул изге нәрсә, ләкин
Үтәлмәсә була бик читен,
Хисләрне дә шул ышанмау баса,
Өзелә башлый хәтта өметең.
Яшәп булмый вәгъдә белән генә!
Миражларга һаман алданып.
Хәзер кирәк эшнең нәтиҗәсе,
Юкса нигә юкка казгану?
... Тик шул миңа бер дә тынгы бирми,
Йөрәк яна гүя факелда.
Син яз әле, аңламаслар микән,
Минем янган йөрәк хакында?!

## ТЫҢЛАНГАН СЕР

Менә икмәк кибете,
Тәмле исләр
Китерәләр авыз суларын.
Икмәк сатып тора икән тагы
Кызларның да иң сылулары.
Сатучы кыз сөйли дус кызына:
— Әй, Мәгъшия, күрсәң, җаным, син,
Кичә кергәч бер бик матур егет,
Ток суккандай каушап калдым мин.
Минем эштән нидер гаеп тапты,
Жалу язды миңа шушында,
Ә мин аңа шундый гашыйк булдым,
Яза яздым хәтта һушымнан.
Озаграк язсын диеп торам,
Бүтән берни килми башыма,
Кулларымнан вак акчалар коела.

Чылтыр-чылтыр идән ташына...
— И, тиле! — ди иптәш кызы. — Эштән
Чыгарсалар... карап җалуга?
— Бүтән җирдән эш тапмаммы әллә,
Төкермим дә эшсез калуга!
Их ул егет тагын килсен иде,
Язсын иде җалу сүзләрен,
Җалуы аның миңа бүләк кенә...
Күрсә идең аның күзләрен!
Төннәр буе күз алдымда тора,
Ияреп йөри көндез шәүләсе,
Барган чакта артка борылып карыйм,
Күрермен күк аның гәүдәсен...
Бөтен күңелем җырлап тора хәзер,
Агылалар уйлар, әй, ташып...
Сара тына,
Дусты иңенә куя
Малайларча чәчле чук башын.

## КИЧКЕ АВТОБУС

Мин Әлмәткә килгәч бик яратам
Кичләр буе тоташ йөрергә.
Кайсы эштән кайта... Кызы белән
Очрашырга кайсы йөгерә.
Соңгы автобус... Уйчан бурильщиклар,
Егетләр һәм кызлар шау-шуы...
Бер кыз ялгыз, аның күзләреннән
Укып була эчке ярсуын.
Ул уйлары белән монда түгел,
Ул сөйгәне белән бәхәстә.
Аңлашылмау таудай була икән,
Ирешкәндә уртак бәхеткә!..
...Ә бер егет якасына чумган,
Формулалар уйлап кайтамы?
Бер ачышка әллә илһам килгән,
Баш ватуның белә ул тәмен!
Эзләнүнең рәхәт газапларын —
«Тавыш барьерларын» үтүе,
Үз-үзенең сопроматын җиңеп,
Әз булса да алга китүе!..
...Менә күксел ковбойкалы егет,
Нәрсә кайный икән аңында?
Берәр эштә горур мин-минлеген
Кискәннәрдер, бәлки, аның да?
Мин-минлек ул — бер чи яра кебек,
Бик авырта чак-чак тисәң дә.
Ләкин кеше — шуның өчен кеше!
Мин-минлек тик булмый исәрдә!
Кешеләр кайта соңгы автобуста,
Җиңеп кайта, кайсы җиңелеп:
Тик җиңелгәч кенә була бит ул
Үзеңдәге көчне нык белеп!..
...Машинадан төшсәм — шагыйрь дустым,
Һаман шулай көләч, таза ул.
Тик тормышны артык нык белгәнгә
Шигырьләрне бик аз яза ул!

## ЭПИЛОГ

Инде вакыт! Сау булыгыз, дуслар,
Сезнең белән рәхәт яшәве!
Сезнең белән җиңел иңне баскан
Дөнья йөкләренең иң дәве!
Рәхмәт сезгә, мине санга санап,
Сөйләдегез йөрәк серләрен.
Сезнең сүзләр миңа көч бирерләр
Менгән чакта тормыш үрләрен.
Чертежчы кыз, Сөмбел, сиңа рәхмәт!
Дусларымны минем күбәйттең.
Бу дусларны белгәч,
Әйтмим хәзер:
«Бушка үттең, гомер, тик үттең!»
... Хыянәт белән яралады берәү,
Шуңа, ахры, бераз бирештем,
Миңа төшкән җаваплылыклардан
Кул селтәргә хәтта җитештем.
Әзерләнгән идем, нәтиҗәсез
Бу көрәшем нигә? — диярга.
Ә син, Сөмбел, шуны тоеп алдың
Һәм бирмәдең башны иярга.
Рәхмәт сиңа!
Инде менә китәм.
Әй, авыр да инде аерылу,
Өзә-өзә күңел җепләрен гел,
Җан әрнетеп читкә каерылу!
Рәхмәт инде,
Мине озата чыктың,
Япон күлмәк киеп болдырга,
Ә җил синең салам чәчләреңне,
Итәк чабуларың туздыра,
Күлмәк чабуларың
Аякларыңа кыстың,
Күкрәкләрең тиз-тиз ябасың,
Ашыга-ашыга үзең барасың,
Сулышларың бик еш аласың:
Каласың!..
Сау бул, Әлмәт,
Һәрбер почмагыңны
Улың кебек сөеп киләндем,
Дусларымны, төзелешләрне күреп
Шатланырга инде өйрәндем!

*1964.*

*Әмирхан Еники*

# КОРЬӘНХАФИЗ*

## Хикәя

Унҗиденче елның көзендә, укулар инде башлангач, безнең мәдрәсәгә яңа хәлфә килде. Гаҗәп кызыклы, шуның белән бергә әллә нинди буталчык бер вакыт иде бу... Узган кыш патша төшерелгәч, шәкертләр хөррият диделәр дә бөтенләй авызлыкларын салдылар. Мәдрәсәдә электән килгән тәртип-низам бозылды, укуларның рәте-чираты китте. Җитмәсә, былтыр гына килеп укыта башлаган арык гәүдәле һәм юаш табигатьле Гариф хәлфә дә бик йомшак кеше булып чыкты. Аны җәдит хәлфә диләр иде, ул шәкертләргә кул күтәреп суга белми иде, хәер, шәкерт кыйнарлык аның көче дә юк иде. Иптидаи (кече) сыйныфларда ыбыр-чыбыр балаларны ничек җитте алай тыңлата алса да, рөштиләрдә (өлкән сыйныфларда) ул бөтенләй көчсез-гаҗиз иде; андагы ат-тай таза шәкертләр бәләкәй, арык хәлфәнең тәмам башы өстеннән йөриләр иде. Акыралар, бакыралар, бер сүзен колакларына элмиләр, үзе күрмәгәндә, артыннан мыскыллап көләләр, кыскасы, мескенкәйгә көн күрсәтмиләр иде. Кайда инде ул монда дәрес! Хәтта бичара хәлфәнең сыйныфта утырып елаган чаклары да булган дип әйтә торганнар иде. Мондый хәлне ничектер аңлавы да читен иде. Гүя моңарчы башлары тукмалудан чыкмаган шәкертләргә кешечә әйтелгән яхшы сүз керми дә, күнекмәгән дә алар аңа, гүя сыртларына аларның һаман йодрык кирәк тә таяк кирәк. Шулай булмаганда, алар өчен хәлфә хәлфә дә түгел, хөрмәткә лаек кеше дә түгел... Юк, түзмәде безнең йомшак күңелле мескен хәлфәбез мондый бәйдән ычкынган кыргыйлыкка, тотты да мәдрәсәбезне, мәдрәсәбезне генә түгел, кариябезне ташлап каядыр китте. Бер генә кыш укып калдык без аңардан.

Инде менә аның урынына яңа хәлфә килде. Билгеле, без аны бик кызыксынып каршы алдык. Бу инде Гариф хәлфә кебек шәкертләр арасында югалып калырлык кечкенә, өтек кеше түгел иде. Озын кара казаки кигән, нечкә билле, киң күкрәкле, уртадан калкурак нык, какча гәүдәле, бәрхеттәй кара сакал әйләндереп алган ап-ак чырайлы, юешләнебрәк торган кызыл иренле, ефәктәй йомшак кара мыеклы һәм аз гына сары йөгергән елтыр кара күзле бик чибәр бер кеше иде ул. Беренче керүендә үк ул безгә, күзләрен кысыбрак, матур иреннәренең чите белән генә елмайгандай итеп, гүя менә аны-моны сизмәгән куяннарга агач ботагыннан койрыгын уйнаткалап, карап яткан сүлән шикелле, эченнән генә нидер уйлап, нидер чамалап, яшерен-астыртын гына карап торган иде. Һәм без аның чын уен, чын теләген белмәсәк тә, бу елмаюлы астыртын карашыннан ихтыярсыз шомланып, эчебездән генә калтыранып та куйган идек. Онытмас борын тагын шуны да әйтим: баштарак без аның исемен дә ачык кына белә алмыйча тордык. Безгә аны «Хафиз хәлфә» дип таныштырдылар, шул ук вакытта бу кеше — «Корьәнхафиз» дип тә әйттеләр. Тик бераздан гына төшенеп алдык: чын исеме дә Хафиз

* Корьәнхафиз — корьәнне яттан укучы.

һәм шуның белән бергә корьәнхафиз да икән ул. Ләкин тиз арада ул шушы соңгы «корьәнхафиз» дигән ләкабы белән халык теленә кереп китте. Без, шәкертләр, аны «Карый хәлфә» дип йөртә башладык.

Бер уңайдан тагын шуны да әйтеп үтәргә кирәк: безнең мәдрәсәне Искәндәр ахун мәдрәсәсе дип йөртәләр. Таш мәчеткә урам аша, иркен генә ихата эчендә аның ике бинасы бар. Берсен, гади авыл өесыман бүрәнәдән салынган кечерәген, яңа мәдрәсә дип, ә икенчесен, такта белән тышланган зуррагын, иске мәдрәсә яки сары мәдрәсә дип атыйлар (сарыга буялган иде ул). Яңа мәдрәсәдә күбрәк Дәүләкән балалары укып йөриләр. Аларны иптидаи сыйныфлар дип атыйлар. Хәер, болай сыйныфлар дип зур итеп әйтү дөрес тә булмас, чөнки бер өй эчендә, бер хәлфә алдына утырып, беренче тапкыр әлифба һәм иман шарты күтәреп килгән җиде-сигез яшьлек балалар белән бергә, инде ничәдер кыш рәттән корьән һәм хәдис ятлап йөргән ундүрт-унбиш яшьлек малайлар да укыйлар иде. Беренче, икенче, өченче сыйныфлар дигән сүз юк, барысы да тик иптидаи дип кенә йөртелә.

Ә сары мәдрәсәдә рөшти (өлкән) сыйныфлар, ягъни анда төрле авыллардан килгән зур шәкертләр ятып укыйлар. Болар инде типсә тимер өзәрлек таза егетләр. Өсләрендә бәрән эчле билле бишмәт, башларында кама читле бүрек, муеннарында ак шарф, кулларында ак перчатка, ә аякларында читек яки тула оек өстеннән кигән тирән киез калалар. Бик көяз булырга яраталар, эскәк белән кашларын нечкәртәләр, бармакларына берәр кыз исеме язылган кашсыз йөзек кияләр һәм безнең ише вак малайларга «каениш» дип кенә дәшәләр иде. Аларның күбесе Дим буендагы башкорт муллаларының һәм байларының муллламәзинлеккә укый торган малайлары иде. Аларга йөге белән азык килә, һәм кыш буе җылкы ите ашап, сары май ашап, бавырсак ашап ятканлыктан, алар бик тазалар һәм бик мутлар иде. Кайберәүләре качып-посып кыпа яр буендагы Ишморат бичәсенә бал эчәргә дә йөриләр иде.

Менә безнең яңа хәлфәбез Корьәнхафиз да сары мәдрәсәнең бер кечкенә бүлмәсенә урнашып, өйләгә чаклы безне, өйләдән соң рөштиләрне укыта башлады. Рөштиләргә шулай ук карт хәзрәт Искәндәр ахун үзе дә көн саен диярлек дәрескә керә иде.

Әйе, беренче очрашу бик нык хәтердә калган. Әйткәнемчә, кара казаки кигән, ак чырайлы, кара сакаллы чибәр кеше тузан эчендә шау итеп торган мәдрәсәгә ничектер мыштым гына килеп керде һәм тукталып, бер сүз әйтмәстән, безнең утырышып беткәнне көтеп торды. Без әле ул елларда да борынгыча астыбызга киез салып, тәбәнәк өстәлләр артына тезләнеп утыра торган идек. Бик уңайсыз, бик авыр иде болай утыруы, аяклар оеп, катып бетә, аларны кая сузарга, нишләтергә белмичә йөдәп, җәфаланып бетәсең. Әмма бу тәбәнәк өстәлләрдән күрәсе җәфалар алда булган икән әле.

Шулай без утырышып беткәч, Карый хәлфә дә өстәлләр алдында торган биек, артсыз урындыкка килеп утырды һәм әлеге шул сүлән шикелле елтыр күзләрен кысып, аз гына көлемсерәп, берни сиздермичә безгә карап тора башлады. Без барыбыз да тынып калдык. Шактый дәшми торганнан соң, хәлфә акрын гына сорап куйды:

— Бүген кизү кем?

— Мин, — диде арткы рәттән бер олырак шәкерт.

— Торып җавап бир, — диде хәлфә аңа, тавышын үзгәртмичә генә. Шәкерт торып басты.

— Мин кизү.

— Исемең ничек?

— Хәкимҗан.

Ямаулы чалбар, җиңнәре беләзегенә дә җитмәгән иске пинжәк кигән озын, чандыр шәкерткә хәлфә аның ныклыгын, тазалыгын, холкын чамалагандай сынап күпмедер карап торды. Аннары сорады:

— Бүген сыйныфта ничә шәкерт?
— Егерме биш.
— Килми калганнары бармы?
— Бар. Өчәү.
— Утыр, — диде хәлфә һәм кулындагы катыргы тышлы озын дәфтәрне тезләре өстенә куеп ачты да малайларны исемнәре белән дәшә башлады. Җавап бирүченең һәркайсына каш астыннан сөзеп кенә карап алды, кайберәүләрдән: «Мондагымы, читтәнме?» яки «атаң кем?» дип сорап та куйгалады. Бу эшне бетергәч, торып, шыгыр-шыгыр иткән өр-яңа читекләре белән йомшак кына басып, тәбәнәк өстәлләр яныннан китап-дәфтәрләребезне карап узды. Шул чагында бер малайның түбәтәе астыннан чыгып торган җилкә чәчен каты гына тартып куйды. Көлемсерәп: «Поп малаемы әллә син?» — диде. Малай дәшмәде, тик күзенә мөлдереп яше генә килде. Тагын, күршесенә нидер пышылдаган икенче бәләкәй генә малайның маңгаена, бер сүз әйтмәстән, куш бармаклап чиртеп алды. Җиңел генә чиртте кебек, ә шулай да малайның маңгае кызарып, бүртеп чыкты. Без барыбыз да ни өчен бу дип, бик аптырап, сагаеп калдык. Малай көлемсерәп басып торган чибәр хәлфәгә сискәнеп һәм сыкранып бер генә карап алды да, маңгаен тотып, тизрәк башын иде. Ләкин тавышын чыгармады. Бу хәлдән безнең эчебезгә, салкын бизгәк шикелле, өшеткеч бер курку йөгерде.

Хәлфә яңадан үзенең биек урындыгына барып утырды. Ак кулы белән кечкенә кара сакалын сыпыргалагандай итеп торды, шуннан соң бер-ике зуррак шәкерттән берничә генә тыныш корьән укытып карады. Ләкин бер сүз әйтмәде, төзәтү-фәлән дә ясап тормады, аз гына уйланып утыргач, тыныч кына:

— Бүгенгә җитте, — диде, — иртәгә чынлап тотынырбыз, ә хәзер, бар, кайтыгыз!

Гариф хәлфә вакытында без, дәрес бетәр-бетмәс, ду килеп, урыныбыздан куба идек, ишек төбенә ташланып, өерелешеп-көрмәкләшеп, букчалар белән сугышып, мәдрәсәне тузанга батыргач кына чыгып китә торган идек. Бу юлы инде без, иске гадәт буенча, алай дәррәү кубып, ишеккә ташланмадык, ничектер ихтыярсыздан тыелып, кабаланмыйча-шауламыйча гына киез итекләребезне, каталарыбызны киеп, бер-бер артлы мыштым гына чыгып киттек. Хәлфә урыныннан кузгалмыйча, башын ия төшеп, сүзсез генә безгә карап калды.

Һәм менә шушы беренче очрашудан соң атна-ун көн дә үтмәгәндер, мәдрәсәдә гомумән һәртөрле шау-шу басылды, тузан да басылды, әчен генә түгел, бөтен ихатасын үле бер тынлык басып алды. Безнең өчен уйнау да бетте, көлү дә бетте, ә шаяруны исә бөтенләй оныттык дияргә ярый.

Икенче көнне үк инде без хәлфә кулында өч талдан үреп ишкән озын чыбык күрдек. Хәер, шәкерт өчен чыбык бик таныш нәрсә ул, әмма чыбыркысыман итеп үргәнен безнең әле татыганыбыз юк иде. Бик зәһәр нәрсә икән. Ничектер сиздермичә генә килеп чага торган елан төсле булып күренә башлады ул безгә... Әйтик, сыйныфта шәкертләр китаплары өстенә иелеп, тонык кына гүләп, һични уйламыйча сабакларын ятлап утыралар. Шул чакта әлеге өчтән ишкән чыбык кинәт, баш очыбыздан выжлап, берәрсенең сыртына барып төшә. Шәкерт чынлап та елан чаккандай үз-үзен белештермичә сикереп-чинап җибәрә. Бөтен сыйныф сискәнеп, агарынып китә: ни булды, ни өчен бу? Берәү дә шауламады, тынлыкны бозмады бит югыйсә! Тик соңыннан гына беләбез: бичара малай, күршесенә борылып, нидер әйтмәкче булган, имеш, бары шуның өчен генә!

Ләкин бу коточкыч усаллыкның безне тетрәткән, безне таңга калдырган хикмәте, билгеле инде, чыбыкта түгел, ә чыбыкны тоткан хәл-

фәнең үзендә иде. Беләсезме, ул бит бер сүз әйтмичә, бернинди кисәтүфәләп ясап тормыйча, җитмәсә әле, майлы елтыр күзләре һәм кызыл иреннәре белән көлемсерәп кенә, сине сыйпап алгандай, китереп суга. Һәм әйтергә кирәк, бик яман суга. Ә берни көтмәгән малай исә, чыбык әчесеннән өзгәләнеп китсә дә, хәлфәнең әнә шул елмайган чибәр йөзенә күтәрелеп карау белән ничектер ярым үлектәй өнсез катып кала, ачу-нәфрәте дә аның кабынып китми, күзеннән яше дә бәреп чыкмый, бары тик ак кәфендәй йөзенә искиткеч бер аптырау-курку гына җәелә. Кычкырып елый да алмый ул, елап җибәрсә, хәлфә моның өчен ишкән чыбыгын бер-бер артлы тагы да катырак төшереп ала. Башынамы, битенәме, аркасынамы — карап та тормый. Кечерәк шәкертләр моңа түзә алмыйлар иде, күбесенең кайткан чакта балак буйлары юеш була торган иде.

Шулай итеп, башта безне үзенең чибәрлеге һәм көязлеге белән сокландырган Корьәнхафиз бик тиз арада бөтен мәдрәсәнең котын алган ерткыч зөбаныйга әверелде. Ерткычлыгының һич чамасы юк иде. Өчтән үргән чыбык нәрсә ул! Чыбык кына әлексә, шөкер итә идек әле... Бер кызып китсә, аның елмаюы ырҗаюга әйләнеп, күзләрен тәмам кан баса торган иде. Мондый чагында ул шәкертне колагыннан сөйрәп торгыза иде дә, бар көченә кизәнеп, яңагына салып җибәрә иде. Шәкерт егылып китсә, яңадан торгызып, тагын сугып ега иде. Аннары баз ишеген ачтырып, шунда типкәләп төшереп җибәрә иде. Бер көнне ул Миңнәхмәт дигән шәкертне чәйханәдән вакытында чәй китереп җиткермәгән өчен генә шулкадәр рәхимсез кыйнады ки, теге бичара һушыннан язды, авызыннан канлы күбекләр килде. Үлә дип торабыз. Бары йөзенә салкын су сипкәч кенә, күзен ачты, анда да бик озак тора алмыйча, идән уртасында бөгәрләнеп ятты. Шуннан соң Миңнәхмәт мәдрәсәгә аяк басмас булды. Моның ише кансыз кыйнаулар еш кына булып тора иде. Мәсәлән, Сафиулла абзый малае Габделбариның да, шундый кыйналудан соң, колагы агып йөри башлады. Ләкин мондый имгәнүләргә Корьәнхафизның һич исе китмәде, аз гына да тыела белмәде, һаман әүвәлгечә елмайгандай ырҗаеп, тиргәми-сүкми генә шәкертләрне вата бирде.

Гаҗәп, залим булган җирдә хаин да табыла икән ул. Безнең залимның да шундый хаине табылды. Бу — җиләк-җимеш подвалы тотучы Гыйбаш сәүдәгәр малае Шәрифҗан бөкре иде. Ул яше белән шактый олы булса да, рөштигә күчә алмыйча һаман безнең арада, иптидаи сыйныфта утыра иде. Берәү белән дә аралашмыйча, берәү белән дә дуслашмыйча, һәркемгә шом салып, өнсез-сүзсез генә йөрүче бер карачкыл булып күренә иде ул безгә. Аның колаклары иләмсез зур иде, һәм малайлар аңардан «бер колагын астына җәеп, икенче колагын өстенә ябынып ята икән» дип көлә торганнар иде.

Безнең Дәүләкәндә, «Марҗа базары» дип йөртелгән мәйданда кино дигән нәрсә бар иде. Ул заманда без аны кино дип түгел, ә «томанный» дип йөртә идек. Билгеле, шәкертләргә «томанный» карау катгый рәвештә тыелган иде, шунлыктан бу сихри җир безне үзенә гел тартып тора иде. Шунда эләгүнең хәйләсен-җаен без эзләп кенә йөри идек. Һәм кайчагында, бигрәк тә кышкы ярминкә вакытында, без кырык хәйлә корып, бик нык яшеренеп, «томанный»га барып чыккалый идек. Ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, безнең «томанный» тирәсендә йөрүебез икенче көнне үк хәлфәгә билгеле була торган иде. Моның җәзасын сөйләп торасы да юк, тик бер нәрсәгә без хәйран кала идек: кайдан белгән бу зөбаный?.. Бары берничә тапкыр шушы каһәргә юлыкканнан соң гына төшенеп алдык: Гыйбашлар «томанный» каршысында гына торалар ич, менә шуның ләгыйнь малае, әлеге бөкре Шәрифҗан, капка төпләреннән «томанный»га кемнәр килгәнен күзәтеп тора икән дә икенче көнне хәлфәнең колагына җиткерә икән. Шул хаин аркасында без өчтән үргән чыбыкны күпме ашамадык. Безнең иң явыз дошманыбыз булып китте

ул, тик бөкре булганы өчен генә без аны эт итеп тукмаудан тыелып калдык.

Кыскасы, Карый хәлфәдән күргәннәрне сөйләп бетерәсе дә түгел һәм, дөресен генә әйткәндә, максат та ул түгел. Мәдрәсәдән читкә, зуррак дөньяга чыгыйк әле, кызыгы аның шунда. Әйе, безне утлы табада биеткән шул ерткыч залим, беләсегез килсә, мәдрәсә тышында бөтенләй икенче кеше булып йөри иде. Корьәнхафиз!.. Аның шушы бер исеме үзе генә ни тора! Һәркемнең телендә ул, һәркемнең күзе аңарда. Мәчеткә ул кара казаки өстеннән көмештәй елык-елык уйнаклаган атлас чапан, башына кара чуклы зәңгәр фәскә жыйнак кына итеп чорнаган ак чалма киеп бара. Намаз вакытында гомуми сафка басмыйча, ахун хәзрәттән бер генә адым арттарак ялгыз басып тора. Намаздан соң хәзрәтнең уң ягына утырып, матур, көчле Мысыр мәкаме белән кычкырып корьән укый. Аш мәҗлесләреннән дә аны һич калдырмыйлар. Анда да ул Искәндәр ахун белән янәшә утыра һәм хәзрәт рөхсәте белән корьәнне дә ул укый. «Әгузебилляһи...» дип аз гына сакауландырып, тавышын аз гына калтырата төшеп башлап җибәрүгә, мәҗлес халкы тәмам өеп, мәрткә киткәндәй тынып кала, ә ишек артына җыелган хатын-кызлар, авызларын яулык читләре белән каплап, тәмам эреп, яшьләрен агызаагыза аны тыңлыйлар.

Ул елны, җитмәсә, ураза да кышкы айга туры килгән иде. Бөтен рамазан буена Корьәнхафиз мәчеттә тәрәвих вакытында кычкырып кәрьән чыкты. Аны тыңлар өчен генә халык ябырылып тәрәвихка йөрде. Менә шуннан соң инде Корьәнхафизның шөһрәте һәм дәрәҗәсе аеруча үсеп китте. Базарда, кибетләрдә, мәҗлесләрдә агай-эне аның зур гыйлем иясе булуына, зирәклегенә, чибәрлегенә исләре китеп, тел шартлатып сөйли торган булдылар. Хәтта күп кенә сәүдәгәр кызларының да ул хыялларына кереп, күңелләрен кытыклый һәм төн йокыларын качыра башлаган иде.

Озак та үтми, халык арасында Корьәнхафизны карт хәзрәттән соң мәхәлләгә имам итеп кую турында да сүзләр йөри башлады. Бу инде колакны торгызырлык хәбәр иде. Дөрес, ахун хәзрәтнең фани дөньяда озак тормасын истә тотып, аның урынына имам табу мәсьәләсен мәчет картлары элек тә үзара сөйләштергәлиләр иде. Ләкин бик сак кына, ахунның үзенә ничек тә барып җитмәслек итеп кенә, чөнки бу бик четерекле, бик катлаулы мәсьәлә иде. Ә инде Корьәнхафизны ахун урынына димләүгә килгәндә, бу аеруча зур гәп, зур бәхәс тудырырга тиеш иде. Хикмәт шунда: Искәндәр ахун үзе саф башкорт иде, ә Корьәнхафиз — Ыслак татары. Шуның белән бергә, мәхәллә халкы да ике груһка бүленеп йөри: төп халык—җир-су биләүче башкортлар; ә сәүдәгәрләр, приказчиклар, тегүчеләр, итекчеләр—барысы да читтән килгән татарлар. Болар арасында мәхәлләгә хуҗа булу өчен һәр даим яшерен көрәш бара. Башкортлар мәхәллә башына «килмешәк татарны» куярга һич теләмиләр, ә татарлар ахун хәзрәттән соң мәхәлләгә имам итеп берәр уңган, өлгер, гыйльме шәп татар мулласын китерергә ашкынып торалар.

Шуның өстенә әле тагын Искәндәр ахунның Бохарадан укып кайткан Әхмәдия атлы үз улы да бар иде. Тик бичара мәхзүм чатан иде, бер аягы белән чокырга төшеп киткәндәй бик каты аксап йөри иде. Ләкин башкортлар барыбер аны атасы урынына имам итәргә ниятләп торалар иде. «Сатан булһала, үзебездеке булыр» диләр иде алар. Ә татарлар исә, мәхзүм ул — гарип кеше, гарип кешегә оеп намаз уку дөрес булмаячак, дип каршы төшәләр иде. Билгеле, алар шушы сылтау белән имамлыкны ничек тә башкорт кулыннан алып, татар кулына бирергә тырышалар иде.

Ә Искәндәр ахун үзе соң бу мәсьәләләргә ничек карый, нindirәк мөнәсәбәттә тора? Моны ачык кына белүче булдымы икән? Иң элек, ахун хәзрәт табигате белән бик аз сүзле, йомык бер кеше иде. Мәҗлес-

ләрдә ул, бүтән муллалар шикелле, үзе башлап акыл сатарга яратмый, бары сорауларга җавап кына биреп утыра, Корьәнне дә күбрәк мәзиннән укыта, хәтта мәчеттә мөнбәргә менгәч, вәгазьне дә бик кыска тота иде. Ихтимал, бу кадәресе аның картлыгы җитүдән дә килгәндер инде. Дөрес, ул бик башкорт җанлы мулла иде, бөтен исәп-гамәлендә иң элек үзенең башкортларына таяна торган иде. Ләкин татарлар белән дә ул бик нык хисаплашырга тиеш иде. Мәсьәлә шунда ки, башкортлар үзләре дин өчен, шәригать өчен алай бик җан атып тормыйлар. Гомумән, дингә җиңел карый торган халык. Купчелеге мәчеткә бик сирәк йөри, шәригать кушканнарны бик иренеп кенә тота. Сер түгел, мәсәлән, Дим буендагы Көрмәнкәй, Шәрип, Казангол кебек саф башкорт авылларындагы мәчетләрнең сукмагын җәй көне үлән басып бетерә, ә муллалары базардан базарга күмәкләшеп кымыз эчеп, бал эчеп, курай тартып, җырлашып, кәеф-сафа сөреп йөриләр. Һәм берәү дә моны гаеп итми, киресенчә, андый мулланы мактап кына сөйлиләр: шәп кеше! Менә шуңа күрә дә башкортка хәзрәт үзенеке булса шул җиткән, калганына аның артык исе китми. Ә татар инде андый түгел. Татар, бигрәк тә аның сәүдәгәрләре — гаҗәп тәкъва халык, дин-ислам өчен җанын да, малын да кызганмый, шәригать кушканны үзе үтәү генә түгел, хәзрәтнең дә бик төгәл үтәп баруын тикшереп торырга ярата. Аннары хәзрәткә тигән күп төрле сәдака да, мәчет-мәдрәсәне карау өчен бирелгән һәртөрле иганә дә күбрәк алардан керә. Шулай булгач, Искәндәр ахунның үз мәхәлләсендәге татарлар белән хисаплашмыйча һич мәҗәле юк. Аңа ике халыкның да көен көйләргә туры килә. Ихтимал, шуңа күрә ул имамлыкка кемне варис итү мәсьәләсе буенча барган бәхәсләрне ишетмәмешкә салынган булып, тел яшереп торырга мәҗбүрдер дә... Ләкин шулай да Корьәнхафизга аның үз мөнәсәбәте ничек, ни уйлый ул бу кинәт калкып чыккан татар турында, җаны кабул итә аламы аны? Мөгаен, юктыр, хәер, ачык кына әйтүе бик читен. Дөрес, ул аңа юл куя, бернинди көнчелек-мазар күрсәтми, әмма шуннан башкасын сизү һич мөмкин түгел. Мәҗлесләрдә ул ап-ак сирәк сакалын күкрәгенә терәп, күзләрен шешенке кабаклары астына яшереп, тын гына утыра. Сүзе бик сирәк чыга, тик әллә нидә бер генә бик хикмәтле һәм усал итеп берәр кинаяле сүз әйтеп куя, шуңа күрә аңардан бераз куркалар да, шул ук вакытта аны, билгеле, олылап хөрмәт тә итәләр. Ләкин мәчеттә булсын, мәҗлестә булсын, хәзрәт үзенең янәшәсендәге Корьәнхафизны гүя күрми дә, белми дә. Атналар буена ул аның белән сөйләшмидер кебек.

Аның каравы, Корьәнхафизның ахун хәзрәткә булган мөнәсәбәтен ачык сизәргә мөмкин иде. Иң элек шуны әйтергә кирәк: Дәүләкән кебек зур бер җирнең бай мәхәлләсенә килеп эләккәч һәм татар сәүдәгәрләренең бихуш булып күтәреп алуларын, хәтта имамлыкка юрый башлауларын белеп алгач, бу хәйләкәр-елгыр бәндә мондый форсатка тешетырнагы белән ябышырга тиеш иде. Ахун хәзрәт урынына имам булып калу — бу инде төшеңә дә кермәслек бер бәхет! Моның өчен иблиснең үзе булырга да теләсәң нинди җәтмәләр корырга да ярый. Ләкин шуның белән бергә ахун хәзрәтнең башкорт булуы һәм башлыча үзенең башкортларына таянуы Корьәнхафизның эшен гаять читенләштерә иде. Хәтта өметсезгә әйләндерә иде. Бу эштә ачыктан-ачык татарлар ягына да басарга ярамый иде, алай иткәндә бөтенесен оттырырга мөмкин иде. Шуңа күрә безнең Корьәнхафиз, башкорт ышанучан, башкорт олылаганны ярата дип булса кирәк, иң элек хәзрәтнең үзенә ничек тә ярарга, ничек тә елышырга тырышты. Ачыктан-ачык ялагайлык күрсәтмәсә дә (чөнки аңа үз дәрәҗәсен дә сакларга кирәк иде), ул карт хәзрәтне гүя хөрмәт итү, олылау йөзеннән аның алдында «тәхсир» дип, «мөбарәк зат» дип баш иеп кенә торды. Һәрвакыт янында булып, аның һәр теләген, һәр боерыгын үтәргә әзер торды. Мәчеттә ул аны култыклап мөнбәр-

гә менгерде. Мәҗлесләрдә ул аңардан узып сүз сөйләмәде, корьәнне дә бары аның рөхсәте белән генә укыды. Кыскасы, бик итагатьле бер кыяфәт белән, ахун хәзрәткә чынлап та бик якын торган бер кешесыман, ул бөтен җирдә аның күләгәсе булып йөрде.

Ләкин болар гына карт хәзрәтнең күңелен җәлеп итмәсен, татар файдасына аның фикере үзгәрмәсен Корьәнхафиз сизенә иде булса кирәк. Монда юхаланып маташу юлы белән генә эш чыгарып булмаячак иде, әлбәттә. Карт хәзрәтне тәмам әсир итәрлек ниндидер бүтән бер бик көчле, бик тәвәккәл чара табарга кирәк иде. Ә безнең Ыслак мишәре, явыз, усал булу өстенә, бик чая кеше дә иде. Чынмы-ялганмы, ләкин ялкынсыз төтен булмый диләр, аның әнә шулай имамлыкны өмет итеп йөргән чагында Дәүләкән шинкарларына барып, марҗалар белән күмүшкә эчеп утыруы турында да сүзләр чыккан иде. Тик, хикмәте хода, моның аңа бер зыяны да булмады. Зур дәрәҗәле чибәр кешенең гамәлен алай бик хөкем итмиләр, күрәсең... Менә шул әрсезлегенә һәм үзенең дәрәҗәсенә таянып, карт хәзрәткә тагы да ныграк якынаю нияте белән, Корьәнхафиз әфәнде гаҗәп бер кыю адым ясый. Ул үзенчә бик дөрес исәп йөртә, ләкин моңардан ни килеп чыкканын алда күрерсез.

Эш болай тора: Искәндәр ахунның чатан мәхзүмнән башка тагын Гайшә исемле җитеп килгән кызы да бар иде. Башкорт кызларының Дим камышыдай бер сылуы иде ул. Озын кара калын толымлы, түгәрәк карасу йөзле, сызылып киткән нечкә кашлы, чиядәй иренле, энҗедәй ап-ак тешле, елмайганда бит урталары чокыраеп китә, үзе карлыгачтай уйнак-сөйкемле иде. Сары мәдрәсәдә ятучы шәкертләр «Гайшә җан!» дип авалар да китәләр иде. Шул «карлыгасты» бер күрер өчен генә алар атна саен хәзрәтнең абзарындагы тиресен түгәргә йөриләр иде. Җомгадан соң ун-унбишләп шәкерт, туй мәҗлесенә хәзерләнгәндәй бик көязләнеп, ак шарфларын чорнап, ак перчаткаларын киеп, бүрекләрен кырын салып, шагыр-шогыр хәзрәт ихатасына атлыйлар. Анда аларны хәзрәтнең ялчысы озын Гыймади каршы ала, һәркайсысына я сәнәк, я көрәк тоттыра. Шәкертләр шарфларын, туннарын салып дәррәү эшкә тотыналар. Зур үрәчәле чанага тиресне төягәч, биш-алты шәкерт аны һай-һулап сөйрәп, яр астына алып төшеп китәләр. Болай ат җикмичә генә күмәкләшеп тарту кызыграк та һәм вакыт та озаккарак сузыла. Ләкин тирләп-пешеп эшләгән шәкертләрнең күзләре гел аш өенең ишегендә генә — шуннан Гайшәҗан комган күтәреп килеп чыкмасмы? Тик, гөнаһ шомлыгына каршы, җиз комганны күтәреп, я чатан мәхзүм, я карт остабикә, я Гыймади хатыны килеп чыга, ә Гайшәҗан юк, Гайшәҗан чыкмый да чыкмый. Һай, аны күрүләре бик тә читен шул! Бигрәк тә хәзрәт үзе өйдә булса, бу бөтенләй өметсез эш инде. Әмма өметсез шайтан дигәндәй, кайчагында көтүләре бушка да китми. Гайшәҗанның да бит әле үз җаны бар, ул да бит шәкертләрнең ишек алдында тирес түккән булып, зарыгып көтүләрен сизеп тора... Һәм менә уйламаган бер чакта гына сылу кыз тәнкәле юка җиләнен башына бөркәнеп, аш өеннән ялт килеп чыга да башын түбән иеп кенә, кечкенә ак пималары белән вак-вак атлап кына капка төбенә китә. Урамга чыгып, кемнедер көткәндәй, бер уңга, бер сулга борылып, каранып тора... тора да аннары керфекләрен шулай ук җиргә төшереп кенә, вак-вак атлап кына кире өйгә таба килә һәм ишеккә җиткәндә генә кыр кәҗәседәй кинәт атылып кереп китә. Авызларын ачып каткан шәкертләр шул чакта мәхзүмәнең озын кара толымлы зифа буен да, кыйгач кашлы, бит урталары чокыраеп торган түгәрәк йөзен дә ичмасам бер рәхәтләнеп күреп калалар. Һәм аларга шул җитте дә! Шунда ук көрәк-сәнәкләрен ташлап (калганын Гыймади үзе дә көрәп бетерер), туннарын киеп, тизрәк мәдрәсәгә элдерәләр. Кайткач, бөтен кич буена «ах, Гайшә хурый» да «ах, Гайшә җаный!» дип, котырып киткән хыялларыннан тәмам исерешеп, киезләре өстендә аунап яталар. Бигрәк тә пешеп кенә өлгер-

гән кып-кызыл җиләк шул! Кемнең генә авызына өзелеп төшәр икән ул татлы-сусыл җиләк?!

Менә шушы җиләктәй мәхзүмәгә безнең Корьәнхафиз нәфесен суза да инде. Әлбәттә, ул шәкерт түгел, хәзрәткә шактый якын торган, аның өенә кергәләп-чыккалап та йөргән кеше, һәрхәлдә, сылу Гайшәне күргәләгән булырга тиеш. Ничек кенә булмасын, сүлән шикелле астыртын мыштым гына каранып йөргән Корьәнхафизда унҗиде яшьлек хәзрәт кызына дөрләп ялкынлы дәрт кабына. Ихтимал, моны мәхәббәт дип тә атарга ярый торгандыр, чөнки мәхәббәт ерткыч җанварларга да хас нәрсә диләр. Кыскасы, ул Гайшәгә өйләнергә тели. Ләкин бу теләкнең нигезендә башлыча бик еракка каратып төбәлгән зур исәп тә ята: әгәр ул берәр могҗиза белән Искәндәр ахунның кияве булып алса, бай мәхәллә һичшиксез аныкы булачак. Башкорт бик туган җанлы, урын һәм дәрәҗәне үз токымына яки үз кардәшенә тапшырырга ярата, шулай булгач, карт хәзрәт тә, гәрчә бердәнбер улын үз урынында күрергә теләсә дә, мәхәллә халкы мәхзүм гарип ул дип каршы торгач, имамлыкны ахыр чиктә яраткан кызының киявенә бирер иде. Бирмичә хәле юк, чөнки мәхәлләнең иң көчле өлеше — татарлар шуны таләп итәчәкләр. Шулай итеп Корьәнхафиз үзенең яшерен максатларына ирешәчәк... ирешәчәк, әгәр дә Гайшә дигән карлыгачны үткен тырнакларына эләктереп ала алса.

Ул башта Гайшәгә булган өметен сиздерергә ашыкмады, ул иң элек үзен бик мәһабәт тотып, бик көяз йөреп, мәхәллә халкы алдында дәрәҗәсен күтәрергә һәм суфиланып, итагатьлек күрсәтеп хәзрәткә елышырга тырышты. Әмма ләкин коры исәп һәм азгын теләк һәрвакытта берәр очыннан сүтелә башлый. Корьәнхафизның мәдрәсәдәге ерткычлыгы тышка чыкты, халык теленә керде, кайбер ярлы-ябагай балалары укуларын да ташладылар. Хәлфә кыйнаганнан соң колагы ага башлаган әлеге Габделбариның этисе Сафиулла абзый, — әйтергә кирәк, Дәүләкәннең мөхтәрәм сәүдәгәрләреннән берсе, — хәлфә өстеннән хәзрәтнең үзенә туп-туры шикаять белдерә. Бу инде хәтәр нәрсә, ышанычлы терәкләрнең берсе какшый башлау дигән сүз. Кем баласы икәнен абайламыйчарак малайның колагына тондырган икән, хәерсез!

Шуның өстенә, бозык хатыннар белән чуалуы турындагы сүзләр дә ешрак кабатлана башлады. Әгәр бу сүзләр ахун хәзрәткә барып җитә калса, Гайшәдән генә түгел, бөтенесеннән колак кагарга мөмкин. Кыскасы, Корьәнхафизга ашыгырга кирәк иде.

Ә тарихи вакыйгалар ул кышны бик куерып китте. Әйткәнемчә, Корьәнхафиз безнең мәдрәсәгә унҗиденче елның көзендә килгән иде. Бөтен Рәсәйне инкыйлап ташкыны басып киткән бер заман иде бу. Ерак Пайтәхеттән көчле инкыйлап җиле, ниһаять, безнең кечкенә Дәүләкәнгә дә килеп җитте. Бездә дә совет дигән яңа власть урнашты. Дөрес, көндәлек гади тормыш үзенең моңарчы хөкем сөргән тәртип-низамы, дине-шәригате белән искечә һаман бара иде әле. Ләкин шуңа карамастан, бу инде яңа чор, яңа заман иде. Тиздән бөтен иске тәртипләр җимерелергә тиеш. Берәүләр моны бик теләп көтә, икенчеләр хафага төшеп, куркып тора. Әмма яңаның тууы кискен, каты көрәшсез булмас кебек. Эшләр шуңа таба бара.

Корьәнхафиз менә шушы буталчык, хәвефле вакыттан файдаланып калырга уйлый. Көннәрдән беркөнне ул карт хәзрәт алдына барып, түбәнчелек белән, ләкин ачыктан-ачык сүзен башлый:

— Тәхсир, сезгә зур гозерем бар, — ди, чибәр йөзендә әдәп белән әрсезлекне бергә чагылдырып. — Тугры сүзем өчен кәефегез кырыла күрмәсен, бары изге теләктән чыгып әйтәм, тәңрем моңа шаһит! Үзегез күрәсез, тәхсир, заманнар бик буталды, иртәгә ни буласын берәү дә белми, зур афәтләр килүе мөмкин... Әйе... Хосусән сезнең кебек тирәякта дан тоткан ахун хәзрәтнең хәле бик мөшкелләнеп китүе мөмкин,

ник дисәгез, әһлеислам арасында да бердәмлек бетте, груһларга бүленеп якалашу китте, хак сүзне житкерүче дин әһелләренә колак салмый башладылар. Алай гына да түгел, бу дәһри бәлшәвикләр чыгарган влас халыкны ачыктан-ачык дин-шәригатькә каршы котырта, хәзрәт-имамнарны халыкның дошманы итеп күрсәтергә тырыша. Мондый шартларда изге мөнбәрдән әһлеголәмәне хак юлга өндәүнең никадәр авыр булуын, шаять, үзегез дә аңлый торгансыздыр... Шуның өстенә, тәхсир, мәгълүм булганча, без барыбыз да бу фани дөньяда мосафирлар гынабыз, зинһар, сүземне авырга ала күрмәгез, әмма ни кыйлмак кирәк, картлыгыгыз бик житкән, хак тәгаләнең тәкъдирен белеп булмый, үз янына чакырып алуы да мөмкин... Аз гына сабыр итегез, остазым! Сезгә булган хөрмәтем искиткеч зур, максатым — иманым шикелле саф, — сез галиҗанәбкә бөтен вөҗүдем белән тугрылыклы булып калуда гына... Мөбарәк җилкәгездә күтәреп барган авыр йөкне ышанып миңа тапшыра аласыз. Изге юлда җаным фида, — мин сезнең калканыгыз булырга телим. Тик хәер-фатихагыздан ташламагыз, тик калбем түреннән чыккан соңгы үтенечемне генә кире какмагыз... Пәйгамбәремез алдына килеп тезләнгән сәхабә шикелле, кулларымны гарешкә сузып, я, хәзрәтем, сездән сорарга җөрьәт итәм: Кадирмәүләнең ихтыярына буйсынып, кызыгыз Гайшәбикә мәхзүмәне миңа хәләл җефетлеккә бирсәгез иде...

— Җитте, хәлфә, җитте! — ди хәзрәт кулы белән ишарә ясап һәм көчкә сулышын алып. — Сез кем хозурына килүегезне белеп килдегезме?

— Белеп килдем, тәхсир, бик яхшы белеп килдем.

— Сез үзегезнең кем идекегезне дә яхшы беләсезме?

— Мин сезнең тугрылыклы хадимегез, тәхсир! — ди Корьәнхафиз, өр-яңа кәләпүшле башын ия төшеп.

Карт хәзрәт авыр күз кабакларын яртылаш кына ачып, судай тоныкк күзләре белән көяз-сылу Корьәнхафизга текәлә.

— Алайса, ишек төбенә китеп, минем сүземне тыңлагыз: килмешәк мишәр өчен минем үстергән кызым да, әзерләп куйган мөнбәрем дә юк. Ишеттегезме?.. Барыгыз, моннан соң бусагама аяк басасы булмагыз.

Моны ишетеп, Корьәнхафиз башта агарынып китә, беравык сүз таба алмыйча катып тора, аннары кара янып, буылып әйтә:

— Сез... сез, тәхсир, бу сүзләрегез өчен бер үкенерсез! Мин... мин бу тәхкыйрьне онытачак түгелмен.

Хәзрәт аңа кулын гына селти. Корьәнхафиз елан шикелле хәзрәт өстенә ысылдап: «Моннан соң сез миннән рәхим-шәфкать көтмәгез!» — ди дә бәреләсугыла чыгып та китә.

Шулай итеп, моңарчы дәшми-тынмый гына йөргән карт хәзрәт үзүзенә бик нык ышанып, масаеп, имамлыкны өмет итеп, хәтта мәхзүмәгә нәфесен сузып йөргән «килмешәк типтәрне» бер селтәнүдә үтерде дә куйды. Билгеле инде, бу Корьәнхафиз өчен хәзрәт бусагасыннан гына түгел, гомумән мәхәлләдән куылу дигән сүз иде. Чынлап та, Дәүләкән сәүдәгәрләрендә хәзер Корьәнхафиз кайгысы юк, һәм башкорт мулласы моны бик нык исендә тоткан булса кирәк. Ләкин ул Ыслак мишәренең никадәр усал-явыз булуын гына уйлап җиткермәгән икән...

Ул кышны мәдрәсәдә укулар бик иртә тукталды, читтән килгән олы шәкертләр чана юлы өзелгәнче үк авылларына таралышып беттеләр. Корьәнхафиз да озакламый юкка чыкты. Без дә, ерткыч тилгәннән котылган чебиләр шикелле, бер иркен сулыш алдык.

Әмма шулай да ул мәлгуньнең бөтенләй үк юкка чыгуына күңел нигәдер ышанып бетми иде. Кешесе андый түгел. Кабердән әйләнеп кайта торганы. Чынлап та, Дәүләкәннең таш мәчетле бай мәхәлләсенә шулай ансат кына кул селтәп китәме соң ул! Байларның кыйммәтле келәмнәр белән түшәлгән залларында Мысыр мәкаме белән кычкырып корьән укуларын, чапан кесәсенә шыгырдап торган «кәгазьләрне»

карамыйча гына салып куюларын тиз генә онытыр дисезме? Юк, әлбәттә. Кеше тиресен алыштырса да, гадәтләнгән кәсебен алай җиңел генә ташламый. Дөрес, соңгы вакытта дөньялар үзгәреп киткәч, бигрәк тә ахун хәзрәт тарафыннан шундый мәсхәрәле рәвештә куылгач, Корьәнхафизның Дәүләкәндәге майлы-ширбәтле тормышы ничектер кинәт өзелгәндәй булды. Имамлыкка омтылу да бер мәлгә әһәмиятен югалтып җибәрде шикелле. Ләкин бу, ихтимал, вакытлы гына бер күренештер. Дин бар, шәригать бар дигәндәй, бәс шулай булгач, аның мәхәлләсе дә сакланыр, мулласыз да, билгеле, тормаслар. Юк, өметне өзәргә һич тә ярамый... Аннары килеп, Дәүләкән үзе һәм аның мәчете утка янса да, Гайшәбикә мәхзүмә кала бит әле, ул бар бит әле. Искәндәр ахуннан кайтарасы үч бар, үч! Моны инде ул «та кыямәт» онытачак түгел. Җае гына чыксын. Гайшәбикәне тартып алыпмы, бүтәнчәме, әмма ул карт хәзрәтне кәҗә урынына бер үкертәчәк әле! Әйтте диярсез. Һәм озакка да сузмаячак ул моны. Белеп тора ул, башкорт җитеп килгән кызын озак асрарга яратмый, бүрек белән бәргәч егылып китмәсә, тизрәк туйлап озату ягын карый. Ахун хәзрәтнең дә Гайшәсенә, уналты яше тулартулмас, тирә-якның исемле муллаларыннан һәм бай башкортларыннан яучылар килә башлаган иде инде, тик хәзрәт ни өчендер үзе генә бирергә ашыкмый иде. Ә хәзер дөньялар болай булып киткәч, сылу кызын исән-имин чагында озатып җибәрүе дә бик мөмкин иде. Шул сәбәпле, Корьәнхафиз каядыр китеп югалса да, Дәүләкән тирәсеннән алай бик еракта йөрмәскә тиеш иде.

Озын сүзнең кыскасы, Корьәнхафизның тагын әле бер Дәүләкәндә «пәйда» буласын без ничектер сизенеп, көтеп йөрдек. Тик кайчан, ничек, нинди кыяфәттә пәйда буласын гына алдан юрый белмәдек, — хыялыбыз җитмәде. Ә ул, чалмалы иблис, һич уйламаган яктан, һич акыл ирешмәс бер рәвештә килеп чыкмасынмы! Бу шулкадәр шаккатыргыч әкәмәт бер вакыйга булды ки, Дәүләкән халкы перәме бот чабып «ах» итте. Валлаһи дип әйтәм, әгәр шушы вакыйга булмаса, мин дә күпме гомердән соң ул бәндә турында вакыт әрәм итеп язып тормас идем. Ярар, барысын да ишеткәнемчә сөйлим әле, — ишеткәнемчә дим, чөнки Корьәнхафизның бу килеп китүен бары эш узгач кына белдек.

Мин инде ул кышны илдәге хәлләрнең кискенләшә баруын, мәдрәсәдә укуларның иртә бетүен әйткән идем. Чынлап та, язга чыгу белән, дөньялар тагын буталып китте. «Аклар» — «Кызыллар» сугышы башланды. Каяндыр, ниндидер тагын чехлар дигән нәрсә калкып чыкты. Менә шул чехлар җәй башында безнең Дәүләкәнгә килеп керделәр. Совет урнаштырып йөрүчеләр каядыр юк булдылар. Өяздә нинди власть, кем кемгә хуҗа, — белгән кеше юк. Әллә нинди билгесез, ышанычсыз бер вакыт. Һәркем өендә посып ята. Баерак кешеләр хатын, бала-чагаларын читтәрәк торган тынычрак авылларга күчерделәр. Искәндәр ахун да буй җиткән Гайшәсен, солдат күзеннән саклау өчен булса кирәк, үзенең туган авылы Ташлыярга озатты.

Шулай да бу чехлар дигәнең бездә алай озак хөкем сөрмәделәр. Аларның солдатлары, җирле халык белән артык аралашмыйча, станциядә үзләренең вагоннарында тордылар. Тик бик фырт киенгән офицерлары гына сәүдәгәр өйләрендә граммофон уйнатып, купец кызлары белән парлап биешеп, кәеф-сафа кылып йөрделәр. Ә бер айдан соң Бәләбәй ягыннан килүче кызылларга каршы торырга теләмичә тиз генә Дәүләкәнне ташлап, чыгып та киттеләр.

Дәүләкәнгә беренче тапкыр «кызыллар» килеп керделәр. Кырыклап олау, ике йөзләп кеше; берәзы ат өстендә, ә күпчелеге—җәяүле гаскәр... Чын армия идеме бу, — хәзер әйтә алмыйм инде, ахрысы Богырыслан — Бәләбәй тирәсеннән җыелып чыккан аерым бер отряд кына булгандыр. Өс-башлары да, кораллары да аларның бик чуар иде; бер ишеләре окопларда аунаган иске шинельдән, икенчеләре — үзләренең чикмәннәрен-

нән; күбесендә штыклы озын мылтык, калганнарында көпшәсе киселгән кыска мылтык, ә кайберләрендә бернәрсә дә юк. Хәер, араларында чын командирларча аркылы-торкылы каеш киеп, шпорлы итек киеп, ян ягына кылыч, наган тагып йөрүчеләре дә бар иде. Кыскасы, кем нәрсә тапса, шуны кигән, шуның белән коралланган булса кирәк. Ләкин бөтенесендә уртак бер нәрсә — башларында яки күкрәкләрендә зур кызыл тасма. Шушы тасма булмаса, аларның акмы, кызылмы, яшелме икәнен дә тиз генә аерып булмас иде.

...Инде тыңлагыз. Отряд килеп кергән көннең төнендә үк Искәндәр ахунның капкасын кемдер бик каты дөбердәтергә тотына. Өй эчендәгеләр сискәнеп уяналар, тын да алырга куркып көтеп торалар. Озын Гыймади капкага чыга... Һәм менә бер заман туп-туры хәзрәт яткан түр якка берәү атылып килеп керә. Шпорлы итекләрдән, кызыл галифедан, ак папахадан, папаханың бөтен буена кыеклап кызыл тасма тоткан; аркылы-торкылы каеш шлеялар кигән, бер янтыгында — кылыч, икенче янтыгында — наган. Зур кара мыеклары орчыктай ике якка сөзеп тора... Идән уртасына аякларын аерып баса да бу, түшәгендә утырган хәзрәттән кычкырып сорый:

— Я, тәхсир, таныйсыңмы?

— Таныйм, — ди хәзрәт, аз гына көттереп.

— Танысаң бик әйбәт, безгә хәзер исәп-хисапны өзәр вакыт җитте.

Йөзе генә түгел, иреннәре кәгазьдәй агарган һәм сакал-мыегы әкрен генә калтыранган хәзрәт әллә артык дәрәҗәдә хәйран калудан, әллә чиксез ачу-нәфрәттән инде, телдән язып, керфеген дә кага алмыйча, Корьәнхафизга озак кына карап тора. Аннары тәмам аптыраган, исе киткән кешедәй ихтыярсыздан сорап куя:

— Ничек сине җир йотмый, ә?.. Я кадир, я мәүла!..

Күзләрен ялт-йолт йөрткән Корьәнхафиз сабырсызланып аңа кычкыра:

— Хәзрәт, аллаңа сыенырга өлгерерсең, минем вакытым юк, сүзне бетерик.

— Сиңа миннән ни кирәк, иблис мәлгунь?

— Гайшәбикә... Кайда Гайшәбикә?

Хәзрәт балаларча һәртөрле куркуны онытып, кинәт тәштитләп каргарга, тиргәргә тотына:

— Алланың дәргаһыннан сөрелгән хаин син, яәҗүз-мәәҗүз булып кубарылган ерткыч вәхши син, җир күтәрмәс нәҗес, кабих зиначы син... Күкләрнең каһәре яусын башыңа, мөртәт!.. — Һәм бәддога кылгандагыча ике кулының сырты белән битен сыпырып куя.

Корьәнхафиз, котырып китеп, наганын тартып чыгара.

— Тукта, хәзрәт! Күрәсеңме менә моны? Авызыңны хәзер кайнар кургашын белән тутырам... Кайда Гайшәбикә?.. Чакыр тизрәк, я!..

— Гайшәне түгел, көчегемне дә бирмим мин сиңа!..

— Юк, бирерсең!.. Җаныңны алам, тәхсир, сузма!

— Җанымны да син ала алмыйсың, бәдбәхет! Җаным алла хозурына китәчәк.

— Атам!

— Ат, я, ат!.. Ник атмыйсың?

Корьәнхафиз сыңар күзен кысып, наганын хәзрәтнең нәкъ башына төзи... Ике кулы белән түшәгенә таянып, артка каерыла биреп утырган хәзрәт ап-ак иреннәрен кыймылдатып, күзен дә йоммыйча наган көпшәсенә карап тора... Корьәнхафиз акрын гына наганын кире төшерә.

— Тәхсир, — ди ул, ниһаять, карлыккан тавыш белән, — кирелегең барма. Бел, синең кебек ахуннарга көн бетте хәзер... Ә минем аркада әле син котылып калачаксың... Аңлыйсыңмы шуны? Я, ник дәшмисең?.. Чакыр алайса Гайшәбикәне, үзем сөйләшәм мин аның белән...

— Ул өйдә юк, — ди хәзрәт, тыныч кына.

— Юк? Ни өчен юк, кайда ул?
— Китте...
— Кая китте?
— Авылга.
— Кайсы авылга?
— Анысы сиңа кирәк түгел.
— Хәзрәт, син уйнама минем белән!.. Мин синең җаныңны да җәһәннәмгә җибәрермен, Гайшәбикәне дә җир астыннан эзләп табармын... Яхшы чакта әйт, кайда ул?
— Ул монда юк, вәссәлам!.. Син кабихка ялганлап тору бик зур түбәнлек булыр иде... Ә кайда икәнен сорама, барыбер әйтмим.
— Әйтмисең?
— Әйтмим.
Корьәнхафиз кызыл галифе кигән аякларын ике җәпле сәнәктәй аерып, җилкәсен җыерып, хәзрәткә бүредәй карап тора. Әлбәттә, хәзрәт алдашмый, юк, алдашмый, тик нишләтергә үзен? Түшәгендә атып үтерергәме, нишләтергә?..
Ә карт ахун аны үчекләгәндәй күзенә туп-туры карап әйтә:
— Я, мәлгунь, атсаң ат, атмасаң — чыгып олак, җәллад шикелле алдымда басып торма!..
Шуны әйтүе була, Корьәнхафиз чытырдатып наганын кыса да селтәнеп бер... түшәмгә атып та җибәрә. Аннары бик яман сүгенеп, ишеккә бөтен көченә тибеп, атылып чыгып та китә. Һәм таң алды караңгылыгы аны, әйтерсең, баш-аягы белән йота.
Шуннан соң ул чынлап та төн эчендә эреп югалган гыйфриттәй каядыр юк була. Иң гаҗәбе шунда ки, кызыл галифеле, ак папахалы Корьәнхафизны хәзрәттән башка Дәүләкән кешеләреннән берәү дә күрми. Ә бәлки, күреп тә танымаганнардыр? Һәрхәлдә, кызыллар отряды озак тормыйча Дәүләкәннән чыгып киткәч кенә, карт хәзрәт өендә булган төнге вакыйга халык арасына тарала. Ахрысы, шуңадыр бу вакыйга кешеләргә ниндидер бер җен әкиятесыман булып тоела, башта аңа ышанырга да, ышанмаска да белмиләр, аннары гадәттәгечә үзләреннән әллә ниләр өстәп бетерәләр. Хәтта Корьәнхафизның яңадан әйләнеп кайтуын көтеп, сагалап йөрүчеләр дә була. Ләкин атналар үтә, айлар үтә, кешеләр бу маҗараны чәйнәүдән, ниһаять, арып туктыйлар, ә Корьәнхафиз шул китүеннән Дәүләкән тирәсендә, нә чалмадан, нә папахадан дигәндәй, бөтән инде күренми. Безгә калса, мәкерле ниятенә ирешер өчен генә чалмасын кызыл тасмалы папахага алыштырган ул залим кызылларга ияреп ерак китә алмагандыр. Кызыллар үзләре үк аны берәр җирдә дөмектереп калдырганнардыр — шулай юрадык без, шулай юрыйсыбыз килде.
— Ә Гайшәбикә? — диярсез инде сез.
Гайшәбикә Ташлыярдан исән-сау әйләнеп кайтты. Мәхзүмәнең бәхете бар икән. Дөньялар тынычлангач, егерменчеме, егерме беренчеме елны Дәүләкәнгә Башкортстанның зур гына бер түрә тиешле кешесе килеп, ахун хәзрәттән әйбәт кенә сорап, матур гына туй итеп, Гайшәбикәне Өфе каласына алып китте. Ул елларда мулла кызларының чибәрләрен, яңача тәрбия итәбез дип, шулай алып киткәлиләр иде.
Соңыннан без Гайшәбикә турында, мәҗлесләрне бизи торган бик шәп «бисә» булган, дип ишеттек. Булыр, бик булыр. Хәтерлисезме, ул сылу карлыгач бичара шәкертләрнең күзләрен ничек яндыра иде!..

1964.

*Шәйхи Маннур*

# МУСА

## Роман[1]

### ӨЧЕНЧЕ БАШЛАМ

#### I

Урман араларына сибелгән вак төркемнәр шулай фаҗигале рәвештә таркалып бетте. Канатлары сынган мескен агачлы киң мәйдан өсте җыелмаган үлекләр, кемлекләрен дә тану мөмкин булмаган кичәге батырлар гәүдәсе белән тулып ята. Бөтен тирә-якны һәлакәттән соңгы таш тынлык баскан. Таркала башлаган мәетләрнең авыр исе хәтта җил үтмәс урман эченә дә күтәрелеп килә. Күз ачып әйләнәнә карасаң, йөрәк кычкыртырлык күренеш иде бу...

Рәссамнар, гадәттә, сугышны кулына чалгы тоткан шыр сөяк үлем символы белән сурәтлиләр. Гаҗәпкә каршы, бу мәйданда да шундый ук өрәкләр, ялт-йолт каранып, урыннан урынга чапкынлап йөриләр иде. «Капут команда»га эләккән теге озын буйлы санитар солдат, бу хәлгә исе китеп карый-карый, иптәшләре белән үлекләр ташый. Менә аның яныннан гына шул өрәкләрнең берсе ыжгырып узып китте дә якындагы бер мәеткә ташланды. Ул изүләрен чишеп җибәргән, җиңнәрен терсәкләренә кадәр сызганып куйган. Җирән йөнтәс беләкләренең икесенә дә төрле маркадагы кул сәгатьләрен югарыга хәтле тезеп менгергән. Аларның алтыны да, көмеше дә, никеле дә барлыгы күренә, чөнки кояш нурында төрле төстәге чаткылар сибеп уйныйлар. Аның күкрәк кесәләренә, Кавказ бишмәтендәге ак нәкышләр шикелле, иңнән-иңгә ак, зәңгәр, сары башлы авторучкалар тезелгән. Бу мәетләрне дә ул тиз-тиз генә капшап чыкты да, үзенә кирәкле берни дә тапмагач, матур юка иреннәрен кыса төшеп, «черт» итеп бер төкереп куйды. Төкерек мәетнең битенә барып төште. Носилка белән үлек күтәреп баручы әлеге санитар бу тәэсиреннән арынып өлгермәде, аларның юлын икенче бер өрәк кисеп узды. Монысының күзләре тагын да шашкынрак, ә бармаклары һәртөрле йөзек һәм балдаклар белән тулган, хәтта баш бармакларына да икешәр балдак кигән иде ул. Монысы шулай да тегенең шикелле чытык чырайлы түгел иде. Санитарлар яныннан узганда, кулларын боргалап, бармакларын уйната-уйната каш сикертеп, елмаю төсе белән тешләрен ыржайтып узды.

— Гут! — диде ул, тагын бармакларын уйнаткалап. Аннары ни өчендер телен чапылдатып куйды һәм: — Гольд![2] — дип өстәде. Бик сөйләшәсе килә иде бугай аның. Ләкин, немец телен белүче булмаганлыктан, бу әсирләрнең берсе дә җавап кайтармады.

---

[1] Дәвамы. Башы 5 нче санда.

[2] Алтын!

Ул уенчак күңелле өрәктән соң санитарлар күз алдында тагын бер фаҗигале кәмит уйналып алды: өченче бер өрәк, әллә каян, вак агачлыклар арасыннан гына килеп чыгып, болардан читтәрәк иңкелдәге куак төбендә яткан бер үлекнең гади кирза итеген салдыра башлады. Ул ара да булмады, нәкъ шул ук вакытта тагын бер өрәк үлекнең икенче итегенә килеп тотынды. Икесе дә бер үк вакытта диярлек итекләрне суырып алдылар да, «Их!», «Их!» [1], «Я!» [2], «Найн!» [3] дип, шаулаша-шаулаша, шул итекләр белән бер-берсенең башына тондырыша башладылар. Һәрберенең ике итеккә дә хуҗа буласы килә иде. Әмма нәкъ шушы секундта икенче бер йөрәк яргыч хәл аларны кинәт айнытып җибәрде. Әлеге, итеге салдырылган үлек, бик тәмле йокыга талган жиреннән көтелмәгән каты шау-шу белән уятылган кеше шикелле, сүлпән генә, теләр-теләмәс кенә торып утырды да, каршында талашучыларга гаҗәпләнгәндәй, күзләрен уарга тотынды. Моны күргән өрәкләрнең котлары очты булса кирәк, кулларыннан итекләре төшеп китте һәм, команда буенча диярлек, икесе ике якка йөгерә башлады. Тик егерме адым да китмәгәннәрдер, аңга килделәр дә, шул ук команда белән хәрәкәт иткән кебек, яңадан борылып, автоматларын итек хуҗасына төбәделәр. Бер үк вакытта һәр икесе унлап пуля сиптереп тә өлгерде. Әлеге татлы йокысыннан теләр-теләмәс кенә уянган кеше, куллары белән эчен тотып, яңадан янтаеп төште һәм соңгы, уянмас йокысына талды. Итек өчен даулашучылар да килешеп, бергә китеп бардылар.

— Бу хәтле дә әзбир булыр дип белмидер идем мин бу немесләрне! — дип куйды озын буйлы санитар. Аның маңгай тамырлары күпкүмгәк булып, бармак юанлыгыдай бүртеп чыккан, ә күз төпләренә утырган ике зәһәр тамчы ут очкыны төсле елтырый иде...

Күмүчеләрне кичә генә сугыш узган быкырдык күл буена китерделәр. Монда немецлар аларга аерым каберләр казытып, башта үз үлекләрен җыйдырдылар. Һәр үлекне аерым калай табутларга салып, кешечә хәстәр белән аерым күмдерделәр, кабер өсләренә каен тәреләр утырттылар. Шуннан соң гына, бу каберлектән бөтенләй читтә, тагын зур бер чокыр казытып, безнең үлекләрне шунда тутыра башладылар. Олы гәүдәле санитарның бу аерма өчен дә җаны бик әрни, тик берни дә эшли алмый иде. Шуңа күрәдерме, ул, җәһәт-җәһәт атлап, якын тирәдәге үлекләрне барлап чыкты. Аларның кул беләзекләрендәге кан тамырына баш бармагы белән басып, йөрәк тибешләрен тыңлап карады һәм йөрүе бушка китмәде. Башта олы яшьтәге бер солдатның, тубыктан түбән аягы бөтенләй өзелгән дип әйтерлек булса да, тере икәнлеге беленде. Аны тиз генә лазаретка, үзебезнең әсир врачлар карамагына алып киттеләр. Аннары, йөри торгач, тагын бер кеше табылды. Ул быкырдык буенда гына йөзтүбән капланып яткан, бөтен киемнәре саз пычрагына чумып, гимнастеркасының җилкә башы һәм бил тирәләре бөтенләй канга катканга, чебеннәр сырып алган бер кечерәк гәүдәле, ялан аяклы өлкән политрук иде. Аның да зәгыйфь кенә пульсы барлыгы беленде.

— Менә, тагын бер мескен тере! — дип, сөенеп куйды Арыслан.

Аны сак кына әйләндереп карадылар. Ялан баш булганга, бөтен чәчләре белән бергә йөзләре дә, хәтта колак яфракларына кадәр күл төбенең чем-кара торфлы суткак пычрагы белән капланып каткан иде. Әйтерсең, ул быкырдык төбен башы белән сөреп йөргән, әйтерсең, ул анда үлемнән качар урын эзләгән.

Яралары аркасында булуы беленеп торганга күрә, бу билгесез кешене носилкага да йөзтүбән салып, немецлардан качыра-постыра, лазаретка алып киттеләр.

Олы санитар хәзер үзен, чынлап та, кирәкле кеше саный иде.

---

[1] Мин. [2] Әйе. [3] Юк!

— Менә күрдеңме, — диде ул Миңгалигә, — без бүген ике кешене коткардык дияргә була! Шуның өчен генә булса да яшәүнең мәгънәсе бар.

— Син бик өметчән кеше икәнсең, санитар, — диде аңа өченче бер әсир. — Мондагы яшәүнең дә мәгънәсен күрәсең.

— Өметсез — шайтан, дигәннәр. Өметең-ышанычың бетсә — яшәп тә торасы юк. Аяк сузарга гына кирәк.

— Шулай инде, аяк сузганчы кыймылдарга туры килә, бүтән чараң юк, — диде Миңгали. — Күрәсеңне күрмичә, кара гүргә кермисең, диләр түгелме. Менә шул инде. Ходай безгә күрергә язган...

Бу күл буенда да зур бер өем — исемсезләр каберлеге калкып калды. Аннары әсирләрне быкырдык эчендәге вак утраучыкларга алып кереп киттеләр.

## II

Хәрби әсирләр лагере катлаулы гыймарәт түгел, аны теләсә нинди кыр уртасына да корып була, тик чәнечкеле тимер чыбыгың гына булсын. Ә немецларның андый байлыгы бөтен дөньяны каматып алырга да житәрлек! Менә, Арысланнар әсир төшкәч, аларны да шушы яныл көл булган авыл читенә китереп, ничектер исән калган озынча ат абзары әйләнәсен катлы-катлы тимер чыбык үрмәләре белән челтәрләп чыгарга куштылар. Һәм алар үз куллары белән үзләренә бер дигән төрмә корып та өлгерттеләр. Бу тирәләрдән җыелган әсирләр барысы да шунда шыплап тутырылды. Абзарның сайгак идәнле өлешеннән урын алып калган кешеләр үзләрен хәтта бәхетле санадылар, ул инде сәкедә яту шикелле әйбәт тоела, чөнки йөзләрчә башка әсирләр, юеш балчык өстендә төн чыгып, бөер һәм үпкәләренә җир суыгы үтүдән иртәләрен озак ыңгырашалар иде. Алар, күз алдында сызып, хәлсез күләгәгә әйләнә баралар.

Ат абзарының бер башында кайчандыр яшь колыннар өченме, каравылчылар өченме салынган кечкенә бер арансыман корылма бар иде. Анда хәзер лазарет урнашкан. Аның лазаретлыгы да шуның төсле генә. Эчендә салам түшәлгән өч-дүрт агач тапчан, бер җимерек өстәл белән бер утыргыч, приборлар кайнату өчен бер пыскый примус һәм юып элгән иске марля кисәкләреннән башка һичнинди җиһаз юк. Бу — әсирлеккә эләккән совет врачларының үз теләкләре белән барлыкка китерелгән бер почмак кына иде. Монда хәтта авыруларның үлекле яраларын юарга спирт та юк, чын мәгънәсендәге йод табуы да кыен. Һәммәсе дә «юктан кодагый». Тик шулай да медиклар, аннан теләнеп, моннан юнәтеп дигәндәй, мохтаҗларга ярдәм күрсәткән булалар. Немецлар һәрвакыт күзәтеп, «үлә торганнар белән азапланмаска!» дигән боерык бирсәләр дә, монда эләккән кешене ничек тә үлемнән йолып калырга тырышалар иде.

Сугыш кырындагы үлекләр арасыннан табылганнарны да санитарлар шушында китереп салдылар. Болардан икесенең яралары бик житди иде. Картның тубыктан түбән тире генә тотып торган аяк йөзен кисеп ташлаудан башка бер чара да табылмады. Кара балчык пычрагына каткан икенчесенең битләрен арчып, көч-хәл белән гимнастеркасын салдырып карагач, сул җилкә башы белән бил итен бомба кыйпылчыгы умырып, бер кабыргасын имгәтеп киткәнлеге мәгълүм булды. Шулай да моны «бәхетле яра» дип атарга мөмкин иде, чөнки кыйпылчык кулбаш сөяген дә, сырт сөяген дә җимермәгән; димәк, ит ярасы озакламый төзәлүе һәм бу кешенең «адәм булуы» ихтимал. Канлы ярасына ябышып каткан гимнастеркасы белән эчке күлмәген салдырганда да, тән итенең умырылган җирләрендәге эреннәрне арчып бәйләгәндә дә каты ыңгырашып ятты ул, бик нык авырткандыр, күрәсең. Әмма аңына

килә алмады, күзләре ачылмады. Дәвалаучы врачлар, аның йөзләре ап-ак җансыз төс белән саргайганлыгын күреп, башларын чайкадылар. Күп, бик күп кан киткән, тамырлар бушап, йөрәк тәмам җегәрсезләнеп калган, диделәр.

— Эх, менә хәзер аңа кан җибәрергә иде! — дип зарланып куйды урта яшьләрдәге хатын врач. — Ләкин каян аласың аны? Резин көпшә белән суыртсаң да әсир тәненнән йөз грамм кан чыкмас. Кан җибәрә алмасаң, каймак, йомырка, ак май, сөт белән туйдырасы иде...

Аның янындагы карт хирург ачы көлемсерәде:

— Буш хыялга бирелмәгез, — диде ул. — Файдасы юк... Әнә, эрзац булса да, шул болганчык кофены кашыклап кына авызына салырга кирәк. Бәлки, йөрәк хәрәкәтен тергезеп җибәрүче бер стимул булыр...

Лазаретның алмашка киертердәй киемнәре дә юк иде. Шуңа күрә авыруның күлмәкләрен тиз-тиз генә юып, кояшта киптереп кидерергә туры килде. Гимнастеркасы юылганнан соң бу яралының якасында кайчандыр бер шпал булганлыгы, җиңендә исә сәяси хезмәткәрләр нашивкасы барлыгы беленде. Мондый билгеләрнең хәзер инде бик хәтәр нәрсә булуын аңлаган санитар кыз үзе үк аларны сүтеп ыргытты. Җиңдәге нашивка эзенә ниндидер мазут сеңдереп, ул төшне яңадан юып киптерде. Анда бетми торган кызгылт-көрән тап утырып калды. Бередә һәркем үз кешесенең хәлен һичбер сүзсез дә бик яхшы аңлый иде.

Картның аягы өметсез булса да, гомуми хәле яхшырак, ул хәзер сөйләшә, биргәнне ашый иде инде. Немец фельдфебеле кереп, исемен дә язып куйды, номер да такты.

— Фамилияңнең моннан соң кирәге юк, оныт, — диде немец. — Әмма менә бу номерны онытма! Син хәзер «№ 28888» дигән кеше. Сезденәме нинди матур фамилия туры килде сиңа: гел сигез дә гел сигез. Ә башкаларга әллә нинди нольләр дә таяклар гына эләгә! — Ул үзенең мондый тапкыр сүзләренә үзе көлде дә хуплау көткән төс белән врачка карады. Тик аның йөзендә бер төрле дә яктылык күрмәгәч, кинәт сүреп, нидер мыгырдана-мыгырдана, ачу белән чыгып китте.

Икенче яралы бер тәүлектән соң гына аңына килеп, күзләрен ачты. Кечкенә генә тәрәзәдән төшкән көн яктысын, салам белән мүкләгән агач стеналарны, юып эленгән марля чүпрәкләрен күрсә дә, ул әле үзенең кайда ятканлыгын төшенә алмады. Тәрәзәдән сузылган кояш нурының аргы читендә озын чандыр гәүдәле, чал чәчле, ияк очына ябыштыргандай гына кечкенә һәм кыска ак сакаллы бер кеше үз өстендәге юка халатының бавын артка бәйләп маташа. Аның янына кабарынкы чәчле, урта яшьләрдәге бер хатын килеп җитә. «Туктагыз, Филипп Михайлович, үзем бәйлим», — ди ул.

Ничәмә көннәр тартышканнан соң, үлем тырнагыннан очраклы рәвештә ычкынып, беренче тапкыр күзләрен ачкан бу яралы, шул ике кешене күргәч, бик гаҗәпкә калды: «Тукта, бу кешеләр ничектер таныш төсле түгелме?.. Ул аларны кайчандыр очратканы бар кебек ич. Кайда иде соң ул?..»

Бар зиһенен туплап, уйлап карады: маңгай сызыклары җыерылып килде, каш арасы уелды, әмма һичнәрсә хәтерли алмады. Тик шунысы шөбһәсез: ул аларны кайдадыр, кайчандыр күргәне бар. Күңел почмагына аларның сурәтләре дә сугылып калган, фәкать ачыкларга гына кирәк...

Шуннан соң аның бу җыерчыклары әз-мәз язылып, үлек чырае беркадәр җанланып киткәндәй булды: «Димәкки, мин әле үзебезнекеләр кулында икәнмен, урысча сөйләшә бит... Йөзләре дә таныш кебек...»

Аннары ул бу фәкыйрь почмакны күздән кичерде. «Берәр медпункттыр инде... Кояш нуры нинди матур булып сузылган... Минем дөнья яктысы күрмәгәнгә байтактыр, ахры...» — дигән фикергә килде.

Аңа бер кечкенә генә сынык ләчтә арыш ипие белән бер савыт аш китереп ашаттылар. Ул әз генә калкынып, терсәгенә таянмакчы булган иде дә, барып чыкмады. Кулларын йөртү бик кыен икән, кашык та тота алмый. Тагын санитар кыз кулыннан туенырга туры килде. Бу ыскырт әче, тәмсез ашны шулай да яратып ашады ул. Ачыккан организм барын да кабул итә икән. Аштан соң, җылы тир белән изрәгәндәй булып, тагын онытылды. Әмма монысы йокы иде инде. Һәм шунда ук әллә нинди хәтәр төшләр: әшәке үкереп килә торган танклар, болганчык күл, сызгырып бомба коелу һәм быкырдыктан күтәрелгән кара бүрәнкәләр аны саташтыра башлады. Озак та үтмәде кебек, ул яңадан күзләрен ачты. Аның янына әлеге купшы чәчле хатын килеп утырды.

— Менә яхшы булды, — диде ул, балаларны мактаганча, елмаеп.— Ашап та, йоклап та алдыгыз. Чыраегызга яшәү сөмсерләре дә чыга башлады. Сез көнләп түгел, сәгатьләп рәтләнә барасыз!

— Рәхмәт сезгә, — диде яралы, сүрән генә көлемсерәгәндәй итеп.

— Ә мин сезне, әгәр ялгышмасам, элек тә күргәнем бар. Хәтерлим... Тик менә исемегезне генә исемә төшерә алмыйм әле. Сез... — Хатын врачның башлаган сүзе киселеп калды. Ишектә яңадан фельдфебель күренде. Аның күзләре очлы иде. Чөнки ул һәрвакыт үзен уяу тота: «Бу руськиларның күтмәгәндә әшәкелек эшләве мөмкин», — дип уйлый иде. Моңарчы аңына килә алмаган яралының бүген ачык булган күзләрен дә бик тиз күреп алды. Һәм шунда ук ярсу тавыш белән:

— Фамилия? — дип кычкырып та җибәрде.

Әле генә кояш нурына сокланган, яңадан яшәргә теләгән авыруның күз аллары кинәт дөм-караңгы булып калды, сөмсерле чыраен суык кургаш болыты басты һәм күзләре йомылды.

— Фамилия?! — дигән дәһшәтле сорау тагын кабатланды. Шактый озакка сузылган паузадан соң гына, башын читкә борып:

— Гумеров... — диде яралы, бөтенләй ят кеше тавышы белән.

— Һумияровф? — дип сорады фельдфебель аңламыйча.

Ләкин кабат җавап килмәде. Яралы кеше яңадан аңын җуйган иде.

### III

Арыслан хәзер санитар түгел иде инде. Аны, башка әсирләр белән бергә, лагерь кухнясына утын ташырга җиктеләр. Алар көн саен таң тишегеннән олы тирес арбасына җигеләләр дә конвой белән урманга китәләр. Анда коры-сары утын хәзерләп арбага төягәч, тагын җигелеп, тартып алып кайталар. Тагын китәләр, тагын алып кайталар. Кухнялар шәп эшли. Әсирләргә кычыткан шулпасы гына түгел, немецларның мондагы вакытлы медпунктында булган үз яралыларына да һәм барлык персоналларына да ашлар пешерергә кирәк. Инде унбиш көн буе Арыслан ат абзарындагы үз почмагына караңгы төшкәч кенә кайта да балчык өстенә йомры усактан үзе әмәлләп печән түшәгән урынына егыла. Аның бау сыдырган җилкәләре әчетә, беләк һәм билләре сызлый, тез буыннары сулкылдап авырта иде. Ул аларны сыпыргалап карый, әчеткән һәм сызлаган җирләренә төкерек сөртеп, үзе урманнан алып кайткан үлән яфракларын ябыштырган була. «Үги ана», «аю табаны» һәм «куян колагы» яфракларының йомшак салкынчасы әз генә булса да тынычлык китергәндәй тоела. Шул сызлаулар басыла төшкәч, талчыккан гәүдә авыр гына ойый башлый һәм каты йокыга китә. Ә төшендә һәр көнне үзенең Ык буйларында йөри. Печән чаба, тал кисә, балалары белән куышып уйный. Ул хәзер һәр төнне, җиткерә алмастай булып, көтеп ала. Чөнки чын дөнья, чын тормыш шул төштә генәдер төсле, ә монысы бары тик авыр бер саташу, ниндидер сихерле пәри

базы булып кына күренә иде. Бүген дә ул, тизрәк йокыга китәргә теләп, караңгыда кармалана-кармалана урынына килеп ятты. Өйрәнелгән гадәте буенча, бисмилла әйтеп, иске чикмәнен бөркәнә генә башлаган иде, күршесендәге кичә бушаган урынга икенче кеше яткырганлыкларын күрде. Аның астында сайгак-фәлән юк, әз-мәз салам гына түшәлгән. Шуның өчен ул урын Арысланныкына караганда тәбәнәк булып тора. Стенага таба карап, аякларын җыеп, корышып яткан ул. Гәүдәгә таза түгелдер ахры, колаткасе малайларныкы шикелле генә тоела. Арыслан, көндәгечә сызланды-сыпыргаланды да бөтен ат абзары эчендә хөкем сөргән төрлечә гырлау, борын сызгыру, төштә сөйләшүләр һәм әчкелтем авыр тир, кер исләре эчендә, ниһаять, тынычланып, йокы рәхәтлегенә чума — оныта башлады. Шул татлы минутта гына яңа күршенең яшерен генә мышык-мышык сулкылдавы һәм нидер пышылдавы ишетелеп куйды. Арысланның йокысы ачылды, колакларын сагайта төште: кем икән, ник төн уртасында мышкылдап ята икән?.. Ә күршесе мөмкин кадәр үзенең бу аяныч халәтен яшерергә тырыша. Шулай да, үксүен тыя алмыйча, вакыт-вакыт йөрәге кычкырткандай: «Эһһәә» дигәләп куя. Аның яндырып агылган уйлары да сүз булып тышка чыга шикелле. Шуңа күрә үзе дә сизмәстән пышылдап ята булса кирәк. Колак салыбрак тыңласаң: «...Хурлык... хурлык... Бетте газиз башым... Ник үлмәдем... Кичер... кичер, илем... Кичер, Чулпаным... кызым, йөрәк валчыгым, ишетәсеңме син әтиеңне?.. Бар да бетте... Инде безгә күрешү булмас...» дигән өзек-өзек сүзләрен аңларга мөмкин иде.

Арысланның бүгенге йокысы баш аңгырайткыч кына булды. Көн буе ат хезмәтендә йөреп алҗыган гәүдәсе ял итә алмый калды гына түгел, һәр төнге матур төшләр дөньясы да үзенең серле чаршавын ачмады. Йокы аралаш әллә нинди саташулар, уйламаска тырышылган ачы уйлар яңадан килеп йөдәткәч, җәйге таңның беренче яктысы белән үк авыр гына торып утырды. Татлы йокысының тәмен җибәрүгә сәбәпче булган яңа күршесенә табигый буларак төксәреп күз төшерде. Ул таушалып беткән вак салам өстендә, противогаз капчыгын баш астына салып, пычракка каткан иске шинелен ябынган килеш чалкан ята, ачык изүеннән җилкә тирәсенең марля белән бәйләнгәнлеге күренә, кызарган күзләре абзар түшәмендәге нindidер билгесез нокталарга төбәлгән, ә керфек төпләре һаман яшәреп тора. Чырае ап-ак, ябык, хәлсез иде. Арыслан аны әрләмәкче булды: «Бигрәк сытык бәрәңге икәнсең, энекәш, күзләрең юеш җиргә утыртылган ахры; хатын-кыз шикелле балавыз сыгып, төн буе йокы бирмәдең; пленда алай сыек булырга ярамый!» — дип оялтмакчы иде, әмма күз тутырып карап торганнан соң бөтенләй икенче сүзләр әйтеп салды:

— Кара әле, якташ, мин сине таныйм лабаса, валлаһи таныйм! — диде ул. — Хәтереңдәме, син безгә, медсанбатка килгән иең?..

— Әйе, килгән идем шул, — диде күршесе гаепле кешедәй юаш кына. — Син инде борчыганым өчен гаеп итмә, туган. Әллә ничек бик авыр булды... Ир башың белән дошманның кулына эләк, имеш! Гарьләндем, үз-үземне кая куярга белмәдем. Бөтен газиз нәрсәләреңнән берьюлы мәхрүм булуның ачысы кинәт бәгырьгә төшеп, төн буе газапланырга мәҗбүр итте. Эх, үлеп тә булмады ичмаса, үлеп тә булмады!..

— Син көткәндә читтә калырмын, көтмәгәндә җаныңны алырмын, дигән шул әҗәл, — диде Арыслан. — Менә без дә шулай булдык. Теге вакытта капчык авызын томалап алдылар да безне дә килеп бастылар. Яралылар белән кайнашкан арада бер нәмәкәй эшли алмадык. Кулда корал да югые. Бөтен санбат — немес авызына туп-туры һап! Күпме яралы мескенне кырып бетерделәр. Аякка басканнар гына исән калды. Врачлардан, әнә үзең дә күргәнсеңдер, Филипп Михайлич белән Бардина гына күләгәдәй йөриләр. Калганнары төрлечә таралып бетте шунда. Бардина, мескен, бик биреште. Ак чәчләре дә күренә башлады. Үзе

әллә ниткән юаш, сүзсезгә әйләнде. Йорт песие шикелле гел Филипп Михайличкә сыенып кына тора.

— Ә ул картыгыз миңа да бик ошый сезнең. Теге вакытта да ут астыннан яралыларны үлемнән коткарды, хәзер әсирлектә дә шул ук постында икән.

— Әйе, бик батыр кеше ул безнең, — диде Арыслан горур тавыш белән. — Немес аны утынга җигә башлаганые, бирешмәде. Немеснең күкрәгенә баскандай, киерелеп каршына басты да: «Мин утыз биш ел буе хирург. Духтор медицина! — диде. — Минем эшем — яралыга ярдәм күрсәтү, хәзер дә шул эш булырга тиеш!» — диде. Җиңәлмәде шул немесең! «Цурюк!» — дип ырылдап кына калды. Тәки үз эшенә кереште карт.

Солдатның яңа күршесе эндәшмәде. Ул ниндидер авыр уйлар эчендә калды. Ниндидер тирән борчулар аңа тынычлык бирмиләр иде төсле. Арыслан аны сүз белән мавыктырырга теләгәндәй, үз хәлләрен тагын байтак кына сөйләде дә:

— Ә син ничегрәк эләктең, күрше? — дип сорады. — Дөрес, монда калган кешеләр хәзер ул хакта сөйләргә яратмыйлар, һәм ул соралмый да, сөйләнми дә... Мин әле тик болай, сүз юктан күрше итеп кенә дигәндәй, соравым иде.

— Юк, дус кеше, бер дә яшерен сере юк, — диде аның сүздәше. — Тик менә газапланам гына. Шул карт хирург шикелле, немец каршына күкрәк киереп баса алмадым... — Һәм ул үзенең «Чәчәкләр яланы»на керүен сөйләп бирде.

— Менәтерә бәй, — диде Арыслан шаккатып. — Соң болай булгач, иптәшкәем, синнән «ярты» тия бит: без табып алдык сине ул быкырлы күл читендәге бер бәләкәй атаудан.

Яралы гаҗәпләнеп күзләрен аңа төбәде.

— Шулаймени?..

— Шулай шул. Әйтәм җирле аны, пычракка чумып каткан килеш тә әллә кай төшең генә танышсыман тоелганые, тикмәгә булмаган икән!

— Әйт әле, дустым, ә хатын-кыз гәүдәсе табылмадымы анда?

— Юк шул, — диде Арыслан, — бер дә туры килмәде... Нигә, әллә бик сөйгән иптәшегез барыемы?

— Юк, — диде күршесе авыр сулап. — Эш — сөюдә түгел. Бик яхшы иптәш иде, үзебезнең Казаннан, Әлбидә исемле саф күңелле бер кыз иде. Шул хәтле кешелекле иде, шул хәтле матур җырлый иде, һич онытырлык түгел... Шундагы фаҗига эчендә һәлак булды микәнни бичаракай...

— Бер дә очратмадык шул, — дип кабатлады солдат.

Ишек алдында чаң суктылар һәм абзар капкасы авызыннан немец вахтманының яшел тавышы яңгырады. Абзар эче, дәррәү аякка басып, тышка агыла башлады. Арысланнарны эшкә куалар иде.

— Кара әле, дустым, — диде күршесе аңа. — Синең исем, фамилияң ничек соң? Нишләптер хәтердән чыккан, әллә сораганым юк иде микән моңарчы...

— Ник, Арыслан Алыпкулов инде мин, — дип җавап бирде солдат, чыгарга кузгалып.

— Ә минем фамилиям Гумеров, онытма, — диде күршесе.

— Һе, алай икән... Ник, санбатка килгәндә бүтәнчәрәгие түгелме соң?...

— Түгел, Гумеров. Син башка кеше белән саташтырасыңдыр!

Шулай бик очраклы рәвештә үлемнән котылган һәм Гумеровка әйләнеп киткән Мусаны эшкә куа башлауларына инде атна тулып узды. Ул әле тәмам савыгып та җитмәгән, җилкә һәм билендәге керле биләве дә алынмаган, аякларын иркен басып атларга хәле дә юк, көрәк белән каты кызыл балчыкны казырга җегәре дә җитми иде. Җиргә егылмас

өчен бөтен тән көчен җыеп, түземлек нервлары мондагы әшәкелеккә кинәт шартлап китмәсен өчен, бөтен рух көчен учына йомарлап йөрергә туры килә аңа. Ничек кенә булса да, алар хәзер көн саен Арыслан белән бергәләп таң иртәдән эшкә китәләр, кояш баеганда кайтып керәләр. Немецлар исә әсирләр өчен иң авыр эшләрне табып кына торалар. Хәзер аларга фронтның ерак тылында танк чокырлары, ут нокталары, артиллерия мәйданчыклары казыталар. Бу эш инде байтак вакытлардан бирле бара. Моны ничек аңларга соң? Нәрсә, әллә немецлар чигенергә җыеналармы, үкчә күтәрергә? Хәер, алай дип аңларга да нигез күренми. Аларның кәеф шәп, баш югары, көньяктагы һөҗүмнәре турында шапырыну җитәрлек. Күрәсең, һәртөрле очракка әзер булырга, язмышның көтелмәгән шаяруларын уяу каршыларга телиләр. Күрәсең, меңләгән әсир кычыткан шулпасын әрәм ашап ятмасын дип, аның актык җан суын шушы канаулар төбендә суырып калмакчы булалар.

Казу эшләре лагерьдан биш-алты чакрым читтә бара. Йөзләгән әсирне берничә немец конвоиры озатып йөри. Шуларның берсе салам чәчле, уңган зәңгәр ситса күзле, бармаксыз Һанс, урта яшьләрдә булуына карамастан, һәрвакыт шаянлыкны, кызык ясауны, туктаусыз авыз гармунында уйнауны ярата. Эш урынына алып килгәч, үз иллесенә «Арбайт!» дип кычкыра да, канау өстендәге чирәмгә ятып, җырларга тотына. Аннары авыз гармуны чината. Шул ук вакытта үз колларының ничек эшләвен күзәтергә дә өлгерә. Әгәр бер-ике әсир, озаграк утырып тәмәке тартса яки, сөйләшә торгач, эшен онытыбрак җибәрсә, Һанс алар янына, песи аяклары белән генә йомшак басып, һичбер ачуланмыйча, көлеп кенә килә дә, гамьсез утыручының яңагына чалт! итеп сугып җибәрә. Теге мескен артка тәгәри. Икенчеләренең аркаларында карабин түтәсе бии. Әсирләр аны «мәрхәмәтле Һанс» дип йөртәләр. Тагын берсе — аз гына чатанлап йөри торган ефрейтор. Бусы инде яр башына баса да көн буе катып тора, барын да күрә, гел кызулый, гел кычкыра; үзе ат атланып йөрмәсә дә, беләзегеннән кыска каеш камчы төшми һәм әсиргә карата бөтен хөкемне шул камчы чыгара. Монысының чын исемен белүче юк, «камчылы чатан» дип кенә йөртәләр. Эшкә барганда-кайтканда колоннаның башында һәм ахырында шул ике Газраил була.

Муса белән Арыслан колоннаның уртасынарак туры килергә тырышалар. Анда иркенләбрәк сөйләшеп атларга мөмкин. Әсирләрнең үзләреннән куелган сакчылар артык бәйләнүчән булмыйлар.

— Я, Арыслан дус, — диде Муса бер көнне, — барын да яхшылап уйладыңмы? Тирә-якны яхшылап күзәттеңме? Урман күләгәләре, куе яфрак аслары ни сөйлиләр?..

— Аларның сүзләре — кош җыры шикелле! — диде Арыслан. — Өндәп җырлыйлар, кызыктыргыч итеп серле генә шаулашалар. «Кил безнең күләгә кочагына, кил, бездә рәхәт!» дигәндәй, кул болгагансыман итенәләр. Ә мин аларга: «Тик бер өмет — кара август төне илтер мине шунда житәкләп!» — дип җавап кайтарам...

— Молодец, — дип елмайды Муса. — Син шактый шомардың хәзер. Зиһеннәрең ачылып китте...

Алар инде урман күләгәләренә, аның иксез-чиксез яшерен кочагына күптәннән бирле кызыгып, кол күзе белән тилмереп карый-карый йөриләр. Буйсынырга риза булмаган йөрәк ниндидер эчке көч белән шунда чакыра иде. Ничек соң шуны тормышка ашырырга?..

Кич кайтып, почмакларына урнашкач, Муса үз иптәшенә яңа бер шигырь укыды:

Кояш батты күптән, ә мин һаман —
Авыр уйлар тулы күңелдә,
Күз алмыйча күрше урманнардан
Басып торам ишегем төбендә.

Бу урманда, бәлки, партизаннар
Кичке ашка учак яккандыр.
«Бабакай»ның батыр егетләре
Разведкадан йөреп кайткандыр... —

дип башлады ул. Ә соңы инде:

Урман, урман, илт син мине шунда
Һәм корал бир минем кулыма!
Үләр идем аклап йөрәгемнең,
Керсез антын сугыш кырында... —

дип тәмамлана иде. Күңелләре тагын да әсәрләнеп киткән Арыслан бик озак итеп Мусага карап торды. Аның йөзендә шигырь дәрте белән дулкынлану һәм гаҗәпләнү чагыла иде:

— Кара әле, бәләкәчем, каян чыгып тора соң бу? — диде. — Әллә син... үзең чыгарасыңмы моны?.. Ник, Гаптулла Тукай мәрхүм барын да әйтә белгән бит, бүгенгедәй итеп әйтеп калдырган... Әллә, бәлкем, ихтимал, син үзең дә Тукайсымактыр...

— Ай-я-яй! — диде Муса көлемсерәп. — Бик югары үрмәләдең, түбәнрәк төш! Кая ул безгә!.. — Һәм кичке ярым караңгы абзарда ул аның колагына пышылдады: — Синнән яшереп булмый инде, дускай. Без бит бергә сәфәр чыгасы кешеләр. Әйе, мин боларны үзем язам...

— Тикмә булмас бу кеше, дигән ием аны, и һәм шулай булып чыкты да! — дип нәтиҗә ясады Арыслан.

## ДҮРТЕНЧЕ БАШЛАМ

### I

Биш-алты көннән соң, алар бер дә көтелмәгәндә үз теләкләренә ирештеләр. Тормышта кайчакта могҗиза булуына да ышанырга ярый торгандыр, ахры. Лагерьга берәр чакрым каларак, баштан баручы «мәрхәмәтле Һанс» килде дә, биш кешене колоннадан чыгарып, бер полицай белән урманга җибәрде. Алар бик яхшы каеннардан гына җыеп, «руськи себерке» алып кайтырга тиеш. Немецлар бүген «руськи мунча» керәчәкләр.

Муса белән Арыслан да шул төркемгә эләкте. Урман эченәрәк керү белән бер-берсенә карашуга, күзләре: «әйе», — диде. Зифа буйлы яшь каеннарның әле сусыллыгы бетмәгән ботакларын шырт-шырт сындырасындыра, алар читкәрәк юнәлделәр. Арттан килгән чакыру тавышларына икенче якка таба кычкырып җавап бирделәр, үзләре һаман эчкә ашыктылар. Инде кочакларындагы каен яфракларын да атып бәрделәр, ә Арыслан, ныграк тавыш чыгарыр өчен, коры нарат ботакларын сындыра иде.

Ниһаять, кычкыру тавышлары еракта калып, чак кына ишетелә-ишетелә, бөтенләй тынды. Бер мәртәбә мылтык аткан аваз яңгырады, ләкин кабатланмады. Кояш, агач башларына соңгы нурларын чәчеп, түбән тәгәри барды. Агач араларына озын һәм серле күләгәләр сузылды. Черкиләр патшалыгы, «чең-чең» кылыч кайрап, төнге сугышка кузгалды. Ә Муса белән Арыслан, сүрелеп бара торган кызгылт кояшны артка ташлабрак, һаман баралар иде...

Алар төн буе шул чама юнәлеш белән ашыга-ашыга атлауларында булдылар. Кечкенә күлләр, баткаклар туры килгәндә әйләнеп уздылар, сай инешләрне ерып яки йөзеп чыктылар. Алар ничек тә булса Волховка якынаерга телиләр иде.

Калын урман эчендә чама юнәлешен җуя башлаганда, таң беленеп ярдәмгә килде. Ләкин озакламый кояш күренүе аларның юлларын кисте. Куелыктан чыкмыйча, кояш белән чамалап алмаш-тилмәш ял иттеләр. Йокы туйдырганнан соң, Арыслан яланрак җирдән әйләнеп керде.

Күзәтү хәтәр-хәвеф сизелмәвен күрсәтте. Шул уңайдан ул үзе белгән тәмле үләннәр дә җыеп алып кайтты, шуның белән тамак туйдырдылар.

Качкынның язмышы һәрвакыт кыл өстендә. Уйламаганда гына тотылыр кебек тоела. Шуның өчен аның бөтен маңгае һәм баш артлары сак күзләр белән, бөтен гәүдәсе, хәтта кан тамырларына хәтле тиз ишетүчән, ләкин күзгә күренми торган сизгер колаклар белән тулган була. Кайдагыдыр наратның нәзек кенә бер коры ботагы җил белән сынып җиргә төшсә яки якын тирәдә бөтенләй күренмәгән усак яфрагы шул ук җил белән шыбырдап куйса, качкынның җаны уч төбенә поса. Кайдандыр, кемнәрдер, яшеренеп кенә атлый-атлый аларны камыйлар төсле тоела.

Муса белән Арыслан, шушы куркынуларның һәммәсен кичерә-кичерә атлап, һичбер авыл кешесе яки немец солдаты очратмыйча, өч тәүлек йөргәннән соң Волховның камышлы сөзәк ярына килеп чыктылар. Чама белән исәпләгәндә, моннан фронт сызыгы ерак булмаска тиеш, ләкин бу буйларда җәйге оборона «йокысы» һаман дәвам иткәнлектән, тирәяк бөтенләй гамьсезсыман күренгән бер тынлык эчендә ята иде. Ничек итеп Волховны кичү турында күп баш ваттылар. Елга артык киң булмаса да, барлы-юклы җегәр белән йөзеп чыгу мөмкинлеге икеле иде. Якын-тирәдән берәр нәрсә эзләштереп карарга булдылар.

Кичке эңгердә яр буен сак кына күзәтеп йөри торгач, камышлыктан аргырак куентыкта казыкларга бәйләнгән өч көймә күреп, күзләрен шулардан ала алмадылар. Ничек итеп кенә булса да берсен чишеп алырга кирәк иде. Караңгы төшәр-төшмәстә үк Муса камышлыкта чишенде дә кыяк араларыннан сиздерми генә йөзеп китте. Бер генә тапкыр да суны чапылдатмыйча, оста тынлык белән җай гына йөзеп барып, ике көймә арасына керде. Көймә күләгәләре аның тән аклыгы шәүләсен каплады. Сакта калган Арыслан Мусаның көймә тирәсендәге хәрәкәтен, тыны-көне беткәндәй, күзәтеп торды. Ә Муса, көймәнең чылбыры казыкка уратып кына куелганын күреп, хәзер генә ул көймәдә кемдер йөргән булуын аңлады. Чөнки хәтта ишкәкләре дә колаксаларыннан салдырылмаган килеш кенә көймә эченә төшерелгән иде. Муса, кабаланудан ярым калтыранган куллары белән көймәне тиз генә ычкындырып, көч белән эчкә таба этәрде. Үзе аның аргы кырыена сыенды да, бер кулы белән ипә-ипә, көймәне камышлыкка сөйрәде. Ниһаять, камышлык көймәне үз куенына яшерде, тотылу куркынычы шактый кимеде, хәтәр адым имин узды. Арыслан Мусаның киемнәрен алып, көймәгә керде. Муса исә арттан этәрә барды да, камышлыкның икенче читендәге ачык суга чыга башлагач, көймә эченә сикереп менде, тиз генә киенеп алды, төн салкынчасы аркасына шактый сизелерлек булып йөгерә иде. Бу ике качкынның күңеле тагын өмет белән тулды, йөрәкләре урыннарыннан кубардай булып тибә башлады. Ыкта үскән Арыслан ишкәкләрне шундый оста сала белә икән, хәтта алардан су тамганы да ишетелми иде. Түбәнгә төшү җиңел. Көймә уйнаклагандай гына шуып бара. Муса күзләре белән тишеп керердәй итеп караңгылыкка төбәлде. Алда борылышсыман урын барлыгы шәйләнә. Хәзергә һичбер шом-шаукым сизелми. Бар да яхшы, бар да имин. Шул борылышта теге ярга төртелсәләр, бик тә һәйбәт булачак. Анда камышлык күләгәсе дә бар кебек тоела иде. Бәхет менә-менә, уч төбендә шикелле генә күренә...

Суның үзәген кыеклаш кисеп, борылма кучкылына таба якыная башлаганнар гына иде, нәкъ шул авыкта култык артыннан шашкын тизлектә патруль катеры килеп чыкты да тирә-якны секунд эчендә прожектор белән болгап алды. Алга карап барган Мусаның күзләрен кинәт төшкән кискен яктылык сукырайткандай булды. Ул автомат тизлегендә көймә төбенә ауды. Арыслан да шунда ук капланды. Аждаһа күзе тагын чагылуга, катер тавышы бик якынайгансыман тоелды. Немецлар, зык кубып, «Һальт! Һальт! дип кычкырдылар да автоматтан

сиптереп алдылар. Аннары, җавап көтеп, күрәсең, беразга тынып тордылар. Ләкин су агымы белән үз җаена агып барган «буш» көймәдән нинди җавап килсен соң? Аның төбенә сузылган ике качкын бары тик аһ оралар гына иде: «Беттек... бар да бетте... Ник бу хәтле юк соң безнең бәхет?!!»

Катер, килеп җитүгә үк, көймәне үзенә эләктереп алды. Муса белән Арысланны, автомат астында сөйрәп, катерга ташладылар. Хәзер инде бу хәрәкәтләрне кесә фонаре гына яктырта иде.

— Рюсиш швайн! [1] — дип кизәнде Мусага бер немец. Бу сүзләрнең соңгысын әйткәндә аның авызы бик киң ачылып, өске тешләре җир кимерүче экскаватор чүмечен хәтерләткән кебек тоела иде. Катер кузгалды. Су өстендә нәрсә өчендер кат-кат борылгалап йөргәннән соң, түбәнгә юнәлеп, Муса белән Арысланны кечкенә бер яр буе пунктына ташлап уздылар.

## II

Алар элекке лагерьга кайтмау чарасын эзләделәр. Анда кайтарсалар, «Ник качтыгыз?» дип теңкәләренә тиячәкләрен һәм аяусыз җәзалаячакларын икесе дә яхшы аңлый иде. Өсләрендә әле үз киемнәре, немец искесе түгел, ә муеннарына каһәрле тамгадай асылган номерларны алар инде урман эчендә үк ыргытып калдырганнар иде. Шуңа күрә алар сүзне бер төрле йөртергә: «Камалышта калганнан соң күп көннәр урманда йөрдек, үзебезнең якка кайта идек, шунда тотылдык», — дияргә булдылар.

Һәм алар, кайда гына сорау алсалар да, шул җавапны бирделәр. Гади генә хәйлә уңышлы булып чыкты: аларның шыр сөяк аркаларында немец шомполлары бермә-бер кимрәк уйнады... Һаман эчкәрерәк озата торгач, аларны җәяүле колонна белән Новгород аша уздырып, Северская станциясендәге лагерьга китерделәр. Бу лагерь җыю-туплау пункты булганлыктан, мондагы әсирләр әледән-әле төрле якларга этап белән җибәрелә тора иде. Дүрт көннән соң Муса белән Арыслан да сигез йөз кешелек колонна сафында юлга чыктылар. Аларны август урталарының коры һәм эссе көннәре буена бер караңгыдан икенче караңгыга хәтле җәяү атлаттылар. Муса белән Арыслан колоннаның уртасынарак туры килеп, тагын ике рус кешесе белән бергә, дүртәүләп бардылар. Төннәрен аларны төрле сарай, склад биналары яки ачык һавадагы чәнечкеле киртәләр эченә тутырып, ике-өч сәгать ял итәргә бирмәделәр, таң беленүгә тагын әйдәргә тотындылар. Болай да мәрхәмәтлелектә гаепләү мөмкин булмаган немецлар тагын да аяусызрак булырга тырышалар иде, күрәсең. Иртән кузгалганда бер тапкыр бирелгән баланда белән әсирләр көн буе атлыйлар. Ул көнне башкача ризык заты күрү түгел, сусаудан авыз читләренә тузанлы соры күбекләр каткан колонна кешеләрен су эчәргә дә туктатмыйлар иде. Өч көннән соң кешеләр шактый күпләп сафтан чыга башлады. Беришеләре ачлыктан йончып егыла да, аларны, күнегелгән гадәт буенча, атып кына китәләр. Икенчеләре исә, сазлык-фәлән узганда тәгәрмәч эзләрендәге кортлы суларны бер генә уч булса да йотып калырга тырыша һәм, озак та үтми, эчен тотып бөгәрләнә дә читкә тәгәри. Боларның да язмышы шул беренчеләрнеке шикелле үк «ансат» хәл кылына. Колонна сафыннан төшүчеләрне атып калдыру немецларның уставында язылган мораль кагыйдә иде, күрәсең. Һәм немецлар аны бик төгәллек белән үтиләр иде.

Әле комлык, әле сазлык, әле чуерташ юллардан ялан аяк атлап бара торгач, бишенче тәүлектә Мусаның хәле житди рәвештә авырлашып китте. Аның аяклары иртәнге уңайда тездән алып, ә кичкә таба бот

[1] Дуңгыз урыс!

төпләреннән үк сөм тоймас булып, атлаганда сөйрәлә башлады. Аның әле яралары да һаман бикләнеп җитмәгән иде. Шул яралар, бигрәк тә билендәгесе, хәрәкәт нервларына зарар китердеме, әллә сырт сөяге эчендәге үзәк нервларга тәэсир иттеме, Мусаның аяклары акыл кушканны, гомуми организм биргән боерыкны тыңламас булды. Алга таба атлауның һич аяусыз мәҗбүрилеге билгеле иде, атламасаң колоннадан бер утын агачыдай төшеп калачагың һәм актык сулышың бер автомат төкереге белән чикләнәчәге дә көн кебек ачык иде. Әмма Муса шул куркыныч астында да аякларын хәрәкәткә мәҗбүр итә алмады. Аңа хәзер дөнья бер бушлык булып, яшәү — мәгънәсез һәм һич кадерсез нәрсә булып күренә башлады. Баштарак Арыслан аны култыклап барды. Ләкин Муса аякларының сөмсезләнүе тагын да көчәю сәбәпле, олы гәүдәле Арысланның да аны әйдәргә көче җитмәс булды; ул манма тиргә батты, пешеп чыкты. Моны күзәтеп килгән Вася исемле рус егете, сул яктан ярдәмгә килеп, Мусаның беләген җилкәсенә салды да кулы белән аның биленнән уратып алды. Арыслан да шулай итте. Хәзер Мусага җиңелрәк тоелса да, Арыслан белән Вася, чамасыз эсседә бишалты чакрым атлауга, тәмам хәлдән тайдылар. Чөнки Мусаның аяклары хәзер бөтенләй йөрми, тагып куйган утын агачлары шикелле җансыз сөйрәләләр генә, иптәшләре исә аны чын мәгънәсендә күтәреп баралар иде. Аларның җәфа чигүләрен бик яхшы күреп, үзенең шундый имгәк хәлендә калуына чамасыз газапланып килгән Муса, ниһаять, түзмәде:

— Булмый инде, иптәшләр, — диде. — Бик рәхмәт сезгә. Бер үләксә өчен яңадан ике кешенең сафтан чыгуы — мәгънәсез. Саклагыз үзегезне, чын йөрәктән әйтәм! Калдырыгыз мине... Язмыш шулдыр...

— Син, бәләкәчем, алай сөйләнмә, яме! — диде Арыслан ачуланган төс белән. — Мин сине ничек ташлап калдырыйм ди? Нинди иманым белән? Менә Вася да шуны әйтер. Ул урыс кешесе булып та, «татар» дип тормады бит әле, үзе килеп ярдәмгә кереште. Ул да сине ташлар дисеңме? Юк, апаем, без бит бер ил солдатлары лабаса!..

Алар Мусаны тагын күтәреп киттеләр. Көннең икенче яртысындагы хәрәкәт ач һәм әйтеп бетергесез сусаган әсирләр өчен тагын да әллә ничә рәт авырайды. Адәм түземенең соңгы чигенә җителгән шикелле тоелды. Юл читендә кул сузып өзәрдәй яфракмы, иелеп алырдай су тамчысымы — берсе дә калмады, тик ярдәм генә итмәде. Арыслан белән Васяның күз алдында артык көчәнүдән килеп туган вак йолдызлар, тычкан утлары уйный башлады. Үзләре, муеннарына авыр таш аскан төсле, һаман сыгыла, һаман түбәнгә таба бөкерәя бардылар, колоннаның уртасыннан әкрен-әкрен койрыкка таба калдылар. Мусаның сөмсез аяклары җирдән бөтенләй сөйрәлеп бара иде инде... Аны вөҗдан газабы изде: ни өчен ул кадерле иптәшләрен шулай җәфалый?.. Алар бит болай да интегүнең чигенә җиткәннәр инде. Кабат интектерүнең нинди мәгънәсе бар? Иртәме, соңмы — барыбер нокта куелачак!..

— Бәхил булыгыз, газизләрем! — диде ул хәлсез тавыш белән. — Тагын бер тапкыр рәхмәт! — Һәм Арыслан белән Вася муенындагы кулларын ычкындырды да, бөтен гәүдәсе белән җиргә салынып төшеп, юл читенәрәк сузылды. — Зинһар колоннадан чыкмагыз, өчебезне дә бетерәчәкләр... Мин сезнең һәлакәтне дә кабул итә алмыйм. Хушыгыз!.. Илгә сәлам сөйләгез!..

Арыслан белән Вася, күзләрен мөлдерәтеп, башларын чайкый-чайкый, соңгы бер секунд карап тордылар да, аяусыз мәҗбүрияткә буйсынарак, колонна агымы ияртеп китүгә каршылык күрсәтмәделәр. Муса, тапталудан сагаеп, читкәрәк шуышты. Ул, үләргә әзерләнсә дә, яшәү инстинкты белән хәрәкәтләнә иде әле. Соңгы сулыш килеп җиткәнче дөнья яктысына, күктәге зәңгәр матурлыкка карап ятырга теләде ул. Андагы нур тулы көчле якты аның күзләрен чагылдырса да, керфекләре йомылмады. Туйганчы карап калырга кирәк.

Уйлары яшен тизлегендә Чулпанына, Әминәсенә барып тоташты. «Бәхил булыгыз, күз нурларым», — диде кыймылдамас телләре белән. Ниндидер арыган, алҗыган көтүне хәтерләткән колонна, башлары түбән иелгән һәм, җилкә почмаклары гына түгел, гомумән бөтен гәүдәләре салынып төшкән, арык кешеләре белән, авыр гына сөйрәлеп узып китте. Муса, соңгы сулышын өзеп аласы Газраилне көтеп, тын да тартмый ята иде. Ач күзле, ыржайган тешле һәм гөрзеле Газраил урынына, тәбәнәк кенә буйлы, чандыр гәүдәле, кипкән йөзле һәм салынкы мыеклы бер карт солдат — колонна артыннан атлаучы немец конвоиры — килеп җитте.

— Стафай! — дип кычкырды ул, Мусага автоматын төзәп.

Муса бу тавышка игътибар итмәде. Аңа барыбер иде. Аның сыгылган лимон кабыгыдай буш һәм сары йөзенә текәлгән немец дөнья белән алыш-бирешен өзгән кешедәге актыккы тәвәккәллек билгеләрен күрде. Муса уң кулы белән аякларына күрсәтте. «Йөрмиләр, тора алмыйм»,— диде, янәсе. Аннары баш бармагы белән йөрәгенә төртеп күрсәтте дә автоматка ымлады, тагын йөрәгенә төртте: «Ат, йөрәккә ат, тиз бетсен!» дип әйтүе иде ул.

Мусаның гаҗәбенә каршы, немец атмады. Башын чайкап торды да нәрсәдер мыгырданып артка карады, нидер көтеп калды. Бераздан соң җигүле ике ат килеп туктады. Берсенә конвойчыларның шинель, ранец, азык-төлек шикелле нәрсәләре төялгән; икенчесенә өч балалы овчарка эте бик матур каеш читлеккә, йомшак печән эченә генә утыртылган иде. Дилбегә тотып килүче аксак рус картына әлеге немец нидер әйтте. Ул кеше кайбер әйберләрне этләр арбасына күчерде дә бушаган урынга Мусаны китереп салды, күтәрергә немец үзе дә булышкалаган булды. Һәм алар китеп бардылар. Көтелмәгәндә мондый хәл килеп чыгуын Муса һич кенә дә аңлый алмады. Ничек соң бу? Каян килеп чыкты мондый мәрхәмәтле карт? Бәлки, бөтен Германиядә актыккы немецтыр бу? Бүтән булмас...

Аның уйлары еракка китте: әйе, без немецларны ихтирам итә, хәтта ярата идек. Немец пролетариаты — иң алдынгы! — дип ышана идек, әллә нинди зур өметләр баглый идек аңа. Рейхстагка сайлаганда компартиянең әллә ничәшәр миллион тавыш алган чаклары да булды түгелме соң? Әле сугыш башлангач та, Гитлер куган ирексезләр, дип уйладык. Пачкалап-пачкалап безнең якка әсир чыгарлар дип тордык... Ә карасаң, Гитлер ул немецларның сөяк чүлмәкләрен бөтенләй икенче якка борып утыртырга өлгергән икән инде! Хәзер алар дөньяга күзләре белән түгел, баш артлары, муеннары белән генә карыйлар. Бу немец — соңгы могикандай адашып калган бер заттыр, үзенең «иске» гуманизмы белән бергә үләргә тиешле бичарадыр... Ихтимал, шунлыктан гына яхшылык итеп маташадыр ул. Хәер, яхшылык эшләгәч, ничек булса да, рәхмәт инде. Тик аның яхшылыгы — бакчаны боз суккач яуган җылы яңгырны хәтерләтә. Ул аякларың йөрмәгәч, тере калуның ни хаҗәте бар?.. Барыбер монысы атмаса, икенчесе атачак бит! Әсирлектә имгәк кемгә кирәк?..

Муса шундый сәер һәм ачы уйлар белән олау арбасында дыңгырдап барды.

## III

Җиденче тәүлектә аларны Двина елгасының Латвия җирендәге ярына китереп туктаттылар. Ташу җәелә торган комлы болын өсте кыяк, ат кузгалагы, тукранбаш, әнис, каз печәне шикелле һәртөрле гади үләннәр белән капланып, чәчәк кою дәверен уздыра иде. Бу болын бер канаты белән еракка сузылып китә дә хутор булып яшәүче җирле халыкның басу киртәләренә барып терәлә. Икенче канаты исә, су буеннан

ук текә яр ясый, кинәт өскә калка. Ул калкулыкның алгы планында, агач моржалы һава юллары белән, тәбәнәк кенә, озын чирәм түбәле берничә яшелчә базы тезелеп китә. Әйләнә-тирәсенә киң итеп бер генә кат чәнечкеле чыбык тотылган. Җиде тәүлек эчендә өч йөзләп кешесен югалткан, тәмам соңгы чиккә җитеп әлсерәгән колоннаны хайваннар урынына шушы ачык абзарга китереп яптылар. Колонна артыннан әлеге арбада ятып барган Муса күзләреннән күпме асыл егетләрнең тәгәрәп яткан үле гәүдәләре читтә кала алмады. Баштарак ул аларны хәтта санап, хәтеренә беркетеп барды. Ләкин тора-бара, йөрәк әрнүенә, күзенә тыгылган яшьләргә түзә алмыйча, исәбен югалтты. Кемнәр генә санап бетерер боларны? Кемнәр исәбенә чыгар?.. Ул үзе дә шуларның берсе булачак. Ачлык белән мәрхәмәтсезлек — немецның автомат шикелле үк ышанычлы коралы. Ачлык белән рус солдатының көчен, гайрәтен сындыра, иреккә омтылучы канатларын каерып ташлый. Кансыз мәрхәмәтсезлек белән әсир күңеленә курку сала. Шушы ике кадак аңа әсирне коллык баганасына беркетеп куярга һәм шунда интектереп үтерергә ярдәм итә. Муса да шул багана төбендә черерме? Аларның беренче омтылышы барып чыкмады. Ә хәзер инде, аяклары аның иркеннән бөтенләй баш тарткач, нәрсә көткәне билгеле. Чебен үлеме белән юкка чыгу никадәр үкенечле булачак... Шуның өчен яшәдеме ул якты дөньяда?..

Мусаны әсирләр күтәреп, шул мәйдан уртасына кертеп ташладылар. Алданрак килгәннәр бәрәңге базларына урнашып өлгергәннәр, сыймаганнары исә турыдан-туры ачык һавада — үлән өстендә яталар иде. Озакламый Муса үзенең Арыслан дустын күреп алды һәм эндәшеп янына китерде.

— Туганкаем! Бавыркаем! — дип кычкырды Арыслан исе-акылы китеп. — Дөрес күрәме минем күзләр, бу синең өрәгең генә түгелме? Ничек исән калдың? — дип, кат-кат сораштырды ул. Янына утырып, кайгырту тулы күзләре белән Муса өстенә карады, тагын әлләниләр әйтеп юатырдай булды.

— Атмады бит арттан килүче немец, — диде Муса. — Әллә ниткән җан булып чыкты, хәтта арбага салдырып алып килде...

— Кара син аны! Алар арасында да кеше дип әйтердәй бер нәмә табылган икән, — дип гаҗәпләнде Арыслан. Аннары ул, үзенең барлы-юклы сәләмәсен алып килеп, Муса янына урнашты. Тирә-яктагы үләннәрне йолкып, печән җыйды.

— Астыбызга түшәк булыр, апаем-энекәем.

Башкалар да үз хәлләрен кайгырта башладылар. Әле генә ямь-яшел үлән булган лагерь эче, бер-ике сәгатьтән соң, ярым такыр комлык төсенә керде. Кичке якта бу лагерьга тагын зур бер төркем әсирләр китерелде. Алар арасында грузин, әрмән, азербайҗан һәм башка тау халыклары күбрәк иде. Болар да үзләренә баш төртер урын кайгыртырга керештеләр. Мусалар янында калган буш урынга озын буйлы, куе кара чәчле ике әрмән кешесе килеп урнашты. Әрмән халкына хас гади, сүзчән табигатьле булган бу егетләр күршеләре белән тиз аралашырга, тату булышырга тырыштылар. Иң элек үз хәлләрен кыска гына сөйләп биргәч, Муса белән Арысланның да хәлен, каян килүләрен сораштылар. Шулай танышып алгач, Муса аларда ниндидер гади иптәшлек сизгәндәй булды. Бу егетләрнең каяндыр төшергән ике сигареты бар икән, шуның берсен Муса белән Арысланга тәкъдим иттеләр. Ә мондый кыйммәтле деликатеска кимендә бер паек немец икмәге табып була иде!

— Рәхмәт, дуслар, — диде Муса. — Без икебез дә тартмыйбыз.

— Чынлап та, — диде әрмәннәрнең берсе, — ул бәладән безгә дә котыласы иде! Без моңарчы көн аралаш бер паегыбызны тәмәкегә бирәбез...

— Һәй-й, — дип сузды икенчесе, — ул юанычың да булмаса, кайгыңа тончыгып үләрсең монда!..

Бу сөйләшүләр арасында Арыслан «хуҗалык» йомышлары белән каядыр йөргәләп кайтты. Берсендә бер кочак иске салам күтәреп, икенчесендә бер дистәгә якын кояшта пәҗегән бәрәңге табып килде. Өченче әйләнешендә әлеге Вася дустын һәм тагын бер егетне ияртеп кайтты. Бусының Миңгали исемле танышы булуын әйтте.

Муса, утырган килеш куллары белән җиргә таянып, хәрәкәтсез аякларын гәүдәсе белән сөйрәтеп алды да Арыслан җыеп түшәгән печән өстенәрәк менеп ятты. Янында ук ул табып биргән ике кәкре таяк та ята иде. Әрмән егетләренең берсе боларның барсын да күзәтеп торды да:

— Нәрсә, авырыйсыз мәллә сез? — дип сорап куйды. Аның сөйләме яхшы ук шәһәрчә булып, таулыларга хас акценты да сизелми иде.

— Шулайрак шул, — диде Муса. — Юлда биш тәүлек җәяү килгәннән соң, аяклар алынды. Билдән түбән икесе дә һичнәрсә тоймый, хәрәкәткә буйсынмый, әллә нәрсә булды.

Әрмән егете, сүз эндәшмичә, Мусаның аякларын капшап карады. Тез тирәләрен, бот һәм балтыр итләрен кыскалап: «Авыртамы?» — дип сорады. Мусаның җавапларыннан соң «һем...» — дип, башын чайкап куйды.

— Болай гына белү кыен инде аны, әлбәттә, — диде аннары. — «Клиника» бик шәптән түгел, кирәкле приборлар җитешми... Үзәк нерв системасында берәр хәл бардыр... Шулай да сез менә бу даруны эчеп карагыз әле... — Әрмән егетенең моңарчы башкалар күзенә чалынмый да калган кечкенә генә бер санитар сумкасы бар икән. Бу брезент сумка, тотылган мамык һәм бинтлар тутырылганлыктан, колак мендәредәй генә булып, бүксәсен кабартып тора иде. Төбендә, шыштырдавык пергамент кәгазьләренә төрелеп, өсләренә латинча «аспирин», «бесалол», «хинин» һ. б. лар дип язылган дарулар да бар икән. Шулар арасыннан актарып, әрмән егете бер кечкенә капны Мусага бирде, анда унлап ак таблетка бар иде. — Иртәсен һәм кичен эчеп карагыз... Аннары, тагын бер әйбәт дару бар. Менә бу якындагы урманда нарат җиләге яфрагы булырга тиеш; әгәр менә шул яфракны җыеп кайтып, кайнатып суын эчү мөмкин булса иде, сезнең аяклар, һичшиксез, тиздән рәтләнер иделәр. Халык медицинасы тапкан дару.

— Әгәрең ки эшкә чыгара калсалар, ул яфракны җыеп алып кайтам мин! — диде Арыслан. — Аны безнең якта да эчәләр. Сез әллә врач буласызмы, якташ?

— Шулайрак, — дип җавап бирде әрмән егете. — Ләкин практика аз әле, ике генә ел эшләп калдым.

— Ничава, моннан әйләнеп кайтканчы прафисыр булырсың әле! — дип елмайды Арыслан. — Утны-суны кичеп, бакыр торбаларны үтеп, дигәндәй...

Шулай сөйләшә торгач, тагын да якынаебрак киттеләр. Врач — Тулиян исемле, ә иптәше — Бабаян икән. Муса белән Арыслан да, Миңгали белән Вася да үз фамилияләрен әйттеләр. Ләкин шунысы сәер иде: Муса да, врач та, ялган фамилия әйтеп, бер-берен алдадылар һәм шуны ниндидер яшерен тойгылары белән үзләре дә сизәләр, хәтта алдашуларын белеп торалар, ә шулай да ышанышкан булып күренәләр иде. «Менә бит нинди көннәргә калдык, — дип уйлады Муса. — Янында яткан һәм сиңа ярдәм иткән иптәшеңә дә чын фамилияңне әйтергә куркасың. Ул да синнән курка. Күрәләтә торып алдашасың... Абау, нинди түбәнлек! Кешеме соң без хәзер?..»

Шул вакыт лагерьда ыгы-зыгы купты. Лагерь коменданты йөри икән, диделәр. Озакламый ул Мусалар яныннан да кычкырына-җикеренә узып китте. Әсирләр, аягүрә басып, җирдә яткан Мусаны каплап

калдылар. Мондый эшне алар хәзер һичбер аңлатусыз да беләләр. Чөнки авыру әсирне немец түрәсе күзеннән яшереп калуны һәрбер намуслы кеше үзенең табигый эше итеп саный иде. Арыслан үзе Мусаны яшерде, үзе лагерь комендантына карап катты. Аның хәтта күзләре акайды: «Я, ходаем, үзең сакла!» дип, эченнән генә тәңресенә дә ялварды ул. Чөнки аның каршыннан узучы немец — лейтенант Шпигель иде. Ул һаман да җиңнәрен сызганып йөри икән, тик беләкләренә тезелеп менгән сәгатьләр генә күренми. Ә тилгәннеке шикелле очлы күзләре әле дә әсирләрнең сул беләзекләрен капшап, сәгать эзли төсле күренә иде. Моны Арыслан аермачык сизде һәм кабаттан тетрәнеп китте. Шпигель шактый ераклашкач, иптәшләре янына чүгәли-чүгәли:

— Эзбир бу немец! — диде ул пышылдап. — Мин аны беләм... Капут командада эшләгәндә күрдем. Әгәрен ки ул лагерь башлыгы булса, иман кетмәгез... — Һәм Арыслан ул трофей бүресенең «сәгать» авында йөргән чакларын сөйләп бирде.

## IV

Иртәгесен әсирләрне таң яктысы белән эшкә кудылар. Алар үзләренең чәнечкеле читлекләрен тагын да ныгыта һәм киңәйтә башладылар. Лагерь почмаклары саен пулеметлы һәм автоматлы сакчылар өчен биек вышкалар үсеп чыкты. Бу лагерьга тоташтырып тагын әллә ничә бүлемтекле яңа читлекләр корылды. Аларның аргы башы ялан кырда ялгыз утырган бердәнбер карт тирәккә барып тоташты. Аның куе яфраклары астына немецлар үзләренә матур бер җыелма йорт китереп салдырдылар. Эшләнеп беткән блокларга яңа төркем әсирләр урнаша барды.

Арыслан, ничек итсә итте, бер-ике көннән соң урман командасына эләкте. Эчкәрәк кергән саен нарат җиләге яфракларын тизрәк өзгәләп, билен бау белән бәйләгән гимнастеркасы эченә тутыра барды. Кичен ул бик нык арып, җилкә белән бүрәнә ташу шикелле адәм түзмәслек авыр эштән бөтен гәүдәләре ватылып кайтса да, кулына бер котелок җылы чәй тотып, канәгать елмаюлы йөз белән Муса янына килеп басты.

— Менә, бәләкәчем, — диде, — сихәтлән. Таптым бит, кайнаттым. Эч, апаем... — Бу сүз аның бик яратып бәләкәй балаларга әйтә торган «энем», «гөлкәем» дигән мәгънәне аңлата иде.

Муса шул көннән бирле бу үлән суын өзлексез рәвештә диярлек әзләп-әзләп эчә башлады, таблеткаларны да капты. Алтынчы көндә аяклары сөм тоя башлап, чак кына хәрәкәткә килгәндәй булды. Муса йөзенә өмет чаткысы үрләде. Чынлап та, әллә яңадан яшәү киләме?..

Әмма бу үләнне җыеп кайнату һәм лагерьга алып керү Арыслан өчен көннән-көн авырлаша барды. Чөнки Шпигель үзенең кемлеген чыннан да бик тиз күрсәтергә тотынды. Ул, яраларын Рига госпиталендә төзәткәч, бу лагерьга комендант итеп җибәрелгән иде. Яңа эштә үзенне башта ук булдыклы итеп күрсәтү кирәклеге, әлбәттә, билгеле нәрсә. Шуңа күрә ул лагерьда «тимер тәртип» урнаштырды. Әсирләр лагерьдан бер генә вакыт чыгып, бер генә вакыт кайтып керергә, кергәндә бик нык тикшерелеп, тентеп кертелергә тиеш. Андый-мондый шикле әйбер табылса, гаепленең эшен шунда ук бетерергә; көндез әсир янына әсир килүне, төнлә тышка йөрүләрне тыярга. Душ кертүне айга бер тапкыр гына ясарга, эрзац икмәкне ике йөз илле грамнан йөз иллегә калдырырга һ. б. һ. б. лар.

Лагерь башлыгы керткән чараларның нәтиҗәсе тиз арада күренә дә башлады. Әсирләр көннән-көн ачка шешенә, көннән-көн күбрәк үлә бардылар. Лагерь эчендә булган үлән кыякларын, яфракларын гына түгел, тамырларына хәтле йолкып ашап бетерделәр, мәйдан шәрә ком-

лык булып калды. Эшкә чыккан кешеләр алып кайткан юкә яфраклары, әнис һәм көпшәләр, кыяк тамырлары теләсә кемгә тими торган иң кадерле ризыкка әйләнде. Адәм түзмәс ачлык үзенең фаҗигале хәлләрен дә тудыра торды. Бер яшь кенә рус егете эшкә чыккан җирендә күп итеп гөмбә ашап кайткан да, төн буе газапланып, үкереп чыкканнан соң, иртәгесен акылдан язды. Әйләнчек булган шикелле, күзе-башы тонып, төрле якка тулганып йөрде дә, «Мама! Мама!» — дип кычкыра-кычкыра, чәнечкеле чыбык киртәгә ташланды. Шунда ук автомат тырылдады һәм бичара егетнең җансыз гәүдәсе җиргә салынып төште... Бу вакыйгадан соң өч-дүрт көн дә узмагандыр, ике поляк белән ике белорусны кеше ашауда гаепләп, әлеге карт тирәкнең ботакларына, бөтен халык күз алдына асып куйдылар. Ә дөреслектә исә вакыйга бөтенләй икенче төрле булган. Мәетләрне чокырга ташуда эшләгән бу дүрт әсир күмәргә дип блоклардан чыгарылган үлекләр арасында яткан бер тере кешене күрәләр. Ныклабрак карасалар, ул үлеп җитмәгән кеше әлеге ике белорусның танышы Бровка дигән солдат була. Үлемнән коткару теләге белән бу дүрт кеше аны немецлар күзеннән сакланып кына үзләре торган баз почмагына яшерәләр, авызларыннан өзеп ризык бирәләр. Ләкин Бровка мантый алмый. Ике-өч көннән соң, базда бер кеше дә юк чакта, үлеп китә һәм аның йомшак итләрен кичкә кадәр күселәр кимергән була. Әлеге дүрт кеше, кичен эштән кайтуга бу хәлне күреп, бик аптырап калалар. Нәкъ шул вакытта Шпигельнең базлар буенча нәрсәдер искәнеп, ыжгырып йөргән чагы була. Монда килеп кергәч, үлеп яткан Бровканы һәм аның тәнендәге умырылган урынны күрә дә шушы ерткычлыкны уйлап чыгара. Бу коточкыч хәл таралганнан соң, бөтен лагерь тетрәнеп кала...

Лагерь саклаучы немецлар әсирләрнең ачлыкка интегүеннән, үзләрен яклардай хәлләре һәм хокуклары булмавыннан бүтәнчә кызык табалар иде: чәнечкеле чыбык аша берәр кишер яки чөгендер ыргыталар. Шул тирәдә булганнар, дәррәү шуңа ташланып, талаша һәм сугыша башлыйлар. Немецлар рәхәтләнеп авыз ерып, бот чабып көлеп торалар. Сөяк ташлап, эт сугыштыралармыни! Һәм шул чакта бу мескеннәр өстенә автомат уты сибәләр... Ә капка саклаучы «СС»ларның «кәмите» тагын да хәтәррәк: вакытыннан ике минут соңга калып капкадан керүче әсирнең корсагына кинәт кенә штык тыгып айкап алалар да:

— Шталинблют! [1] — дип, кычкырып көләргә тотыналар. Вәхшилек корбаны, җиргә сыгылып төшеп, җан бирә. Аны шул ук әсирләрдән чокырга озаттыралар. Мондый күңел ачулар өчен берәү дә беркем каршында да җавап бирми. Шпигель «сынлы сәнгать»не дә яратучы немец иде. Ул, лагерь уртасына багана утырттырып, зур фанер тактага бота-сатаклы юан таяк сурәте ясатты да астына: «Таяк — синең әфәндең, буйсынмасаң, теләгәнчә җәза бирер!» — дип яздырды. Кешеләр, ачлык җәфасы өстенә, мыскылланган намус газабыннан интегә башладылар.

Моңарчы һаман шат күңелле, һаман хәрәкәтчән булырга, иптәшләренә булышырга яраткан Арыслан да җил өрсә аварга торган былтыргы әрем сабагыдай шыр кибеп, ябыгып калды. Ул хәзер боек чырайлы һәм авыз эченнән генә нидер көйләп йөрүче моңлы бер кешегә әйләнде. Ык буйлары, туган авылы турында да кабат күрү мөмкин булмаган ерак бер тылсымлы җир итеп кенә сөйли башлады. Күршедәге сүзчән әрмән егетләре дә, әүвәлге ачык чырайларын җуеп, бик нык салпайдылар. Һәр кеше, үз бармаклары белән казыган җир куышына, йомран шикелле качып, бөкшәеп утырырга ярата иде.

Ачлык һәм тоткынлык газаплары гына җитмәгән кебек, әсирләрне бет басты. Бет шул хәтле азды, кешеләрнең ач тәннәре өстендә генә урын тапмагансыман, комга таралып, мыжлап йөри башлады. Әз генә

---

[1] Сталин каны.

буш вакыты булганнар, өсләрендәге сәләмәләрен салып, бет үтерү белән мәшгуль иделәр. Ләкин аны болай гына бетерү мөмкин булмаганлыктан, таш белән кыру юлын уйлап чыгардылар. Арыслан да каяндыр юнәтеп, ике таш алып килде. Олырак яссысын җиргә куеп, күлмәген шуның өстенә салды да икенче ташның очлырак башы белән бетләрне шытыр-шытыр чүкергә кереште.

Муса бу эшне карап һәм өйрәнеп торды.

— Кая, бет машинаңны миңа да биреп тор әле, дускай, — дип көлгән булды ул. — Итем бетте, җелекләремне суыралар бугай инде...

Яннарындагы Василий да эчке күлмәген салып ташлап, ташка чират көтә иде.

— Карагыз әле, карагыз: алып китәләр бит! — дип кычкырды ул.

Күлмәк, чынлап та, кыймылдый иде... Бет үз эшен һаман эшли бирде: тәүлек саен дистәләп-дистәләп кеше тифтән кырыла иде.

Шушы авырлыкларга, шушы мәхрүмлекләргә үч иткәндәй, Мусаның аяклары әзләп-әзләп рәтләнә барды. Ул хәзер аягүрә басты, таякларга таянып атлый башлады. Таблеткалары күптән беткән булса да, Арыслан аңа нарат җиләге яфрагын ничек тә табып тора иде. Үзе чыга алмаса, башкалар аркылы кайтартты. Әмма шулай да Мусаның күңеле үсмәде. Киресенчә, аның рухын төшенке, төссез һәм канатсыз хисләр, пәрәвез оясы шикелле, кара җәтмә белән чорный бардылар. Калку җиргә корылган лагерьның чәнечкеләре аша Двина ярлары, тын гына бормаланып аккан кара-кучкыл сулары күренеп, үзенә чакыргандай булып ята иде. Муса һәр көнне ул суларга күзләрен талдырып карамыйча, каяндыр ерактан, туган ил эчләреннән килгән агымнар белән күңеленнән генә сөйләшмичә булдыра алмый, үзенең шушындый көчсез һәм аяныч хәлдә калуына исәпләгән саен исе китеп, кая ташланырга, нинди чара табарга белми иде.

Әйләнә-тирәсендәге шушы коточкыч һәм адәм акылы ирешмәстәй вәхшилек, меңләгән кешеләрнең шуны күтәрә алмыйча һәлак булуы, шул үлем чокырларында ятып калуы аның күңелендә көйдергеч нәфрәт белән бергә көч һәм чара юклыктан сыкрану уятты. Әйе, үч һәм нәфрәт чиксез, ләкин шул нәфрәтне корал итеп күтәреп, кайнар көрәшкә ташлану мөмкинлеге юк. Кайда, кем белән, нишли аласың? Өрәкләр ич, бүген-иртәгә юкка чыгасы күләгәләр, тиф үләтләре генә! Көрәшү мөмкинлеге булмагач, өмет һаман сүрелә, таң күгендә ялгыз калган ерак йолдыз шикелле, төссез бушлыкта эреп, күз алдында югала бара. Төнге кургаш болытлар төсле караңгы уйлар як-ягыңны кочып ала... Нинди оят!.. Анда туган ил кан эчендә коена, ә ул аның авыр язмышын уртаклаша алмый, анда Мусадан башка җиңәчәкләр, ул монда жир корты булып, бары тик бет белән сугышып, куышта ята. Әйтерсең лә, бик борынгы мәгарә кешесе!.. Ник соң теге карт немец атып үтермәде аны?.. «Тукта, алай ансат кына үлеп котылма әле, күр безнең кем икәнне!» дигәндер ул. Шуңа күрә, үтенүгә дә карамастан, атмый калдыргандыр. Һәм карт немец үз максатына ирешә: Муса хәзер барыбер кеше түгел, омтылыр идеалы һәм бернинди киләчәге булмаган күзле үләксә генә, заман һәм бушлык эчендә кирәкмәскә урын билəп ятучы бер мәхлук, әсир дигән сәяси үлек! Мондый гомернең нигә кирәге бар?..

Бу күңелсез һәм очына чыккысыз борчулы уйларыннан котылырга теләгәндәй, ул әрле-бирле йөренгәли, тагын урман һәм болын өсләренә, Двина буйларына карап ала. Әмма ул да юаныч китерми. Эчендә кайнаган кайгы-хәсрәт, сагыш һәм үкенеч утлары, таш стеналарны, тимер түбәләрне кубарып һавага омтылган янгын өермәсе төсле, соң дәрәҗәдә ярсып, тышка чыгуны, бушанып калуны сорый. Шуннан инде ул, чокыр кырыена утырып, сәләмәләренең яшерен кесәсеннән уч төбедәй генә дәфтәрен чыгара да аның белән сөйләшергә тотына. Уйлар, күз яшьләре шикелле яндырып, кәгазь өстенә түгелә бара.

Кая гына башым куйсам да,
Кайгы талый йөрәк итемне.
Кич ятсам да, иртә торсам да,
Әллә нәрсәм житми шикелле...

Мин кол монда, йортсыз-ирексез,
Ирексез һәм илсез — мин үксез...

Алтын иркем, азат тормышым,
Кая очтың киек кош булып?
Ник очмады соңгы сулышым,
Шунда бергә сиңа кушылып?..

...Двина, Двина!
Көчле агышыңны
Борып булса иде кирегә,
Җырым белән бергә бу гәүдәмне
Алып китәр идең илемә...

Бер үк төрле көннәр һәм төннәр, бер үк ачлык һәм үлем, бер үк төрле кансызлык һәм газаплар — һаман шулай дәвам итәләр. Тик һаваларга гына үзгәреш керде. Сентябрь башланып, төннәр шактый салкынайды. Балчык чокыр эчендә әз-мәз салам, печән заты булса да, тузган-каткан киемнәр эчендәге арык тән барыбер туңа, тизрәк таң атып, кояш чыгуын көтә-көтә калтырап бетәсең. Шпигель инде әллә кайчан ук: «Лагерь вакытлы, күчерү-аралану пункты», — дигән иде. Әмма һичбер үзгәреш күренми. Хәер, көн саен дистәләп, йөзләп теге дөньяга күчерә торалар ич... Ихтимал, шуны әйткәндер ул. Әгәр хәлләр һәнүз шулай сузылса, озакламый Мусага да «оҗмах нәүбәте» килеп җитүе бик мөмкин...

Төнге балчык суыгында каткан буыннарын коры юкагач сынган шикелле шарт-шорт китереп, Муса үз бармаклары белән казып кергән куышыннан көчкә чыкты да иртәнге сүрән кояшка йөзен куеп ятты. Шунда ук рәхәт булып китте. Лагерь читләренә чәнечкеле чыбык коймаының челтәрле күләгәләре төшкән, алар ниндидер гигант гәүдәле үрмәкүчнең кара җепләрдән корган куркыныч авы шикелле шомлы булып күренәләр. Битләренә һәм күкрәкләренә әз генә җылы йөгерү белән Мусаның күз алдына никтер кинәт кенә Әминәсе килде. Ул лагерь чыбыкларының тыш ягына баскан да, Чулпанны кул очларына ук күтәреп, әтисенә караткан. Чулпан исә, нечкә кулларын әтисенә таба озын итеп сузып, бик матур елмаеп тора. Бу рәхәт җылылык та, иртәнге кояштан түгел, Чулпан сулышыннан, аның шулай ягымлы көлеп торуыннан килә төсле. Баш калкытыбрак карасаң, Әминәнең үз йөзе дә күренгәндәй була. Ләкин ул көлми. Аның йөзе боек, моңсу һәм үпкәләгәнсыман тоела. Әле күңеле һаман язылмады микәнни соң?.. Шушыларга ялганып, Казан, матбугат йорты һәм Мәдинә шәүләсе дә күзенә чалынып узды... Һичнәрсә юк иде, бик нык ялгышты Әминәкәй. Юкка үзен дә, Мусаны да шулай үкенечле итеп калдырды... Хәер, болар турында уйлауның бер мәгънәсе дә юк инде хәзер. «Сак-сок дигән кошларның арасына тау үскән». Ут тавы. Чәнечкеле коймасы да бар. Алар җимерелеп юкка чыкканчы, Мусаны да кортлар кимереп бетергән булыр...

Кояшның һаман көчәя барган рәхәт нурлары аның күзләрен кытыклый башлады. Ул аларны йоммаска тырышты. Чөнки чыбыклардан югарыда әле һаман әтисенә кулларын сузган кызчыгы, аңа «әтие-ем!» дип эндәшкәндәй, елмаеп тора иде. Шул чагында бер дә көтелмәгән һәм бик сөенечле бер хәл булып алды. Каяндыр, якындагы урманнанмы, җиләс кырларданмы, әллә шушы Двина буеның ерактан күренгән матур болыннарыннанмы очып килеп, ниндидер сөйкемле бер кошчык һич курыкмастан чәнечкеле чыбыкларның иң өске каттагысына кунды да мөлаем бер тавыш белән сайрый башлады.

Муса белән Арыслан гына түгел, бу минутта лагерьда булган бик күп тоткыннар үзләренең әрләән куышларыннан чыктылар да чиксез гаҗәпләнү һәм сокланудан, сабый баладай, авызларын ачкан килеш шул нәни кошчыкка карап калдылар. Аһ, нинди могҗиза! Кайчаннан бирле аларның мондый гүзәллекне күргәннәре һәм ишеткәннәре юк иде. Нинди кошчык соң бу? Кай тарафлардан очып килгән? Әллә адашып килгәнме, әллә юри белеп килгәнме?.. Әллә, карасаң күз җитмәс еракларда калган газиз туган җирләрдән, сөйгән ярлардан, күз нурыдай балалардан килгән сагынычлы сәламме соң бу?

Исемсез кошчык үзенең беркатлы матур моңын һаман түгелдерә бирде. Ә югарыга, шул кошчыкка карап калган тоткыннарның күз төпләреннән кайнар яшь тамчылары битләре буйлап яндырып тәгәри иде. Алар бу яшьләрен яшерергә дә, сөртеп алырга да оныттылар. Чөнки һәркем шушы кошчык җыры белән үзенең сандугачлы әрәмәләренә, кәкүкле урманнарына, акчарлаклы күл буйларына, сабан тургайлы басуларына һәм иң мөкатдәс хатирәләренә китеп югалган иде.

Бу кошчык Мусага тагын Чулпан булып күренде. «Кызчыгым, син инде кошчыгым булып әверелдең. Миңа сәлам сөйләвендер инде бу. Минем рухымны күтәрергә теләвеңдер!..» — дип сөенде ул эченнән генә. Аннары бу кошчыкны үз янына чакырасы килде. Үзенең нинди көннәр кичерүен, горур җаны нинди мәсхәрәлекләр эчендә тапталуын, нинди кара язмыш тырнагында изелүен сөйләргә теләде. Юк, сөйләп кенә калмыйча, канатына хат бәйләп, туган якларга очырасы, андагы кешеләргә: «Без шундый-шундый җәһәннәм базында ятабыз, килегез тизрәк, коткарыгыз безне!» — дип әйтәсе килде. Әмма боларның берсе дә мөмкин түгеллеген, барысы да хыял гына булуын яхшы аңлый иде ул. Шуңа күрә, бик кечкенә, бик тыйнак соңгы теләге үтәлсә дә, чиксез канәгать булачак: сайрасын гына иде ул кошчык, озаграк сайрасын иде! Иртәгә дә, берсекөнгә дә килеп сайрасын иде!..

Кошчык, әлбәттә, икенче мәртәбә килмәде. Үзенчә шулай берәр минут сайраган булды да каядыр очып югалды. Әмма үзенең гаҗәеп җырын Муса дәфтәрендә калдырып китте. Төшкелектән соң, Муса аны Арыслан белән Миңгалигә укыды.

Син оч, кошчык, көчле җырым булып,  
Шушы сиңа соңгы теләгем.  
Тәнем калсын монда,  
(Нәрсә ул тән?)  
Барсын илгә минем йөрәгем... —

дип бетерде ул. Арыслан һаман башын түбән игән килеш, хәсрәтле чыраен үзгәртмичә, сүзсез утырды. Ниһаять, шактый вакыт узганнан соң гына:

— Бәхетле син, Муса бәләкәчем, — дип, тирән көрсенеп куйды. — Эчеңдәгеләрне җыр белән әйтеп бирәсең. Кошлар белән дә сөйләшә аласың. Үлеп барган йөрәкләргә кайнар сүзләрең белән утлар кабызасың!.. — Һәм ул, яу кырында аяк-куллары каты яраланып, берничә яраксыз һәм ярдәмсез калган солдатча авыр үксеп, бөтен түземлекләре сынган тавыш белән елап җибәрде. Иртәнге кошны тыңлаганда елавын иптәшләреннән бик оста яшерә белгән иде, бу юлы инде булмады, әллә күңеле артык нечкәреп калды, әллә шигырь шулай тәэсир итте: кайгы ташкыннары кинәт дулап агып киттеләр. Муса хафага төште. Ычкынмый ычкынган нык кешене тынычландыра белү ифрат кыен эш иде. Кайгыларга бирелмәүчән күренгән әз сүзле Мингали дә аны юатырга тырышты. Ярый әле, Арыслан молодец егет икән, үз-үзен кулга алып өлгерде һәм, сулкылдый-сулкылдый, сүзләрен ялгап җибәрде: — Бир син, миңа да бир бу шигырьләреңне, сигезенче туганым! Мин аларны иң изге догаларым шикелле итеп, юк, алай гына да түгел, күз карам шикелле итеп саклап йөртермен! Ә инде туган җирләргә исән йөреп сау

кайтсак, нибуч, төрлечә лыкылдаучылар булыр әле, менә шунда мин аларның бу җырларны күзләренә капалармын: «Мәгез, укыгыз, белегез безнеңниләр күргәнне, нинд әен тәмуг утларында кайнаганны! — дип әйтермен. — Барысы да менә шушы уч төбедәй кәгазьдә! Йөрәк каны белән язылган бу юллар! Бу безнең кер тимәгән Сәвитски пашпортыбыз!» диермен.

Муса аны кочаклап алды.

— Рәхмәт, дускай, син минем иң якын иптәшем, ничә тапкыр үлемнән алып калган чын туганым, — диде. — Синең яхшылыкларыңны мәңге онытмам!.. Ләкин, ай-һай, Арыслан бәгырем, туар микән ул кайту көннәре?.. Соңгы вакытларда күңелем бермә-бер төшенкеләнеп китте: шушы каһәр суккан Шпигель итеге безне дә таптап, шул котырган бетләре безне дә кимереп бетерер кебек тоела башлады. Белмим, чыга алырбызмы без бу җәһәннәм чокырыннан?

Алар бик озак сүзсез моңаеп утырдылар. Сентябрьнең кичкә борылган салкын кояшы инде бөтенләй диярлек җылытмый башлаган иде. Муса шинель сәләмәсен, астыннан алып, җилкәсенә салды.

— Бәлки бер котылырбыз әле... — диде, сабыр холыклы Миңгали.

— Бөтенләй үк кул селтәп бетермик әле дөньядан, — дип өстәде Арыслан да. — Ату эчтән җимерелсәк, сузылып ятып үләргә генә кала бит...

Шулай утырганда, лагерьның бу почмагында кешеләр хәрәкәте һәм ниндидер ыгы-зыгы барлыгы күзгә чалынды. Озакламый Шпигель үзенең берничә кешелек командасы белән әсирләр арасында йөргәне күренде. Шул яктан тыны-көне бетеп үз чокырына килгән Вася немецларның еврей эзләүләрен хәбәр итте. Муса хәтта көлеп куйды.

— Нинди еврей калсын бу җәһәннәм чокырында? Әллә кайчан атып бетергәннәрдер инде!

— Мин дә шулай уйлаган идем, — диде Василий. — Однако, берне тотып алып киткәннәрен үз күзем белән күрдем, бәрәңге базыннан тапканнар, имеш...

Бу хәбәр барысы өчен дә яңа һәм сәер булып тоелды. Чөнки, гадәттә әсирләрне беренче тапкыр җыеп сафка бастыргач та, иң элек яһүдләрне аерып, каядыр алып китәләр, тик аннан соң гына комиссар, коммунистларны чокчынырга тотыналар иде.

Буласы шомлы хәлне көтеп, кешеләр үз чокырларына таба елыштылар. Ул арада Шпигель үзенең «СС» өере белән Мусалар каршына килеп басты. Электән үк карасу чырайлы ике әрмән егетенең һәм Мусаның инде күпме вакытлардан бирле ачык һавада, җилдә, кояшта янып каралып беткән, ачлыктан кипкән борыннары тырпаеп, иякләре очлаеп калган йөзләренә шактый озак карап торды да мыскыллы усал көлү белән:

— Йуде, йуде, йуде! — дип, алар өстенә имән бармагын йөртеп чыкты ул. Янында торган «СС»чылар шунда ук бу өч кешегә ташландылар да җилтерәтеп ояларыннан суырып алдылар. Ләкин көтелмәгән каршылык килеп чыкты. Арыслан белән Миңгали һәм якында торган башка әсирләр, Мусаларны бирмәскә тырышып:

— Йуде түгел, татар, әрмән, — дип кычкыра башладылар.

Шпигельнең мондый каршылыкка ачуы килде.

— Цурюк! — дип кычкырды ул парабеллумын болгап. — Күрсәтермен мин сезгә әрмән! Чишендерегез үзләрен!

Ике әрмән егете үзләре үк чишенеп ташладылар. Шпигель, якын ук килеп, аларның гаурәтләрен карады да, сүзе дөрес чыкмаудан тешләрен шыкырдатып, кире чигенде.

— У-у, шварцһунд! [1] — дип ярсыды ул.

[1] Кара эт.

Мусаны ике «СС»чы чишендерде. Арыслан белән Вася, хәле китеп егылмасын дип, аның янында ук басып торалар иде. Хәзер инде Шпигель Муса каршына килеп басты, кулларын югары күтәртте. Һәм шырялангач калган бәләкәй генә гәүдәле, каршы килергә бер генә әмәле дә булмаган, кипкән яфрактай калтырап торган әсирнең гаурәтенә иң ятсыз рәвештә текәлеп караганнан соң:

— Ә-ә, син дә йуде түгелме? Ха-ха-ха! — дип, әллә нинди әшәке тавыш белән кычкырып җибәрде. «СС»лар Мусага ташланды. Әмма Шпигель сүзенә тагын каршы төштеләр:

— Юк, ул татар, мөселман! — дип кычкырды Арыслан түземсез тавыш белән. Шпигель аны кагып җибәрде. Арысланның күзләренә ут кабынгандай ялтырап китте. Ике кулы да йомарланган иде аның. Әрмән егетләре белән Вася да сүзгә кушылдылар.

— Әйе, ул татар кешесе, аларның дине шулай сөннәтле булуны куша, — дип, үзләренчә аңлатырга тырыштылар. Ләкин Шпигель моңа ышанмады. Әллә нәрсәләр әйтеп сүгенде дә Мусаны үзе йолкып алып, шәрә тән килеш комендатурага озаттырды.

Арыслан белән Тулиян аның ике култыгына килеп тотынды.

— Цурюк! — дип кычкырды немец. — Сезгә тагын ни кирәк?

— Йөри алмый ул, — диде Арыслан, тешен кысып.

— Йөрер! Йуделәр һәрвакыт симулянт! — һәм шашкан күзле Шпигель, кулындагы камчысы белән Мусаның как сөяккә калган нечкә сыйракларына чыжлатып китереп сукты. — Менә хәзер сикергәләп чабар ул!

Әмма Муса чаба алмады, аякларын кылыч кискәндәй, җиргә капланды. Иптәшләре аны күтәреп торгыздылар. Муса, дөньяга карамыйча, аскы иренен өзеп чыгарырдай итеп тешләгән иде.

— Илтегез! — дип кычкырды Шпигель һәм үзе алдан китеп барды. Мусаны комендатурага китереп керткәч, Тулиян белән Арыслан берберенә карашып алдылар. «Нишлибез? Харап итәләр бит», — ди иде аларның күзләре. Икесе дә тәвәккәл хәрәкәт белән немец каршына бастылар.

— Тимәгез! — диде Арыслан җан ачысы белән. — Ул минем братым, лутче мине атыгыз!..

— Һерр комендант, — дип немецча эндәште Тулиян. — Ул яһуд түгел — татарин. Мин медик кеше, яхшы беләм. Хаталык булмасын... Йөри алмавы да хак: үзәк нерв системасы осколок белән өлешчә зарарланган...

Шпигель һаман ышанмады.

— Ник йудене яклыйсыз? Үзегезне дә атам! — дип җикерде ул.

— Атыгыз, әмма дөресен әйтәбез, — диде Тулиян.

— Әһә, шулаймы, яхшы! Хәзер үк йуде белән бер чокырга китәчәксез, шәп булыр! — Һәм ул ике «СС»чыны каядыр йөгертеп җибәрде.

Озак та үтмәстән, алар киң олы битле, шактый ук кысык күзле һәм бәләкәй борынлы бер әсирне алып керделәр.

— Менә татарин нинди була! — дип үкерде Шпигель, ул әсирнең йөзенә күрсәтеп.

Почмакта көчкә терәлеп торган ялангач Муса, бу кешене күргәч шаккатып, аның йөзенә төбәлде. Бер генә секундка икеләнгәндәй булды, ләкин һич шик юк, бу — шул. Бу — аның белән бергә МГУда укыган дус казакъ егете Кучкарбаев иде. Һәм Муса, куанычыннан үз хәлен бөтенләй онытып, «Кучкарбай!» — дип кычкырып җибәрде. Сәет тә аны тиз танып алды һәм, кочагын җәеп:

— Ой-ба-яй, чырагым! — дигән тавыш белән аңа ташланды...

Сөенүеннән нишләргә белмәгән Арыслан: «Заген бит, заген бит»[1], — дип нидер кабатлый иде.

[1] Әйттем бит.

Үз этлеген итә алмый калган Шпигель камчысын шалт итеп өстәлгә сукты да:

— О, рюсиш швайн! [1] Бер-берен яклыйлар! Һераус! [2] — дип, дулый-дулый аларны куып чыгарды.

— Җәбри эзләп акылдан язган ач бүре! — диде Арыслан. Ә башкалар сүрән генә көлешеп алдылар.

...Муса үзенең бу җәһәннәм чокырыннан исән чыга алмаячагына тәмам ышанып җитте. Һич шөбһә юк, бүтән бик күпләр шикелле, ул да шушында калачак. Инде әле дә тән һәм җан нинди дер могҗиза белән түзеп килде. Арысланга, карт хирургка, Бардинага һәм тагын күпләргә рәхмәт. Алар бит аны үлгәннән терелтеп, яшәү бирделәр. Әгәр дә теге вакыттагы качуыннан котыла алган булса, икенче кат бирелгән бу яшәүнең бик матур мәгънәсе булыр иде. Ә хәзер — булмады инде. Булмады... Чулпанкай ятим калып, сыңар канатсыз булып үсәчәк...

Бу авыр кичерешләрен үз тирәсендәге иптәшләренә сөйләмәде ул. Нигә кирәк? Аларның да кәефен бозарга ярамый. Тик күптәнге тугры дусты Арысланга гына үз кулы белән язылган бер истәлек калдырасы килде. Ул аңа «Арыслан дуска» дигән кыска гына бер шигырь багышлады. Мондагы юлларда да шул ук бер нәрсәне, антына тугры булып, һәйбәт үлем белән үлүне, васыять итеп әйтте ул.

Илгә исән кайтып, искә алсаң
Әсирлектә үткән көннәрне,
Онытма, дус, синең белән икәү
Бергә елап, бергә көлгәнне.
Без серләшеп синең белән бергә
Җиңеләйтә идек кайгыны.
Авыр булыр, беләм, язмыш безне
Көтмәгәндә кинәт аеруы.
Бәхетең булып, бер көн илгә кайтсаң
Газиз әнкәң, әткәң янына,
Ә мин монда калсам кайталмыйча,
Азык булып җирнең карнына, —
Сөйлә минем якын дусларыма,
Сөйлә минем сөйгән халкыма:
Үлде, диеп, шагыйрь тоткынлыкта,
Тугры булып изге антына!..

Ләкин ул ялгышкан булып чыкты. Язмыш әле аңа дигән үлемне алай тиз генә әзерләп куймаган икән. Ул әле шагыйрьне әллә кайдагы еракларга ташлап, әллә нинди бормалы юллар гиздерергә, тагын әллә ниләр күрсәтергә, әллә нинди утларга салып сынарга уйлаган икән...

Октябрь башындагы көннәрнең берсендә үз хәлләре белән йөрердәй әсирләрне лагерь эченнән куып чыгарып, озын бер сафка тезделәр дә милләтләргә аера башладылар. Татар, башкорт, чуваш һәм удмуртларны, мариларны бер тирәгәрәк җыеп, кемнең Германиягә, кемнең Польшага җибәреләчәген әйттеләр. Әрмән, грузин, азербайҗаннарны да аерып алып, төрле җиргә билгеләделәр. Руслар арасыннан да бер команда туплап куйдылар. Шпигельнең күзләре бик кызган, төсе бозылган иде. «Кая ташып йөртәләр, шушында гына да кырып бетерер идем мин аларны!» — дип зарланган кыяфәтле иде ул.

Милләтләргә аерганнан соң, төркем-төркем душ кертеп, ун минутта юындырып чыгардылар, бетләрен дә кыздырып, сакал-мыекларын да кырып алдылар. Әсирләрнең барлык юньле-рәтле киемнәрен бу лагерьга килгәнче дә, һәм килгәч тә, әллә кайчан талап бетергәннәр иде инде. «Мунча» кертеп чыгаргач, аларның никадәр эленке-салынкы сәләмәгә төренгәнлекләре бигрәк тә ачык күренде. Җитмәсә, Германиягә китәсе төркемнәр бит әле алар. Һәртөрле Халыкара Кызыл Хач вәкил-

[1] Урыс дуңгызы.
[2] Чыгып китегез.

ләре кебек эшлексезләр дә күзәтеп калуы мөмкин. Шуларны уйлаптырмы, Остминистериум вәкиле Шпигельгә әсирләрне рәтләбрәк киендерергә кушты. Шпигель үз запасындагы «байлыкны» өләшергә тотынды. Мусага кара-яшел төстәге озын һәм киң бер шинель эләкте, Бельгия солдатыныкы булса кирәк. Ә катып, кәкрәеп беткән ботинкалары — берсе кырыклы, берсе кырык икеле булып чыкты. Мусаның гадәттә утыз сигезле ботинка кия торган аяклары өчен бу инде алаптай галош сөйрәгән шикелле иде. Җир себерә торган шул шинеле белән шушы ботинкаларын киеп җибәргәч, атлаган саен шинель итәгенә басып абына да башлагач, Муса бөтенләй адәм көлкесенә әйләнеп, кәмиткә охшап калды.

— Туктале, бәләкәчем, син бөтенләй пәри курчагы булгансың бит,— дип көлде Арыслан. — Теге, кинода көлдерә торган кем ие әле, Чапли Чарлин диләр иеме? Шуңар охшагансың бит. Кил әле, бас әле, рәтләп карыйк булмаса...

Һәм алар бер-берсенең киемнәрен тәртипкә китерергә тотындылар. Мусаның киң озын шинелен күтәреп, биленнән юкә бау белән буып карадылар. Ләкин алай барып чыкмады, түшәк тышыдай капчыкны уртасыннан буып куйган шикелле генә булды. Шуннан соң озын итәкнең артыгын кисеп ташларга уйладылар. Ә кайчы каян табарга? Кайчы түгел, пычак та юк иде. Баш вата торгач, аның да хәйләсе табылды: Муса үзенең алюминий кашыгы сабын ташка кайрый башлады һәм, озакламый, пычаксыман бер нәрсә килеп чыкты. Арыслан елмаеп куйды:

— Менә бит, булды. «Чынлап торып җыласаң, сукыр күздән дә яшь чыга», — дигән иптәш Сталин дип, доклад сөйлидерие бездә бер персидәтел. «Тутырыгыз заданҗене!» — дип, өстәл сугып та куя торганые. Дөрес әйткән икән, чыкты бит; кашык ие — пычак булды. Кирәк чакта баланда ашарлык та рәте бар...

Икесенең дә күптән көлгәннәре юк иде, аларга бу үзгәреш рух кертте, күрәсең. Шинель итәген шул пычак белән кисеп ташладылар да, сәдәпләр урынына агач шакмаклар ясап, нечкә тимер чыбык белән борып куйдылар. Арысланның үз киемнәре дә шундый ук осталык белән «адәм рәтенә» кертелде.

Бу бет базарыннан кузгалып чыгуга, Муса башта шулай җанланган дай булып, хәтта таякларын да атып бәргән иде, тик әчке Германиягә үк җибәреләсе мәгълүм булгач, кәефе яңадан кырылды, борчылырга тотынды.

— Туган ил тирәләреннән һаман ерак китәбез... Латвия әле ул — ындыр арты кебек кенә иде, тагын кайларга олактыра икән бу дошман безне? Һаман кайтып булмастайрак җирләргә сөйриләр...

Арыслан исә аның белән килешмәде:

— Юк, бәләкәчем, ялгышасың, — диде ул, баш түбәсен кашып. — Бу тәмугтан котылуыңа сөен генә син. Ач бүредәй котырган бетләргә ташланган үләксә идек бит без, шул чокырда кимереп бетергән булырларые. Ә яңа җирдә, може, крәстиянгә-фәләнгә эләгеп куюыбыз бар...

— Симез фрауларның дуңгыз ялчылары булып, дисең инде син. Әйдә, чучка с ним, мин риза, — дип көлгән булды Муса.

Китәр көн килеп җитте. Кырык икенче елның октябрь урталары иде. Моңарчы Арыслан белән Муса бер урынга, бергә китәбез дип җыеналар иде, ләкин аларны аердылар. Нәкъ шул китәсе көнне генә Арыслан билгеләнгән команданың Польшага, нииндидер Демблин дигән урынга җибәреләчәген игълан иттеләр; Муса, Миңгали, Тулиян һәм тагын егермедән артык укымышлырак кеше, шул элек әйткәнчә, Германиягә озатыласы булды.

Кинәт кенә хәлләрнең болайга таба борылуы Муса белән Арысланны кайгыга төшерде. Күпме вакытлардан бирле бөтен кайгы-хәсрәтне бергә уртаклашкан, инде аерылмас дус булышып җиткән кешедән аерылу

һәр икесе өчен дә бик авыр иде. Алар сагыш тулы кочакларына берберсен кыскан килеш сүзсез калдылар, күзләреннән яшьләр тәгәрәде, аннары өч тапкыр кайнар итеп үбешеп алдылар. Туган илдәге адресларын алмаштылар. Кем исән кайтса да, иптәшенең гаиләсенә сәлам илтеп тапшырырга, монда күргәннәрен һәм ахыргача турылыклы булганнарын балаларына сөйләп бирергә тиеш. Муса үзенең бер дәфтәр шигырьләрен Арысланга тапшырды.

— Әгәр булдыра алсаң, сакла, дустым, — диде. — Туган илгә кайткач, Минзәлә газета редакциясенә генә тапшыра калсаң да, югалмас.

— Тәндә җаным булганда! — диде Арыслан. Бу аның шигырьләрне кулына тотып, ант итүе шикелле яңгырады. Аннары өстәп куйды ул: — Син дә инде, сигезенче туганым, исән йөреп сау кайт и әбәзәтелни безнең Сайкичүгә кил! Минем сәламемне тапшыр... Хәер, мин әле бер дә үләр күк тимим, үзем дә кайтып җитәрмен. Һәм без синең белән Сайкичүдә, картлар янына түр башына тезелеп утырып, куырган каз ботарлый-ботарлый, яртыны суга-суга, үлем белән яшәү китабының ахыр кыйссаларын сөйләп бетерербез. Иртәгесен Ык буена, ак чиләк белән уха пешерергә китәрбез. Эх, булыр ул чагында бәйрәм!

Тагын бер тапкыр аларның күз яшьләре мөлдерәде, ачлык һәм газап бозган чырайларын матурлап, елмаю балкыды, озак итеп кул кысыштылар. Командалар җәяүләп Двинскига кузгалырга торганда гына, Арысланны сак кына артка дәшеп, чәнечкеле чыбык аркылы ашамлык ыргытып өлгерделәр. Арысланның кухняда эшләүче иптәшләре бар иде, алар элек тә, бик кыен чакларда, булышкалап килделәр, бу юлы да онытмаганнар икән. Иске брезент кисәгенә төрелгән ризыклар арасында яртыдан зуррак ипи белән бәрәңге, хәтта пешкән үпкә-бавыр кисәкләре һәм олы бер карын да бар иде. Шулай итеп, алар көтмәгәндә юл ризыгы белән дә тәэмин ителделәр.

Яңгырлы төндә, Двински шәһәре вокзалында конвойлы дусларның юллары икегә аерылды.

## БИШЕНЧЕ БАШЛАМ

### I

Мусаны, башка әсирләр белән берлектә, челтәр тәрәзәле вагонга утыртып, Рига, Каунас, Варшава, Познань шәһәре аша Берлинга китерделәр. Ләкин шәһәр тышында ук вагоннан төшерделәр дә, гадәттә буш ящиклар йөртә торган рәшәткә кузовлы йөк машинасына төяп, төньяк-көнбатышка таба алып киттеләр. Октябрь ахырлары булса да җылы, кояшлы көн иде. Кузов рәшәткәләре аркылы тирә-ягына хәйран күз белән карый-карый барган Муса уйга батты: менә нинди икән ул Алман иле. Таулар да, текә ярлы коры елгалар да, кырын-ярын басулар да, калын урманнар да күзгә ташланмый. Һәркайда бертөрле пейзаж: яшел тигезлек, дүрткел-дүрткел агачлык, игенлек, болынлык, җимешлек. Һәркайда текә чүлмәк түбәле, калын стеналы кызыл кирпеч өйләр, күп урыннарда аерым утар — аерым йортлар, торымнан-торымга кечерәк местечкалар, еш кына вак шәһәрләр — һәммәсе дә тар гына асфальт юллар белән бер-беренә тоташа, һәммәсе дә чиста, тәртипле һәм йөз елларга чыдарлык итеп эшләнгәннәр. Кирәк чакта ул йортларның һәркайсы крепость, ДОТ булырлык иде. Һәр көтүлектә бер үк стандарт белән ясалгандай аклы-каралы, эре токымлы, олы җиленле симез сыерлар, калын йонлы, итләч гәүдәле зур сарыклар төркеме күренеп кала. Юлны да бу немецлар иренмичә төзегәннәр: алар бара торган магистральгә тигез дүрткел итеп кискән гранит ташы җәелгән. Әмма ул ташлар бер дә иренмичә, кыйгач бизәкләр һәм түгәрәк орнаментлар белән матурлап түшәлгән. Әйтерсең, юл үзәгеннән таш пальма кыяк-

лары үсеп чыга да ике якка сыгылып кала. Ә ныклыгы ягыннан — теләсә нинди танкларың дөбер-шатыр килеп үтсә дә, шайтаным да булмаячак. Магистральнең ике читендә юан-юан агачлар күләгә төшереп утыралар, ул агачлар артында җәяүлеләр һәм велосипедчылар сукмагы сузыла, анысына асфальт җәелгән. Ә инде сукмакның аргы кырыйларында кәүсәләре акка буялган груша һәм алма агачлары кыпкызыл чәйнектәй җимешләре белән сыгылып утыралар. Бер секундка Мусаның хәтта авызыннан сулар килде. Кайчан инде аның мондый җимешләрдән авыз итмәгәненә! Бигрәк тә, әнә шул үсеп торган сабагыннан өзеп алып ашау — нинди ләззәтле булыр иде!..

Кешенең уйлар агышы — гаҗәп нәрсә. Әле генә күзгә чалынган бер күренеш бөтенләй икенче хатирәләрне кузгатып җибәрә. Сыгылып утырган алмаларны күрү Мусаның да уйларын әллә кая алып китте. Әле генә диярлек алмагачлар чәчәктә утырган чак күз алдына килде аның. Кайда гына, кайчан гына иде әле соң бу?.. Әйе, шушы май аенда гына. Җимерек авыл алма чәчәкләре эчендә. «Сагыну» көе. Әлбидә... Әллә кай төше генә бик таныш, бик якын булып Әминәгә охшаган Әлбидә. Нинди нәфис иде аның тавышы!.. Аннары, бомба һәм мина төтеннәре, баткак күлнең пычрак фонтаннары белән караңгыланган ак төн... Бар да челпәрәмә килде. Дөньяның асты-өскә капланды... Муса бу хакта ничәмә тапкырлар газапланды инде. Кинәт исенә төшеп уйлый башлый да, йөрәге умыртып авыртырга тотына. Ул үзен гаепле саный. Бик тәҗрибәсез, бик ачык авыз булды бугай ул куркыныч алдында. Саклый алмады бит ул изге җанны, саклый алмады... Югалды мескен күлләр төбендә... Йөрәге талануга түзәр әмәле калмагач, бу авыр уйларын куа башлый ул. Икенче нәрсәләр белән мавыгып, шул газаптан котылырга тели. Әмма барыбер Әлбидә сурәте күз алдыннан китми. Менә хәзер дә шундый ук хәл. Аның йөрәге тагын сулыгып-сулыгып авырта башлады. Күкрәк челтәре тараеп калгансыман тоелды. Тирән сулап, тагын әйләнәтирәгә, табигатькә карады. Үз-үзен башка фикерләр, башка тәэсирләр белән мавыктырырга, немец җирләрен күзәтергә мәҗбүр итте. Күңел түрендә һаман шул изге образ торса да, тирә-як белән мәшгуль булырга теләде.

Кара, нинди икән болар, хәтта мондый мәдәни яклары да бар икән! — дип уйлады ул. Әмма шушы юл буенда һичбер саксыз-нисез иркенләп пешеп утырган, яхшы күңелле кешеләр үстергән бу гүзәл җимешләр белән немец комсызлыгын, фашист вәхшилеген ничек бергә тәңгәл китерергә соң?.. Муса, шушы мәсьәләне чишә алмыйча, озак баш ватты. Чынлап та, шушындый гүзәл биналар төзегән, ачык бакчалар үстергән, шушындый цивилизацияле бер тормыш корган илнең башкалар өстенә вәхшиләрчә ташлануы, аларны көлгә күмүе мөмкинме?.. Бу уйларның очына чыга алмагач, тагын соклануында дәвам итте. Әйе, бөтен нәрсәләрен нык итеп, озак елларга чыдарлык итеп эшләгәннәр болар. Кара син аларның уем-уем көпчәкле автомашиналарын гына: ничәшәр тонна тартсалар да, бертөрле пычрагында да батып калмаячаклар! «Тигр» дигән танкларын бәреп тишә алмыйча, безнең артиллеристларның җелеге кибә. Самолетлары безнең күкләрдә каракоштай куркусыз очалар яки усал шөпшә шикелле уйнаклап кына йөриләр. Хәтта аларның туп атларына кадәр фил хәтле бит, тавыңны сөйрәрләр. Ә бездә мондый атлар да, мондый юллар да, мондый массив һәм нык техника да — берсе дә юк иде. Менә нәрсәләре белән масаялар икән алар! Европада безнекедәй техникалы кеше юк, без барыбер җиңәбез, дип уйлаганнар, күрәсең. Ә инде салам түбәләре, чокыр-чакырлы юллары, агач арбалары белән арык атлары, әле һаман да төзелеп бетмәгән промышленносте белән сугыш техникасы канатланып җитмәгән Россияне иңнән-иңгә, буйдан-буйга таптап чыгу алар өчен, гомумән, артык җиңел булып күренгәндер. Әйе, тылың һәм техникаң нык булу яхшы, әлбәттә;

ләкин дошманыңның кем икәнен белергә дә кирәк ич. Хәер, немецлар, анысын да беләбез, дип уйлыйлардыр хәзергә. Һаман баралар бит. Сталинград урамнарында сугышалар икән, димәкки, Иделгә килеп чыкканнар... Башлары бик әйләнгән чак, тантаналары бөтен юл буйлап күзгә бәрелеп тора, хәерле булсын...

Юл агышында туган тәэсирләр, шулай итеп, Мусаның уйларын сугыш мәйданнарына, Идел буе — туган җирләргә борып алып киттеләр. «Бездә нихәлләр бар икән соң? — дип пышылдады ул көрсенеп. — Мәскәү янындагы шикелле удар ясау өчен көч җыялар микән, әллә башка күңелсез сәбәпләр дошманны Идел ярларына кадәр китерде микән?..»

Немец машиналары, гади бер инеш күпереннән узып, сулгарак борылдылар да кечкенә бер авыл уртасына тукталдылар. Моны Вустрау авылы диделәр. Аның тирә-ягындагы урманнарда әрмән, грузин, азербайҗан, татар һәм хәтта румыннар өчен һәртөрле лагерьлар барлыгы мәгълүм булды. Машиналардан төшеп, төркемнәргә аерыла башлагач, Мусалар өч кенә кеше калды. Муса үзенең бу ике юлдашын танымый да әле, бер-ике сүз алмашуда гына аларның элек укытучы булулары беленде. Немец конвоиры аларны урман эчендәге ябык лагерьга алып китте.

Кызык булып чыкты бу лагерь: нибары иллеләп кенә кеше, торырга бараклары да бар, урман эче дә бик матур, немец та атлаган саен өстеңдә таяк, камчы күтәреп тормый, эш белән дә артык интектермиләр. Олы тирес арбасына җигелеп, урманнан утын тартып кайтудан башка әллә ни хезмәт тә юк. Тамакка да рәтле генә диярлек ашаталар икән. Муса боларның һәммәсенә дә бик сәерсенеп карап йөрде. Юк, бу инде Шпигель җәһәннәме түгел! Бу ни хикмәт соң? Ни өчен немецлар ике төрле кыланалар? Нигә монда болай бик юмартланып киткәннәр икән?.. Ләкин Муса өчен барыннан да гаҗәбрәге: монда гел Идел буе халыкларыннан булган әсирләр генә җыелуы, аларның да күбрәге татарлардан булуы иде. Башкорт, чуваш, мари кешеләре дә сирәк-мирәк күренә. Ә татарлар арасында укытучы, инженер, геолог, агроном, газетчы һәм башка шуның ишеләр икән. Димәкки, укымышлы халыкны җыйганнар монда...

Вустрауга килеп бер кич кунуга, Муса янына беренче таныш кеше килеп чыкты. Бу — немец формасын бик купшы итеп, пөхтәләп киенгән Кәрип Ишбулдин иде. Муса көпә-көндез төш күрә төсле яки күзләре саташа төсле тойды үзен. Чөнки ул танышларыннан немец киемендә йөрүче берәүне дә күргәне юк иде әле. Кинәт кенә күптәнге кечкенә бер эпизод келт итеп аның хәтеренә килеп төште: Кабан күле өсте. Ул Мәдинә белән көймәдә йөргәндә аларга очраган икенче бер көймә. Ишбулдинның шунда ул кызны исерек авызы белән мыскылларга маташуы, теге гөнаһсыз кызның хурланып елавы — барысы да Мусаның күз алдыннан яшен тизлегендә сызылып узды. Моннан унике еллар элек булган иде бу. Шуннан соң Муса бу кешене берәр тапкыр очраттымы-юкмы, хәтерли алмады. «Кара син, ә? Кайсы якка киткән моның эшләр? Нинди кыяфәткә кергән?..» дип уйлады ул хәзер.

Ишбулдин аны ерактан ук танып, кин елмаеп килде дә әллә каян ук ике кулын күрешергә сузды:

— А, исәнмесез, Муса кордаш! Менә көтмәгәндә кадерле кунак! — дип, күтәренке тавыш белән шатлыгын белдерде. — Исәнлек-саулыкмы, авырмыйсызмы?..

— Ярыйсы әле, — диде Муса гаҗәпләнгән караш белән. — Күрәм, сез монда иске кеше, үз кеше булсагыз кирәк... Нәрсә, әллә немец генерал иттеме? Формагыз бик шәп!

— Юк ла, — диде Ишбулдин оялчан көлеп, — унтерофицер генә бит... Мин... ни... монда...

— Нишләп алай бик аз? — дип сорады Муса тагын да гаҗәпләнгәнрәк төстә. — Нәрсә, әллә монда палач-фәлән булып кына торасызмы?..— Ул аны немец формасында күрүгә ачуына чыдаша алмый иде.

— Сез инде бигрәк! — диде Ишбулдин чиктән тыш җәберсенеп.— Нетактично! Гүяки мин үзем теләп... — Ул шуннан башка сүз эндәшмәде. Нәфис хатын-кыз аягы рәвешендә эшләнгән муштугын күкрәк кесәсеннән алып, немец сигареты кыстырды да, «хушыгыз» дип, авыз эченнән генә мыгырдап, китеп тә барды.

«Каты бәрелдем бугай, — дип уйлады Муса. — Бәлки, чынлап та, үзе теләп түгелдер...»

Икенче көнне бөтенләй таныш булмаган яңа бер әфәнде килеп күреште:

— Сау-сәламәт кенә килеп җиттегезме, Муса Җәлил әфәнде! — дип кулын сузды ул, бармакларындагы асылташлы йөзек кашларын уйнатып. — Без сезне күптән көтәбез инде, хуш килдегез, мәрхәба! Зур өметләр баглыйбыз!..

Муса чәчләре үрә торгандай сискәнүле караш белән аңа текәлде. Ул илле-илле ике яшьләр тирәсендәге бер кеше булып, урта буйлы, аркасы бераз бөкрәярәк төшкән тулы гәүдәле, чал керә башлаган кара чәчле, озынчарак йөзле, ияк очы керпе сакаллы иде. Аның сәүдәгәрләрчә ачык чырайлы булуы, нәзек озын борын астындагы калын иреннәренең, авызындагы алтын тешләрен күрсәтер өченме, әллә сөйләшер өченме, гел ачылырга гына торуы һәрхәлдә бу кешенең башкалар белән тиз аралашырга, тиз алыш-биреш итәргә яратуын күрсәтәләр кебек иде. Муса аның бу сыйфатларына артык игътибар да итмәгән булыр иде, бәлки, ләкин таныш булмаган сүздәшнең беренче авыздан ук аның исем-фамилиясен әйтеп эшкә керешүе сагаерга һәм аның йөзенә ныклабрак карарга мәҗбүр итте. «Кем соң бу? Минем исем-фамилияне каян белә? — дип сорады Муса үз-үзеннән. — Минем аны гомердә дә күргәнем юк ич. Ә немецлар өчен мин һәрвакыт Муса Гумеров, рус газетасында журналист. Әмма бу зат минем Берлинга килүемә коймак пешереп куйган кодам шикелле сөйләшә?..»

Бу аптыраулы уйларны озакка сузарга ярамый, кунакның үзен сөйләштерү кирәк иде:

— Исәнмесез, — диде Муса уртача тыныч кына тавыш белән. — Дустанә сүзләрегез өчен рәхмәт... Ләкин сез мине башка берәү белән саташтырдыгыз булса кирәк. Минем фамилиям — Гумеров.

— Һи-һи-һи! — дип көлде бу кеше тагын дусларча тавыш белән. — Аңлыйм, аңлыйм, әфәндем. Читләр кулында грифтар булганда, үз исемеңне яшерү дә мөмкин. Әмма без — үз кешеләр. Качышлы уйнамасак та була...

— Сез үзегез качышлы уйныйсыз: кем икәнлегегезне әйтмәдегез.

— Ах, гафу боерасыз, Муса әфәнде, әйтергә өлгермәгәнмен икән шул. Габдерахман Шәфи Алмаз дигән бәндәгез булам мин. Әлбәттә, сезнең мине белүегез — мөхаль эш. Атаклы адәмнәрдән түгел. Әмма мин сезне бик яхшы беләм! Мин сезнең белән егерме җиденче еллардан ук таныш. Сез ул чакта ук танылган шагыйрьләремездән идегез. Әйе, әйе! Сез гаҗәпләнеп карыйсыз: каян белә, дисезме? Юк, сер түгел, без фәкыйрегез ул елларны Мәскәүдә булган идек, хәтта туган җиребез Казаннан да бер уңайлы коммерция белән әйләнергә туры килгән иде...

— Менә ничек! — диде Муса кәефле гаҗәпләнү белән. — Сез алайса минем өчен бик кызыклы, бай истәлекле кеше икәнсез. Ышанам ки, сез әле, әлбәттә, миңа ул хакта тәфсыйллырак итеп сөйләрсез.

— Әлбиттә, әлбиттә, — диде Шәфи Алмаз, Мусаның хезмәтенә әзер торган кешедәй. — Без әле сезнең белән күп мәртәбәләр ултырдаш булырбыз... Ә хәзер, менә нәрсә, әфәндем, — дип сүзен кырт борып җибәрде Шәфи. — Сезнең безгә дустанә хезмәтегез кирәк. Без аңа мохтаҗ-

быз! Сез танылган шагыйрь, милләтебезнең зур кешесе, җәмәгать хадиме...

— Әт-тә-тә-тә! — дип елмайды Муса. Ни өчендер аның кәефе уйнаклап, шаяртып сөйләшәсе килә башлады. — Сез шулай, үгезне мөгезеннән эләктереп, сөйләшик дисез инде, шулай тышауламакчы буласыз...

— Я, хода! Нинди үгез, нинди тышау? — дип нәразыйлык күрсәткән булды Шәфи. — Юк, Муса әфәнде, каршымызда бик житди вазифа тора!

— Хуш, сөйләгез, сер булмаса. Әллә хаҗга-фәләнгә барыргамы? Ялганам!..

— Һай, усал телле икәнсез, әфәндем, белми идем,— дип, чынлап ук зарлана башлады бу кеше. — Хаждамы соң әле кайгы? Әнә күпме мөселман кардәшләребез немес лагеренда ачка интегә, тифтән үлә. Менә сез үзегез дә нинди кибеп, саргаеп калгансыз, рәхәт булмагандыр, күрәмсең!

— Рәхәт булмыймы соң! — диде Муса көлеп. — Куроттагы шикелле, кояшта яныл кына яттык... Дәвам итегез.

— Дәвам дип, менә шул мөселман туганнарыбызны, вә дәхи Идел-Урал буендагы мискин вә бичара вак халык әсирләрен аерым урыннарга җыеп, әҗәлдән коткару һәм аерым тәрбия кылу иде безнең ният. — Шәфи Алмаз заманында мәдрәсә, хәтта җәдит мәктәбе дә күргән кеше иде. Шуның өчен ул үзенең немец арасында әле онытылып бетмәгән «укымышлы» телен тулысынча эшкә җигәргә тырышты. Ә бу тырышлык аның маңгаеннан бөрчек-бөрчек тир чыгарды; зур гына кесә яулыгы тартып алып, маңгай һәм муеннарын сөрткәләде. — Әйе, менә шул изге ният белән йөргән булабыз; шул әсирләр өчен «Идел-Урал» исемендә кечкенә генә булса да гәзитә чыгарып маташабыз. Менә шул гәзитәбезнең баш мөхәррире урынын сезгә тәкъдим итмәкче идек...

Мусаның бая көләсе килсә, хәзер кинәт ачуы купты. Озын сәләмә шинель итәкләрен җилфердәтеп, кискен хәрәкәт белән аягүрә басты:

— «Идел-Урал?» — дип сорады ул шаккатып. — Әллә кайчан тарихның чүплек базларына ташланган һәм әллә кайчан сөякләре череп көл булган үләксәне каян тартып чыгардыгыз, әфәндем? Ничек аның баш мөхәррире булыйм мин? Сез мине кем дип уйлыйсыз? Мин Советлар Союзы гражданины, шундый газетада баш мөхәррир? Фашистлар газетасында?..

— Әстәгафирулла тәүбә, тәүбә! — диде Шәфи Алмаз да, сикереп торып. — Ничек телегез бара? Кем, минме яки меңләгән әсирләрме фашист?.. Юк, сезнең белән тыныч кына мөсахәбә кылу, чынлап та, мөмкин түгел икән! — Һәм ул Муса янынннан хәтта читкәрәк атлап китте.

— Бигрәк тә яхшы, — диде Муса, — бигайбә... Хушыгыз!

— Юк, туктале, сез алай кырт кисмәгез әле! — Шәфи җәһәт кенә кире борылып килде. Бу минутта ул, яхшы товарны кулыннан ычкындырырга теләмичә, кат-кат әйләнеп килеп сатулашучыга охшый иде. — Сезнең каммунис булуыгыз да мәгълүм безгә. Сәвит кул астында кем каммунис булмас? Әммә ләкин ул безнең эшебезгә комачаулык итми, әгәр сез немесләргә турыдан-туры дошманлык күрсәтмәсәгез... Хәер, бу хакта сезгә Көнчыгыш эшләре министре Розенберг әфәнде үзе ачыграк сөйләр. Ул сезне шушы көннәрдә үзе кабул итмәкче булып тора...

Муса өчен бу яңалыклар берьюлы артык күп булып китте. Монда бик уйлап эш итәргә кирәк икәнлеген шунда ук сизенеп алды: «Ашыгу ярамас, болар ниндидер зур һәм кара эшләр башлап җибәргәннәр төсле... Обстановка белән ныклабрак танышырга кирәк...» — дип уйлады ул. Һәм Шәфи Алмазга, башын ия төшеп, әйтте:

— Әфәндем, без кызыбрак сөйләштек бугай. Арылган, алҗыткан.

Яңа гына юлдан килгән кеше ич. Нервлар да какшамаган түгел... — диде. — Бәлки, без бу сүзләрне киләчәктә дәвам иттерербез?

— Бик хуп, бик хуп, — дип куанды Шәфи. — Әлбәттә, шулай, мәйлегез. Тоткан җирдән генә чыбык сынмый бит...

Һәм алар шактый ук тату, хәтта дустанә бер төстә кул бирештеләр. Шушы сәгатьтән дипломатия башланды...

## II

Элекке Муса юк иде инде. Дошман кулына төшкәннән соң башыннан кичкәннәре, аның бөтен ерткычлыгын үз җилкәсендә татуы, моңарчы рәтле генәсыман күренгән кешеләрнең, шул кабахәт шартларга түзә алмыйча яки ерак яшерелгән икенче бер табигатьләрен өскә чыгарып, бүтән төрлегә әйләнеп китүләре аны да бик нык үзгәртте. Кырыс булырга, сагая төшәргә һәм дөньяга күзләрен ачыбрак карарга, тирәнтенрәк уйларга өйрәтте. Дошман, нихәтле генә әшәке булмасын, кайберәүләргә барыбер үз йогынтысын ясый иде. Ничек алар фашистның кем икәнен күрмиләр? Ачка үлү яки эт күрмәс җәзалар тату куркынычы шулай барына да күз йомарга мәҗбүр итәме, әллә моның тирәнрәк башка сәбәпләре дә бармы — Муса һич аңлый алмый иде.

Карип Ишбулдинның, немец хәрби формасына гашыйкларча киенеп, каршына килеп чыгуы ана бик нык тәэсир ясады. Ул кинәт тетрәнеп киткәндәй булды: «Кара син, ә? Безнең татар кешесенең дә шул каһәр төшкән свастикалы форманы киеп йөрүе мөмкин микәнни соң? — дип уйлады ул. — Ә бу малай кайчандыр совет кешесе иде бит һәм бөтенләй үк рәтсез дә түгел кебек иде... Димәк ки, болай булгач, аның фашист солдаты белән бергә, безгә каршы сугышка баруы да ихтимал була торгандыр инде? Коточкыч, коточкыч!.. Юк, бу фаҗига булачак, һичкайчан төзәтүе мөмкин булмаган кара фаҗига булачак!..»

Ә инде икенче көнне Шәфи Алмазның, эт күмелгән җирдән куян колагы гына күрсәтеп, ефәк теле белән сөйләнүе бу хәлнең төп мәгънәсен шактый ачыклый төште. Шунда ук аның күз алдына Карип Ишбулдин яңадан килеп басты. Шәфи Алмаз сөйләгәннәрнең җанлы иллюстрациясе кебек тора иде ул. Муса бу хакта тагын озак кына баш ватса да, һаман әле ачык бер нәтиҗәгә килә алмыйча, өченче көнне лагерь эченә чыгып китте.

Сирәк урман эче көзге тынлыкка чумган. Кояшлы көн шактый җылы, тик салмак исенкерәгән җил генә үзенең салкын сулышын бәргәләп куя. Картрак агач яфракларындагы сары тутлар еpaктан караганда гәрәбә чукларысыман булып күренәләр. Шпигель лагереннан котылган кешегә бу урыннар иң саф һавалы, иң матур табигатьле курорт шикелле тоела. Бу әхвәл сиздермәстән кешегә тәэсир итә; моңарчы кичергән газаплардан калган авыр басынкылык, кәефнең салпылыгы әкренләп югала бара, күңелдә җиңеллек уяна, бөтенләй сүнә язган өмет чаткылары яңадан яктыра башлый. Муса, үзенең чишелмәгән уйлары белән һаман мавыгып, шушы хисләр эчендә атлый бирде. Ләкин уйлаган саен кәефе үзгәрә барды. Монда китерүләренең төп сәбәбен аңлаганчы туган котылу сөенече кинәт әчке сагаю белән алмашынды һәм күңеленә яңа шом кереп оялый башлады. Ишбулдин белән Шәфи күләгәсе һаман күз алдында. Юк, хәерлегә түгелдер монда китерүләре!

Тар гына урман юлыннан бер төркем әсирләр утын төялгән йөк арбасы тартып кайталар. «Һәйдә тарт, һәйдә тарт!» — дип, көй белән кычкырган тавышлары ишетелә. Барак янындагы солдат кухнясының нәзек торбасыннан чыккан сыек зәңгәр төтен туп-туры булып һавага күтәрелә. Әчкелтем усак ысы ерактан ук борынны ярып керә. Ләкин

Муса боларның берсен дә сизмәгән, күрмәгән кебек атлый бирә. Әйтерсең, Казан янындагы «Васильево» ял йортының нарат паркы буйлап гамьсез генә һава сулап йөри ул! Шул чагында кемнәрнеңдер «Сагыну» көен җырлый башлавын ишетү Мусаны уятып җибәрде. Күзләре белән аларны эзли башлады ул. Кухнядан бер читтәрәк тумран өстендә бәрәңге әрчеп утыручы өч-дүрт әсир ягыннан килә иде бу тавыш. Муса шунда таба атлады. Арба сөйрәүчеләр дә, шунда кайтып, утын бушата башладылар. Җыр ахырына таба Муса аларның яннарына килеп басты. Аның килгәнен бер озынрак буйлы, чандыр йөзле, җирәнчәрәк чәчле, кайчандыр янып торган җитез күзле, егерме биш-егерме алты яшьләрендәге егет хуплап каршы алды:

— Әйдүк, абзыкай, — диде ул. — Рәхим ит, утын бушатасың киләдер инде синең... — Һәм, Мусага карап, аптырабрак калды. Муса да аңа карады. Алар икесе дә бик нык үзгәргән: ябыккан, йончыган, картаеп киткән иделәр. Карашып тору шактыйга сузылды. Шуннан соң калку буйлы егетнең чибәр йөзе кинәт яктырып китте:

— Атакай! — дип кычкырды ул мишәрчәләбрәк. — Өнемме, төшемме?.. Бу — син түгелме соң, Муса абый?!

Муса да аны танып алды: бу егет моннан җиде-сигез еллар элек Муса җитәкчелегендәге әдәбият түгәрәгенә йөргән мәскәүле Әхмәт Симаев иде.

— Исәнме, Муса абый, җаным! — дип кочаклап алды да елап җибәрде ул.

— Исәнме, Әхмәт! Исәнме, туганкай! Менә кайда күрешәбез! — дип, Муса да аны кочаклап аркаларыннан какты.

Көтмәгәндә очрашу шатлыгы тудырган кызулык белән Симай аны: «Әйдәле, әйдәле, кәбәм!» — дип, өстерәгәндәй, читкә таба алып китте.

Бу егет Мусаны электән үк ярата иде. Заманасында ул аңа ияреп шигырьләр дә язды, аның шикелле үк шагыйрь буласы килде, ләкин журналистика институтында уку һәм шул елларда газетада эшләү аны икенче юлга борып җибәрде. Сугыш башланганда да Мәскәү газеталарының берсендә эшли иде ул.

— Бүген үләсең, дисәләр, гаҗәпләнмәс идем, әмма сине монда очратуыма ис-акылларым китте, Муса абый! — диде Әхмәт, һаман әле гаҗәпләнеп.

— Эх, дустым! — дип куйды Муса, тирән көрсенеп. — Без беребез дә тилгән тырнагына эләккән чеби булырбыз дип уйламаган идек шул. Лачын булып һаваларда йөзү турында гына хыялландык. Дошманны үз җирендә кыйнамакчы идек... Ә тормыш менә ничек итеп көлде бездән.

— Әмма мин алай бөтенләй үк куркак һәм көчсез чеби дип уйламас идем үзебезне! — диде Симаев, каршы килеп.

— Юк, Әхмәт, мин дә алай ук диюем түгел. Мин Волхов фронтында эләктем. Безнең кешеләр, Власов хыянәт итүгә дә карамастан, актык төркемнәренә, актык сулышларына хәтле сугышып, искиткеч батырлыклар күрсәтте, туган иле өчен егетләрчә үлә белде. Әмма шулай булса да, менә күрәсең ич, без синең белән чебешләр хәленә төштек. Ә безнең ишеләр — ничәмә меңнәр! Күз алдыңа китер. Аларның желеген ачлык суыра, тәннәрен бет талый, йөрәкләрен ирексезлек корты кимерә!

— Ә шулай да ул чебешләрнең эчендә лачын ята, Муса абый, — диде Әхмәт, тагын килешмичә. — Алар әле җиңелмәгән, алар әле баш имәгән! Аларның тик канатларын каерып, богаулап кына ташлаганнар. Менә минем, әйтик, канатларым гына бушансын — яңадан һаваларга үрләп, дошманның йөзенә ташланачакмын!

— Афәрин! — дип елмайды Муса, аңа сокланган караш белән. — Ничек эләктең соң син, лачынкай, мондый гайрәтле булгач?..

Мусаның көлебрәк әйтелгән бу сүзләре Әхмәтнең хәтерен калдырмады, ул үзе дә көлемсерәп җавап бирде:

— Әмин, чыннан да, лачын идем: десантчы булыр бу абзаң, Муса абый, — диде ул эчке горурлык белән. — Быел кыш уртасында Мәскәү тирәсеннән качып барган немесләрнең тылына төштек. Ну кыйраттык та без аларны ичмаса! Тегеннән безнең регуляр частьлар куа килә, ә без арттан һәм кабыргадан пешерәбез — кая керер тишекләрен дә тапмыйлар. Пушкин әкиятендәге Дадон солдатлары шикелле, киң яланнарда өелеп ятып калды немесләр. Юллар ватык-җимерек техникасы белән бөялде. Март азакларына хәтле шулай сугышып йөри-йөри, тәмам җелекләренә үттек без аларның. Немеснең иң курыкканы десантчы белән партизан булып китте. Ниһаять, март ахырларында юллар бетә башлагач, сугыш хәрәкәтләре әкренәйде, немесләрне авыллардан кубару кыенлаша төште...

Язгы төннәрнең берендә дүрт кеше разведкага киттек, авылдагы хәлне белергә кирәк иде. Кердек керүен, хәлне дә белдек, ләкин әйләнеп чыга алмадык — немесләр берәм-берәм эләктереп алдылар. Эх, үкенечле булды ул төн! Дүртебез дүрт җирдә канда аунап ятабыз. Һушыбызны җуйган саен, өстебезгә чиләкләп кое суы тондыралар. Без болай да кар өстендә инде. Аңга килүебезгә тагын пытка башлана: «Әйт, кызыл дуңгыз, комисариш, десант отрядыгыз кайда?»

Ахырда без карга ябышып туңа башладык һәм үзебезнең кайда ятканны оныттык. Әмма ни өчендер үтермәгәннәр безне. Мин, күзләремне ачкач, Кувшинка дигән зур бер авыл мәктәбендә ятканымны белдем. Нииндидер яхшы җаннар китереп салганнар. Бөтен аркам чи ит иде, боздан кубарып алган булсалар кирәк. Бот-сыйрак һәм муеннарны чуан баскан, үпкәләр, иске музикән күрүге шикелле, гыжлап тора иде. Бер көнне баштан-аяк марля белән уранган бер кеше килеп керде. Бу — минем иптәш, Карпуша иде. «Хәлең ничек? — дип сорады пышылдап. — Федор белән Игнат үлделәр, эчләренә кан сауган булган, — диде. — Терел тизрәк, монда врачлар руслар, качабыз...» — диде, һәм чыгып та китте.

Әз генә рәтләнү белән без чынлап та качтык. Карпушаны яктырткыч пуля егып салды, бил сөяген җимергән, эчен харап иткән иде — үлде; минем сыйракны тиштеләр. Хәл беткәнче йөгердем. Кан тамып барган эздән килеп тоттылар. Икенче лагерьдан тагын качтым, тагын тоттылар. Шулай итеп, алты ай эчендә дүрт лагерьга җиттем. Берсеннән качам, икенчесенә китереп ябалар. Ниһаять, Берлин төбендәге Вольһайдегә китерделәр. «Шталаг III Д» дип атала иде ул. Монда инде өзлексез допрослар, резин таяк һәм немес йодрыгы ашаулар бетеп китте. Безне ничектер майлый, сыйпаштыра башладылар. Пропагандистлар курсына димлиләр, «Остарбайтер»лар арасында эшләргә, янәсе; тагын әллә кайларга чакыралар. Шуннан Вустрауга китерделәр. Күрәсен, Муса абый, әле безнең канат көеп бетмәгән! Әз генә тернәкләнәм дә тагын качам әле мин!

— Качып, кая барырсың соң? — дип сорады Муса. — Мин дә качар идем югыйсә...

— Һи-и, юл табылыр, Муса абый. Польшага, поляк партизаннарына!

— Әйтүе генә ансат! — дип куйды Муса Әхмәткә сокланып. — Тәвәккәллегеңә ышанам да бит, ләкин барып чыгармы?..

— Әйдә бергә качабыз, Муса абый! — дип тәкъдим итте Әхмәт кинәт кенә.

— Ай-һай, — диде Муса икеләнеп. — Мин дә качып караган идем инде... Тотылдым...

Аннары сүзне икенчегә борды:

— Ә бу Вустрау нинди лагерь соң? Нигә монда татарларны гына диярлек җыйганнар?

Әхмәт Симай гаҗәпләнү белән Мусага карап куйды.

— Юри бирәсеңме мондый сабыйлар соравын, Муса абый, әллә чынлапмы?

Муса, үзе дә уңайсызланып, акланырга тотынды.

— Соң минем килгәнемә өченче генә көн ич әле, һичкемне белмим. Менә бүген беренче тапкыр сине күрүем; белмәгән кешеләр белән сөйләшеп тә булмый ич...

— Алайса, Муса абый, син әле бик яшел икәнсең! Моннан бит Шәфи Алмаз үзенә кадрлар сайлап ала. Идел-Урал легионы, Идел-Урал штаты, Идел-Урал комитеты, тагын әллә нинди шайтан оялары шунда. Кыскасы, уптым-илаһи немесләргә сата безне. Менә мин дә аңа яллanырга килдем — туган илне сатарга!

— Кит, кит! — дип кычкырды Муса, кигәвен кугандагы шикелле кулларын алга таба селтәп. — Әшәке сөйлисең, авызың кутырлар!

— Дөресе шулай, Муса абый. Дөреслек — дөп итеп башка суга, диләр. Сине дә бит монда кияү егете итеп китермәгәннәр. Сизеп торам: инде тәкъдим ясап та өлгергәннәрдер.

Әхмәтнең кинәт болай сөйли башлавына Муса аптырап калды. Шаяртамы, мыскыл итәме?.. Аның ачуы кабарып, төсе бозылды, чыраена рәнҗү күләгәсе йөгерде:

— Син, Әхмәт, лыгырдыкка әйләнгәнсең, телең белән тизәк изәсең шикелле! — диде ул. — Әле генә бертөрле сайраган идең. Хәзер исә дуңгыз көенә мыркылдый башладың! Чын сүзең бармы соң синең?

— Чыны шушы, Муса абый! Дөрес, теләп түгел! Әмма борылыр җирең юк, мәҗбүр итәләр. Моннан качуны мин дә барып чыкмастыр дип уйлыйм. Шулай булгач, гәрчә эчеңнән саф булып йөрсәң дә, барыбер алар ялчысына әйләнми хәлең юк. Аннары, мин генәмени? Һәм син генәмени? Монда Фоат Булатов, Нәзир Һадиев, Исрафилев дигән инженерлар бар; монда Абдулла Алиш дигән балалар язучысы бар, монда үзен Такташтан да шәп шагыйрь дип йөри торган Рәфикъ Гыйлфанов бар; монда немес кияве булырга ашкынучы Айдагулов, Шиһап Нигъмәти, Гунафин һәм Нафиков дигән җанварлар бар; һәй, алар монда дөнья тулы! — дип тезеп китте Әхмәт Симай. — Алар уйлаганнардыр инде... Иблискә нинди хак белән җан сату турында җыелышта фикер алышып булмый, аны һәркем үзе генә хәл кыла...

— Ә кайда соң алар? — дип сорады Муса, гаҗәпләнеп. Чөнки бу өч көн эчендә алар хакында һични ишетмәгән иде әле ул.

— Менә, күршедә генә. Анда «фрайлагерь» — ягъни ачык, иркен лагерь. Алар инде «сират күперен» кичкән кешеләр, оҗмахка чират көтәләр. Ә безнеке «Зондерлагерь» — ягъни ябык, бикле лагерь дигән сүз. Безнең әле гөнаһлар юылып бетмәгән, сират күперен кичмәгән...

Муса үз блогына килеп җиткән иде инде. Алар салкынчарак кына аерылыштылар. Әхмәт Симайның ике төрле сөйләшүе аны аптырашта-рак калдырды. Ул егет чыннан да шулай юл югалту алдында торамы, әллә сынар өчен, тел яздырыр өчен генә шулай сөйләндеме? Хәзергә моны аңлау кыен иде.

«Кичке аш»тан соң үзенең салам түшәкле сәндерәсенә менеп яткач та Муса шул хакта баш ватты. Ләкин аның пошынулы уйлары еракка-рак сикерде: әнә монда нинди эшләр бара икән! Әнә монда аны ни өчен китергәннәр икән! Аның күзен каплаган кара пәрдә кинрәк ачылып киткәндәй һәм артындагы әшәкелек ныграк күренгәндәй булды. Каршына Симай әйткән Алиш, Булатов, Һадиевлар һәм легионга җыеп китерелгән меңнәрчә кешеләр килеп басты. Алар да шулай: «Бер мин генәмени», — дип уйлый микән? Шулай уйласалар, нинди куркыныч!

Ул тыныч кына уйлый алмый башлады. Хәзер үк бу сәндерәдән сикереп төшәсе һәм, мәйданга чыгып, барына да аңлатасы, «Әй, кешеләр, уяу булыгыз! Монда сезне иң әшәке җинаять чокырына төртеп төшерергә җыеналар!» — дип кычкырасы килде. Тик бу мөмкин түгел иде. Әле

бер ягына, әле икенче ягына әйләнеп ятты, һаман тынгы тапмады. «Болай булгач, Шәфинең бөтен татар-башкорт җирен башкөлләй немецка сатып җибәрүе көн кебек ачык! — дип пышылдый иде ул. — Әгәр шул татар солдаты, фашист формасы киеп, үзенең антын һәм намусын таптап, үз туган иленә каршы корал күтәрергә һәм үз туганнарына атарга мәҗбүр ителсә, — моннан да кабахәтрәк нинди җинаять булуы мөмкин?.. Әгәр бу пычрак эш эшләнә калса, бөтен татар халкының йөзенә мәңге юылмый торган кара тап сыланачак! Тарих каршында мондый хурлыклы көннәргә калганчы, хәзер үк үлү, үзеңне үзең юк итү мең тапкыр артыграк!..»

Әмма мондый ансат юлны Мусаның күңеле шунда ук кире какты: үлде-котылды бер тинтәк! — дип, үз-үзен ачы мыскыллап куйды ул хәтта... Менә бит хәлләр ничек тиз үзгәрә. Әле кайчан гына Мусага тик үз башы кыйммәт иде. Әгәр Шпигельнең үлем чокырыннан котыла калса, аның өчен дөньяда иң зур бәхет шул булыр кебек тоелды. Ә инде монда килеп, шомлы яңалыклар белән танышкач, үз җанынны коткару мәсьәләсе чыпчык баласын мәчедән саклаусыман нәрсә генә булып калды. Монда меңнәрчә кешеләрнең җанын саклау, аларны ирексез хыянәттән коткарып калу кирәклеге беленде...

Нишләргә соң? Нинди юл табарга?.. Ун меңләгән кешеләр легион лагерьларына тупланган хәзер. Аларны тарату, иске урыннарына җибәрү берәүнең дә кулыннан килмәячәк. Бердән, немец хуҗа. Ул инде шушындый этлекне башлаган икән, димәкки, бу кешеләрне файдаланырга, үзенең ертык-тишекләрен шулар белән әзме-күпме ямарга тели. «Идел-Урал штатлары» — җиң эченнән күрсәтелә торган арыш прәнниге генә. Икенчедән, легион лагерена китерелгән солдатлар үзләре дә иске тамугларына китмәячәк хәзер. Чөнки берәүнең дә тиктомалдан ачка интегеп үләсе килми. Һәркемгә җан газиз, бер генә көн булса да артык яшәү кадерле, бүген исән калу кыйммәт. Аның күңел түренә гаиләсе, бердәнбер баласы яки бердәнбер карт анасы яшеренгән. Ахыр көнендә, кайтып, шуларны бер күрсә, ул үкенмәячәк. Әйе, аның иң ахыргы теләге шул: кайчан да булса бер кайтып күрешү, газизләрен кайнар кочагына алу. Ә бу бит изге теләк. Моның өчен кем кемне гаепли ала? Димәкки, солдатны шул кавышу көненә тапсыз чырай белән илтү кирәк. Соң ничек эшләргә моны?..

Мусага эссе булып китте. Өстендәге шинель сәләмәсен кайтарып ташлады. Йокысын качырган уйлары, кар өстеннән агарга маташкан беренче язгы гөрләвек шикелле, боргалана-сыргалана юл эзли иде. Бая Әхмәт Симай әйткән егетләр тагын аның күз алдына килеп басты. Аларның берничәсе кайчандыр Мусаның яхшы танышлары, хәтта иптәшләре иде. Алиш инде бөтенләй үз кеше. Алар бер мәйданда үстеләр, Казан урамнарында бер сукмактан йөргән егетләр. Ул үзенең тыйнаклыгы, кече күңелле, басынкы холыклы булуы белән һәркемнең хөрмәтен казанган кеше иде. Нинди генә авыр елларда да кешеләргә шикләнеп карау, иптәшләренең бары тик начар ягын гына эзләү һәм алар өстенә кара ягу шикелле нәрсәләрне бөтенләй белми иде ул. Алтын егет! Әгәр бу каһәрле дөнья бөтенләй җимереп ташламаган булса, бәлки, хәзер дә шундыйдыр әле ул...

Нәзир Һадиевны әйтеп торасы да юк: ул аңа үз туганы кебек якын. Аның әтисе галим-педагог иде. Мусаларны Хөсәениядә дә, Халык мәгарифе институтында да ул укытты. Нәзир дә шунда Мусадан бер генә елга түбән сыйныф шәкерте иде, алар аралашып, дуслашып киттеләр, фикердәш булып үстеләр. Шуның өстенә, әтисе үлгәннән соң, егерменче елларда, Муса ачка интегүдән укуын ташлап, урамга чыгып китү хәленә җиткән чакта, бу шәфкатьле кешеләр аңа үз өйләренең җылы почмагын бирделәр, үз балалары кебек итеп карадылар. Бу яхшылыкны Муса һичкайчан онытачак түгел! Хәзер ул Нәзирне күрсә, үз туганыдай итеп

кочагына кысар иде. Юк, андый дусның «бер мин генәмени?» дию мөмкин түгел, аларның фикерләре элекке шикелле бер үк юлдан агылыр иде!..

Фоат Булатов та аның күптәнге дусты. Ул егет «Кечкенә иптәшләр» һәм соңыннан «Октябрь баласы» журналына үзенең спорт турындагы материалларын, Казан мәктәпләрендә кемнәр чемпион булу хәбәрләрен яудырып кына тора иде. Шуның өстенә, ул рәсемгә дә оста малай булып чыкты: журналга әллә нихәтле юмористик шаржлар ясап, фоторәсемнәр төшереп җибәрә һәм аларның байтагысы журналда урын да ала иде. Муса әле дә хәтерли: бу таманча буйлы, житез гәүдәле һәм шул чагында ук инде калын пыялалы күзлек кигән үсмер егет утызынчы елның җәендә Мәскәүгә үзе килеп, журнал редакциясе белән танышып йөргән иде. Хатлар аша гына таныш булган Муса абыйсына бик тиз иялашеп, үзләшеп алды ул һәм үзенең куанычы белән мактанмыйча да кала алмады:

— Муса абый, кара әле моны! — диде ул, сул як түш кесәсе каплавычындагы значокны кулы белән өскә калкытып. — Мәктәп чемпионы булыр абзаң!..

— Нәрсә буенча? — дигән булды Муса.

— Йөгереш буенча! — диде Фоат. — Вузга кергәч, Казан чемпионы булам, аннары — СССР чемпионы!

— Тукта әле, дускай, — дигән иде Муса ул чакта, Фоатны баштанаяк күздән кичереп. — Борчак сибә башладың түгелме? Ботларың бик кыска күренә ич синең!

— Бер дә борчак түгел, — диде Фоат житди итеп. — Йөгерешчегә бот озынлыгы нигә? Җиңел булсын ул. Ә мин җил шикелле — очам гына!..

Шуннан соң алар очраша алмадылар. Муса, Казанга килгәч, аны эзләштереп караган иде, ләкин аның күптән вуз бетереп, кайдадыр юллар төзүче инженер булуын гына ишетә алды... Димәкки, ул да монда булып чыга... Әхмәт Симай да әйбәт комсомолец һәм Мусаны ярата торган егетсыман күренә иде. Тик хәзерге очрашуда аның төрлечәрәк сөйләвен генә, ничектер, аңлап булмый. Юк, аның итәгеннән бик нык тартырга кирәк булыр әле!

Муса шулай алар белән күңелленнән сөйләшеп ята торгач, бу егетләр аның як-ягына килеп бастылар. Дусларча елмаешып, бар да аңа кул сузып торалар һәм үзләренә чакыралар кебек иде. Мусага ничектер җиңел булып, авыр уйларындагы томан пәрдәләре ачылып киткәндәй тоелды... Әйе, язның кар өстендәге беренче зәгыйфь һәм сукыр гөрләвеге дә, эзләнә торгач, үзенә юл таба һәм гөрли-гөрли ага башлый, озак та үтмәстән ярларга тулып, көчле ташкынга әйләнә!..

Якындагы Вустрау авылыннан әтәч тавышы килде. Мусаның бу якын һәм җан рәхәте бирә торган тавышны ишетмәгәненә йөз ел бар кебек иде инде. «Кара, монда да әтәч бар икән... — дип гаҗәпләнде ул. — Ничәнче әтәч соң бу?.. Ничәнче?..» һәм ул йоклап китте.

*(Дәвамы бар.)*

*Рәшит Гәрәй*

## Үзәннәрдә йөрим

Җир авазы тыздан ишетелер
Уҗымнардан, яшел үләннән...
Буразнада үскән дусларымның
Карашлары ерак төбәлгән.

Рәшәләре күзне камаштыра,
Офыкларга карап туймассың!
Күкрәгемне ачам... Хисләрем дә
Рәшәләргә кушылып уйнасын!

Төн йокысын җуйган игенченең
Хыяллары — басу түрендә:
Таңда әмер көткән солдат кебек
Әзер тора язгы һөҗүмгә.

Окобында посып калганнарны
Гафу итмәс күңеле берсен дә.
...Йокласа да, кырда арышларның
Тирбәлүен күрә төшендә.

## Яшел чирәм кебек бәбкәләр

Яшел чирәм кебек яшь бәбкәләр
Сабый чагым искә төшерә.
Бәбкә саклап йөргән гамьсез еллар
Кире кайтса икән кешегә...

— Ташла, юләр, әллә кайчан узган
Вакытларны уйлап саташма.
Сабый чагың, әнә, улыңа күчеп,
Сөенә-сөенә бәбкә ашата.

## Ялан аяк чыгып чабарга

Әй, кыстыйлар аны авылларга,
Үгетлиләр: шигырь укырсың.
Ә ул, никтер, һаман риза түгел,
Игеннәргә гыйшкы юкмы соң...

Басуларга яңгыр ява диеп,
Хәбәр килде кайсы арада...
Шагыйрь әзер ерак үзәннәргә
Ялан аяк чыгып чабарга.

## Болыт булсаң

Саф җилме син?.. Әгәр саф җил булсаң
Теләгемне синнән яшермәм:
Сабый чакта әнкәм назлагандай,
Йомшак кына сыйпа чәчемнән.

Әллә инде таңда калка торган
Йолдызымы син минем күгемдә...
Йолдыз булсаң, барыр юлларымны
Яктыртып тор гомер-гомергә.

Ә бәлки син, миңа күренмичә,
Куерырга торган болыттыр...
Болыт булсаң, яңгыр булып яу да,
Сөюемне сүндер, оныттыр.

*Ибраһим Салахов*

# КҮКЧӘТАУ ДАЛАЛАРЫНДА

## Романнан өзек

## Пролог

Башыннан Кара таудың күч[1] киләде,
Күчкән саен бер юрга ат буш киләде.
Аерылу туышлардан[2] яман икән, —
Мөлдерәп ике күздән яшь киләде.

*(Казакъ халык җыры.)*

— Я, тәңрем!..

Бол дөньяңды юктан бар кылдың. Асмандагы коштарга, судагы балыктарга, даладагы киектәргә, җанвардарга, адәм заттарга җан бирдең. Синең күңелең ак, рәхимең мул, мәүлем! Кара төндә яктыртып асманга ай белән җондызлар яктың.

Анау җаткан аскар[3] таудар, яшел җефәк кигән сылу агачтар, төн җоктамый куанып, сайрап торган былбылдар, тургайдар... Эчсәң туялмас, суы кәүсәр болактар... Толпар ат белән атылып очканда бер җагыннан бер җагына җитә алмаслык хәйран киң дала.

Болар, кодрәтең мул ходаем, безгә биргән өлкән сыең. Без сиңа көнтөн дога кыламыз, шөкер әйтәмез. Уемызда безнең кер җок, таш болактай саф. Гөнаһыбыз булса, хатамыз булса, кичерә күр, рәхимеңнән ташлама, тәңрем, газиз мәүлем! Брак, айткан сүзем көфер булмасын, ходаем, далаң бүген өлкән кайгыда...

Монау, яктырып туып килгән көннең күзе бүген казакъ даласына куаныш булмады, гой, ялгызымыз...»

Йөрәктән сызылып, сыкранып чыккан зарлы дога тәгәлләнмичә өзелде. Саргаеп кипкән кылганга тезләнеп утырган, ике кулын күккә күтәргән чал казакъ Ходайбирген әкә өчпочмаклы томак бүрек кигән башын авырлык белән генә көнчыгышка борды. Аның картлыктан һәм ачлыктан суырылган, тиресе җыерчыкланып сөяккә ябышкан куллары калтыранып, бармаклары саксаул ботакларыдай катып, бөгелә алмыйча, берберсенә кушыла алмыйча тырпаеп дерелдиләр. Күз кабаклары шешеп, салынып төшкән. Күзләре күренми. Бары сирәк-мирәк укмашып каткан саргылт төкләр генә керфек булуын төсмерлиләр. Бәлкем, Ходайбирген әкә әле яңа гына үзе укыган доганың, ялваруларының бөек җаббарга ирешүен һәм көтмәгәндә далада могҗиза пәйда булып, янгыр ява башлавын күрергә тырышып тәмле калгый торгандыр? Бәлкем?..

Кызганычка каршы — юк. Ул күзләр инде бик күптән даланың хәйран матурлыгына соклана алмыйлар. Алар инде моннан утыз еллар элек Кинәсары ханның зәкәтчеләре камчысыннан сүнгән. Ләкин адәм

[1] Күч — бәла-казадан качып баручылар.
[2] Туыш — туганнар.
[3] Аскар — биек.

баласы күрүдән туктый аламы соң! Маңгай күзләре сүнү белән күңел күзе кабына — кеше үзенең барлык әгъзалары белән, кан тамырлары белән сизә, тоя башлый. Күңел күзе тоеп сызланудан да дәһшәтлерәк тагын нинди газап бар соң бу җир өстендә?!.

Кайгы — йөрәккә батып, кисеп кергән агулы хәнҗәр. Ул ачу булып ташый, хәлсезләнеп егылган кешеләрне дә аягүрә бастыра. Бәлкем, бу соңгы күтәрелү, соңгы омтылыш, әгъзаларның иң соңгы хәрәкәтләнүедер. Менә хәзер дә шундый газаплы-ачынулы бер талпыну булып алды. Ходайбиргән әкәнең салынып төшкән кабаклары көнчыгышка борылу белән бер тартылдылар, бер җыерылдылар, укмашкан керфек кылчыклары тетрәнделәр. Карындык төсле саргаеп куырылган, эчкә баткан төксез яңаклар буйлап эре-эре тамчылар тәгәрәде. Алар ияк очына гына асылынган сирәк чал сакалга җыелдылар да калтыранып керле көпегә — бишмәткә тамдылар.

Нәрсәдән куркынды соң бу күрми торган дөм-сукыр күзләр? О, алар күрделәр, дала өстенә килә торган афәтне, аның барлык фаҗигале күренешләрен тетрәнеп күрделәр!..

Офыктан, утлы кармавычларын ерак ташлап, янып торган үрмәкүчсыман, кояш акрын гына югары үрмәли. Ул әле ялкынсыз, әмма шул кадәр кызып кабарган, аның шәүләсеннән бөтен көнчыгыш шомланып кызарып күңелгә куркыныч салып тора. Үрмәкүч акрын гына биеккә үрелә. Күк читендә адашып, тукталып калган болыт кисәкләре аның утлы пәрәвезләренә уралып көяләр — күгелҗем кара төсләрен ашыгып үзгәртәләр, кызаралар, яна башлыйлар, кинәт ялкынланып дала өстенә сузылалар.

Төн эчендә сүрелергә өлгерә алмаган һава яңадан кыза башлый. Үрмәкүчкә охшаган кояш ут шары булып кабарып, ялкынланып даланы көйдерергә тотына.

Менә шуның өчен дә, бүген бу туып килгән көнне дала башка вакытлардагы кебек куанып, балкып каршыламый. Җәйләүнең күрке һәм милке кылган, быел чак кына күтәрелгән дә, чәчәкләнә дә алмыйча, сабакта катып калган. Ә хәзер саргайган энәләрен тырпайтып дошманын күргән керпесыман тора.

Курыкмаслык та түгел, инде ике ел рәттән корылык. Күктән бер тамчы яңгыр таммый, күләгә төшми. Елгалар, болаклар, күлләр кибеп корыды. Үсемлекләр сулды. Күзнең явын алып, балкып торган чәчәкләр шиңде.

Елдагыча бәпкә чыгарырга ашыгып кайткан кошлар, канатларын көйдереп, оя ясарга урын таба алмыйча каңгырып, башка җирләргә очтылар. Боланнар, җойраннар, кыр кәҗәләре, кыр сарыклары сусызлыктан әлсерәп адаштылар. Җәйләүдәге мал чеметеп кабарлык үлән таба алмады. Ул гынамы?

Үткән кыш уртасында, көннәр кинәт җылынып, даладагы кар эри башлады. Берничә көн рәттән яңгыр яуды. Таулардан гөрләвекләр кузгалды. Катып, туңып көч-хәл белән җан саклап килгән кошлар, бу көтелмәгән җылылыкка куанып, тавышланып күккә күтәрелделәр. Иөзеп, берсен-берсе куып, чыр-чу килделәр. Далага көтелмәгән җанлылык һәм матурлык кайтты. Әйтерсең лә, яз башы.

Ләкин бу куаныч түгел, киресенчә, табигатьнең артык мәкерле һәм һәлакәтле шаяруы иде. Озак та үтмәде, чатнама суыклар башланды. Дала өстен пыяла төсле ялтырап торган калын боз каплады.

Тибендә йөргән елкылар, тояклары белән казынып, боз ватарга азапландылар. Тыгызланып яткан кылган боз астыннан күренеп ымсындырды... Ләкин катыдан-каты елкы тояклары да бу хыянәтчел боз катлавын ватып, күренеп торган кылганны иреннәренә тидерә алмадылар. Тояклар ярылды, тубыклар, сыйраклар канга батты. Елкы балалары хәлсезләнеп боз өстенә аудылар. Елкы артыннан ияреп, тибеннән кал-

ган үлән белән тамагын туйдыручы куйлар бер-берсенең йоннарын ашадылар.

Кышлаудагы барлык халык — карты-яше, хатын-кыз, бала-чага берсе калмый далага чыкты. Алар балта, көрәк, китмән, казык белән каһәрле боз катлавын ватарга керештеләр. Даланы каплап йөргән исәпсез күп малга боз астыннан чукып ачылган кылган туярлык азык була аламы соң?!

Бу бәла өстенә тагын күз ачкысыз бураннар башланды. Ачлыктан коры сөяккә калган, ләкин әле аяктан егылмыйча йөргән соңгы малны буран, өер-өере белән куып алып китеп, елга, күлләрнең бозлары астына илтеп төшерде. Өердән аерылганнары бүреләргә, шакалларга азык булды.

Далага дәһшәтле җот килде. Кичә генә ничә йөз өер елкы, меңләгән куй, йөзләгән дөягә хуҗа булган бай казакълар бармак белән генә санарлык кара мал белән калдылар. Ә гидәй казакъларның ялгыз-ярым маллары җотның беренче көннәрендә үк аякларын суздылар. Бу ел ләгънәтле куян елы иде. Казакъ халкын авыр бөлгенлеккә төшергән бу кара ел, соңыннан, өлкән куян исемен алды. Ул онытылмый. Аның кара күләгәсе соңгы елларга хәтле даланы тетрәтеп торды. Аксакал казакълар әле бүгенге көннәрдә дә, өлкән куян елындагы дәһшәтле күренешләрне искә алып, зар елыйлар.

— Батыр — бер уклык, бай — бер җотлык!

Бу мәкаль әнә шул фаҗигале елларның куркынычлы тавышы инде.

Менә шушы өлкән куян елындагы җотта казакъның урта йөздән килә торган ыруларыннан берсе булган Каравыл иле кара җәяү калды. Аның җәйләүләре мал үләксәләре белән чуарланды. Кышлау әйләнәләрендә яңадан-яңа каберләр калкып чыкты. Гүя җир, гарипләнеп, үзенең бөкреләрен чыгара башлады. Кышлау ташландык хәрабәгә әйләнде. Аңа төрле яктан ач бүреләр, шакаллар җыелды.

Элекке елларда төн йокламый мал саклап, туктаусыз өреп йөргән ышанычлы таза ау этләренең дә тавышы тынды. Моны сизеп алган бүреләр, шакаллар кышлауның уртасына ук өерелеп килеп улыйлар, ансыз да ачлык белән сызылган җәрәхәтле йөрәкләргә шом һәм куркыныч салалар иде.

Инде күп төнлекләрдән төтен чыкмый. Казаннар бер асым ит күрмичә тутыктылар. Сабалар кымыз татымыйча кибеп куырылдылар. Тәбәнәк түгәрәк өстәлгә ябылган дастархан буш — бавырсак, корт, эремчек, сыкма, тозлы майлар әллә кайчан бетте. Башка елларда җәй урталарына хәтле абдыраларда — сандыкларда өелеп ята торган карын-карын сары май, колгаларга, йон арканнарга эленеп куела торган каклаган симез казлар, мае тамып тора торган шоҗыклар хәзер бары төштә генә күрергә калды.

Өлкән куян елында Каравыл ыруының бик күп адәмнәре газаплы ач үлемгә дучар булып, үкенечле рәвештә менә шушы таш түбәдәге зиратка яттылар инде. Бүген бу ыруның әле үз аягында йөри алырлык хәлдә булганнары, соңгы тапкыр зиратка җыелып, үзенең кадерле ырудашлары белән бәхилләшәләр.

Каравыл ыруы күчеп йөри торган Алка күл җәйләве заманында үзенең гүзәллеге, бай утлаулары белән барлык казакъ даласында атаклы җәйләү булган.

Бу җирләрне халык яратып, мактап һәм горурланып Сары арка дип атаган. Аның турында акыннар, думбра чиртеп, җыр җырлаганнар:

— ...Сары арка — сайран [1] җирем — ай,
Табылмас хәйран илем — ай,
Көмештәй саф суы бар,
Айдай якты күлем — ай...

[1] Сайран — рәхәт, күңелле.

Таулары биек, даласы киң, җәйләве иркен, дастарханы мул була ул Сары арканың. Ләкин...

Данлыклы Сары арка бүген шулай кансырап, азапланып үлем белән тартыша. Ул инде беркемгә дә ярдәм кулын суза алмый һәм үзенең кадерле ыруларын, намуслы балаларын билгесез сәфәрдән борып алып калырлык хәл дә таба алмый. Аның көчле, шәфкатьле канатлары зәһәрле ялкын белән көеп өтелгән.

Каравыл ыруы бүген кузгала. Ул, ата-бабаларының данлыклы җәйләүләрен ташлап, билгесез, ерак илләргә юл тота. Менә шул ирексез, кайгылы сәфәр алдыннан бу ыруның өлкәннәреннән саналган Ходайбиргән әкә әрвахларга илнең соңгы догасын тапшыра:

— Тәңрем!..

Тагын зарлы, карлыккан тавыш кабатланды. Чал карт, калтыраган кулларын күккә сузган килеш, көнчыгыштан зиратка таба борылды.

Каберләр... Алар җир өстеннән аз гына калкып, ерткыч җанварларның өннәресыман, түмгәкләнеп торалар. Аларга быел кар да тукталмаган, үлән дә чыкмаган. Каберләр өстендә тамнар[1] да юк. Бары зират уртасындагы ләхете җимерелеп, балчыгы түбән иңгән бер кабер өстендә генә ялгыз таш багана. Аның башы түгәрәкләнгән. Ташның бит ягына яңа туган ай сурәте төшерелгән. Айдан түбәнрәк, уеп, гарәп хәрефләре белән ниндидер сүзләр дә язылган булган. Ләкин җил, яңгыр ул хәрефләрне ашаган, ташны шомартып ялаган. Хәзер инде анда нинди сүзләр язылганын да һәм бу кабергә нинди дәрәҗәле кешенең мәете куелуын да һич белә алырлык түгел. Таш үзе дә яртылаш җиргә бөкрәйгән. Әйтерсең лә, бу җансыз багана да, дөньядан бизеп, үз иреге белән кабергә керергә җыенган. Зират биек үр өстендә. Аның әйләнә-тирәсе кыргый ташлар белән коршалган булган. Әмма хәзер ул ишелгән. Бүген менә шушы каберстанны халык ураган.

Алдынгы сафта — аксакаллар. Алар, әрвахларга хөрмәт йөзеннән бу изге туфракта тезләнеп торырга тиеш булсалар да, карт сөякләренең сызлануына, чатнавына түзә алмыйча, аякларын бөкләп утырганнар. Аларның башларында өчпочмаклы зур томак. Томакның колаклары эчкә бөкләнгән. Өсләрендә — көпе-чапан. Бил киң каеш билбау белән буылган. Бай һәм дәрәҗәлерәк чалларның бил каешлары көмештән эшләнгән төрле төймә, ай-йолдызлар һәм асылма калта-янчыклар белән бизәлгән. Аякларда күн читекләр. Кәвешләрне зиратка якынлашканда, үр битендә, салып калдырганнар. Аксакаллар башларын түбән иеп, күзләрен ярым йомып, тирән уйда — догада калгыйлар. Алар арасында ап-ак гөмбә кебек булып, башларына зур урамал яулык ураган кимперләр — карчыклар күренә. Алар да аксакалларга охшарга тырышып җиргә иелгәннәр.

Икенче сафта карасакаллар — ир уртасы казакълар. Аларның кайсы томактан, кайсы бәрән кырпулы очлы бүректән. Өсләрендә — ала-кола чикмән, бишмәт. Уң кул астында, җирдә — камчы. Кашлар җыерылган, күзләрдә ачу катыш ямансылау. Алар Ходайбиргән әкәгә карап, тезләнеп катып калганнар.

Өченче сафта — ничек туры килде шулай утырган урта яшьтәге хатыннар. Алар, бит урталарын гына ачык калдырып, койрыклы кимәчәкләргә[2] уранганнар. Хатыннарның алдында, тирә-ягында — чебен булып сырышкан бала-чага. Аларның өс-башлары ертык, кайберләре бөтенләй шыр-ялангач. Алар аналарыннан нәрсәдер сорап тавышланалар, елыйлар, берсен-берсе чеметеп сугышып китәләр. Аптыраган хатыннар ачу белән тынгысыз балаларның башына сугып, төртеп җиргә чүктерәләр. Ә кечерәкләргә, көчләп, керле имчәкләрен каптыралар.

[1] Там — кабер өсте корылмасы.
[2] Хатыннар баш киеме.

Иң артта — яшь киленнәр, кызлар, буз [1] егетләр һәм яшүсмерләр. Киленнәр озын чәчәкле, бизәкле шәлгә уранганнар. Кызларның өстендә кып-кызыл, үтә яшел, үтә сары төстәге озын күлмәк. Күлмәк өстеннән билне кысып тора торган бикасап камзул кигәннәр. Камзулның изүләре, итәкләре алтын, көмеш ука белән каелган, бер пар гына кызыл, яшел, күк кашлы зур көмеш каптырма белән каптырылган. Башларында бәрхет такыя яки киң кырпулы ефәк тышлы бүрек. Аларга тәңкәләр тагылган һәм нәкъ түбәдә кабарып торган өкеләр [2] кадалган.

Егетләр юка итеп сырылган якасыз чапаннан, башларында тар кырпулы бүрек яки ак киездән тасмалар тегелгән аеры эшләпә. Каеш белән буган билләренә тубылгы саплы, тугыздан түгәрәкләп үргән камчы кыстырганнар. Яшьләр, гадәттә, җәйләүдән җәйләүгә күчкән вакытта кия торган бәйрәм киемнәрен киеп чыкканнар. Ләкин шуңа да карамастан, аларда элекке дәрт, кыюлык һәм гамьсез шаярулар юк. Ачлык яшьләргә дә үзенең кара күләгәсен ташлаган һәм алардагы тынгысыз ашкынуны сүндергән. Алар аптырап, нәрсә эшләргә белмичә, Ходайбиргән әкәнең хәрәкәтен күзәтәләр.

Халык кулларын югары күтәрде — кайсы тавышланып, кайсы иреннәрен генә кыймылдатып Ходайбиргән әкә артыннан доганы кабатлады, соңгы өмет белән аллага ялварды:

— ...Көннең күзеннән даламыз көйде. Күземезнең карасыдай күргән Алка күл корды. Җот малымызны кырды. Киң даланы безгә тар кылдың, мәүлем. Казакъның балалары бүген күз яшен болактай агыза. Син үзең күреп, ишетеп торсыңгуй, ходая... Монау торган таш түбәдә Каравыл иленең өлкәннәре — безнең аталарымыз, аналарымыз, бер карыннан туган карындашларымыз, хәләл сөтебезне аямаган балаларымыз... Анау мәңгелек дөньяда аларга иман байлыгын биреп, җаннарын җәннәттә кыл, тәңрем, илаһи амин...

Зарлы дога өзелде. Ходайбиргән әкә, томагын салып, ләхет ягы умырылып түбән ишелгән кабер ярына сәҗдәгә ятты. Дала кинәт ыңгырашып, ярсып китте. Зират буенда утыручылар елап, такмаклап, зарлап, иңрәп Каравыл ыруының иң кадерле җаннарын үзенең салкын кочагына алган җиргә — кара туфракка егылдылар. Кешеләр бер-берсен генә түгел, үз-үзләрен онытып, кабер туфрагын тырнап, кочаклап өзгәләнергә, еларга тотындылар. Бу көтелмәгән шау-шудан һәм ата-аналарының акылдан шашып җирдә аунавыннан коты очкан балалар җан тавышлары белән акрып елап далага качтылар. Аларга беркем дә игътибар итмәде, күрмәде. Зират өстендәге халык, үз йөрәген үзе тартып алып кабергә салырдай булып, йолкынды.

Дәһшәтле аһ-зар көчәйгәннән-көчәя барды. Дала елап, иңрәп газапланды. Ачлык белән сызылып сызланган, хәлен югалткан Каравыл ыруы — картлар, ир егетләр, кимперләр, яшь кызлар җан тетрәткеч ялвару белән җирдән-күктән, бер үзенә туксан тугыз исем: рәхимлелек, кодрәтлелек, гаделлек һәм дәһшәтлелек исемнәрен үзләштергән мәгъруp көчтән — аллаһе тәгаләдән ярдәм кулын сузуны, казакъ балаларын җот, ачлык тырнагыннан тартып алуны сорады.

Ләкин ул кул күренмәде. Илаһи көч бу аһ-зарны ишетмәде.

Ходайбиргән әкә сәҗдәдән торды. Калтыранган куллары белән капшанып томагын алды да башына каплады. Артык зарлы елаудан, газапланудан арыпмы, әллә югыйсә бу канлы күз яшьләренең һичбер файда китерә алмавына күзләре җитепме, халык җирдән башларын күтәрә башлады.

— Балалар, аттанаек! — Чал карт ашыгып урыннан торырга омтылды. Ике егет йөгереп килеп, Ходайбиргән әкәне култыклап урынынн

[1] Буз егет — өйләнмәгән егет.
[2] Өке — каурый бизәк.

торгыздылар да акрын гына ярдан түбән алып төшеп киттеләр. Башка ирләр дә урыннарыннан кузгалдылар. Бары кимперләр генә, каберләрдән аерыла алмыйча, битләрен тырнап, озак газапландылар. Тагын тавышланып зарлап еладылар, гүр өстеннән уч-уч балчык алып күкрәкләренә яшерделәр.

Үр астында, Алка күлнең сусыз уйсулыгында, юлга хәзерләнгән — йөк төялгән атлар, дөяләр күптән көтеп торалар иде инде. Ходайбирганэкәне култыгыннан күтәреп атка атландырдылар. Ул кыйблага карап тагын бер кат дога кылды да атының тезгенен тартты.

Кәрван кузгалды. Алдан — пар үркәчнең ике ягына йон арканнар белән урап бәйләнгән киез өй кормалары, кирәгәләр, киезләр, уклар, чаңгыраклар һәм башка йөкләрен акрын гына тирбәлдереп дөяләр атлады. Кайбер дөяләрнең үркәчләренә казан төсле итеп төрелгән киезләр утыртылган. Алар эчендә кимперләр, яшь балалар чайкала. Дөяләр артыннан сыңар атка дугасыз, камыт белән генә җигелгән ике тәгәрмәчле арбалар тезелгән. Тәгәрмәчләр кеше буеннан да биегрәк, үз гомерләрендә бер генә тапкыр да кучәрләре майланмаганга алар шыгыршыгыр килеп, сыкранып ирексез генә әйләнәләр. Бу арбаларга биек итеп тусь агачлар — җыелма агач караватлар, казаннар һәм башка хуҗалык әйберләре төялгән. Арбаның астына тире чиләкләр, турсыклар асылган. Картлар, ир уртасы адәмнәр артта. Калган халык, хатын-кыз арбалар артыннан җәяү атлый. Кайда соң ул ярсып, берсен-берсе узып оча торган тулпар атлар?! Кайда ул элекке вакытларда җәйләүгә күчкәндә була торган бәйгеләр, күкбәр алулар? Кайда соң ул көннәрнең шау-шуы?!.

Кояш ашыгып югары күтәрелде.

Ә кәрван, аңа үч иткәнсыман, төньякка карап юл тотты. Кәрван алдында — озын кара күләгәләр. Әйтерсең лә, алар алдагы, билгесез язмышның шомлы шәүләләре булып сузылганнар. Ләкин ул күләгәләргә беркем дә игътибар итми. Чөнки һәрбер кешенең күңелендә бу күләгәләрдән дә караңгырак кара кайгы утыра. Каравыл иле хәзер шомлы бер тынлык эчендә, авыр хәсрәт белән кышлавын, ничә язлар, җәйләр күчеп йөргән җәйләүләрен ташлап, кайчандыр күз кебек тулып торган, хәзер исә кибеп беткән күленнән аерылып, иң кадерле кешеләрен мәңгелеккә үзенә алган зиратны калдырып, билгесез язмышка атлый.

Нәрсә көтә аларны алда?

Бәхетме? Әллә тагын да дәһшәтлерәк һәлакәтме? Шатлыкмы? Әллә йөзеп чыга алмаслык кайгы диңгеземе? Нигә, нигә бу юлсыз юллар куркыныч шобага булып уралалар?!.

Исәпсез күп тояклар, шыксыз зур тәгәрмәчләр кузгалып китүгә, көл төсле күпереп торган туфрак соры төтен булып күтәрелде. Кәрван шул тузанга күмелеп, чайкалып, таралып китеп билгесез алга атлый, әйтерсең лә, оялары туздырылган кошлар!

Каршыдагы үр өстендә өй булып күтәрелгән ак таш. Шул таш өстендә адашып килеп утырган ялгыз бер яшь карагай. Ул әле бөтенләй сабый, яшькелт энәләре ефәк төк булып кына калыкканнар. Ул бер үзе, ялгыз-ялгызак. Нинди рәхимсез юлаучы аны туган ыруыннан адаштырган. Кем аны ялангач дала читендә, таш өстендә үксез бала итеп калдырган. Кем? Кояш күтәрелә, утлы укларын ялгыз сабый өстенә ташлый... Кайда агаларның калын, киң күләгәләре? Кайда ачы, суык җилләрдән саклаучы баһадир аркалар?

Менә шул ялгыз яшь карагай үреннән юл кинәт борылып уңга сузыла. Еракта, бик еракта ак болыт булып Бурабай, Күкчәтау тауларының үркәчләре күренә. Бәлкем, Каравыл балалары эзләгән бәхет шул гүзәл таулар күләгәсендәдер?

Кәрван акрынлап, чайкалып үрдән төшеп югалды. Аның артыннан күтәрелгән тузан, соргылт болыт булып, ялгыз карагай өстендә бик озак асылынып торды.

Бераздан күктә бер зур бөркет күренде. Ул үзенең тутыккан соргылт канатларын киң җәеп, салмак кына кагып, зират өстендә әйләнде. Кинәт канатлар катып, асылынып калдылар. Бөркет комсыз үткер күзләре белән җиргә текәлде. Даладан җанлы ризык эзләде. Ләкин җир өстендә үлем тынлыгы. Бер генә дә хәрәкәтләнгән җанвар күренми. Хәтта сукыр тычканнар да йөгереп үтмиләр. Йомран да өне өстенә чыгып, алгы аякларын күтәреп сызгырмый. Бөркет — күзләренә ышанмады ахрысы, таш булып җиргә ташланды, гүр туфракларына сугыла язып чайкалды да тагын күтәрелде. Ул әйләнде, һәрбер түмгәкне күзеннән сөзеп үткәзеп, тагын ачу белән күккә очты.

Җил исте. Тубылгыларның корган ботаклары бер-берсенә кагылып кыштырдадылар. Җил ниндидер бер ят ис алып килде. Әрем исе. Юк, көек исе! Озакламый Найзатумар ягыннан, Каравылның ташландык кышлау курганнарыннан төтен күтәрелде. Көйрәп торган далага утлы елан булып ялкыннар үрмәләде. Дала яна башлады.

Бөркет зират өстеннән тагын да берничә кат урады да, корбан табудан өмет өзеп, ахры, канатларын авыр кагып, кәрван киткән якка борылды. Ишелеп яткан гүр туфраклары өстеннән шомлы кара күләгә үтте.

## I

Мең тугыз йөз илле бишенче елның унөченче май көне иде...

Җил автомашина өстенә ябылган сырма капотны юл буенча тартыпйолкып килде-килде дә, бер борылышта кинәт күтәреп алып китеп, күздән югалтты. Машина туктады. Кабина тәрәзәсе алдындагы автомат щетканың туктаусыз уңга-сулга авышып пыяланы сөртеп торуына да карамастан, юл бөтенләй күренми башлады. Бары үкереп, кайчак ачы сызгырып машинага ташланган җил тавышы гына ишетелде. Карның яуганы да күренми. Ул туктаусыз, көчле ташкын булып ишелә, өердән яңа гына алып кайтылган айгырсыман бер урында уралып дулый да дулый иде.

Моторның калтыранып гөрелдәве тынды. Автомат щетка тәрәзәне соңгы кат сөртеп, ярты ай сызып узды да туктап калды. Кабинаның сул як ишеге тар гына ачылып, солдат фуражкасы кигән, куе кара сакаллы кешенең башы күренде. Мөгаен, шофер юлны карарга омтылган иде, — булмады: җепшек кар укмашып биткә сыланды. Ишек ашыгыч ябылды. Җил, ачу иткәндәй, вак ком бөртекләре китереп сипте, сыздырып, камчылап үтте. Ишек тагын ачылды, шофер бу юлы арты белән төшә башлады. Ләкин кирза итекләр басмага нygытып басарга өлгермәделәр, җил уралып килеп ишекне каерып җибәрде. Аяклар таеп китте, шофер чайкалып кар өстенә барып төште.

— Зинһар ябыгыз! — Кабина эченнән кискен тавыш ишетелде. — Баланы харап итәсез бит, ябыгыз дим ишекне!

Шофер, сикереп торып, кабина ишеген япты.

Кабина эчендә утырган хатын, өстендәге җәйге юка пальтосы белән баласын урап кочып, башындагы мамык шәлен алга ук төшереп, үз сулышы белән сабыйны җылытырга тырышты. Бала мышнап, тәмле ару белән йоклый. Табигатьнең рәхимсез афәте аны тынычсызламый. Ана куены һәрвакыт җылы һәм хәвефсез була ич... Хатынның аягында резина бота. Ул аларны бер-берсенә сугып, аягын җылыта, баланы тирбәтә, вакыт-вакыт калтыранып, иңнәрен селкетеп ала.

Шофер иң элек итекләре белән типкәләп көпчәкләрне тикшереп чыкты, аннары арткы тәгәрмәчкә басып, кузов өстенә күтәрелде.

Йөк өстенә ябылган брезентның кабина як очы ачылып, башлыклы плащ кигән күзлекле кеше күренде. Ул аягына басарга өлгермәде, җил каршы яктан сугып, аны кар баскан йөк өстенә екты. Шофер нидер кычкырды, ләкин җил аның тавышын бөтенләй икенче якка кар белән бергә туздырып алып китте. Күзлекле кеше тезләнеп торды, мүкәләп кузов кырыена хәтле килде, җилгә аркан торып, аягүрә басты. Йөк өстеннән тартылган арканга тотынып шофер да аңа таба үрмәләде. Алар икәүләп брезентның бер почмагын ачтылар да астан ике тимер көрәк, түгәрәкләп уралган тимер чыбык бәйләмен чыгардылар. Шофер, кар астында казына торгач, зур гына брезент кисәге һәм иске бер телогрейка тартып алды. Көрәкләрне, тимер чыбык бәйләмен көрткә ташладылар. Шофер, көч-хәл белән телогрейканы өстенә киеп, брезент кисәген култык астына кысты. Икесе дә кузовтан төштеләр. Шофер, карга ташланган коралларны җыеп алып, җитез генә машинаның алдына чыкты. Плащлы кеше, көрттән аякларын ала алмыйча, озак кына азапланды. Ул уң аягын чыгарып, сул аягын ике кулы белән күтәреп алга бастырды да шуннан соң гына атлап китә алды.

Юлчылар тәгәрмәчләр алдына өелгән карны көри башладылар. Буран элеккедән дә көчлерәк тузынды. Карны гына түгел, көрәкне дә бер яктан икенче якка чайкады. Баскан җирдә көрт үсә. Алда бер нәрсә дә күренми. Керфекләр бозланып бер-берсенә ябышалар. Бит алмалары кызып яна. Кинәт җил чигенгәндәй булды. Аз гына тынды. Ике юлчы, шул арадан файдаланып, мотор өстенә брезент ташлап, почмакларын тимер чыбык белән бәйләргә ашыктылар. Ләкин җил брезентның бәйләнеп җитмәгән чабуына ябышты һәм йолкып, очыртып алып китте.

Түбәсе балчык белән ябылган тәбәнәк саман кураның урам як капкасы шыгырдап ачылды. Ишелеп кергән буранга каршы иярле ат җитәкләгән хатын чыкты. Аның уң кулы тезгендә, сул кулы башына бөркәнгән чапанны кысып тоткан. Хатын, атны җилгә арт белән борып, өйнең почмагына ышыкланды. Ат җылы курадан буранга чыгуга тынычсызланды, башын чайкап пошкырып куйды. Капкадан икенче кеше чыкты. Аның башында иңнәренә төшеп торган өчпочмаклы зур томак, өстендә озын көпе, биле киң каеш билбау белән буылган. Аягында башлары очланып күтәрелгән пайпаклы итек. Кулында зур корык. Корыкның очына йон арканнан элмәк бәйләнгән. Кеше юеш карда тая-тая ат янына килде дә тезгенне сул кулына алды, корыкны хатынга бирде:

— Ал, ходайга тапсырып, аттанаен. Моңа буранда елкының чыгып китүе бар, гуй.

Ир кеше, калын киемнән булуына карамастан, җитез генә ияргә күтәрелде, өзәнгеләрне рәтләде, хатын корыкны сузды.

— Җулың уң булсын.

— Айтсын!

Атка атланган кеше корыкның элмәген сул беләгенә элде дә тезгенне тартты. Ат, башын күтәреп, җитез генә кузгалды. Озакламый алар, буранга күмелеп, күздән югалдылар. Хатын пышылдап дога укый-укый курага таба атлады.

## II

Гайшә, тыштагы буран төсле туктаусыз өерелгән уйларыннан арынырга тырышып, юрганын башыннан ук ябынды да күзләрен чатырдатып йомды һәм иреннәрен чак-чак кына кыймылдатып үз-үзенә йокы чакырды: «Мин йоклыйм, бер нәр-сә-дә... уй-ла-мыйм. Бер-ике-өч-дүрт. Йок-лыйм...» Ләкин уйлар, язгы бозлар кебек, бер чумып китеп, бер калкып чыгып тагын җыела, тыгызлана башладылар. Баш чыңлап, чат-

нап китте. «Кем ул? Кайда ул? Нигә миннән, унҗиде ел буена, туган әтиемнең исемен яшерәсең? Әллә?..» Гайшәнең күзләренә яшь тыгылды, бөтен тәне туңып, чымырдап китте. «Юк, юк, бәгырем!» Ул үксеп, елап, мендәргә йөзтүбән капланды. «Әйтмә, әйтмә алай! Син... син ташландык бала түгел, түгел, җанкисәгем Зәйтүнә!..»

Кинәт өй түбәсендә нәрсәдер каерылып, шалтырап күтәрелде дә гөрселдәп бакча эченә ауды. Саман стеналар селкенеп китте.

— Әни! Әни дим!

Гайшә сискәнеп урыныннан сикереп төште, өстәлдәге кысып куелган унлы лампаның филтәсен күтәрде. Каршыда — стена буендагы кечкенә караватта — куркып уянган кыз бала. Сабый әле йокылы-уяулы, күзләрен дә ачып җиткермәгән. Ләкин ул нәни куллары белән капшанып нәрсәнедер үзеннән этәреп җибәрмәкче була:

— Өй җимерелдеме, әни?

— Юк, юк, курыкма, Алмагөл, — Гайшә йөгереп килеп, кочаклап, кызны мендәренә салды, — мин бу — әниең, курыкма, колыным.

Озын кара керфекләр күтәрелде, чак кына кысынкы күзләр гадәттәгедән зуррак булып аптырап карадылар. Ике бөртек кара карлыган лампа яктысына чагылды. Алмагөл күзләрен тагын бер кат йомып ачты, балаларда гына була торган сөйкемле бер ышанучанлык белән елмайды, ике кулын сузып анасының муенына сарылды.

— Син китмә, әни! Мин яман төш күрдем, куркам. Минем янга ят, әни.

— Ярый, ярый! Ятам, алтыным. — Гайшә кызының кулларын акрын гына кулларыннан ычкындырып, үзе дә аның янына кысылды. — Курыкма, йокла. Ул — җил шулай тавышлана.

Өй түбәсеннән тагын нәрсәләрдер шуып төшеп тәрәзә яңагына сугылдылар, челпәрәмә килеп ватылдылар. Ана куенына кереп иркәләнгән Алмагөл бу соңгы сугылуларны ишетмәде, изрәп йоклап китте. Гайшә сагаеп тыңлады, дөбердәү кабатланды. «Шифер! Шифер җимерелеп төшә. Чатырны алып ташлаган икән, каһәр суккан буран!»

Күз алдына ак палаткалар һәм суыктан бөрешкән кешеләр килеп басты. Уйлар икенче агыш алдылар. «Мин әле җылы түшәктә, әзер ашта. Ә совхоздагы халык?! Мескеннәр, мондый буранда нишлиләр икән? Бу нинди афәт булды соң? Тояк инде унбиш көн өйгә аяк басмады. Әллә, иртәгә көн ачылса, «Алка күл»гә барып кайтыргамы? Бу арада кайната да хәбәр китерми. Юк, иртәгә, соңгы дәресләрне Арсланбиккә тапшырып, Тояк янына барып кайтмыйча булмас».

Керфекләргә йокы кунмады. Гайшә, арып, аптырап, караваттан төште.

Алмагөл иреннәрен күпертеп, мыш-мыш сулый — гамьсез йоклый. «Нинди рәхәт чак!» Гайшә үз кызына үзе сокланып, аның иркен, тигез сулыш алуына карап, куанып елмайды, иелеп Алмагөленең битеннән үпте, шуып төшкән юрганын күтәреп япты, читләрен матрац астына кыстырып куйды.

«Инде нишләргә икән? — Әйтергә дә өлгермәде, сискәнеп төчкереп җибәрде. — Әбәү! Баланы үзем куркытып уятам, ахрысы».

Ул тиз генә мич куышында торган киез итекләрен алып киеп, җилкәсенә җылы халатын салды да өстәл каршындагы урындыкка барып утырды. Өстәлнең бер кырыенда — пөхтәләп өелгән китаплар, икенче кырыенда — дәфтәрләр. Уртада, күзге алдында — озынча хрусталь ваза. Анда берсеннән-берсе матуррак кыңгыраучыклар — умырзая чәчәкләре. Аларның һәрберсендә үзенә генә хас бер төс чагыла. Бу әле яңып торган җете төсләр түгел. Аларда — сабыйлык, туып килә торган матурлыкның гүзәл шәүләсе генә. Ләкин бу кыңгыраучыкларда никадәр җылылык, никадәр самими шатлык — яз шатлыгы бар! Гайшә әле кичә генә бу умырзаяларны даладан җыеп алып кергән иде бит. Нинди

матур, кояшлы, чәчәкләре белән балкыган хуш исле яз иде кичә далада... Халык тирләп-пешеп, беренче буразналарга бодай сибә, чын-чыннан сабанда сайрашып, ярышып эшли һәм өр-яңа ындырларда беренче мул уңышны — гәрәбә бодай өемнәрен күрергә өметләнә иде түгелме соң?

Тәрәзә рамнары тагын дерелдәде. Җил аларны суырып алырга теләгәндәй тартты, йолыкты, аннары бар көче белән этәреп җибәрде. Вак боз кисәкләре ком булып тәрәзә пыяласына сибелде. Мичнең капкачлары тартылып сугылып куйды. Морҗада кеше күңелен пошыра торган улауга охшаш шомлы бер тавыш туктаусыз шыңшыды. Йокларга да, эшсез уйга бирелергә дә мондый төндә куркыныч иде. Гайшә өелеп торган дәфтәрләрнең иң өстәге берсен алып, алдына куйды, ачты. Баш юлда эре, тигез хәрефләр белән «Корыч ничек чыныкты» романында Павел Корчагин образы» дип язылган. Яңа юлдан шундый ук ачык, пөхтә хәрефләр белән текст башлана. Гайшә һәр сүзгә, тыныш билгеләренә тукталып, тикшереп укырга һәм ара-тирә кызыл кара белән төзәтмәләр ясарга тотынды.

Өч дәфтәрне тикшереп чыкты да тукталды. Бармаклары бушап китте, каләме тәгәрәп өстәлгә төште. Ул, ике кулы белән чигәләрен кысып, үзе дә сизмәстән уйга чумды.

Инде икенче көн менә шулай. Гайшә вакыт-вакыт кайда икәнен, нәрсә эшләгәнен дә белмичә зиһенен югалта. Бүген менә мәктәптә, дәрес вакытында, бер укучысын торгызып, Николай Островскийның иҗаты турында сөйләргә кушты. Кыз, ашыгып, бар белгәнен сөйләде. Сөйләп бетергәч, бәя көтеп укытучысына кыюсыз гына карады: «Сез минем җаваптан ризамы?» — янәсе. Ә укытучы башын түбән игән дә эндәшми. Мескен кыз бик озак басып торыр иде, чеңгелдәп кыңгырау шалтырады. Гайшә, сискәнеп китеп, укучыларына тәнәфескә чыгарга рөхсәт бирде. Нинди бәйләнчек уйлар борчый иде соң аны?

Куллар чигәдән ычкындылар да акрын гына өстәл тартмасын ачтылар. Зәңгәр конверт. Хат! Гайшәнең Ташкент унъеллык мәктәбендә укучы кызы Зәйтүнәдән килгән хат. Ана бу хатта язылган сүзләрне инде күңелдән белә. Ләкин ул аны тагын укый.

Хатның беренче битендә язылган сүзләр күңелле, хәтта куанычлы да. Зәйтүнә барлык фәннәрдән бишкә генә укуын, хәзер инде аттестат алу өчен имтиханнарга хәзерләнүен язган. «Әни, мин дә синең юлдан китәргә, укытучы булырга уйлыйм. Без, дустым Сәгадәт белән, педагогия институтына укырга керергә гариза бирергә җыенабыз. Син каршы түгелдер бит, әнкәй?» Бу юлларны укыганда Гайшә чын күңелдән куана һәм горурлана. Аның кызы Зәйтүнә инде югары мәктәп ишеген ачарга тели, белемгә үрелә. Нинди ана моңа шатланмас? Ә менә икенче биттәге юллар?..

«...Автобиографиямне язарга утырсам, аптырап калам. Кем соң минем әтием? Кайда ул? Нинди кеше булган ул? Нигә миннән унҗиде ел буена туган әтиемне, хәтта аның исемен, фамилиясен дә яшереп киләсең? Син кызыңны гафу ит, әни. Мин инде сабый түгел бит. Төшенәм. Әллә? Әллә мин законсыз туган ташландык баламы?..»

Ике тамчы кайнар яше хат өстенә тамды. Хәрефләр җәелеп, берберсенә кушылып, күгелҗем тапка әверелделәр.

— Син хаклы, ләкин... — Гайшәнең тыны кысылды. Бугазга ниндидер төен тыгылды. Ул буылып йөткерде дә тагын кабатлады. — Ләкин әтиеңнең язмышын мин үзем дә белмим бит, акыллым...

Кинәт ул нәрсәнедер хәтерләгәндәй башын күтәрде, почмакта торган китап шкафына җентекләп карады, аннары, борылып, стена буендагы сандыкка карашын туктатты.

— Мөгаен, шушында.

Гайшә торып сандыкны ачты да аның эчендәге кием-салымнарны

ашыгып идәнгә бушата башлады. Озак та үтмәде, сандыктагы барлык әйбер идәнгә өелде.

— Менә ул!

Гайшәне телгә китергән бу әйбер катыргы папка иде. Идәндәге кием-салым киредән, рәтле-рәтсез рәвештә, сандыкка тутырылды. Гайшә сандыкны япты да, аның өстенә утырып, кулындагы папканы ачты. Аның эче буп-буш, озак еллар ятудан ул инде саргая да башлаган. Папканың буш булуы Гайшәне гаҗәпләндермәде, ул ике катыргыны бергә кушып ябыштырган тасманың өске катлавын ертып, папканың уң як каплама катыргасын ачты. Аннан юка гына бер блокнот чыкты. Институтта укыганда күп кенә студентлар истәлек альбомнары, көндәлек дәфтәрләр язу белән мавыгалар иде. Гайшә алар белән кызыксынмады, артык мәшәкать санады. Ләкин язмыштан узмыш юк икән... Беренче мәхәббәт аның кулына да каләм тоттырды. Дөрес, ул, башка тиңдәшләре кебек, шигырьләр, җырлар язу дәрәҗәсенә кадәр барып җитә алмады. Шулай да беренче хисләр, икеләнүләр һәм газаплы кичерешләр, күңелгә сыеша алмыйча, кәгазь битенә дә күчәргә теләделәр.

Бу блокнот шулай уйламаганда башланган иде һәм ул нәкъ шулай ук бер дә көтмәгәндә төгәлләнмичә өзелде дә. Язмыш бөтенләй башка, тар һәм тайгак тыкрыкларга борылды. Инде бу блокнотны дәвам иттерү түгел, аның башкалар күзенә эләгүе генә дә Гайшәгә тагын да яңа бәла өстәве мөмкин иде. Блокнотны бөтенләй югалтырга йөрәк кыймады. Нинди вөҗдан беренче мәхәббәтнең изге истәлеген таптап үтәргә рөхсәт бирә алыр?! Гайшә бу язмаларны яшереп, иң авыр шартларда да югалтмыйча, саклап килде.

Менә бүген, унҗиде елдан соң, шул блокнот яңадан ачылды.

«...Кызлар, сезнең кайсыгыз Гайшә?

Тамара — тапкыр, Клара белән мин уйланып алганчы, ул җавап та биреп өлгерде:

— Кайсыбыз матуррак, шунысы Гайшә булыр. Абайлабрак карагыз әле, иптәш командир.

Без, баскычта тукталып калып, култыкланган килеш көлешә башладык. Юлыбызны кисеп туктаткан егет үзе дә аз гына кызарды, ләкин каушамады.

— Ялгышасыз, мин командир түгел, студент.

Тамара миңа терсәге белән төртте дә чакырылмаган кунакны капшый башлады:

— Кайсы факультеттан?

— Тарих.

— Ничәнче курстан?

— Өченче.

— Күрше икән, — мин дә түзмәдем, сүзгә кысылдым, — ләкин сезне...

Тамара сүземне авызымнан йолкып алды:

— Шома егетне беренче тапкыр очратабыз.

— Алайса таныш булыйк: Сәет Батталов. — Ул һәрберебезнең кулын каты-каты итеп кысты, без исемнәребезне әйткән булдык. — Бераз йөреп килик.

Без авыз ачарга да өлгермәдек, Сәет, арабызга кереп, култыклап алып та китте. Дәрес арасындагы унбиш минутлык кына тәнәфес иде, еракка китә алмадык. Институт ишегалдындагы мәйданда гына арлыбирле атладык. Сәет үзе турында артык сүз кузгатмады, һаман шаярып, вак-төяк репликалар белән безне көлдерергә тырышты. Мин аптырашка калдым. Ничек инде, тиктомалдан, күрмәгән, белмәгән кызны — Гайшәне эзли. Минем исемемне кемнән белгән? Үзем кызыксынам, ә батырып сорарга кыюлыгым җитми...

Үзе болай буйга-сынга килешле күренә. Тулаем хәрби киемнән. Башында фуражка, өстендә хаки төсендәге гимнастерка һәм галифе чалбар. Аякларда ялтырап торган итек. Буйга миннән калку — мин аның жилкәсеннән генә. Йөзе түгәрәк. Мөгаен, бу аның тулылыгыннан, тазалыгыннан шулай күренә торгандыр. Күзләре... Мин ул вакытта Сәетнең күзләренә текәлеп карый алмадым. (Соңыннан гына мин ул яшькелт-күгелҗем күзләргә сокланып карый торган булдым.)

Бу кызык, табышмак очрашуны звонок бүлде. (Андый вакытта звоногы да артык тиз була бит аның.) Инде аудиториягә йөгерәбез дигәндә генә, Сәет минем кулымнан кысып: «Кичкә, аллеяда көтәм»,— диде...

...Тиктомалдан башны әйләндерде бит җүнсез егет. Лекцияләр дә колакка керми. Һаман уйланам. Ничек инде ул, белмәгән, күрмәгән Гайшәне эзли? Бәлкем, ул мине түгел, башка Гайшәне эзли булыр?!. Нигә эзли? Аңа нәрсә әйтергә тели? Минә авыртмас башка тимер тарак.

Тамара минем тынычсызлануымны сизеп алган да теңкәмә тия. «Кара, Гайшә, акылдан шашма. Хәрби кешеләр ухаживать итәргә бик оста булалар», — ди дә шаркылдап көлә башлый. Ачуланып урамга чыгам. Үзем кояш баеганны көтәм...

...Ниһаять, кич килеп житте. Йөгерәм. Нәрсә әйтер икән, нинди серләрен ачар икән бу табышмак егет?

...Әбәү, нинди боз йөрәкле кеше ул!

Мин аның белән артык сөйләшә алмадым, сикереп тордым да йөгердем. Бар көчемә йөгердем. Ярый әле — аллеяда берәү дә йөрми иде. Күрсәләр! Аның сүзләрен ишетсәләр! Бөтен институт гайбәтенә калыр идем бит. Мин тулай торактагы бүлмәмә кайтмадым, яр астындагы карлыганлыклар арасына төштем дә егылдым.

Нинди гарьлек, нинди гарьлек! Ул мине яратмый. Тамараны да, Кларaны да, берәүне дә... «Миңа ачуланма, мин мәхәббәтне белмим, белергә дә теләмим, акыллым», — ди.

Шул инде акыллы сүз буламы? Мин аңладым... Ул кеше түгел — таш!

...Менә инде бер атна ул һәр кич, ашханәдән чыкканда, мине гастроном чатында көтеп тора.

— Гафу итегез, — ди, чак кына башын иеп, елмая төшеп. Без, култыклашып, ашыкмыйча гына Ленин бакчасына таба атлыйбыз.

Нинди гаҗәп кеше ул? Һаман иптәш студенты Моратны мактый. «Ул — булган, ул — акыллы, ул — матур. Ә мин...» Шуннан китә тезеп үзен кимсетеп. Имеш, аннан пешмәгәнрәк кешене эзләп табуы да читен.

— Ярый, — дим мин, шаярган булып, — син пешмәгән, ә иптәшең Морат үтә пешкән. Алай булгач, нигә ул башлап миңа үзе сүз катмады. Яучылар аша сөйләшү заманы үткән инде.

— Чын мәхәббәт телне бәйли, аякларны тышаулый ул, — ди.

Әллә чыннан да шулай микән?

...Сәет мине иптәше Морат белән таныштырды. Морат — нәфис вак сөякле, ак чырайлы егет. Ул аз гына сөйли, бара-бара да онытылып уйга кала. Мин үзем дә характерым белән Моратка тартым. Юк, мин куркам. Ике уйчан бергә кушылса, тормышның ни яме булыр?!

Нигәдер дус кызларымнан читләшә башладым. Хәтта Тамарадан да, Кларадан да... Юк-бар хәйлә табып, аларны калдырам да ашыгам... Кая? Үзем дә белмим. Ялгыз йөрим, юксынам. Кемне? Күпме генә тырышсам да, мин күңелемне Моратка бора алмадым. Гаҗәп бит... Морат мине өзелеп сөя, газаплана. Мин аннан качам. Сәет гомумән мәхәббәттән баш тарта, ә мин аны эзлим... Мәхәббәт, нигә син шундый чуалчык юллар чатына куясың кыз баланы?

...Көтмәгәндә, китапханәдән кайтышлый, мин тубдиспансер янында Сәетне очраттым. Ул, башын иеп, күңелсез генә бара иде. Үзем дә сизмәстән йөгереп барып аның беләгеннән тоттым. Урам уртасында! Кешеләр ни уйлаганнардыр. Күрәсең, артык зарыкканмын. Ул минем бу тотнаксызлыгыма гаҗәпләнмәде дә, ачуланмады да, хәтта елмаймады да, атлавында дәвам итте. Аның йөзе агарган, кашлары сытылган. Ул еламсыраган бер тавыш белән:

— Гафу итегез, Гайшә, бик ашыгам, — диде дә, капылт борылып, аптекага кереп китте.

...Бүген кич нигәдер эчем пошты. Дәресләремне дә хәзерли алмадым, күңелсез... Боегып утыра идем, телефонга чакырдылар. «Мөгаен, Сәет... Кинога билет алгандыр», — дип куана-куана йөгердем.

Трубканы алсам — чыннан да Сәет.

— Мин, Гайшә... Вокзалдан... Морат авырып китте. Ашыгыч рәвештә Ялтага озатабыз... — диде дә көрсенеп трубканы куйды.

Барыйм дисәм, коеп яңгыр ява.

Нигә алданрак әйтмәде икән?

...Мин, мин гаепле. Мин үземнең вөҗдансызлыгым белән кичерелмәс җинаять эшләдем. Тыела алмыйча елыйм, ләкин күз яшьләре үлгән кешене терелтә аламы соң? Нигә, нигә мин Моратның саф мәхәббәтен кире кактым икән.

Ялтадан Моратның үлүе турында хәбәр килгәч, Сәет бик озак миңа күренмәде. Күпме төннәрне йокысыз үткәрдем, мендәрем күз яшемнән кипмәде.

...Мин бәхетле!

Юк, без икебез дә бәхетле. Кайберләүләр: «Мәхәббәт ул кыз белән егет булып йөргән чакта гына кайнар. Бергә кушылгач, ул көннән-көн сүрелә, ахырында күнегүгә генә кала», — диделәр. Мин менә шул сүрелүдән курка идем. Юкка гына икән. Сәет белән кушылуыбызга инде ярты елдан артып бара. Безгә тулай торактан аерым бүлмә дә бирделәр. Иптәш кызларым сокланып (бәлкем, кайберәүләре көнләшеп тәдер) карыйлар. «Сез нинди тату, күңелле, ага белән сеңел дә сезнең төсле тора алмас», — дигән булалар. Чыннан да шулай бит. Безнең бер-беребезгә булган мәхәббәтебез көннән-көн көчәя генә, тамырлана гына бара. Торган саен без бер-беребезне якынрак, матуррак, тирәнрәк итеп күрәбез.

Сәет тырыш, киң күңелле, җәмәгатьчел кеше икән. Яхшы уку белән бергә, ул комсомол оешмасы эшләрен башкарырга да өлгерә. Спорт ярышларында да, һәвәскәрләр түгәрәгендә дә иң элек ул күренә. Сәеткә ияреп, мин дә студентлар коллективының төрле җәмәгать эшләренә катнаша башладым. Икәвең дә бер юлдан баргач, бигрәк күңелле була икән!

...Бүген әдәбият тарихы дәресе булмады, профессорны кулга алганнар.

— Ул халык дошманы булган, диләр.

...Институның директорын, тагын өч укытучыны төнлә квартираларыннан алып китеп, төрмәгә япканнар.

Алар да халык дошманнары булдылар микән? Нинди куркыныч!

Сәетне институт комсомол комитетының секретаре итеп сайладылар. Ул һаман, элеккечә дәртләнеп, бетмәс эш артыннан чаба. Нигәдер йөрәк сызлый. Мин хәвефләнәм. Хәерлегә генә булса ярар иде инде?..

...Ике шатлык бергә якынлаша. Тиздән институтны тәмамлап, укытучы дипломы алабыз. Тиздән безнең беренче балабыз дөньяга киләчәк. Мин инде аның тибешен дә тоям. Сәет тә түземсезлек белән аны көтә. Белмим, кыз булыр микән, әллә ир бала...

Сәет соңгы көннәрдә сизелерлек үзгәрде — өйгә кайтты исә китап ала да утыра, сөйләшми.

Нәрсә булды аңа?

Мин бала көтәм. Нәкъ менә хәзер, ана булу якынлашканда, иркәләнәсе килә... Ә Сәет күңелсез!

— Ни булды? Ни булды?! Уф... аңлый алмыйм. Сәет бүген кайтмады. Юк. Аны да... алганнар. Көн буе йөгердем. Бармаган җирем, сорамаган кешем калмады. Кайда икәнен дә әйтмиләр.

Әнә инде таң да атып килә. Мин һаман утырам. Кайда, кайда син хәзер, җанкисәгем, Сәет?!.

...Инде өченче көн, караңгы төште исә, чакыралар... Өстерәлеп, Черек күл кырындагы өч катлы караңгы өйгә барам.

Болай да җәрәхәтле, телгәләнгән йөрәккә тоз сибәләр. Һаман, һаман бер тигәнәк сорау.

— Сәет Батталов институтта нинди контрреволюцион эшләр алып барды? Яшермәгез. Әйтегез!

Мин аның турында бар белгәнемне, чын күңелдән, яшермичә сөйли башлыйм.

— Юк, — боз төсле салкын тавыш уемны бүлә, җаным тетрәп китә, — ташлагыз юк-барны. Халык дошманы Батталовның җинаять эшләрен ачып салыгыз!

Мин елыйм. Нәрсә әйтим соң?! Ул бернинди дә җинаять эшләмәде бит. Нигә газаплыйлар мине?

Теге боз тавыш тагын кабатлана:

— Сез халык дошманын якларга тырышасыз. Файдасыз! Гаепсез кешене НКВД кулга алмый. Төшендегезме? Кайтыгыз. Уйланыгыз. Иртәгә — соңгы срок.

Ике солдат мине ишеккә хәтле озатып килә.

Бүген кич тагын чакырачаклар. Күз алларым караңгыланып, бөтен тәнем бизгәк тоткан төсле калтырана. Нәрсә, нәрсә әйтергә кирәк соң аларга?..

— Сәет, Сәет бәгырем, әйтче, әллә, әллә син чыннан да ялгыш юлга борылган идеңме? Миңа әйтмәдеңме? Әбәү! Нинди коточкыч уйлар!..

— Мин халык дошманы Сәет Батталовтан бөтенләйгә ваз кичәм...

Күз алларым караңгыланды, тез буыннарым йомшарып, сыгылып китте. Чак-чак кына аумыйча өстәлгә тотынып калдым.

Факультет җыелышыннан ничек тулай торакка кайтып җитүемне дә хәтерли алмыйм. Әллә китерделәр, әллә инде үзем өстерәлдем.

— Сәет бәгырем, син мине гафу ит? Мин зур җинаять эшләдем. Нишлим соң, нишлим?

Тиздән безнең балабыз туарга тиеш. Әгәр иртәгә диплом алам дигәндә генә институттан куылсам?! Ул баланы ничек тәрбияләрмен? Мин беләм, мин ышанам, мең кат ышанам, син гаепсез! Ләкин безнең уртак балабыз хакына, аны бәхетсез итмәс өчен генә мин андый нахак, пычрак сүзләрне әйтергә мәҗбүр булдым. Кичер, бәгырем, мин мәңгегә синең белән!..

Сәетнең кулга алынуына өч ай дигәндә бала дөньяга килде. Кыз бала, атасыз, фамилиясез.»

— Менә, кызым, — Гайшә күрсәнеп блокнотны япты, — синең атаң турында бар белгәнем. Тукта, ул, сүзен бүлеп, уйланып калды: — Әллә? Әллә хат урынына шушы блокнотны Зәйтүнәгә җибәримме? Иртәрәк булмас микән?

Буран һаман басылмый. Морҗадан тагын улаган, шыңшыган тавышлар ишетелә башлады. Гайшә лампаны сүндерде дә урынына барып ятты.

— Сәет, син дөньяда бармы әле? Кайда син? Нәрсә дип кызыңа җавап бирим соң?

## III

Бүген иртә белән генә Күкчәтау даласы күгендә ялт иткән кояш балкый иде. Бер болыт әсәре күренмәде. Сабан тургайлары бер туктаусыз очып, чырылдап, биек, якты иртәнге күктә гамьсез талпыналар. Аларга кызык та, сәер дә иде. Бу язда дала бөтенләй үзгәргән — аксыл кылган урынына кубарылып ташланган дымлы, кап-кара җир. Аның өстендә төрле кортлар, коңгызлар, суалчаннар үрмәли. Эзләп мәшәкатьләнәсе дә юк — әзер, тәмле, туклыклы азык...

— Егетләр! — Бригада иртәнге ашны ашап бетерүгә, Арсланов гадәттәге «биш минутлык»ны ачты: — Көн отличный. Бүген бар педальләргә басыгыз! Мин инде агрегатларны тикшереп чыктым. Тракторлар ходта, чәчү машиналары көйләнгән. Карагыз, башбаштакланып үзегезчә җайларга маташмагыз. Инде нибары ике мең гектар чәчәсе җир кала. Сыныгыз катса да, сынатмагыз, дуслар. Бригаданың йөзен каралтмыйк, яме? Но, шуның белән митинг тәмам, тракторларга!

Иргали, сүзен сөйләп бетерер-бетермәс кузгалып, үзенең тракторына таба атлады. Бригада членнары да шаулашып өстәл яныннан тордылар — кайсылары тракторларына, кайсылары тракторларга тагылган чәчү машиналарына таба таралдылар.

Озак та үтмәде, беренче бригада станы моторлар гөрләве, сигнал-гудок тавышлары белән колакны тондырды. Иң алдан орлык төягеч машиналар үтте. Өчәр-дүртәр чәчү машинасы өстерәгән тракторлар — агрегатлар берсе артыннан берсе кузгалды. Аларның кайсылары стан кырыеннан ук башланган кырга керделәр, кайсылары, юлга чыгып, арырак киттеләр.

Директорның кабинеты палатканың бер почмагына гына кысрыкланган иде. Бар җиһаз — өстәл, урындык һәм карават. Тояк, гадәтенчә, иртәнге ашка кадәр бригада учетчиклары алып килгән сводкаларны карап-тикшереп, үзенең блокнотына күчермәләр ясады. Аннан хуҗалык эшләрен башкаручы Тутаевны чакыртып, ягу-майлау материаллары, азык-төлек, икмәк һәм башка кирәк-яракларны алып килү өчен калага ничә автомашина җибәрү турында күрсәтмә бирде, банкка хәзерләнгән поручениеләргә, чекларга кул куя башлады.

— Иптәш директор, өч минуттан сәгать җиде. — Палатканың икенче як почмагында рацияне җайлап мәшәкатьләнгән солдат киемендәге радист наушникларын сала-сала Тоякка эндәште. — Килегез, хәзер башлана.

Тояк, документларын өстәл тартмасына салып бикләп, блокнотын алды да рациягә ашыкты. Бүген партия өлкә комитетының секретаре язгы чәчүнең барышы турында совхоз директорларының радиокиңәшмәсен уздыра иде. Беренче чыгыш «Алка күл» совхозы директоры Тояк Бөркетбаевка билгеләнгән.

— Алла-алло, мин — «Алка күл», сезне яхшы ишетәм. Башлыйбыз. Микрофон алдында директор.

Радист ымлап Тоякка утырырга кушты, үзе өстәлнең артынарак авышты.

— «Алка күл» директоры Бөркетбаев сөйли. Сәлам. 13 май иртәсенә безнең совхоз буенча 8873 гектар бодай чәчелде. Тагын 7130 гектар кала. Орлык житәрлек, бригадаларга ташылган. Техника бар. Трактористлар житешми. Бу биш көндә генә алты тракторист, өч шофер машиналарын кырда калдырып чыгып киттеләр. Беренче бригада — бригадир Иргали Арсланов — һәм икенче бригада — бригадир Николай Поддубный — көндәлек чәчү планын 120—135 процентка тутыралар, эшнең сыйфаты да яхшы. Калган бригадаларда тоткарлык бар, ул якка хәзер үзем чыгам. Төшке аш вакытында «биш минутлыклар» үткәрәбез.

Радист рацияне «прием»га күчерде. Тояк башка совхоз директорларының чыгышларын тыңлый башлады.

Радиокиңәшмә бер сәгатькә якын сузылды. Дөресен әйткәндә, башка совхозларда да чәчүнең барышы әллә ни алда күренми. Ләкин өлкә комитеты секретаре, Бөркетбаевка аеруча кисәтү ясап, чәчүнең темпын кызулатырга, алдынгы агрегатларны төнлә чәчәргә күчерүне тәкъдим итте. Иң ахырда:

— Һаваның торышы үзгәрергә тиеш, мөмкин булган барлык чараларны файдаланып, ашыгыгыз, иптәшләр, — диде.

Тояк киңәшмәдән соң өченче бригадага барырга, анда бер-ике көн булып, бригаданы ныгыту чараларын күрергә планлаштырган иде. Чөнки бу бригада бөтен «Алка күл»не артка өстери. Инде өч бригадир алмашынды, ә эштә һаман үзгәреш юк — чәчү, планлаштырылган графикка керү түгел, көннән-көн артка чигенә, үзара ызгыш-талаш һаман бара.

Ләкин уйламаганда маршрутны үзгәртергә туры килде. Икенче бригаданың учетчигы бригадир Поддубныйның авырып калуы турында белдерде. Бу хәбәр Тоякны бик нык борчыды. Бу инде өченче бригада түгел, армиядән кайткан солдатлардан оештырылган тәртипле, эшчән бригада. Николай бригаданы үзе оештырды, ныгытты һәм алдынгылар сафына алып чыкты. Шундый бригадирның сәламәтлеге турында кайгыртуны кичектерергә мөмкинме соң?

Менә шуның өчен Тояк, киңәшмә бетү белән, бригада аш пешерүчесе Каракүз янына кереп, аны-моны капкалады да атына атланып юлга чыкты. Әмма борчылу урынсыз булган икән. Станга якынлашуга, үрдән автомашина күренде, Тояк янына килеп житү белән шып туктады. Кабинадан тирләгән-пешкән Николай сикереп төште.

— Сәлам, иптәш директорга!

Тояк, сәлам алу урынына, сорау бирде:

— Николай, сине авыра дигәннәр иде бит?

Бригадир жиңе белән маңгаендагы тирне сыпырып төшерде дә кулын селтәде:

— Пустяк. Кичә, менә шулай тирләгәч, салкын су эчкән идем, йөрәк бераз шаяртты. Эш тыгыз, орлык бодаен агрегатларга өлгертә алмый башладык. Чәчүне кызу тоталар. Әйдәгез, безнекеләр монда гына.

Тояк Николайны үз-үзен сакламавы өчен бераз шелтәләде дә атын икенче юлга — бригаданың чәчү кырына таба борды.

Солдатлар тырышып эшлиләр, чәчүнең сыйфаты да яхшы. Әгәр бу темп белән барсалар, дүрт көндә бригада үзенең барлык 3900 гектар кырын чәчеп бетерәчәк. Тояк монда озак тукталмады. Бригада членнарына рәхмәт әйтеп, тагы да яхшырак эшләргә чакырды да, Николай сораган запчастьларны һәм солярканы кичкә хәтле жибәрергә вәгъдә биреп, килгән юлына кире борылды.

Ярты юлга життем дигәндә, көн болытлап, салкын жил исә башлады, ә ялгыз карагайга якынлашканда кар явып, буран күтәрелде.

Тояк, станга бармыйча, атын Арсланов агрегаты чәчеп йөргән кырга таба борды. Ызан башында бригадир үзе дә очрады. Алар бер-ике сүз

белән генә аңлаштылар да, икесе дә ике якка китеп, кырдагы халыкны җыярга, төрле җирдә өелеп яткан орлык бодайларын ни туры килде шуның белән каплап, ябып, җил очыртып китүдән саклау чараларын күрергә тотындылар. Ашыктылар. Өермә көчәйгәннән-көчәя генә барды. Иң куркынычы — мондый буранга беренче тапкыр очраган кешеләрнең адашып калу ихтималы иде. Ләкин халык таралмады, бер тирәгә тупланып, бодай өемнәрен ябу, саклау өчен буран белән алышты.

Бригада машиналарны бер җиргә туплап, радиаторлардагы суны агызып, чәчү орлыкларын буран таратмаслык итеп япкач кына, тыныч күңел белән, хәл җыярга дип палаткага килгән иде. Тояк та тапчанга ятып калгыды. Әмма монда да тынычлап ял итәргә туры килмәде, каты җил палатканы урыныннан кубарып алып ташлады.

Буран һаман өерелә, тирә-якта бер нәрсә дә күренми. Бары ара-тирә генә авышкан болытлар арасыннан тулган ай тәгәрәп чыга да аз гына вакытка даланы яктырта. Беренче бригаданың егетләре менә шул арада төрлесе төрле якка таралып, тәгәрәп барган әйберләрне куып, кулга төшкәнен трактор янына ташый, өя бардылар.

Бу эш берничә сәгатькә сузылды. Ахырында трактор янына матрац, одеал, чемодан, табак-савыт һәм башкалардан торган зур гына чүмәлә өелде. Аны палатканың киндере белән ябып, тапчаннар, өстәлләр белән бастырып куйдылар.

Менә шунда гына арганлык беленде — басып тора алмыйча чайкала башладылар, кайберәүләр брезент астына үрмәләп кереп, йокларга әзерләнделәр. Халык йөгереп эшләп тирләгән иде, хәзер туктагач, тир катып, өшетә башлады.

Бу — май буранының иң мәкерле капкыны. Бу бәлане сизенгән Тояк арыган, йончыган кешеләргә утырып ял итәргә дә рөхсәт бирмичә куа башлады.

— Әйдәгез, туктамагыз. Барыгыз да кызлар тора торган вагонга!

Ул арада иң соңгы кеше булып, зур мичкә күтәргән Иргали килеп чыкты.

— Ташла бочкаңны, — Тояк ачу белән Иргалинең җилкәсендәге мичкәне йолкып алып тәгәрәтеп җибәрде, — Бочкаң корсын. Халыкны сакла. Барысын да вагонга алып бар. Бер адәм дә далада кала күрмәсен.

Алар икәүләп, йоклаганнарны уятып, күтәреп торгызып, ашыктырып, вагонга таба куа башладылар.

Халык зарланып, сүгенеп, теләр-теләмәс кенә җилгә каршы кузгалды. Иргали алдан китте. Тирә-якка кычкырып-кычкырып, брезент асларын капшап, далада берәү дә калмаганлыгына ышангач кына, иң соңгы булып Тояк Бөркетбаев атлады.

## IV

Кемдер тәрәзәне шакыды. Гайшә, йокысыннан сискәнеп уянып, күзен ачты. Тәрәзәне тагын шакыдылар. Ул, өстенә ябынган юрганын ачып ташлап, урам як тәрәзәгә үрелде һәм каушаган тавыш белән эндәште:

— Кем анда? Кем кирәк?

Күрәсең, урамдагы кеше аның тавышын ишетмәде, тагын да катырак итеп тәрәзәнең рамына суга башлады. Гайшә куркынып караваттан идәнгә сикереп төште, тәрәзәнең пәрдәсен күтәреп, ачу белән кычкырды:

— Акрын. Тәрәзәне ватасың бит! Син кем, кем дим?

Урамнан тонык тавыш ишетелде:

— Килен... Ишегеңне ач!

Ул тагын да нәрсәдер әйтте, ләкин Гайшә аны ишетә алмады. Әле һаман тынмаган буран соңгы сүзләрне кагып икенче якка алып китте. Ләкин Гайшә тавышны танып өлгерде.

«Ай, кайната килгән ич!»

Ул кабаланып күлмәген эзли-эзли сөйләнде: «Менә урындык өстенә генә куеп яткан идем бит, юк». Гайшә анда үрелде, монда сугылды — күлмәк табылмады.

Кай җәһәннәменә китте соң? Ашыкканда гел шулай...

Ул сукрана-сукрана чыгып, аш өйдән шырпы алып керде дә өстәлдәге лампаны кабызды. Күлмәк караватъ очындагы урындыкның аркасына эленгән. «Ай хәерсез... Ашыкканда күз бәйләнә дигәннәре шулдыр инде».

Гайшә сөйләнә-сөйләнә күлмәген, киез итеген киеп, аш өйгә чыкты, стенада эленеп торган фонарьны алып кабызды, аннары өстенә фуфайка ябынып, тышкы ишекне ачты.

Тар гына ишек алды, аны үткәч — түбәсе салам белән ябылган саман стеналы киң кура. Гайшә фонарьны җиргә утыртып, бастырыкны тартуга, зур капка бар буена ачылып китте. Курага ап-ак тузан ыргылды. Фонарь ауды. Гайшә йөгереп килеп фонарьны күтәреп алды да бураннан читкәрәк ышыкланды.

Капкадан кемдер керде. Аның өс-башы сырма кар. Ул якынлашты. Юлчының ияк очында тиен койрыгысыман кабарып торган сакал — ап-ак мамык. Ул нindидер озынча төргәк кочаклаган — анысы да ап-ак. Тиен койрык чак кына селкенеп мамыгын койды, карлыккан тавыш ишетелде:

— Килен, өйалды ишеген ача бир, сабый туңып калмасын.

Гайшә ашыгып ишеккә таба атлады, үзе гаҗәпләнде.

«Җиде төн уртасында нәрсә алып килә соң бу кайната?»

Алар ике ишекне үтеп, аш өйгә керделәр. Гайшә түшәмгә эленгән асылмалы лампаны кабызды.

— Калкам! — Карт тирә-якка каранды. — Кайда куяен?

— Хәзер, ата, үзем...

Гайшә кабарып торган ак төргәкне кайнатасының кулыннан алып мич кырыендагы сәкегә салды, ашыгып биләүсәләрен сүтә башлады.

— Буранда калган мосафир адәмнәр, гой. Ходай әйдәп маган туры китергән. Сезнең өй жыкын булган соң усында борылдым. Даладагыларны алып керәем. Син сабыйны карый бир, калкам.

Карт, сүзләрен әйтеп бетерер-бетермәс, тая-тая курага чыгып китте. Гайшә биләүсәне сүтеп бетереп, киезне ачты.

Баланың йөзе күренде. Ул тирләгән, бит алмалары кызарып кабарганнар. Бу күтәреләә. Әллә яктыга, әллә сулышы иркенәеп китүгә, ул күзләрен ачты. Аңа, ахрысы, әле ике яшь тә юк. Үзе шундый тулы, йөзе түгәрәк, күзләре зәп-зәңгәр. Бала нәни кулларын сузып җибәрде, кабарып торган ал иреннәре җәелде. Сабый рәхәтләнеп киерелде һәм елмайды.

— Үс-үс!

Гайшә баланың кулларын түбән төшереп, күкрәгеннән аякларына хәтле сыйпап чыкты.

— Тфү, тфү... Бигрәк сөйкемле.

Баланың күзләре Гайшәдә тукталып калдылар. Иреннәре җыелды, бөрелде. Кинәт ул кычкырып елап җибәрде.

— Әбәү, алдандыңмыни? Әниең түгелмени?

Гайшә баланы киездән күтәреп алып, түр өйгә, үзенең караватына алып барып салды, башын гына ачык калдырып юрган белән урагаңга бала тынычланмады, тирә-якка каранып, сытылып елавында дәвам итте.

— Менә уенчык, кара әле нинди матур. Үркәчләре нинди зур! — Гайшә этажеркада торган уенчык дөяне алып баланың кулына тоттырды. Күзләр тагын яктырдылар, гаҗәпләнеп, кызыксынып карадылар. Гайшә яулык белән яшь бөртекләрен сөртте. — Менә шулай... Мин сиңа тагын уенчыклар бирәм. — Гайшә этажеркага борылуга, бала кулындагы дөяне идәнгә атып бәреп, элеккегә караганда да катырак ярсып елый башлады.

— Әни, кем елый?

Алмагөл уянып, торып утырды, йодрыгы белән күзләрен уды, аннан йөгереп әнисе янына килде.

— Әни, бу кемдең бәпәсе?

Гайшә аңа җавап бирмәде, караватның сиртмәсенә басып баланы тирбәтергә, юатырга тырышты:

— Елама, елама, акыллым, әниең хәзер килә.

Ул арада ишек ачылды.

— Мөмкинме?

— Мөмкин, мөмкин. Алмагөл, син тирбәт, әнә уенчыклар бир. — Гайшә ишектән керүчегә каршы атлады. — Түргә узыгыз, тукта, чишендерим үзегезне.

— Рәхмәт. Улым ничек, өшемәгәнме? Газиз, Газиз, елама, акыллым, мин монда.

Әнисенең тавышын танып бала елаудан туктады.

— Юк, өшү кайда!.. Ул изерәп тирләгән, мин аны кулыма алганда үзем дә курыккан идем... Күз ачкысыз буран бит. Ярый әле — безнең әтигә туры килгәнсез. — Гайшә, йөгереп килеп, хатынның пальто төймәләрен ычкындырды. Җиңнәрен салдырды. Аягына күз ташлап башын чайкады: — Ай-яй... аягында резина бота! Өшегәндер бит. Салыгыз тизрәк! — Ул тиз генә урындык китереп хатынны утыртты да үзе үк ботасын салдырып алды, аякларын кысып-кысып карады. — Юк, өшемәгән. Менә пима киегез. — Гайшә мич башыннан кара киез итекләр алып үз кулы белән кидерде. — Инде әйдәгез, түр өйгә, улыгыз янына утырыгыз. Туктагыз, өстегезгә шәл салыйм, сез дерелдисез. — Хуҗа, ашыгып, юлаучының җилкәсенә мамык шәл япты.

Газиз көн буена машинада, аннан чанада сугылып, туңып ватылган. Инде ул елавын онытып йоклап та киткән иде. Алмагөл баланың болай тиз йоклап китүенә кәефсезләнеп, караватт тирәсендә әйләнде дә, ят кешенең якынлашуын ишеткәч, тиз генә уенчыкларны кочаклап, каредән одеал астына кереп ятты. Ул башын аз гына ачык калдырып, йоклаганга сабышып, бәбинең әнисен көтте. Хатын баласы янына килде.

— Арган икән, мескенем, йоклап киткән.

Ул, салкын кулларын баланың тәненә тидермәскә тырышып, иплэп кенә юрганны аяк очыннан ук урап япты, аннары читкәрәк китеп, кесәсеннән яулык алды. Алмагөл бу ят хатынның һәрбер хәрәкәтен, төсен, буен кызыксынып күзәтә башлады. Аның маңгай чәчләренә, кашларына, хәтта керфекләренә юка гына боз кисәкләре ябышкан. Алар ялтырап-ялтырап китәләр. Хатынның битендә күз яшьләре төсле тамчылар. Күрәсең, бозлар шулай эреп төшәләр.

«Ул безнең әнидән биек. Күлмәге нинди матур, ут шикелле янып тора. Кайдан алды икән андый күлмәкне?» Хатын чәчен тарый башлады. «Әнинең чәче озын, кап-кара, минем чәчем төсле. Ә бол апаның чәчләре җилкәгә генә төшеп тора, нигә алар шулай кабарган икән? Җирән елкының җалы шикелле. Минем дә осындай чәчем булса?» Алмагөл үз уеннан үзе чак кына кычкырып көлеп җибәрмәде. Ирennәрен тешләде. Күзләрен чытырдатып йомды. Зөбәрҗәт аш өйгә чыкты.

— Гафу итегез, сезнең исемегез ничек, ханым?

— Зөбәрҗәт.
— Бигрәк матур исем.
— Ә сезнең?
— Минем гади генә, Гайшә.
— Нигә алай дисез? Бик җиңел, онытылмый торган исем бит.

Гайшә самоварга каен тузы яндырып салды да торбасын учак авызына каратып куйды. Аннары ул тиз генә барып, каршы почмакта торган шкафны ачты, графин һәм рюмка алды.

— Мин онытып та торам, самовар кайнап чыкканчы аз гына җылынып алыгыз әле, — ул алтын путал белән каймалаган озынча рюмкага спирт салды һәм бераз су өстәде, — мәгез, эчеп җибәрегез, сез әле дәдерелдисез.

— Әдәпсезлек булмасмы? Бусагадан атлауга...
— Юк, юк, бу бит җылыну өчен генә.
— Мин бик курыккан идем. Җитмәсә, бала белән бит. Май аенда мондый буран булыр дип кем уйлаган. Чыннан да, туңып киттем, сез гаепләмәгез инде.

Зөбәрҗәт елмайды, юка, матур иреннәре җәелеп чак кына ачылдылар. Ап-ак тешләре күренде. Озын, саргылт керфекләре астыннан ялтырап зәңгәр күзләре карады. Дөресен әйткәндә, хатын-кызларда берберсенең матурлыгыннан көнләшү әле дә саклана. Алар аны ачыктанача белдермәсәләр дә, күңелләреннән сызланалар. Ләкин Гайшәдә бу тойгы, матурлыктан көнләшү, бервакытта да булмады... Ул иптәш кызларының матурлыгына һәрвакыт сокланып, куанып карады, бер генә тапкыр да көнләшмәде. Менә бүген дә бу билгесез хатынның сылулыгы аңа чын рухани рәхәт һәм өенә ямь биргән төсле булды. Үз чиратында Зөбәрҗәт тә куанды. Моннан бер генә сәгать элек, дала уртасында бензины бетеп, карга батып калган суык машина эчендә, Газизен кочаклап нишләргә белми аптырап утырганда, ул мондый мөлаем, туган күңелле хатынның якында гына яшәвен һәм аларны шатлык белән каршы алачагын һич тә күз алдына китерә алмаган иде бит. «Ул нинди ачык йөзле. Аның күзләрендә никадәр җылылык һәм шәфкать бар.» Зөбәрҗәт аз гына «әчимме-әчмимме» дип икеләнеп торды да рюмканы иреннәренә китерде һәм тиз генә, тын алмыйча эчеп җибәрде.

— Менә салкын су.
— Рәхмәт.

Зөбәрҗәт, чак кына йөзен чытып, стакан белән суны алды. Бер генә йотып Гайшәгә кире бирде, яулыгы белән иреннәрен сөртте.

— Безнекеләр нигә кермиләр икән инде?
— Ай алла, исемнән дә чыгып киткән ич. Нигә кермиләр соң?

Гайшә ашыгып, өстенә дә кимичә, йөгереп тышка чыгып китте. Капка алдындагы кар көрәлеп почмакка өелгән, капка ябылган, бастырыгы да салынган, фонарь каршында ике кеше өсләрендәге карны кагалар. Гайшәнең кайнатасы атларны эчке курага алып кереп, бәйләп йөри.

— Ярар инде, өйгә керегез. — Гайшә сөйләнә-сөйләнә юлчылар янына килде. — Үзебез кагып кертербез, мич ягылган.

Ишеккә арты белән торып, бүреген кагучы плащлы кеше кинәт борылып Гайшәгә карады. Бүрегендәге карны кагудан туктады. Кура уртасындагы баганага эленеп куелган фонарь аларның йөзен яктыртты. Бер-берсенә текәлеп йотылып карадылар. Җил тагын сызгырып нәрсәләргәдер бәрелеп, тавышланып үтте. Плащлы кеше тирән бер дулкынлану белән ишетелер-ишетелмәс кенә дәште:

— Сез... Гафу итегез... Гайшә түгелме?

Гайшәнең күз аллары караңгыланып китте. Фонарь чайкалды. Ул үзе дә сизмичә кулларын алга сузды, аннары кинәт куркынып артка чигенде...

## V

Вагонның тар һәм тәбәнәк ишегеннән кысылып, бөкрәеп, ак аюсыман керәү керде. Ишек төбендә чүгәләп утыручылар, бер-берсенә кыйшая-ава төшеп, ишектән кергән суык җилдән, керүченең кар белән каткан киеменнән чирканып тартылдылар, юл бирделәр. Калгып утыручылардан берсе, башын күтәрмичә генә, ачуланып мыгырданды:

— Яп тизрәк! Монда кәбестә башлары ятмый бит.

Ишек күптән ябылган иде инде. Бусагада торучы, акрын гына аякларын атлап, алгарак — яктыгарак чыкты. Бу — киң җилкәле, калку күкрәкле, эре сөякле кеше иде. Аның өс-башын, очлы папахасыннан алып күн курткасына һәм буркаларына чаклы, юеш кар сырган. Маңгаена, чигәләренә чыгып калган чәчләренә, кашларына һәм керфекләренә боз укмашкан. Киң, түгәрәк йөзендә әле эреп өлгермәгән аксыл бәс һәм кара таплар.

Ул тагын бер адым атлап туктады да, идәндә ятучылар өстенә бозларын коймаска тырышып, папахасын ике куллап сак кына салып, каршыдагы сәкенең буш кырыена куйды. Аннары куртка кесәсеннән яулык чыгарып, чыланган, керләнгән битен сөртә башлады. Чәчләргә, кашларга, керфекләргә укмашкан боз кисәкләре тиз генә эремәделәр. Хуҗа аларның эреп төшүләрен көтәргә дә теләмәде — тартып, йолкып, төкләре белән суырып алырга тотынды. Керфекләр җиңеләеп күтәрелделәр. Күзләр ачылып, яктырып китте.

Түшәмдә бер туктаусыз чайкалып торган асылмалы лампа. Аның куыгы корымланган, урта бер төше кителгән. Тишекне кәгазь ябыштырып ямап куйганнар. Тыштагы җил вагонга килеп сугылган саен, ямаулы куык эчендәге озынча кызгылт ялкын әле бер, әле икенче якка үрелеп, авышып китә дә шунда ук лыпылдап кысыла.

Вагон эче тынчу. Томан. Төтен. Тимер мичне кыздырып ягуга да карамастан, вагон стеналарына бәс сарган. Түшәмнән бер туктаусыз эре-эре тамчылар тама.

Бу — беренче бригадада эшләүче кызлар тора торган күчмә вагон. Ул башта тимер юл вагоннарына охшатып аслы-өсле дүртәр урынлы бүлемнәр һәм аралыклар белән эшләнгән булса да, соңыннан, урын җитмәү аркасында, аралыклар да такта белән түшәлеп, ике катлы сәкесәндерәгә әйләндерелгән иде. Бары уртадагы ишектән түргә хәтле генә тар тыкрык калган.

Ирләр, үз палаткаларын буран аударгач, ирексездән шушында килеп кысылырга мәҗбүр булдылар. Кызлар хәзер барысы да түбәнге сәкегә күчеп, парлашып одеалга уранганнар да бер-берсенә кысылып, кочаклашып ятканнар. Вагонга алданрак килеп өлгергән егетләр югары сәкедә, сәндерәдә. Аларның кайсысы кызлар калдырган матрацта, кайсысы коры тактада. Егетләр башларын юеш фуфайкалар якасына яшереп, тезләрен күкрәкләренә хәтле тартып, бөгәрләнеп йоклыйлар. Калганнары идәндә. Сәке буена чүгәләп, башларын тезләренә салганнар. Берничә тракторчы, сәке читенә, кызларның аяк очына утырып, башларын тота алмыйча иелеп-иелеп калгыйлар.

Сәндерәнең алгы башында кемнәрдер саташып кычкыралар.

— Радиаторга су кирәк...

— Павлуша! Тизрәк, тизрәк...

Каршыдагы сәкенең кырыенда йокымсырап утырган егет, сискәнеп уянып, башын артка ташлады. Кире иелгәндә аның күзләре вагон уртасында басып торучыга төште. Чикләвек төсле соргылт, аз гына кысынкы күзләр гаҗәп бер тизлек белән зурая, түгәрәкләнә башладылар. Егет кинәт кенә йодрыгы белән күзләрен каты итеп уды да туп шикелле сикереп урыныннан торды:

— Җолдас директор, утырыгыз.

— Утыр, утыр, калкам. Урын табылыр.

— Җок, ага, сез утырыгыз.

Егет балаларча оялып, каушап, бер Тоякка, бер сәкеләргә күз йөртеп чыкты да капыл гына сәке астына иелде, кычкырып җибәрде:

— Уй-бай, урын таптым, ага.

Ул, башын да күтәрмичә, тәгәрәп сәке астына кереп югалды.

Тояк, идәндә йомарланып яткан ике егетнең арасына ипләп кенә уң аягын куеп, кагылмыйча атлап китмәкче иде, кинәт берсе сискәнеп кычкырып җибәрде:

— Сукыр! Күзең чыкканмы әллә? Борынны изә яздың!

Ул башын күтәрмәде, керпе төсле җыерылып, фуфайкасының якасына башын яшерә генә төште. Тояк бөкрәеп сәке читенә утырды. Башы чатнап авырта, берәү чүкеч белән туктаусыз сугып тора кебек.

«...Әле җиде мең гектардан артык чәчелеп бетмәгән җир. Һәрбер стан башында тау-тау булып өелеп яткан орлык, куптарылып ташланган палаткалар. Түбәсеннән су үтә торган пычрак караңгы вагоннар. Өстәвенә бүген икмәк тә килеп җитмәде. Халык иртәдән бирле авызына валчык та капмаган!».

Тоякның иелеп төшкән муенына бер-бер артлы ике салкын тамчы тамды. Ул чирканып башын күтәрде, муенын учы белән сыйпап, сөртеп алды, көрсенеп тирә-якка каранды.

Тояк кесәсеннән портсигарын чыгарып папирос кабызды, йотылып, авызын тутырып төтен суырды.

«Нигә болай? Нигә барлык планнар җимерелә. Нигә бу халык пычрак суык идәндә ауный. Алар өйсез-көйсез йолкышлармы? Юк. Алар, үз теләкләре белән йорт-җирләрен калдырып, даланы иген басуларына әйләндерер өчен, халык бәхете өчен көрәшкә килделәр бит. Инде бар тапканнары менә шушы кысынкы, юеш вагонмы? Бөркет улы Тояк, бу халыкның язмышы өчен син гаепле бит!»

Баш иелде, яңадан-яңа авыр чәнечкеле уйлар тыгызланды. Ләкин арыганлык, суыктан җылыга керү тәнне изрәтте. Тояк утырган килеш калгып йоклап китте.

Тояк сискәнеп күзен ачты. Вагон эчендә ыгы-зыгы, талаш, кычкырыш. Нәрсәгә тавышланалар? Нәрсә буләләр? Идәндә ятканнарның берсе, елан чаккандай калтыранып, үкереп сискәнеп торды да башына ябынган лычма су фуфайкасын Тоякка атып бәрде.

— Менә кем гаепле!..

Фуфайка директорга чак тимәде, өстә ятучыларның берсе тотып калды. Тояк утырган урыныннан селкенмәде, егеткә текәлде. Бу — яңа гына курс бетереп кайткан яшь тракторчыларның берсе Илһам Атласов иде. Аның бит мускуллары тетрәнә, авызы кыйшая. Кара чәчләре тузган. Маңгаеннан керле кар суы саркып, ябык, озынча бите буйлап иягенә төшә. Илһамның зур кара күзләре акаеп Тоякка кадалганнар. Ул тотлыга-тотлыга кычкыра:

— Ашарга ипи юк. Ятарга урын юк. Бу целина түгел, каторга! Без кем? Арестантлармы, господин директор? — Ул мәсхәрәләп көләргә тырышкан иде дә, барып чыкмады — юка иреннәре тартылып кыйшайдылар, тавышы кызлар тавышысыман нечкәреп китте. — Ә-ә, безне каршы алганда митинговать иттегез, «хуш килдегез!..» Ә менә хәзер рәхим итеп карагыз! — Ул ике кулын җәеп вагон эчендәге шапшаклыкны күрсәтмәкче иде, уң кулын кызган мич кабыргасына тидереп, сүгенеп җибәрде... — Дуңгыз кебек пычракта ауна!.. Издевательство! Дуңгызлар да хәзер болай тормыйлар. Монда предательство!

Соңгы сүз Тоякка пычак булып кадалды. Чыннан да, бу сүзләрне Илһам әйттеме? Һәрвакыт үзенең туган баласы кебек якын күреп, кирәк урынында булышып, сокланып йөргән ышанычы шулай сөйлиме? Тояк Илһамны кышын станциядәге митингта күреп, бу егет эштә терәк бу-

лыр дип уйлаган иде. Илһам анда Татарстаннан килгән комсомоллар исеменнән сөйләде. Нинди ялкынлы, ышанычлы, өметле фикерләр әйтте ул анда...

Тояк аны үзе димләп, Кукчәтауга механизаторлар курсына җибәрде. Иң тыгыз эшләрен калдырып, Илһамның хәлен белер өчен, калага барды, кучтәнәчләр җибәрде. «Бу — ышанычлы егет. Совхозда мондый егетләр күбрәк булса, эш җиңелрәк булыр», — дип юанды. Хәзер ул әнә нәрсә сөйли.

— Илһам! Ә үзең? — Вагонның аргы почмагында башына одеал ябынып, ярым бөкрәеп утырган кыз одеалын ачып җибәрде. Ләкин томан эчендә аның йөзе күренмәде. Тавыш ашыгып, ярсып чыкты: —Ә үзең трибуна өстендә нәрсә сөйләдең? «Без кыенлыклардан курыкмыйбыз, һәрвакыт алдынгы рәттә булырбыз». Бу синең сүзләрең түгелме? Без,— тавыш ачулы яңгырады, — без дә прянник ашап утырмыйбыз. Без дә йомшак караватларда ятмыйбыз!

— Ләйлә! — Югары полкадан ишетелгән калын тавыш кызны бүлдерде. — Син бик кызарма! Илһам дөресен әйтә. Что без, этләрме?

Берничә тавыш, бу сүзне куәтләп, җәнҗалны кыздырырга ашыкты.

— Дөрес!..

— Нигә куркып торырга!..

Түземенең чигеннән чыккан Тояк сикереп торып кычкырды:

— Бу нинди башбаштаклык?!

Берничә тавыш берьюлы акырып Тоякка сөйләргә бирмәде.

— Җитәр!

— Иптәшләр! Ул безне куркытмакчы була.

— Туктагыз! — Ишек төбендә чүгәләп утырган Иргали Арсланов ашыгып күтәрелде. — Сез сукырмы? Директор үзе дә көне-төне безнең белән бергә бит.

— Подхалим!

Мич өстенә кием киптерергә дип асылган колганы кемдер суырып алып, селтәп җибәрде. Тояк иелеп калды. Колга сәке тактасына сугылып шартлап сынды. Кызлар җан тавыш белән кычкырып, акыра-елый башладылар. Шау-шу күтәрелде. Шул вакыт ишек ачылды, тузынып кергән буран эченнән кеше күренде. Ул бусагадан атлауга чайкалды, төбеннән киселгән агач төсле ава башлады. Аны тотып алдылар. Вагон эчендәге шау-шу басылды, барысы да вакытсыз килеп чыккан юлаучыга карап аптырап калдылар.

## VI

— Ашот, син нигә җәяү? — Тояк сабырсызланып, шоферны сорау белән күмде. — Машина кайда? Продуктлар?

— Машина? Мин машинаны...

Ашот сүзне башласа да ялгап китә алмады. Күзләре йомылды. Киезләнгән кара сакалы буйлап керле су тамчылары агып төште.

— Куфарян! Син йоклыйсың бит!.. — Тояк иелеп төшкән җөнтәч башны күтәрде. — Ни булды? Нигә җәяү калдың?

— Ә?

Куфарян уянып күзләрен ачты. Тояк тагын шул ук бер сораунь кабатлады:

— Машина! Машина кайда?

Ашот җавап урынына көрсенеп сулады, иреннәрен ялап алды:

— Су! Авызым кипте.

Бер кружка суны ул тын да алмыйча йотлыгып эчеп куйды. Кемдер кабызган папирос сузды.

— Мә, туган, йокыны төсләп җибәр.

Ашот папиросны алып бер-ике суырды да, сәкенең читенәрәк тартылып, тураеп утырды, машинаның кай җирдә туктап калуы турында сөйли башлады.

Йокы качты. Ыгы-зыгы башланды. Тояк тракторчыларга юлга хәзерләнергә кушты. Завхозны чакырттылар. Сәке астыннан күзләрен уа-уа заправщик — директорга үзенең «почмагын» бүләк иткән теге йомры егет — чыкты. Тимер мич өстенә чиләкләр тезелде — радиаторларга җылы су кирәк! Шау-шу вагон эченнән далага — тракторлар янына чыкты. Төн, буран, факеллар, чиләкләр, боерыклар, сүгенүләр, чакырулар барысы бергә буталды.

Беренче булып Арслановның тракторына җан керде. Аңа чана табанына утыртылган күчмә вагон теркәделәр. Бригадир үзе белән бергә ике егет алып кузгала башлагач кына, атылып-бәрелеп вагонга Ашот килеп керде. Аны димләп, сүгеп станда калдырырга теләсәләр дә, булмады. Ябышып ятты. Ахырында кул селтәделәр. Иргали рычагка басты. Трактор Найзатумарга борылды.

Җил басыла төшсә дә, төн болытлы, юл күренми иде. Иргали юл эзләп вакытны әрәм итмичә, дала буена турыдан-туры ярдырып китте. Тәвәккәл таш яра дип юкка әйтмәгәннәр икән. Озак та үтмәде, трактор Найзатумарга, юл уртасында калган машина янына килеп чыкты. Дәррәү төштеләр. Машина кузовындагы продуктларны вагонга күчерә башладылар.

Иргалинең кайтуы бәйрәм булды. Бригаданың барлык членнары аны шаулашып-куанышып каршыладылар. Бигрәк тә Каракүз. Ул баскан урынында тора алмады, трактор килеп туктар-туктамас, тагылма вагонның ишегенә ябышты. Бригада инде икенче тәүлек ашамаган, поварның йөрәге ничек сызланмасын!

Даладагы плитә-мич кар астында. Ышаныч вагон эчендәге тимер мичкә калды. Каракүзгә булышучылар күбәйде: кайсы икмәк ташыды, кайсы капчык белән ярма кертте, кайсы консерва банкаларын ача башлады. Утын да килеп өелде. Тимер мич кызарып бүртенде — якын килерлек түгел. Аның өстендә ике зур кастрюль. Берсендә тары боткасы, икенчесендә чәй кайный.

Бокырдап, тавышланып аптыраткан эчәгеләр, майлы ботка һәм шикәрле чәй белән тулгач, җәелеп тынычландылар. Халыкның йөзе дә яктыргандай булды. Ара-тирә шаярган, көлгән тавышлар да ишетелә башлады.

Ә менә директорның үзенә ашарга утырырга һаман вакыт җитмәде. Бер мәшәкать өстенә икенчесе өстәлде, куаладылар, ашыктырды — ашыйсы килү истән чыкты. Ярый әле, Иргали зарыктырмады, тиз әйләнеп кайтты. Беренче бригада тамагын туйдырып тынычланды. Ә калган биш бригада? Андагы халык та инде икенче тәүлек авызына валчык та капмаган бит. Көн туганны, буран тынганны көтү җинаять! Хәзер үк гамен күреп, азыкны аларга җиткерергә кирәк. Тояк юлга чыгасы тракторларны тагын бер кат җентекләп тикшерүне, кирәк булган материал белән тәэмин итүне Арслановка тапшырды да үзе вагон-складка завхоз Тутаев Муса янына разнарядка язарга керде.

Азны күпкә бүлү җиңел эш түгел икән. Блокнотның биш-ун бите язылды, сызылды, ертып ташланды. Аеруча май, чәй-шикәр авыр бүленде — аз, бик аз җибәргәннәр. Тутаев түземен югалтып, базадагы «бюрократлар»ны сүгеп тә карады. Әмма аңа карап фактуралардагы нетто-килограммнар грамм да артмады. Юрганга карап аякны сузарга туры килде.

Ниһаять, директор разнарядкага кул куйды — килгән азык җан башына бүленеп төгәлләнде. Тагын үлчәү, бүлү, капчык, ящик табу һәм ташып төяү азабы башланды.

Иң соңгы трактор төялеп бетеп юлга борылды. Тояк аны станнан чыкканчы озата бармакчы иде, кемдер җиненнән тартып туктатты:

— Ага, дим!.. — Каракүз ачулы тавыш белән эндәште. — Инде өч кабат килдем, гой. Ашыгыз Вераның бүлмәсендә тора, суынып калды. Барыгыз, ашчан үләсез, гой.

Тояк тукталды. Трактор буран эченә кереп югалды. Ашказаны бокырдап куйды, чыннан да ашасы килгән ич.

— Йөреңез.

Каракүз һаман әле китмәгән икән. Боерыкка буйсынырга туры килде.

— Хәзер бараен, кырындас.

Тояк, кызның артыннан ияреп, җепшек карда тая-тая кызлар вагонына таба атлады.

Учетчица Вераның бүлмәсе — кысрык почмак. Карават. Урындык. Газета ябылган кечкенә өстәл. Анда өстенә тәлинкә капланган миски. Чәйнек, кружка, кашык. Бер түтәрәм күмәч. Каршыдагы стенага «яркенат» эленгән. Тояк кепкасын стенадагы кадакка элеп, урындыкны тартып өстәл янына утырды, кесәсеннән пәке чыгарып күмәч турады. Фанер стена артындагы гөжелдәү басыла төште — йоклап киттеләр, күрәсең.

Тояк мискидәге ботканы ашап бетереп, кружкага чәй агыза башлаганда гына ишекне шакыдылар.

— Керегез.

Куфарян керде:

— Иптәш директор, яңа парторгны алып килдем.

Тояк кружкадагы чәен киредән чәйнеккә салып аягүрә басты.

— Әйтегез, керсен.

Куфарян, «ярый» дип, борылып чыгып китте.

Тояк, тынычсызланып, ишекле-түрле йөри башлады.

— Җана! Бол җана борынгының урынын баса алырмы? — Ул туктап уйланып торды да урындыкка утырды, папирос кабызды. — Бар иде, гой җолдас, алтын җолдас.

Папирос кызарып яртысына хәтле янып төште. Бер-бер артлы зәңгәр бөҗралар күтәрелде. Күңел якын дусны, юлдашны сагынды.

...1954 нче елның декабре иде. Чатнап торган суык көннәр. Тояк, булачак совхозның мәшәкате белән көн буенча Күкчәтау урамнарында йөгереп арып, гостиницадагы номерына кайтып егылды. Кинәт номерның ишеге ачылды, билгесез кеше шакып та тормады, үз күреп туптуры узды. Ул озын, таза; өстендә кара бәрән тиресеннән билен бөрмәләп теккән тун. Башында шундый ук кара бөдрә бүрек. Аякларда кара киез итек. Ул ышанычлы, нык адымнар белән атлап килеп караватта яткан Тоякка зур йонлач кулын сузды.

— Хәерле кич! — Тавышы күкрәп чыкты. Тояк, аптырап, торып утырды. Теләр-теләмәс кенә кулын бирде. — Ялгышмасам, «Алка күл» совхозының директоры Тояк Бөркетбаев буласыз? Мин Николай Николаевич Сыщенко. — Тояк, гадәтенчә, беренче очрашкан кеше белән җитди-официаль төстә күрешергә теләсә дә, булмады. Керүченең елмаеп торган ачык йөзе, бер-берсенә кушылып үскән калын кара кашлары астындагы зур кара күзләре аны үзенә буйсындырдылар. Ул елмайды, якын бер дустын очраткан кебек күреште. Николай Николаевич Тоякның кулын каты кысып, селкеп торды. — Сезнең белән танышуыма бик шатмын.

Тояк кунакка үзен тәкъдим итәргә өлгермәде, Николай Николаевич, нәкъ үз өендәге кебек, иркенләп өс киемен, бүреген салып шифоньер эченә элде.

Ул хаки төсендәге гимнастеркадан, күн галифе чалбардан, билдә — киң каеш. Калкып торган киң күкрәктә «Алтын йолдыз». Николай

Николаевич чәчен бармаклары белән генә тарап алды да, урындык алып, Тояк янына килеп утырды, сөйләп китте:

— Минә, иптәш Бөркетбаич, бүгенге көннән, без икебез бергә эшли башлыйбыз. Парторг. Менә обкомның карары. — Ул гимнастерка кесәсеннән дүрткә бөкләнгән кәгазь чыгарып, Тоякның алдына салды. Тояк кәгазьне җәеп укып та бетерә алмады, Николай Николаевич, башланган әңгәмәнең өзелеп калуына борчылгансыман, тизрәк сүз ялгарга теләп кулын сузды. — Ярый, ташла, калганын мин киткәч укырсың.

Тояк ирексез буйсынды, обком карарын укып бетерер-бетермичә өстәлгә куйды. — Хикмәт карарда түгел, эштә. Танышып алыйк: фронтта — танкист. Гражданкада — механик. Харьков трактор заводыннан. Тракторны, комбайнны, автомашинаның барлык маркаларын күз йомып йөртәм. Бозылса — төзәтәм. Ә менә авыл хуҗалыгын, — ул кинәт сүзен кисеп, балаларча беркатлылык белән елмайды, — иген үстерү эшен, дөресен әйтим, чамалы беләм. Казагстанны бүген күрәм. Беренче казакъ дустым сез буласыз. Сөйләгез, совхоз ничек башлана?

Ул көчләп Тоякның авызын ачтырды. «Менә кеше, авызыңнан сүзеңне тартып ала», — дип сокланып, шундук ияләшеп, Тояк совхозның ничек корыла башлавын сөйләп китте. Алар бер-берсеннән аерылыша алмыйча, озак утырдылар, киңәштеләр, план кордылар. Николай Николаевич икенче көнне үк совхозның механизация көчләрен барлыкка китерү эшенә тотынды.

Шундый бәхетле кешеләр була бит җирдә. Алар өчен һәрбер ишек ачык, һәрбер кеше таныш, һәрбер эш ятышлы. Казакълар андый кешеләрне «йолдызы ак» диләр. Менә шундый ак йолдызлы кешеләрнең берсе, мөгаен, Николай Николаевич Сыщенко. Аз гына вакыт эчендә ул совхоз өчен кирәкле булган барлык техниканы: трактор, автомашина, чәчү машиналары һәм башкаларны җыештырып алды.

— Яңа кала электричествосыз буламы? Двигатель кирәк. Машина булгач, ремонт мастерское да булырга тиеш. Станоклар, инструментлар табарга кирәк, — дип, ул төн йокламыйча шулар артыннан чапты. Вокзал аның штабквартирасына әверелде. Бер көнне машиналар кабул итте, икенче көнне шау-шулы эшелоннарны каршы алып, трибунага чыкты, яшьләргә ялкынлы речьләр сөйләде, яңа җирләрне тизрәк үзләштерергә чакырды.

«Алка күл» җиренә беренче эшелон кузгалды. Николай Николаевич — алдагы тракторда. Ул, яшьләр белән бергәләп, беренче палаткаларны корышты. Алар белән бергәләп совхозның территориясен карап чыкты, булачак бригадаларның станнарын билгеләде. Шундук бригадалар оештыра башлады. Техниканың телен яхшы белгәч, аңа механизаторлар белән сөйләшү, аларның сыйфатларын билгеләү, бригадирларны сайлап алу да җиңел иде. Ул бригадаларны оештыруга аеруча күңел бирде. Николай Николаевич бик тиз арада совхоз кешеләренең иң якын, иң кирәкле кешесенә әверелеп китте. Аны яраттылар. Аннан курыктылар һәм олыладылар.

Түземсезлек белән көткән яз да килеп җитте. Билгеле, ул монда, башка җирләрдәге кебек, шаулап, тавышланып, кояш балкытып, чәчәкләр исе аңкытып килмәде. Акрын гына, сызылып кына кар китте. Аның кай вакытта, кайда югалуын берәү дә күрмәде. Кояш күренде, аны болытлар капладылар, салкын җил исте, тагын кояш чыкты, җылытты. «Алка күл» даласы ак киемен шулай күрсәтмичә генә, тавышсыз гына салды.

Иртәгә «Алка күл» даласында беренче буразналар сызылачак. Нинди зур шатлык! Совхозның барлык эшчеләре дәртләнеп, куанып шул мәңге хәтердә калачак тантаналы көнгә хәзерләнәләр. Тракторлар, культиваторлар, сабаннар, зигзаг тырмалар үзләренә билгеләнгән участокларга якынлашып тукталдылар. Иртәгә!

Нәкъ менә шул «иртәгә» дигән кичне Бөркетбаев белән Сыщенконы Кукчэтауга — партия өлкә комитетына чакырдылар.

Аяз көнне яшен суккандай булды. Икесе дә коелып төштеләр. Сорау да, үтенү дә, баш тарту да файда итмәде.

Партия өлкә комитетының карары катгый булды. «Николай Николаевич Сыщенконы Кызыл Тау районына совхоз директоры итеп билгеләргә, «Алга кул» совхозына тиз арада яңа парторг җибәрергә».

Тояк «Алка кул»гә ялгыз, уң кулын югалткан кешедәй тилмереп кайтты. Язгы чәчүнең бар авырлыгы һәм җаваплылыгы аның өстенә ятты. Ә күңел һаман ышанмады, көтте. Менә-менә Николай Николаевич кайтып килеп, йөнтәс кулын сузар төсле иде...

Ишекне шакыдылар. Тояк башын күтәрде. Сүнгән папиросы кулыннан төшеп китте. Ишектән башлыклы плащ кигән күзлекле кеше керде.

## VII

Сый сыек булды. Берәр кружка суынган чәй — бар хөрмәт. Үзара сүз дә ялганып китә алмады. Сорау, җавап бирү рәвешендә генә барды. Вакыт соң. Тояк та, Сәет тә арыганнар. Һаваның торышы рәтсез. Ә совхозның хәле... Тояк бу турыда сүз башласа да, иртәнге радиокиңәшмәдә партия өлкә комитеты секретарена биргән рапортыннан артыкны әйтә алмады. Дөресендә, ул рапортка тагын нәрсәне өстәргә була? Күз алдындагы афәтне кабатлап телгә алудан ни хәер?..

Тояк өстәлгә таянып сөйләгән килеш калгып китте.

— Иптәш директор, — Сәет, караваттан кузгалып, эшләпәсен кулына алды. Протез сыкрап чинап куйды, — сез, булмаса, бу караватка ятып ял итеп алыгыз, мин вагонга, бригада янына чыгыйм.

— Ә? — Тояк сискәнеп сикереп торды. — Гафу итәсез... жок, жоктауга булмайды. Хәзер алтынчы бригадага баруым кирәк. — Ул папахасын киеп ишеккә атлады. — Мин сезне бригадир Арсланов белән таныштырып китим.

Вагонның ишеген ачуга, Тояк бусагада аз гына тукталып калды. Яп-якты. Ничек болай? Бая мич яктысында гына утырган идек бит. Түшәмдә куыклары ялтыратып сөртелгән, филтәләре тулы чыгарылган ике «ярканат» янып тора. «Мөгаен, Куфарян Куктирәктән алып килгән». Тояк иелеп бусагадан атлады. Аның артыннан Сәет керде. Ул, яңа кеше буларак, вагонның эчен җентекләп карап алды. Тимер мич янында ике кыз табак-савыт юа. Берсе — урта буйлы, таза. Бите түгәрәк. Кыйгач сөрмә каш. Кап-кара чәч ике толым итеп үрелеп күкрәккә төшерелгән. Икенчесе — күршесенә караганда калку, чандыр. Аның йөзе озынча, ябык күренә. «Под кружок» киселгән, тузып торган кызгылт чәч. Кызлар, Сәеткә астыртын гына карап, эшләрен дәвам иттерәләр. Сәкенең бирге башында чыланып беткән фуфайкалы берәү мискиен тез өстенә куйган да, башын да күтәрмичә, ашыгып ботка ашый. Башкалар аслы-өсле сәкегә тыгызланып ятканнар, йоклыйлар. Тракторчыларның бер өлеше башка бригадаларга азык алып киткәнгә, хәзер инде вагон бераз бушый төшкән иде.

Уртагарак узгач, Сәет тавышын күтәрмичә генә исәнләште. Кызлар, икесе берьюлы елмаеп, сәлам алдылар. Ботка ашап утыручы сискәнеп башын күтәрде дә мискиен тоткан килеш аягүрә басты. Ул, авызындагы боткасын йотар-йотмас, ашыгып нәрсәдер әйтмәкче иде, чәчәлде, миские чак кына кулыннан төшеп китмәде. Кызлар пырхылдап көлеп җибәрделәр.

— Утыр, утыр, Иргали. — Тояк егетнең су саркып торган җиңеннән тартты. — Лач су булгансың, гой. Хәзер сал да элеп киптер. Син әллә ашка да килмәдеңме? Кайда булдың?

Иргали, кередән сәке кырыена чүгеп, бер-ике кашык ботка капты да шуннан соң гына директорга борылды.

— Завхозга булыштым, иптәш директор. Аргы складның ишегән көчкә ачтык. Кар баскан.

Тояк Иргалине, Каракүзне, Вераны Сәет Батталов белән таныштырды да:

— Менә нәрсә, бригадир, — дип төп сүзгә күчте, — мин хәзер бригадага задание бирергә уйлаган идем, халык йоклап калган. Уятмыйк, бүгенге азап җитәрлек булды.

Иргали, калгып китеп, маңгае белән сәке баганасына сугылды да сискәнеп башын күтәрде, кызарган күзләрен зур итеп ачты. Тояк, Сәеткә карап, «менә хәл ничек» дигәнсыман башын чайкады, элеккегә караганда катырак тавыш белән һәм сүзен бүлеп-бүлеп әйтеп дәвам итте:

— Хәзер ят та ял итеп ал. Таң иртән бар тракторчыларны Наузатумар маңгаендагы сөрелеп бетмәгән участокка җибәр. Калган халык чәчүлекне карасын, машиналарны майлап, көйләп куйсын. Инде төштән соң, көннең бите ачылса, может, чәчүгә чыгарга булыр, төшендеңме?

— Бик төшендем. — Иргали хәтта аптырап карады. — Нигә төшенмәскә? Кояшның колагы гына күренсен... Болай да целый бер көн казага китте.

— Сүзең дөрес, бригадир, безнең казакъ халкы, казаның хәерен бирсен, ди. Безнең өчен хәер — туктalып калган эшне тизрәк урыныннан кузгатып җибәрү. Таң иртән Күкчәтауга машиналар җибәрү кирәк. Бензин, солярка азаеп калган күренә. Җыелма өйләрнең детальләре дә ташылып бетмәгән.

— Машиналар җитешми бит, иптәш директор.

Тояк, кесәсеннән блокнот чыгарып, кайсы шоферны кая җибәрү турында киңәшә һәм яза башлады.

Сәет сүзгә кушылмады, катышырга җае да чыкмады. Директор белән бригадир хуҗалыкның конкрет эше турында — кешеләрнең исемфамилияләрен, машиналарның номерларын, маркаларын әйтеп сөйләштеләр. Ә Батталов өчен бу хуҗалык әлегә вагон артындагы төн төсле караңгы.

Хәзер бар игътибарны менә шушы әңгәмәгә тупларга — мөмкин кадәр күбрәк исемнәрне, хуҗалыкның аерым тармакларын, урнашкан җирләрен хәтерләп калырга кирәк иде. Менә бу сәгатьтән башлап аның язмышы шушы кысынкы вагондагы кешеләрнең язмышы белән бергә бәйләнә бит... Шулай булгач... Сәет бер директорга, бер бригадирга карады. Алар әйткән исемнәрне, фамилияләрне күңелдән кабатлап торды.

Шулай да күңел иләс-миләс. Уй бүленә. Моннан әле өч-дүрт сәгать кенә элек булып үткән көтелмәгән вакыйга күз алдыннан китми.

«Онытылган, өмет өзелгән иде бит. Өнме? Төшме? Кайдан, кайдан килеп чыктың син, Гайшә?! Очрашу! Унсигез елдан соң очрашу һәм... бер-береңә күтәрелеп тә карамыйча, бер авыз сүз дә әйтә алмыйча борчылу... Ә бала? Сабырсызлык белән көткән беренче куанычыбыз... Ул бармы? Бармы ул кадерле җан дөньяда?» Сәетнең маңгаена салкын тир чыкты. Ул чак-чак кына соңгы сүзләрен кычкырып әйтмәде. Батталов тиз генә кесәсеннән папирос алып кабызды, суырды. Тынычланырга тырышты — әмма...

«...Юк, Гайшә инде башка кеше. Ул менә бу, каршыда утырган Тояк Беркетбаевның... ә син, Сәет?..»

— Җолдас парторг, — Тояк, бригадир белән сүзен бетереп, Сәеткә таба борылды. — бая әйткәнчә, сез шушы бригададагы халык белән, эш белән танышыгыз. Мин юлга чыгам.

— Юк... — Сәет сискәнеп уянып китте. Башта нәрсә әйткәнен дә хәтерли алмый калды. «Нәрсә дидем? Да, юк... Юк». Карангыда утыру коткарды. Тояк Сәетнең шашып калуын, аптыравын сизмәде. Ул арада

Сэет үзен кулга алды һәм юри, сүзләрен сузып, уйланган рәвештә, ялгап китте: — Минемчә... иптәш директор, мондагы эшләрне бригадир Арсланов үзе дә башкарып чыга алыр. Миңа кая да булса ераграк торган бригадага бару файдалырак булыр. Шулай түгелме?

— Җаксы, — Тояк урыныннан торып папахасын киде, — мин каршы түгел. Алай булса... — Ул бераз уйланып торды, — җаксы, сез өченче бригадага барыгыз. Ул Куйташта тора. Анда бер генә юл, егетләр күрсәтерләр. Мин алтынчы, бишенче бригадаларда булырмын. — Сәет, аралыктан чыгып, директорга узып китәргә юл бирде. Тояк ишеккә таба бер-ике атлады да кире борылды. — Да, бригадир, син хәзер конюшнига барып, елкычы Буранбайга әйт, көннең күзе күренүгә Карагир белән күк бияне иярләп монда алып килсен. Без... — Ишектән бер чиләк су күтәреп Вера керде. Тояк сүзен бүлеп аңа эндәште: — Монауның ни, Вера, тагын чәй куясыңмы?

— Юкка. — Кыз елмаеп башын чайкады. — Күрәсез бит, Бөркетбаич, идән ничек каткан, бераз сөртеп алырга кирәк. Оят.

— Ә кайчан ял итәсез?

Ул арада Каракүз йөгереп килеп, Вераның кулындагы чиләкне алып, мич өстенә куйды, җавап та биреп өлгерде:

— Анысы өчен кайгырмагыз, ага, вакытын табарбыз. Кызның җаны кырык.

Каракүзнең чаялыгы Сәетне дә сүзгә тартты:

— Ә кырык беренчесе?

— Билгеле инде, — Каракүз җитди кыяфәт белән кашларын җыерды, — чыбык...

Барысы да кычкырып көлеп җибәрделәр.

— Ну, җитәр, — Тояк бармагын янап тыелырга кушты, — халыкның тынычын алмыйк, йокласыннар. Әгәр Вера рөхсәт итсә, без аның бүлмәсен тагын берәр сәгатькә арендага алырга уйлыйбыз? Рәнҗемисезме?

— Ул ни дигән сүз, иптәш директор?!

Вера үпкәләп карады, аннары:

— Барыгыз. Мин монда Каракүз янында йоклармын, — диде.

— Ну, алайса рәхмәт. Җолдас Батталов, әйдәгез, атлар килгәнче ял итеп алыйк.

Сәет белән Тояк Вера бүлмәсенә чыктылар. Кызлар идән юарга хәзерләнә башладылар. Иргали мич өстендәге колгага эленгән фуфайкасына урелде.

Саркып, сүрән генә көн туа. Җил туктаган. Кар яумый. Ләкин соргылт, авыр болытлар һаман әле ябага йон булып салынып өстерәләләр.

Юл пычрак, тайгак. Карагир атлагак саен таеп, сөртенеп китә — башын чайкап кылганга борылырга омтыла, Тояк тезгенне бушатты. Елкы баласы сизгер, шунда ук юлны ташлап кылган өстенә чыкты, юыртып китте.

Ялгыз карагай үренә күтәрелгәч, Тояк башын күтәреп әйләнә-тирәгә күз ташлады. Әле күптән түгел генә күтәрелгән, тырмаларга өлгермәгән буй-буй буразналарга кар сырышкан. Кичәге буранда кыр өстендә туктап калган сабаннарга, чәчү машиналарына кыйгачланып көрт яткан.

— Менә сиңа язгы чәчү!..

Тояк, көрсенеп, тужуркасының якасын күтәрде, папахасын басыбрак киде, тезгенне тартты. Карагир, сискәнеп, башын чайкап чаба башлады. Тояк аны тартып туктатты, җиңел җилешкә төшерде.

Ялгыз юлчының юлдашы — үлән [1]. Үләне юк юлчының юлдашы — уй, ди казакъ. Тояк үләнгә бай егет иде. Ул бала яшеннән үлән, думбра моңы белән үсте. Аның тавышы көр, җыры мул. Нәкъ менә хәзер күңел җырга ятмады. Уй борчыды, очсыз-кырыйсыз, чуалган уйлар.

[1] Үлән — җыр.

...Карагир тайгак юлдан кылганга чыкты. Хәзер аңа җиңел — җилдертеп бара. Бөркет улы Тоякка да үзенең хуҗалык эшләрен җилдертеп алып барырга вакыт иде инде... Барып чыкмый. «Алка күл» һаман такыр юлга чыга алмый. Ансыз да сузылып, таркалып барган чәчү ләгънәт төшкән буран аркасында тагын артка чигенде. Иртәгә, берсекөнгә, аннан соң көннең күзе ничек карар. Кайгың булса — дустыңа бар, карының ачса — куышыңа бар, ди картлар. Авыз ачылса — сер күренә. Тояк беренче очраган кешегә серен ачып егыла алмый. Ләкин ялгыз атлау да читен...

Тояк үзенең уйларын шулай ерактан урап алса да, төп фикер тел очында гына иде.

— Яңа парторг арка таянычы була алырмы?

Беренче тәэсир! Ул алдый да, алдамый да. Дөресен әйткәндә, Сәет Батталов Тоякның күңеленә ул көткән кеше булып керә алмады. Эшләпә, костюм, галстук, күзлек, өстәвенә — протез! («Бу — балалык. Тышкы кыяфәте кешенең эчке дөньясын ача алмый».) Тояк үзенең беренче уен кире кагар өчен Сәетнең биографиясен тартып чыгарды. Анда да күңелне юатырлык, ышанычны ныгытырлык нигез күренмәде. Студент. Ун ел төрмәдә утырган. Аннан кайткач, бухгалтер — өстәл кешесе. Тояк эзләгән зәмин: авыл хуҗалыгында эшләү, техниканы белү, яисә массаны җитәкләп бару практикасы берсе дә табылмады. Менә шушы кеше Николай Николаевич урынына баса!

«Тукта, Бөркет улы, — күңел түреннән икенче бер тавыш килде, — син нигә алдан кисәсең? Ул да ак ният белән билен буганнарның берсе түгелме? Бүген килде. Бүген үк атка атланды. Сез икегез дә юлда ич...»

Карагир кинәт куркып артка чигенде, пошкырып борылды, баш бирмичә далага чапты. Тояк, егылуын егылмаса да, яхшы ук сискәнде, өзәнгеләргә басты, тезгенне каты тартты. Карагир бераз тартылып барып борылды, үзе һаман дерелди, колакларын торгызган, ялт-йолт тирә-якка карана. «Нәрсәдән өркеде?» Тояк та ян-ягына борылды.

— Уй-бай, җанварым! — Тояк кычкырып көлеп җибәрде. — Курыкканың шул булдымы?

Йоннарын коя башлаган соры куян җан көченә сикереп үргә кача. Болытлар сирәгәйгән. Көн яктырып килә. Озакламый кояш та чыгар төсле. Тоякның күңеле тынычлап, иркенәеп китте. Ул Карагирне кызулап, йолкыш куян качкан юлга чыкты.

Бу якның күренеше башка. Дала соргылт. Былтырдан калган кылган киез булып түшәлгән. Кар да аз, анда-санда уйсулыкта гына күренә. Карагир башын чайкап кешнәп җибәрде. Тояк яңа гына шәйләде: еракта өер-өер елкылар утлап йөри. Ат заводы елкылары. Моннан егерме километр ераклыкта Чагана үзәне буенда дәүләт ат заводы урнашкан. Ул асыл нәселле аргамаклар үстерә. Казакъ елкысы да бар, бигрәк тә бияләр. Аларны савалар. Әнә аргы үр итәгендә, Ак болак буенда, ике киез өй. Төнлекләрдән сузылып зәңгәрсу төтен күтәрелә. Анда кымыз фермасы. Тоякның борыны кычытып китте, әйтерсең лә, әчкелтем кымыз исе аңкыды... «Юыртып барып бер-ике савыт кымыз эчкәндә яхшы булыр иде...» Тояк ымсынды, ләкин тезгенне ул якка тартмады, тизрәк бригадага барып җитәргә кирәк. Инде ерак калмады. Әнә алда, офык читендә, күгелҗем томан. Юк, ул томан түгел, Күкчәтауның мәрмәр үркәчләре... Күңел нечкәреп, шушы далада мал көтеп йөргән көннәр искә төште.

Менә ул Тоякның туган туфрагы, туган даласы. Ата-ана кочагын белмичә үскән ятимне иркәләгән җәйләү һәм ашкындырып күтәргән мәһабәт Бурабай. Синең керсез, изге мәхәббәтең алдында нинди йөрәк ачылмас, нинди күңел җыр булып ташымас?!

Акрын, аннан көчәя-көчәя барып моңлы бер җыр күтәрелде. Дала яңгырап китте. Тояк туган җире белән күреште.

— Күгелҗем күк Күкчәтауны томан баскан,
Аның башы болытларның чәчен ачкан.
Бер кыя бар, сөнге булып төп-тек тора,
Әйтерсең лә, коеп куйган мәрмәр таштан.

## VIII

Август аеның караңгы һәм яңгырлы төннәренең берсе иде. Туксабай авылы — алка булып тезелеп утырган бер дистә киез өй — җиргә сеңгәндәй югалып, тавышсыз-тынсыз йоклый. Кинәт берничә эт алмаштилмәш тавыш бирделәр дә тындылар, күрәсең, киредән арба астына ышыкландылар. Авылның читендә утырган иске киез өй янына, елкычы Бөркетнең куышына атлы бер юлчы килеп туктады. Аның аты шабыр тир, үзе манма су.

Озак та үтмәде, бу өйгә авылның урта яшь ирләре, егетләре җыелды. Төн буенча шыпырт аңгәмә барды. Бу вакытсыз йөргән юлчы Бөркетнең атасы Ташҗан әкәнең кече энесе Лачынтай иде. Ул Җидесу ягыннан килгән. Лачынтай, моңа кадәр казакъ илендә ишетелмәгән гаҗәп хәлләрне әйтеп, тыңлаучыларны хәйран уйга калдырды.

— Ак патша, — диде ул сүз ахырында акрын, ләкин көр тавыш белән, — яман уйда. Ни кирәк, сораганын аямадык — мал бирдек, ат бирдек, куй бирдек, җон бирдек, акча бирдек. Ул инде чебен җаныбызга кул сузды. Бу хурлыкка казакъ иле ничек чыдасын. Кичә үзбәк йорты кулына мылтык, кылыч алып, Ташкенттагы солдат җыя торган өйләрне утка көйдереп, түрәләрен куды. Аму-Дәрьядан алып Сыр-Дәрьяга чаклы ярчылар [1] чапты. Моны ишетеп Җидесу казакълары да атка менде, кулына корал алды. — Тыңлаучылар башларын күтәреп берберсенә карадылар. Лачынтай, бераз тынып, җир учакны урап алган дусларына уйларын җыярга мөмкинлек бирде, алдындагы аяктан берике йотым кымыз эчте. Аннан тамагын кырып, тавышын күтәрә төшеп дәвам итте: — Үткән йолдызның тулган ай көнендә Өлкән Алма-Ата авданында илнең өлкәннәре җыелды. «Инде ни кылабыз?» — дип, халык бер-берсенә караганда, авылнайлар, болыснайлар, аксөякләр беравыз булып, ак патшаны яклап, җан бирүгә чакырды. Шунда Тукаш Бөкин дигән бер егет атылып торды да, каты сүз әйтеп, аксөякнең йөзенә кара якты, битен тырнады. «Ак патшага инде кол булмыйбыз. Солдатка аксөяк бармайды, гидәй китәде. Сүзем бер — казакъ иле бүген атка менеп, кылыч алсын! Урысның чиновнигын, казакъның сатлык аксөяген аямый таптасын», — диде.

— Бәрәкалла! — Тыңлаучылар тавышланып сүзне күтәреп алдылар. — Дөрес айткан!

— Тукаш ир егет икән.

Шул ук таңда бу авылдагы барлык ир егет, атка атланып, Лачынтай белән далага китте. Алар арасында Тоякның атасы Бөркетбай да бар иде.

Еллар буенча кайнар яшь түгеп, байлар, биләр, чиновниклар камчысы астында иңрәгән гидәй казакъларның түземе чигеннән чыкты. Дала ат тояклары дөпелдәүдән, үч алуга чакырган ачулы авазлардан, кылычлар, сөңгеләр, китмәннәр чагылудан дер селкенде. Кузгалыш Каспий диңгезе ярларыннан Кытай чигенә, Тянь-Шань тауларына кадәр чайкалды. Бары Күкчәтау, Акмолла авданнарында гына ун меңнән артык ир егетләр атка атланып, ни туры килсә шуның белән коралла-

---

[1] Ярчы — хәбәр бирүче.

ныл, азатлык өчен көрәшкә бил бәйләде. Алар болыснайларны, стражникларны үтереп, «хезмәткә чакыру исемлекләре»н яндырып, телеграф баганаларын аударып, юлларны яптылар. Баш күтәрүчеләрне һәм аларны яклаучыларны җәзалау өчен далага яңадан-яңа отрядлар чыкты. Омск генерал губернаторы Күкчәтау өязенә генерал Ягодкин командасында унтугыз кавалерия сотнясы, аеруча нык кораллландырылган унбер пехота ротасы җибәрергә мәҗбүр булды. Бу отряд, баш күтәрүчеләрне очратканчы, тыныч авылларны яндырып, малларын куып алып китә башлады. Әле моңа кадәр кузгалышка кушылмыйча, икеләнеп, ике арада калган казакълар да, карательләрнең вәхшәтлегенә түзә алмыйча, атка атланып, кулларына корал алдылар.

26 сентябрьдә баш күтәрүчеләр генерал Ягодкинның отрядын Коҗас җәйләвендә куып җиттеләр.

Баш күтәрүчеләр якынлашуга, отряд икегә бүленде — пехота фронт буенча сузылып ятып, мылтык, пулемет уты ачты, кавалерия отрядның тылын һәм флангларын саклап, һөҗүмгә ташланучыларны ян-яктан кысарга ашыкты. Тузан, ут, җан тетрәткеч ай-вай күтәрелде. Ике як бер-берсе белән буталды. Дала уртасында дәһшәтле сугыш башланды.

Беренче, көчле ташлануга чыдый алмыйча отряд бераз чигенсә дә, баш күтәрүчеләр үз теләкләренә ирешә алмадылар. Кылыч, сөңге, кистән белән ташланучыларны мылтык, пулемет кырып салды. Кавалерия ян-яктан кысып, урап ала башлады. Баш күтәрүчеләр котылгысыз үлем чолгавын күреп, чигенә башладылар.

Нәкъ менә шул, өметнең тәмам киселгән вакытында, отрядның тылы артындагы үрдән меңләгән атлылар чыкты. Бу Лачынтайның егетләре иде. Алар ачулы кычкырулар белән солдатлар өстенә ташландылар. Инде тәртипсез рәвештә чигенеп, кача башлаган беренче төркем, уйламаганда килеп чыккан булышлыкны күреп, дәртләнеп, гайрәтләнеп кавалериянең һөҗүмен кире какты һәм пехотаны таптап үтте. Генерал Ягодкинның отряды көч-хәл белән генә җыелып Күкчәтау ягына чигенергә мәҗбүр булды.

Бу тиңсез сугышта Сары арка үзенең йөзләгән батыр егетләреннән аерылды. Лачынтай да үзенең арка таяныч дусларын югалтты. Шулар арасында аның бердән-бер энесе Бөркетбай да мәңгегә күзләрен йомды...

Баш күтәрүчеләр белән җәзалау отрядлары арасындагы сугыш кара көзгә хәтле барды. Баш күтәрүчеләр бик күп бәрелешләрдә патша отрядларын тар-мар китереп, станицаларны, хәтта калаларны урап алып, курку салдылар.

Ләкин билгеле бер үзәк командага оешмау, таркау хәрәкәт итү, тиешле дәрәҗәдә коралланмау, сугыш тактикасын белмәү һәм бай казакълар, муллаларның ак патшага буйсынырга чакырып коткы салулары, ниһаять, кыш килеп җитеп, ышыклануга урын таба алмау аркасында баш күтәрүчеләрнең көче акрынлап таркалды.

Үз уеннан чигенмәс батырлар коралларын ташламадылар, өметләрен югалтмадылар. Кайбер төркем Кытай чиген үтеп Колҗа, Кошгар җирләрендә тупландылар, кайбер төркемнәр Тянь-Шань таулары арасында сакландылар. Ә иң гайрәтле тәвәккәл егетләр, Тургай даласына чыгып, Амангелде Иманов отрядына кушылдылар. Көрәш Октябрь революциясенә хәтле дәвам итте.

1916 нчы елның кар аралаш яңгыр яуган көзге төннәренең берсендә Ташҗан әкәнең өенә тагын Лачынтай килде. Ул озак тукталмады. Хәвеф-хәтәрле вакыт. Авылдан-авылга җәзалау отрядлары йөреп баш күтәрүчеләрне эзәрлеклиләр, аларның туганнарын, хатыннарын кулга алып «заложник» итәләр, төрмәгә ябалар. Ташҗан әкә: «Мин инде яшемне яшәдем, ашымны ашадым, төрмәдән дә, үлемнән дә качмыйм.

Лачынҗан, кулыңнан килсә, киленем Асылкулны сакла. Бөркетбай, ни әйтәсең, шәһит китте... Мин Тоякҗан белән калып көнемне күрим...» — дип авыр уйга калды. Тояк җир бишектә гамьсез йоклый иде. Асылкул елап улының өстенә ауды.

Таң беленер-беленмәс Лачынтай белән Асылкул атка атландылар. Ташҗан әкә аларны озатып, ак юл теләп калды.

Көннәр ай, айлар ел булып йөрәкне тырнап, сызылып сузылды. Ерак юлга китүчеләрдән хәбәр килмәде.

Бары авыл җәйләүгә күчкәндә генә, Ташҗан әкәнең өенә бер мосафир туктап:

— Лачынтай Амангелдегә кушылган. Асылкул юлда барганда авырып дөньядан күчкән... — дигән кара хәбәр әйтте.

Тояк ата-анасыннан аерылып, карт бабасы кулында, ятим булып калды.

Җитәм дигәндә генә өмет җимерелде. Карт хәлсезләнеп иске киезгә сузылды. Гидәйлек яткызамы? Ташҗан әкә ирексездән таякка таянып торды. Туксанбай хаҗиның алдына килеп баш иде. Ак патша ауды, аның урынына Колчак патша килде. Ул китте, атаман килде. Ләкин далада һичбер үзгәреш күренмәде. Авыл һаман әле әүвәлгечә Туксанбай хаҗиның кабагына карап, дерелдәп торды. Хаҗи карт елкычыны «кызганып» куй багарга алды.

— ...Бүз тургай, чырылдыйсың җиргә төшеп,
Мин йөримен кичкә кадәр тамак эчми [1].
Ат итеп ак таякны кулыма тотып,
Кыйналам куй артыннан иртә-кичен.

Ай... ау, бүз тургай,
Чырылдыйсың, кошым, ай!
Котылыр көн булыр микән
Шушы байдан беркөн, ай?!

Утырып куй күзәтсәм, таңым атмый,
Йөргәндә малны карап шәфәкъ батмый.
Җаным, ай, әйләнәмдә бер адәм юк.
Билем чишеп түшәгемә бер төн ятмыйм.
Ай... ау, бүз тургай!..

— Ата!

Тояк җан тавышы белән кычкырып җибәрде. Җыр кырт киселде. Ташҗан әкә сызлаган сөякләрен көчкә җыеп, таягына асылынып аягүрә басты. Әле генә куй, кәҗә бәтиләре белән сикереп уйнап йөргән Тояк зур тәкәнең мөгезендә күлмәгеннән эленеп тора. Баланың йөзе агарып киткән, кечкенә генә кара күзләр чыгып китәрдәй акайганнар. Тәкә дә, аның мөгезенә эленгән кечкенә Тояк та бу көтелмәгән хәлдән аптырап, кузгалырга куркып катып калганнар.

Ташҗан аякларын авыр сөйрәп Тоякны коткарырга ашыкты. Тәкә әүвәлгечә кузгалмыйча тик тора. Тояк, олы әкәсенең якынлашуын күреп, куркуын онытып көлеп җибәрде:

— Ата, кулыңны бир.

Ташҗан кулын сузарга өлгермәде, тәкә сискәнеп артка чигенде, аннан бар көче белән башын чайкап чабып, үрдән түбән төшеп китте. Куйлар, кәҗәләр өркеп төрлесе-төрле якка таралдылар. Бала тагын җан тавышы белән кычкырды. Карт үз аягына үзе уралып егылды.

Ул ава-түнә килеп җиткәндә, бала үр астында иссез ята иде. Ул ташка сугылган, авызы, борыны кан.

---

[1] Тамак эчми — ашамыйча.

Бәхеткә каршы, елкычылар килеп чыкты. Алар Тоякны күтәреп якындагы болакка алып барып юындырдылар, исенә китерделәр, кымыз эчерделәр. Карт тагын оныгын житәкләп куйлар артыннан китте.

Ә бүз тургайлар, бернәрсә дә булмаган төсле, очынып очтылар, чырылдап күккә күтәрелделәр. Алар киңлектә, биеклектә, алтын нурлар эчендә коендылар.

Тояк атка менде, ул алдынгы булып килә алмаса да, берничә бәйгедә үк ат өстендә яхшы йөри белүен күрсәтте. Ташжан әкә көннән-көн артка чигенде. Бигрәк тә аяклар аны артка тарттылар — сызладылар, йокы бирмәделәр. Буыннарны көзән җыерды, карт йөри алмый башлады. Шулай итеп, куй багу да аның кулыннан китте. Менә шул көннәрдә тургай даласыннан Лачынтай кайтып килеп, Ташжан әкә белән Тоякны үз авылына, Бурабай ягына күчереп алып китте.

Ташжанның инде соңгы куанычы Тояк белән думбра булды. Ул алардан бервакытта да аерылмады. Ашка чакырсалар, берсен житәкләп, икенчесен кулына кыстырып барды. Кунакта Тоякка симез калҗа, кабырга тоттыра, кымыздан соң думбраның кылларын кузгата иде.

Ташжан әкә үзенең бар белгәнен, күргәнен Тоякның күңеленә салырга тырышты. Бәлкем, карт бу әңгәмәләр белән үзенең авыр язмышын бик азга гына булса да онытырга тырышкандыр. Ә бәлкем, ул Тоякның ятимлеген исенә төшермәскә, яшерергә тырышкандыр. Кем белә... Кич булды исә, ул Тоякны куенына ала да, өлкән көпесен баштан ябынып, сөйли башлый. Бала бер куркып, бер куанып, ахырында рәхәтләнеп тыңлый һәм изрәп йоклап китә иде. Карт чалның сүзе экият түгел, әңмәгә-тарих, Каравыл ыруының озын юлы. Монда гүзәл Сары арка да бар. Монда куркынычлы «өлкән куян» елы да бар. Монда атаклы акын — шагыйрь Акан Сире һәм матур үләннәр, жырлар... Монда Туксанбай хажи. Ак патша... Монда Тукаш Бокин, Амангелде Иманов... Монда канлы сугышлар һәм... дөньядагы иң кадерле кешеләр — Бөркетбай белән Асылкул... барысы да, барысы да терелеп күз алдына басалар...

Тояк аларны күрә, күңеле белән кочаклый, үбә... Кич якынлашуга, ул үзе өлкән атасының муенына сарылып, ялынып сорый башлый:

— Ата, ата, дим, тагын да әңгәмә әйтче!..

Жомга көнне Ташжан әкә йокысыннан гадәттәгегә караганда күп иртә торды. Түгәрәк өстәл янына чәйгә җыелгач, ул энесе Лачынтайга карап сүз кузгатты:

— Бүген бер төш күрдем. Өлкән атамыз Ходайбиргән, жаны жәннәттә булсын, үпкә әйтте. «Өлкәнәйне-зиратны оныттыгыз, безне ташладыгыз», — дип авыр карады, кабагын төшерде. Әрвахларга барып, тез чүгеп дога бирмәү гөнаһ гой, тәңрем үзе кичерсен... Алдымызда Рамазан шәриф. Шушы йолдызга дога бирәмме дигән изге ниятем бар. Бу фарызның башы миндә, аягы синдә, калкам Лачынтай. Син миңа атарба табып бир дә, Тоягымны яныма утыртып, юлга чыгарып сал, зират кылып уралаен, савабы булыр, иншалла.

Лачынтай агасының ябык йөзенә, бөкрәеп кечерәйгән гәүдәсенә, дереддәп торган шыр сөяк кулларына карап башын чайкады.

— Ага жан, үтә олыс жир гой, чамаңыз...

— Жок сүзне куй! — Карт энесенә рәнжеп, сүзен кире какты. — Ниятемне бозма, ходайдан курык!

Башка сүз булмады. Шул көннән юлга хәзерләнә башладылар.

Юлчылар, бер авылда кунып, икенче көнне иртә белән исән-сау ялгыз карагай үренә життеләр. Карт карагай, канатларын жәйгән бер-

кеттэй, коңгырт кара ботакларын таратып, ялгыз моңсулык белән каршылады.

Арбадан төшкәндә, карт аякларына баса алмыйча авып китте. Тояк йөгереп килеп аны кочаклап өлгерде, җайлап кылган өстенә утыртты. Болай да көзән җыерып азапланган аяклар арбада оеганнар — таяк шикелле бөгелмәс булганнар. Карт йөзен чытып, аякларын уа-уа сызланды. Тояк атны туарып, тышаулап утларга җибәрде. Бераз ял иткәч, Ташҗан әкә азапланып кына торды. Тояк аны култыклады. Алар акрынлап ziратка, үр өстенә күтәрелделәр. Каберләргә якынлашу белән карт баланың кулыннан тартты.

— Утыра кал, калкам, әүвәл намаз укып, дога кылаен. Шуннан аргы аталарыңның өйләрен күрсәтәең.

Тояк киек уты сырышкан түмгәк таш өстенә утырды. Ташҗан әкә йомшак кылганга урнашты. Ул аякларын сузып җибәреп, кулларын күкрәгенә кушырып, утырган килеш кенә намаз укыды, озак итеп дога кылды, теләк теләде. Аның тавышы думбра белән үлән әйткәндәге кебек көр, яңгырау түгел, ничектер бүтән, басынкы, зарлы иде. Тояк башта бу тавыштан куркып елап җибәрә язды. Бераздан күнекте — тирәякка карап үзен юатты.

Көн кояшлы булса да, көзгә тартым, салкынча. Каберләр өстендәге вак кылган, әрем, алар арасыннан калкып, себерке булып күтәрелгән тиле бәрән үләннәре саргая башлаганнар. Вакыт-вакыт кагылып киткән җилгә алар ашыгып кыштырдашып куялар. Алардан да, дога укыгансыман, шомландыргыч өн чыга. Тояк үз авылында да, башка авылларда да балалар белән ziратка баргалады. Кабер ташларын карап йөрде. Андагы каберләр җир өстеннән күтәрелеп, күшәп яткан кара сыер төсле булып, әллә кайдан күренеп торалар. Ә мондагы каберләр җирнең эченә ишелеп төшкәннәр — чокыр-чокыр булып яталар. Кабер ташлары бер-берсе өстенә ауганнар. Бары зират уртасында бер таш кына егыла алмыйча бөкрәеп калган.

Тояк зират өстендә башка күз туктатырлык нәрсә тапмады. Ташҗан догаларын тагы да моңлырак, әүвәлгедән дә зарлырак тавыш белән укырга керәште. Тоякның күзләре томаланды. Ул уйга калды: «Бу доганы ата-бабаларыбыз ишетеп ята микән? Хәзер алар кабердән чыгып, торып килсәләр?» Ул, үз уеннан үзе сискәнеп, бабасына сыенды. Картның башы түбән иелгән. Көпе якасына тәрәлеп тырпайган аксакалдан эре-эре тамчылар тәгәри...

Тояк борылып үрдән түбән карады. Дала... Ул хәзер сары, кызыл чүпләрдән өлгеләп баскан киез төсле чуарланып янып тора. Үрнең уң ягында — тирән уйсулык. Ул уйсулыкның ярында вак кына куаклыклар.

Намаз укып, дога кылып, әрвахларның рухын тынычландыргач, Ташҗан әкә шул урында кырын ятып бераз хәл җыйды. Кояш төшкә авышты. Тояк ул арада арбага барып турсыктан әйрән эчеп килде. Ташҗан кузгалды:

— Колыным, кулыңны бир... Бәрәкалла... — Ул бөкрәя төшеп аягүрә басты. — хәзер аргы ата-бабаларыңның төп өйләрен күрсәтәм...

Алар ишелгән каберләр арасыннан атладылар...

Кайтыр юлга чыккач, Ташҗан әкә зират өстендә башлаган сүзен дәвам итте:

— Калкам, син әле колынсың. Бер көн килер, читтә йөреп, тарыгырсың, үз илеңне сагынырсың. Бака — күлендә патша, балык — суында патша, егет — илендә патша. Айлан колыннан, дөнья гиз. Бырак, ата өен ташлама. Каравыл ыруы бол туфракны кыенчылыкта, ачлыкта ташлады. Син ир җегет булсаң, шушы җәйләүне үзеңә куныс — ил кыл. Туган җиргә көчеңне аяма... Тояк тыңлады. Әңгәмә юлны кыскартты. Кояш батканда алар авылга җиттеләр.

Уразаның икенче җомгасында, бабаларын зират итеп кайтканнан соң озак та тормый, Ташҗан әкәнең җиназасы күтәрелде. Авыл кышлауга кайтты. Тоякны Күкчәтаудагы балалар йортына бирделәр.

Сүз атасы — колак, су атасы — болак, юл атасы — тояк, ди казакъ халкы. Кечкенә Тояк та әле катып өлгермәгән йомшак, кимерчек тояклары белән үз юлының беренче сукмагына басты. Бу әле аның өчен эз салынмаган, йөрелмәгән серле һәм куркыныч сукмак иде. Кая барыр, нинди юлларга алып чыгар икән бу сукмак? Әкияттәге кебек очсыз-кырыйсыз, борма-борма томаннарга кереп югалган бит ул кеше юлы. Нәрсә көтә, нинди язмыш сагалый аны алда?..

Дөресендә, ул билгесез киләчәк турында аз уйланды. Тоякны җәйләүгә дә, кышлакка да охшамаган таныш түгел шау-шулы тормыш аптыратты. Ул кызыктырып чакырды да, куркытып өркетте дә. Өереннән аерып алынган елкы баласы кулга озак иялэшә алмый. Аның күзләре һәрвакыт зур булып ачылган, колаклары торган була, тәне туктаусыз калтырана. Ул әйләнә тирәдәге һәрбер нәрсәдән хәвеф-хәтәр көтә. Юк кына бер кыштырдау яки биектәге бер кошның ашыгып үткән күләгәсе дә аның котын ала.

Балалар йортындагы беренче көннәрдә Тояк та шулай хис итте. Шау-шулы уеннарга катышмады, берәү белән дә сөйләшмәде. Гел читтә, ялгыз калырга тырышты. Аның уйлары һаман далада, җәйләүдә, өлкән атасының думбрасы, үләннәре, кызыклы хикәяләре тирәсендә әйләнде. Ләкин бу кыргыйлык һәм кыюсызлык озакка сузыла алмады. Ул, үзе дә сизмәстән, акрынлап күпчелек агымына тартылды. Тояк та шулай итеп балалар йортының тынычсыз тормышына күнегә башлады. Ләкин кинәт тулып ташу, кызулык, киреләнеп калу — юылмады, гомерлек холык булып аның артыннан калмыйча иярде. Еллар ашыгып агылдылар.

Сукмак юлга алып чыкты. Инде иркенләп, киерелеп атлап китәргә генә кирәк иде, ләкин...

Шулай була бит ул, кеше сәфәргә хәзерләнә, ярсый, кабалана, тиз-тиз җыена, чыгып китәр көнне дүрт күз белән көтә. Шул зарыгып, ашыгып көткән көн тугач, бусагадан атлап чыгар минутлар килеп җиткәч кенә, кинәт аяклар авырая, күңел икеләнә башлый.

Тояк тырышып укыды, җидееллык мәктәпне тизрәк тәмамлап, белемнең яңа, тагын да биегрәк баскычына күтәрелергә ашыкты. Ул көн килеп тә җитте. Соңгы саубуллашу кичәсе дә шау-шу белән узып китте. Бу кадерле кичә күңелле дә, ямансу да булды. Нигә икән? Бу сорауга Тояк кына түгел, башкалар да җавап таба алмадылар.

Күкчәтау шәһәрендә, педагогия техникумыннан башка, урта белем бирә торган уку йорты юк иде. Тоякның күңеле бу техникумга тартмады, каядыр читкә, зуррак шәһәргә талпынды. Балалар йорты һәм мәктәпнең директоры Тоякның бу теләген кире какмады,— Кызыл яр шәһәрендәге авыл хуҗалыгы техникумына барырга тәкъдим итте. Тояк һәм аның иптәшләре Уралбай, Куанычбик һәм Казыйхан куанып ризалык белдерделәр. Бу очраклы бер юнәлеш иде. Кая да булса китәргә, китәргә!

Кигәр көн килеп тә җитте. Моңа хәтле канатланып йөргән Тояк коелып төште, кәефе бозылды, күңеле борчыла башлады. Ул инде Кызыл ярга барырга язылганына үкенә башлады. Әмма чигенергә соң иде инде. Тояк тугыз ел тәрбияләнгән балалар йортыннан тирән бер пошыну белән чыкты.

Ул арбаның артына аякларын салындырып утырды. Каланың аргы башында, тауга күтәрелеп менгән урамнарның берсендә, кызылга буялган өй түбәсе күренә, бер югала, бер тагын калкып чыга. Күзләр һаман шул түбәне генә күзәттеләр. Уйлар! Ә уйлар шул кызылга буялган тимер түбәле өй эчендәге ыгы-зыгы белән чуалды. Арбадан сикереп

төшеп, киредән шул йортка йөгереп китәсе килде... Тәгәрмәчләр кинәт җиңеләеп, зырлап тәгәрәделәр. Тау битендәге кызыл ялкын сүнде. Тояк башын түбән иде.

— Ахау, шөркөн!..

Тояк сискәнеп китте.

— Сиксән күл Кәкчәтауның тирәсендә,
Һәркайсы алтын кесә кыясында.
Һавасы дәртка дару, җофар исле,
Көне-төне суласаң да туясыңмы?..

Ат тотып баручы Уралбай, каршыга күтәрелеп килгән Кукчэтау тауларына карап, бар тавышына үлән әйтте. Туры айгыр юртудан туктап акрын адымга күчте. Уралбай шәһәр эчендәге кебек дилбегәне дә йолыккаламый, каеш әлмәк белән кулына киелгән камчыны да күтәрми, иркен көр тавыш белән җырлый. Тояк та түзмәде, җырга кушылды.

Вокзалда озак көтәргә туры килмәде — билетларны алуга, Карагандадан, Кукчэтау станциясе аркылы, Кызыл ярга бара торган поезд килеп тә җитте.

Вагон эче халык белән шыгрым тулы. Басып торырлык урын калмаган. Тояк тамбурга чыкты. Паровоз даланы яңгыратып сузып кычкырды да көрсенеп кузгалды. Тимер идән астындагы авыр тәгәрмәчләр тыктык килеп ашыгып йөгерделәр. Тояк вагон ишегенең тәрәзәсенә үрелде. Офыкта үркәчләнеп күтәрелгән күксел таулар артка чигенәләр. Йөрәге, нәкъ вагон тәгәрмәчләресыман тавышланып, сулкылдый иде.

— Җок, ата! Мин Кукшэтауны тастамаймын. — Тояк ике кулы белән битен каплап үксеп-үксеп елый башлады. — Мин уралып тагын сиңа киләм, Кукшэтауым...

Гомер үтә. Яшьлек аның агышын сизмичә дә кала. Менә өч ел узып китте. Тояк Кызыл яр авыл хуҗалыгы техникумын бетереп, агроном дипломын кулына алды. Ул тизрәк Кукчэтауга кайтып, шунда хезмәткә урнашырга план корган иде. Кызыл Армия сафына алдылар.

Бөркетбаевның каршында хәзер җәйрәп яткан очсыз-кырыйсыз диңгез, Япон диңгезе. Бер карасаң, ул тылсымлы көзге булып күзне чагылдыра, үзенә чакыра. Яр буеннан китәсе килми, ә бер карасаң, чәчләрең үрә тора. Бер-берсен таптап, җимереп, тау-тау дулкыннар күтәрелә. Алар ярсу ат шикелле пошкырып, ак күбекләр чәчрәтеп, ыңгырашып ярларга сугылалар, хәлсезләнеп кире чигенәләр. Аннан тагын элеккегә караганда да куркынычрак тавыш белән үкереп ташланалар.

Яшь солдатларның күбесе башта, казарма тормышына, хәрби тәртипкә тиз генә ияләшә алмыйча, туганнарын, сөйгән кызларын сагындылар, хат көттеләр. Хат килүгә, алар тагын да тирәнрәк ямансуладылар. Тоякны мондый хисләр борчымады. Аның туган өе дә юк, җаны ачып торган ата-анасы да юк. Сөйгән кызы? Канат!.. Аның турында уйлау инде файдасыз. Ә шулай да йөрәк үзенең беренче мәхәббәтен оныта аламы соң? Ул, аккош канаты кебек, ак, озын, зифа буйлы кыз иде бит. Калын кара каш астыннан иркәләнеп карый торган карлыган күзләр. Нинди ышанычлы, өметле күзләр иде алар. Кем уйлаган ул самими күзләрдә дә хыянәт булыр дип? Техникумда, бер курста, янәшә утырып укыдылар. Бергәләп дәресләрен хәзерләштеләр, бар серләрен яшермичә уртага салдылар — шатлык, кайгы, байлык, ярлылык, — барысы да уртак булды. Техникумны бетереп чыккач, бергәләп Кукчэтауга эшкә китәргә һәм... үзләренең ояларын корырга вәгъдә дә куелган иде.

Өченче курсны бетерер-бетермәс Канат авырып өенә кайтып китте дә килмәде. Тояк сагынып, зарыгып Канатыннан хәбәр көтте. Озак та үтмәде — хәбәр килде. Ләкин бу Тояк көткән, күңелне канатландыра торган хәбәр түгел иде инде. «Калкам, инде үпкәләмә, мин үземә өй булдым», — диган. Мондый көтелмәгән хыянәттән соң, Тояк кызларга нәфрәт белән карый башлады.

Менә шуның өчен дә башка күп кенә солдатларга туктаусыз комачаулык ясый торган «гражданка» җепләре аны бәйләмәделәр, тартмадылар, ул барлык уйларын бары хәрби тормышка туплады.

Тояк алты айлык полк мәктәбен бетереп чыгып, отделение командиры булды. Һәрвакытта тәртипле, кыю һәм җитез булуы белән ул полк командованиесе алдында мактау һәм хөрмәт казанды. Тагын өч ел узып китте. Аның белән хәрби хезмәтне бергә башлаган солдатлар өйләренә тарала башладылар. Инде Тоякка да полктан китәргә кирәк иде. Ләкин ул сроктан тыш хезмәт итәргә калырга гариза язды. Командование аны куанып каршылады — рота старшинасы итеп билгеләде. Сәгатьле, тәртипле хәрби тормыш Тоякны үзенә бәйләде.

— Тагын бер ел хезмәт итегез, хәрби мәктәпкә укырга җибәрербез, сездән яхшы командир булачак, — диде полк командиры.

Тояк үзе дә шуны чамалый иде...

Өмет бәхет булып бусагага килеп басканда гына челпәрәмә килеп ватылды, сугыш башланды.

Бары мең тугыз йөз кырык сигезенче елда гына Тояк капитан дәрәҗәсендә полкның административ хуҗалык бүлеге начальнигы хезмәтеннән йөрәк авыруы белән отставкага чыкты. Врачлар аңа Казагстанга кайтырга киңәш бирделәр.

Күкчәтауга кайтуга Тоякны партия өлкә комитеты чакырып, авыл хуҗалыгы бүлегендә, бүлек башлыгының ярдәмчесе булып эшләргә тәкъдим итте. Үзенә бу кадәрле җаваплы эшне тапшыруга Тояк башта аптырап калды. «Алып бара алырмынмы?» — дип икеләнде. Ләкин икеләнә торган вакыт түгел, эшләргә, тапшырылган бурычны акларга кирәк иде.

Фронттан берничә мең километрлар ераклыкта булуга карамастан, сугыш Күкчәтау даласына да үзенең авыр ярасын салган, өлкәнең төп тәрәге булган авыл хуҗалыгы бик нык какшаган. Чәчүлек җирләренең яртысыннан артыгы кысыр калган. Мал кимегән, бигрәк тә эш атлары азайган. Авылда хатын-кыз, бала-чага гына, барлык эш шулар җилкәсендә.

Менә шушы җимерелгән дөньяны яңадан күтәрергә, колхозларны ныгытырга, иген игү, мал үрчетүне аякка бастырырга кирәк иде. Эш өлкә комитетында, шәһәрдә саналса да, Тояк авылдан, колхозлардан кайтмады. Ул фронттан кайтучылардан бригадалар оештырды. Украинага, Белоруссиягә барып, йортсыз-җирсез калган гаиләләрне җыеп алып килеп, колхозларга урнаштырды, хәллерәк колхозлардан бурычка мал алып, бөтенләй малсыз калган колхозларда мал үрчетә башлады. Эш — буа буарлык. Дәвалану, шәхси тормыш, гаиләле булу турында уйланырга чират җитми иде әле. (Врачлар хаклы булдылар. Күкчәтауга кайтып, туган дала һавасын сулап, тын ала башлауга, йөрәкнең чәнчүе, тын кысуы үзеннән-үзе югалды.) Ул арада уйламаган бер вакыйга булып алды.

Тояк Күкчәтауда, элекке балалар йортыннан бер генә чат түбән торган Хәдичә исемле тол хатынның өендә бер почмак алган иде. Ул монда бик сирәк, командировкалардан кайткан араларда гына туктый, мунчага кереп, киемнәрен алыштыра да тагын китә. Шуның өчен Тояк бу йортта үзеннән башка тагын бер квартирант торуын абайламады. Минск каласыннан кайткач, ул Хәдичә апайга килде. Күчтәнәч итеп ике плитка такта чәй, җиләк-җимеш китерде. Тол хатынның куанычы эченә сыймады, йөгерә-йөгерә самовар куйды. Чәй эчкән арада зарланып та алды:

— Менә инде бер атна Гайшә больницада ята, бара да алганым юк, буш кул белән авыруга ничек барасың инде.

— Кем ул Гайшә дигәнегез?

— Ай алла, — Хәдичә аптырап Тоякка карады, — белмисеңмени? Минем янымда бер укытучы кыз да тора бит әле. Гайшә исемле үзе. Бик акыллы, инсафлы кыз. Үзе Казан ягыннан. Монда җаны ачый торган туганы да юк бит, ичмасам.

Чәй эчеп бетерүгә, Тояк, Хәдичә апайны ияртеп, бераз күчтәнәч алып, больницага китте. Ләкин аларга Гайшә янына керергә рөхсәт бирмәделәр. «Хәзер ярамый», — диделәр. Тояк ул көнне колхозга китмәде. Икенче көнне иртәрәк торып тагын больницага барды. Бу юлы да Гайшә янына керергә рөхсәт ала алмады. Бары өченче көнне генә Тояк, баш врачтан үтенеп сорап, авыру Гайшәнең койкасы яныннан туктамыйча уралып кына чыкты. Авыру койкада чалкан ята. Өстендә соры одеал. Күзләре йомык. Озын кара керфекләре хәрәкәтсез катып калганнар. Кабаклары күгәргән. Аның йөзе кечкенә, түгәрәк кенә. Яңаклары эчкә баткан. Тояк кергән вакытта авыруның температурасы күтәрелгән, бите янып кызарып тора иде. Менә шушы кызыллыктан башка бер генә дә тереклек эсәре беленми. Хәтта сулыш алуы да сизелми иде. Тоякны палатага алып кергән сестра үзе дә хәвефләнеп ашыкты, Тоякка туктарга бирмичә тиз генә ишеккә барды.

— Гафу итегез, — диде ул коридорга чыккач, — аның үпкәсенә суык тигән. Хәзер авыру кризис кичерә.

Гайшә больницада өч айдан артык ятты. Тояк үзенең кулыннан килгәнне — акчаны да, вакытын да җәлләмәде. Чын күңелдән, туган җанлылык белән булышты. Табылмаган даруларны тапты. Ашамлыкка карый башлагач, ит-майдан өзмәде.

Күрмәгән, белмәгән кешенең бу кадәр шәфкать һәм кайгырту белән игътибар итүе Гайшәне гаять шатландырды, рухын күтәрде һәм тизрәк аягына басарга мөмкинлек бирде. Шулай бер дә уйламаганда алар бер-берсенә иялләштеләр һәм озакламый бер гаилә булдылар. Гайшә, элеккечә, мәктәптә балалар укытты. Тояк һаман үзенең колхозлар эшендә булды. Алдагысы елда уртак шатлык — Алмагөл дөньяга килде. Гаилә тормышы бигрәк тә күңеллеләнеп китте.

Мең тугыз йөз илле дүртенче елны, партия Үзәк Комитеты Пленумының чирәм җирләрне үзләштерү турындагы карары чыккач, Тояк үзен совхоз төзү эшенә җибәрүне үтенде. Бу теләккә партия өлкә комитеты каршы килмәде. Тояк Бөркетбаевка совхоз оештыру эше тапшырылды. Ул үзенә кайчандыр бабалары ташлап китәргә мәҗбүр булган «Алка күл» җәйләвен сайлап алган иде.

Кырлар үргә күтәрелде. Биткә салкын җил бәрелде. Тояк башын күтәрде. Уйлар таралдылар. Күзләр яктырып киткәндәй булды. Күк йөзендә әле һаман киез булып урнашкан болытлар. Ләкин офыкның көньяк итәгендә аз гына ачыклык. Кояш нурларының чаткылары сизелә. Бәлкем, төшкә таба көн ачылып та китәр.

Тояк Карагирне сулга, тар юлга борды. Монда инде җир бераз саркый төшкән. Юл коры. Күрәсең, бу якта кар әллә ни күп яумаган. Алда кечкенә генә каенлык. Ялангач, яфраксыз ботаклар җил белән чайкалып бер-берсенә сугылалар, кыйналалар. Шул чыбык ботаклар арасыннан күчмә вагоннарның торбалары күренеп кала һәм төтен күтәрелә. Карагир, төтен исен сизеп ахры, йөрешен тизләтте — бригада станына таба ашыгып юыртты.

## IX

Өченче бригаданың станына якынлашкан саен, Сәетнең кашлары җыерылып, йөзе чытылганнан чытыла барды.

Уң якта юлның буеннан буена каерылып ташланган калын катламнар. Трактор берничә тапкыр ураган да киткән. Аръякта, былтыргыдан калган, саргаеп карала башлаган кылган. Анда ала-кола кар.

Юлның сул ягында сөрелеп, тырмаланып, орлык чәчелгән басулар. Ләкин кайсы якка карама, анда хуҗасыз ташланган сабан, тырмалар, чәчү машиналары. Ызан читендә туктап калган тракторлар.

Куе кара болытлар авыраеп, җиргә якынаеп сөйрәләләр. Суык җил исә. Гүя кышка терәлеп килгән көз. Җитмәсә, Сәетнең протезлы аягы туктаусыз сызлый, вакыт-вакыт йөзләгән энәләр бер җиргә кадалгандай була. Аягы авыртуга чыдый алмыйча, протезны күтәреп, сикереп-сикереп китә. Протез өзәнгедән ычкына. Сәет, иелеп, аягын кулы белән күтәреп ботинканы өзәнгегә кидерә дә йөгәнне тарткалап куя. Җирән кашка аңа карап ашыкмый, башын түбән иеп, үз көенә акрын гына юырта бирә.

Менә үр. Үр өстендә тезләнеп яткан куй төсле ак таш. Димәк, килеп җиттек, алда стан булырга тиеш. Чыннан да үргә күтәрелүгә стан күренә. Ул үр астында гына. Бер-берсенә капма-каршы туктатылган ике вагон. Бирге почмакта — күчмә кухня. Аръякта — озын брезент палатка. Монда да ничек туры килде, шулай туктап калган тракторлар, чәчү машиналары, аударылган сабаннар, баклар, тырмалар. Башын күтәреп, «ни хәлләр бар икән», дип борчылып чыккан бер җан иясе күренми. Әллә чыннан да барысы да качып беткәннәрме?

Сәет, палатканы узып китеп, тирә-якка каранып нәрсәдер эзләде. Аның карашы чүп-чар ташланган өемгә текәлде. Ул атын шул өем янына туктатты. Иярдән төшеп, җирән кашканы трактор артына бәйләгәч, Сәет тагын тирә-ягына каранды. Ләкин палаткадан да, вагоннардан да кузгалып чыккан кеше күренмәде. Сәет аркасына салынган ике яклы йон капчык — курҗынны акрын гына алып өем янына китерде дә чүп-чар белән күмеп куйды.

Палатканың ике як кабыргасы буенча тыгызланып тезелгән тапчаннар. Уртада — кагып-сугып кына ясалган озын өстәл. Ике якта — калын тактадан ышкыламыйча гына кагылган эскәмия. Өстәл өстендә — шайтан туе. Уртада — бер кырые яньчелгән чиләк. Аның тирәсендә — ауган, түнгән кружкалар, банкалар, мискиләр, буш шешәләр. Алар арасында балык башлары, кылчыклар, суган кабыклары. Бирге яктагы мискидә ашалып бетмәгән тозлы кәбестә.

Җир идән папирос төпчекләре, чүп-чар кәгазь белән чүпләнгән. Палатка куелганнан бирле себерке йөзен күрмәгән, ахрысы. Палатка тәрәзәләренең бер пыяласы да калмаган. Иң аргы башта тәрәзә тишегенә майланып беткән бушлат тыгылган. Калганнары ачык, җил өреп тора.

Халык шыгрым тулы. Барысы да тапчаннарына сузылганнар. Кайсы бушлат белән уранган, кайсы одеал ябынган, кайсы өстендә ни бар, шуның белән ауган. Башлар күренми. Бары аяклар, аяклар.

Сәет, ишек төбендә тукталып калып, тамак кырды, йөткергән булды. Плащының башлыгын төймәләреннән ычкындырып, кесәсенә салды. Эшләпәсен каккалап, суккалап төзәтеп киде. Күзлеген озак кына сөртеп яңадан колакларына элде. Тавыш бирүче, күтәрелеп караучы булмады. Сәет алгарак узды.

— Сәлам батырларга!

Тагын тавыш-тын юк. Сәет, аптырагач, урындык кырыена килеп утырды да өстәл өстендә аунап яткан табак-савытларны терсәге белән этеп җибәрде. Бер-ике кружка, шешә тәгәрәп җиргә төште.

— Мин монда кешеләр бар дисәм, берәү дә юк икән.

Тынлык. Сәет кесәсеннән «Беломорканал» пачкасын чыгарып ертты да бер папиросны авызына капты, шырпы сызды.

— Барин! — Палатканың аргы башыннан калын бер тавыш мөңгерәп чыкты. — Тартырга бир!

— Тарт. Яхшы кешеләр өчен... җәл түгел.

Почмакның аргы очында киң читле камыш эшләпә чайкалды. Менә

эшләпәнең хуҗасы да күренде. Сәет чак кына шаркылдап көлеп җибәрмәде. Эшләпәле ике кулы белән тапчан кырыена тотынып гәүдәсен күтәрде дә, чайкалып китеп, өстәл янына килеп басты. «Һоп!» Ул озын буйлы, түгәрәк сипкелле битле, беренче карашка ягымлы гына егет. Трусиктан. Кулмәксез. Орчыкланып, бүртеп-бүртеп торган мускуллы киң күкрәгендә энә төртерлек буш урын калмаган, — «бизәп» бетергән. Зур кара бөркет канатларын күкрәк киңлегенә җәеп җибәргән дә тырнаклары белән шыр-ялангач кызны күтәреп очып бара. Кызның күкрәгендә язу — «мәхәббәт өчен үләм!» — дигән соңгы сүзләре. Егетнең ялангач муенында кара галстук. Галстукның очында кызыл ефәк белән чигелгән елан. Гәүдә туктаусыз чайкала, бөркет тырнакларына дучар булган мескен кызый, чыннан да, очып китеп барган төсле тоела.

Егет, бик җитди кыяфәт белән, өстәлдә яткан «Беломорканал»га үрелде. Бер папиросны чиртеп чыгарып шырт кына иреннәренә кысты да, кинәт авызын кыйшайтып, җирәнүле елмайды, яшел күзләре белән Сәеткә текәлде. Сәет эндәшмәде. Егетнең иреннәре җыерылды, кабаклары салынды, тагын җитди кыяфәткә күчте. Сәет һаман аннан күзен алмый күзәтеп торды. Егет, бер кулы белән өстәлдә яткан шырпы кабын ачып, шырпыны алуга, кап, сикереп китеп, яндыра торган ягы белән кырын ятты. Шырпы үзеннән-үзе сызылды да чытырдап яна башлады. Егет папиросын кабызуга акырып җибәрде:

— Братцы, барин разоряется, не зевайте!

Моңа кадәр тып-тын яткан халык шатыр-шотыр урыннарыннан торды. Тапчаннар асты өскә килде. «Беломорканал» кулдан-кулга күчте. Шау-шу бераз тынгач, Сәет эшләпәле егеткә карап тыныч кына, ләкин палаткадагыларның барысы да ишетелерлек итеп эндәште:

— Мин барин түгел, яңа парторг.

— Да?!. — Егет егылып китә язган булып ике кулы белән өстәлгә таянды. Сүс кашлар сикерде. Күзләр чыгып китәргә якын булып акайды. Аннары эшләпәсен артка чөеп палатка эчендәгеләргә борылды. — Ишеттегезме, суык аяклар? Безгә яңа парторг килгән! — Әйтеп тә бетермәде, өстәл өстенә менеп аякларын салындырып утырды, яшел күзләрен Сәеткә кадады. — Парторг дисең, ә? Яңа гына мичтән чыктыңмы? Ә безгә ак эт, кара эт, барысы бер эт. Шулаймы, әфәнделәр. Ха-ха-ха...

Ул шаркылдап көлә башлады. Аңа башкалар кушылдылар. Бөтен палатка, акылдан шашкансыман, тыела алмый шаркылдарга тотынды. Сәетнең тыны кысылды. Тәне калтырана башлады. Ләкин ул акылын җыеп, үзен кулга алып өлгерде. Күзләрен һаман өстәл өстендәге нахалда тотты. «Тагын нинди номерлар ташлар икән?»

Камыш эшләпәле, бөркет тырнагындагы кызны ике кулы белән кыса-кыса, чәчәлгәнче көлде дә тагын Сәеткә акаеп карады:

— Парторг булырга синең арт ягың юылып бетмәгән әле. Бездә комган юк.

Арттагылар тагын шаркылдадылар.

— Өстенә бастың, Семафор!

— Борыныңны кыс!

— Ха-ха-ха...

— Безнең муенга утырып, оҗмахка барырга җыенган... Тот капчыгыңны.

Эссе су сиптеләрмени, Сәетнең бөтен тәне кызып яна башлады. Маңгаена тир чыкты, бөтен тәне сулкылдады. Сәет үзенең бу хәлен сиздермәскә тырышып, иреннәрен тешләде. Кулларын кесәсенә тыкты.

Семафор отыры каныгып, мыскыллый бирде:

— Башыңда козгын оясы. Борыныңда — велосипед. Тәгәрмәчләрең каеш белән тартылган. Син парторг түгел, пешеп җитмәгән шалкан.

Тагын да хахылдау башланды.

— Цыц! — Семафор өстәл тирәсендәгеләргә: «Шауламагыз, мин аны хәзер төпсез чуманга утыртам», — дигәнсыман сул күзен кысып алды да тагын сүзгә кереште. — Бар иде бер парторг, Николай Николаевич Сыщенко. Вот, законный, килеп керсә, котың очар. Имән. Күкрәгендә өч алтын йолдыз, шаярма, синең төсле бозау түгел. Полный кавалер. Сөйләсә, тавышы аю булып акыра. Коеп куйган хохол. Вот, жалкы, обком тартып алды. Син нәрсә? Син сөйрәлеп йөргән сөлек.

Ачу акылны җуйды. Сәет ничек сикереп торып, нәрсә кычкырганын да белми калды.

— Молчать!

— Минем авызны тыгарга? Андый әле... тумаган.

Көтмәгәндә Семафор сул кулы белән Сәетнең яңагына сугып җибәрде.

Сәетнең күзләреннән утлар күренде. Күзлек челпәрәмә килеп ватылды, Сәет чайкалып китеп тапчанга сугылды. Кемдер аны күтәреп торгызып, эшләпәсен башына кигезде.

— Семафор! Бу — хулиганлык!

Күзлекнең кыйпылчыклары кабакны телеп, ике күз кан эчендә калды. Сәет үзен яклаучының кем булуын шәйли алмады. Ләкин казакъ егете булырга кирәк — акценты казакъча иде. Сәет кесәсеннән яулыгын алып күзләрен сөртте дә, уң кулын тагын плащ кесәсенә тыгып, өстәл янына басты. Палатка эчендәге халык тавышсыз-тынсыз Сәет белән Семафорга карап катып калдылар: «Кем җиңеп чыга?»

Тагын күзләрне кан басты. Сәет тагын яулыгын алып, күзләрен сөртте. Уң кул кесәдә калды.

Семафор авызын кыйшайтып нәрсәдер әйтергә җыенган иде, Сәет аның күзенә текәлде.

— Син жулик түгел, сука!

Семафор кинәт артка чикте. Ул блатнойлар дөньясында «сука» сүзенең «сатлык җан» мәгънәсендә булуын һичшиксез белә. Шуңа ахры, аның тавышы икеләнеп чыкты.

— Юк, честный.

— Честный булсаң, әйт: сугарга ни хакың бар синең? Иң элек син мине мыскыл иттең!

— Хакың, имеш... — Семафор кемгәдер күз кысты. — Крыса, каләм очын...

Шундук өстәл астыннан сап-сары керпе чәч күренде. Күсенеке кебек бүселеп чыккан күзләр Сәеткә карап чекерәйделәр. Крыса сул кулы белән Семафорга нәрсәдер сузды. Ялтыраган финка очы чагылып китте.

— Сиңа «хак» кирәкме?! — Семафор атылып Сәетнең алдына басты. Яшел күзләре ялт-йолт итте. Бите кызарды. — Мә, сиңа «хак!» — Финка ялтырап күтәрелде.

Сәет тиз генә артка чигенде.

— Ташла, гад! Атам!

Күтәрелгән кул кире төшә алмыйча баш өстендә асылынып калды. Бармаклар бушадылар. Финка җир идәнгә кадалды.

— Артка чиген!

Семафор, нәрсә эшләргә белмичә каушап, аркасы белән өстәлгә барып терәлде.

Сәет, наганың төбәгән килеш, күзләрен Семафордан алмыйча чүкте дә сул кулы белән финканы алды. Карап торучылар барысы берьюлы сулап куеп, башларын түбән иделәр. Берәү дә Сәеткә карарга базмады. Сәет үзе дә хәзер аларны күрми. Ул наганны сузган килеш катып калган. Тәрәзә тишегеннән салкын җил ургылды. Маңгайдагы бөрчек тир тәгәрәп биткә йөгерде. Сәет уянып киткәндәй булды.

— Ну, ничек, Семен Петрович? — Сәет наганын кесәсенә салып,

бөтенләй дусларча, үзара бер нәрсә дә булмаган кебек елмаеп эндәште. — Номер үтмәде, ә?

Симка җиргә төбәгән күзләрен күтәрде, аптырап карады. «Минем исемне кайдан белә?» Аннары сүзсез, лап итеп эскәмиягә утырды.

Карап торучылар да, «Инде эш бетте» дигәндәй, сүзсез генә урыннарына таралдылар. Сәет палатканың түбәсен күтәреп торган казыкның башына финканы кыстырып сындырды да сабын өстәлгә ыргытты. Бер шешә челпәрәмә килеп ватылды.

— «Каләм очын» да тота белергә кирәк!

Сәет өстәл буендагы икенче урындыкка, Симкага каршы утырды.

— Иптәш парторг! — Симка Сәеткә кырын карап кына сүз башлады. Тавышы да мөңгерәп түгел, сытылып чыкты. — Минем бер соравым бар.

— Рәхим итәсез! — Сәетнең тәне рәхәтләнеп, иркен сулыш алды. «Әһә... Парторгка күчтеңме? Тыңлыйм».

— Сандугач булып сайрадыңмы?

— Сайрадым.

— Озакмы?

— Бер катушка.

— Крыс!..

Теге керпе баш, өстәл астыннан атылып чыгып, бер колода өр-яңа атлас карталар сузды.

— Буришь? Рамсишь? Или на стос?

— Шайтанга булса да уйныйм.

— Крыса! Порядок!

Крыса атылып-бәрелеп өстәл өстендәге табак-савытны җыеп алып, уртага клеенка җәеп ташлады. Семафор яңадан терелде, күзләре ялтырап яна башлады. Бит урталары кызарды. Аркасына ташланган галстукны алдына тартып, гадәттәгечә авызын кыйшайтып елмайган булды.

— Пошли.

— Бер минут!.. Уен алдыннан минем бер шартым бар, — диде Сәет.

— Такылда... — Семафор тагын элекке тонына күчте.

Палаткадагылар урыннарыннан кузгалдылар: «Тагын ни булган?» Сәет, урындыгыннан торып, палатка эчендәгеләргә күз йөртеп чыкты.

— Иптәшләр, сезгә нәрсә кирәк, нәрсә житешми?

Мондый капыл сорау уңышсыз булды, ахры. Әллә инде төшенмәделәр, берәү дә авызын ачмады, аптырап тордылар. Барысы өчен Семафор җавап бирде:

— Акча.

— Тагын?

— Ашарга.

— Тагын?

— Урын-җир каралган, юарга кеше юк.

— Тагын?

— Җитәр. Бик бай булсаң, шул әйткәннәрне алдыбызга сал!

Халык шаулаша, кычкырына башлады:

— Симка дөрес әйтә!

— Акыл сатма, кулга бир!

— Җитәр! — Сәет кулын күтәрде. — Аз гына сабыр. Ашау-эчү ягын бергәләп рәтләрбез, урын-җир бар. Кер юучы табылыр. Ә акча? Акчаны, егетләр, эшләп алырга кирәк. Сездә әле мең сигез йөз гектар җир сөрелмәгән. Мең ярымнан артык гектар җир чәчелмичә ята. Сез кияү егетләре түгел бит.

— Дуңгызлар да түгел!.. — Почмактан нииндидер калын бер тавыш акырды.

— Ярый. Менә нәрсә, егетләр. Аз гына тыңлагыз әле. — Шау-шу

бераз басылды. Сәет сүзен дәвам итте: — Аласы акчаларыгызны шушы бер-ике көн эчендә алырсыз, ә менә калганын эшләп алырга кирәк. Алма — пеш, авызыма төш — барып чыкмый. Кем эшли, шул ашый. Давай, егетләр, хәзер күп сүзне ташлап мировой уйныйк. Буш кашык — авыз ерта.

— Могарыч синнән!

— Ярый. Мин аңа да барам. Миннән булсын. Семафор, әйдә, миңа бераз булыш. Егетләргә бераз күчтәнәч бар иде. — Сәет нәкъ Семафор шикелле авызын кыйшайтып күзен кысты. — Киттек!

«Ни була?» — дип шаккатып карап торган Крыса, Сәетнең кыланышын күргәч, күсе күзләрен челт-челт китереп авызын ерды:

— Менә — артист!

Сәет белән Семафор чыгып китеп, озак та үтмичә, әйләнеп килеп керделәр. Семафорның җилкәсендә аркылы салынган курҗын.

— Туганнар! Барин чынлап бөленә: «тере су» алып килгән.

Симка үзе курҗынны актарып өстәлгә биш шешә аракы, берничә бәйләм колбаса, зур бер кета балыгы ташлады.

— Молодец, парторг! Крыса, давай син бүген кок!

Крыса кружкаларны җыеп өстәлгә китереп куйды. Башта колбасаны, аннары кетаны турап ыргытты.

— Палаткада барлыгы ничә борын? — Сәет учы белән сугып шешәләрне ача-ача Семафорга карады. — Сана!

— Егерме бер.

— Нәкъ. Барыгызга йөз граммнан. Ә Семафор белән миңа ике йөздән. Без бераз эшләп алдык бит!

Сәет тагын авызын кыйшайтып елмайган булды.

Семафор чәчми-түкми аракыны тиз генә бүлеп чыкты — унтугыз кружкага йөз граммнан, ике зур яшел кружкага икешәр йөз граммнан.

— Ну, давай, туганнар, яңа парторгның саулыгына!

Палатка эчендәгеләрнең берсе дә калмый өстәл янына тыгызландылар, кружкаларын күтәрделәр. Сәет үзенә билгеләнгән яшел кружканы күтәреп иң элек Симка белән, аннары калганнар белән чәкештереп чыкты да, ыгы-зыгы арасында аракысын өстәл астына түгеп, буш кружканы йотылып эчкән булды, йөзен чытты. Кетаның бер кисәген алып авызына капты. Күз ачып йомганчы колбаса, балык өстәлдән юк булды.

— Ну, парторг, давай, катай!

— Давай.

— Юк, миңа бир, — Семафор колоданы Сәетнең кулыннан йолкып алды, — минем ход. Нәрсәгә йөрисең?

— Ирек синдә. Син король.

— Давай. Синең пеләш башыңа! Отылсаң — безнең судка.

— Отсам.

Семафор җавап таба алмыйча аптырап калды.

— Белмим.

— Дурак. Мин башымны салам, ә син нәрсә куярга белмисең. Менә честный вәгъдә, мин отылсам, каршы тормыйм. Теләсәгез ничек судлагыз, сезнең право. Әгәр мин отсам, — Сәет палатка эчендәгеләрнең барысына да тукталып-тукталып карап чыкты, — бер кеше калмыйча хәзер үк эшкә чыга.

— Анысын егетләрдән сора.

Инде бераз кызып, күңелләре күтәрелгән егетләргә карап елмаеп, Сәет күзен кысты.

— Ну, туганнар, барамы?

— Бара!

Сәет алдына ташланган карталарны кулына алып җәеп җибәрде дә нәкъ уртадан бер картаны суырып алып өстәлгә ташлады.

— Мә, валет! Пан или пропал.

*Марзия Фәйзуллина*

## Таш, диеп, җавап биргән

Аннан-моннан дигән малай
Чыпчыкка дип таш аткан.
Чыпчык очкан, аткан ташы
Тәрәзәләрен ваткан...

Куркуыннан бик тиз генә
Өенә чабып кергән.
Анасы: кем ватты, дигәч,
Таш, диеп, җавап биргән.

## Горчисны бал дип

Горчисны бал дип, күп итеп
Икмәк өстенә яккан.
Ашык-пошык, комсызланып
Бик зур иттереп капкан.

Авызыма ут капты, дип
Башлаган акырырга.
Янгын сүндерүчеләрне
Тотынган чакырырга.

## Хат

Мәктәпкә бармау хәйләсен
Эзләгән Аннан-моннан.
Кыш бабайга ярдәм сорап
Бер хат язган соңыннан:
— Урамга чыкмаслык суык
Алып килче, кыш бабай.
Бар кеше әйтерлек булсын
Ай-яй суык, ай-яй-яй...
Салкыныңны җиткерә күр
Утыз бер градуска.
Мәктәпкә бармаска, диеп,
Әйтсен радио дус та.

## Чыпчыклар

Чыпчыклар өй кыегына
Күптән корганнар оя.
Бакчага чыпчык төшмәскә
Әби карачкы куя.

Карачкы ертык күлмәктән,
Башында иске бүрек.
Кулына тоткан зур таяк,
Шүрләрсең син дә күреп.

Тик нигәдер карачкыдан
Чыпчыклар курыкмыйлар,
Түп-түгәрәк сары битле
Көнбагышны чукыйлар.

Ял итәләр карачкының
Иңбашларына кунып.
Әби үзе пыр туздырып
Йөри чыпчыклар куып.

## Песи баласы

Кая китеп юкка чыкты
Безнең песи баласы,
Никадәрле эзләсә дә
Табалмады анасы.

Ары чапты, бире чапты,
Күрми акны, караны.
Мияу, мияу, кайда син, дип
Мыраулап та карады...

Песи баласы мияулап
Килеп чыкты сикереп.
Ул киез итек эченә
Йоклаган икән кереп.

## Кыш бабай

Җилкәсенә капчык асып
Кыш бабай килеп керде,
Төрле кызык сүзләр әйтеп
Бүләк өләшеп йөрде.

Аннан кыш бабай тыпырдап
Бик шәп бии башлады...
— Биемәскә, аягында
Безнең апа башмагы!

## Чебиләр

Тышта бик җылы булса да
Тун кигәннәр чебиләр.
Яңа гына тусалар да
Йөгерешеп йөриләр.

Эремчек, тары ярмасы,
Суалчан яраталар.
Суалчан дип ботинкамның
Бауларыннан тарталар.

Көш-көш, дигәч, китсәләр дә,
Тагын килеп тарталар.
Тарта-тарта ботинкамның
Бауларын чуалталар.

## Сутан тураганда

Ашка салырга суганның
Сайлап алдым олысын.
Әрчи башлагач еладым,
Килмәсә дә елыйсым.
Күзгә керә әчесе,
Ничек кенә әрчисе!

Әрчүен әрчедем инде,
Эшнең бетте зурысы,
Пычак белән вак-вак итеп
Калды аны турыйсы.
Ашка суган турыйм мин,
Көлә-көлә елыйм мин.

## Казлар

Бер-бер артлы тезелешеп
Казлар күлгә баралар.
— Казлар, кая киттегез? — дип
Сорау бирә балалар.

Казлар шунда бертавыштан:
— Елга-га-га-га...— диләр.
— Ул елга түгел — күл! — дигәч,
— Ул ага... Ага... — диләр.

## Боз-сөңге

Өй кыегында боз-сөңге
Чак-чак эләгеп тора,
Егылам, дип яшен коя:
«Тот! Тот! Тот!» — дип кычкыра.

## Тигәнәк

Тигәнәккә якын килсәң
Итәгеңә сырыша.
Шуңар әни: тигәнәк күк
Сырышма, дип орыша.

# ИЛНЕҢ ТУРЫ УЛЫ

*(Нур Баянның тууына 60 ел тулу уңае белән)*



Минем өстән пуля яуса да,
Җәрәхәттән каннар тамса да:
Халкым өчен постта торырмын,
Халкым өчен туры булырмын.

НУР БАЯН.

**Н**ур Баян — поэзия күгендә балкый торган йолдызларыбызның иң яктысы, бүтәннәрдән аерылып, күзгә ташлана торганы түгел. Әмма аны күренер-күренмәс, сүнәр-сүнмәс кенә җемелдәүче йолдызга да охшату дөрес булмас иде. Нур Баян поэзиябез күгендә Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Гадел Кутуй, Әхмәт Фәйзиләр белән бер чорда калыккан һәм шул йолдызлар белән бер сафта яктыручы яраткан йолдызларыбызның берсе.

Без, аның энеләре, Нур Баянны бала чакта ук ишетеп, белеп, яратып укып килдек. Ул хәзер дә безнең исебездә. Без хәзер дә аның шигырьләрен еш кулга алабыз һәм шат елмаю, дәрт, романтика белән сугарылган юлларын бирелеп укыйбыз. Укыйбыз һәм аның шигырьләрендәге бүген дә тонықланмаган аһәңнәрне ишетәбез. Менә шагыйрьнең «Сайланма әсәрләр» җыентыгындагы беренче шигырь. «Шлем кигәч» дип аталган бу әсәр астына «1926 ел» дип язылган.

Авылда җир сукалап үскән малайның кызыл эшелоннарда йөрүе, обмоткалы ботинка һәм шлем киеп үткән еллары турында сөйләп килә дә, шагыйрь, яшь буынга карап:

Алар әле:
Марс өстен менеп карарлар,
Анда тормыш булса,
Маяк кадап,
Ленин исемен анда тагарлар, —

дип шигырьне тәмамлый.

Поэзиягә Нур Баян әнә шундый ашкынулы, дәртле хисләр белән килеп керә һәм, Һади Такташларның күтәренке тавышына кушылып, бер-бер артлы яңа җырлар иҗат

итә башлый. Нинди генә аһәңнәр юк ул җырларда! Илдә төзелеп яткан яңа тормыш симфониясе, егерменче һәм утызынчы елларда барган киеренке көрәш авазлары, үткән тормыш авырлыкларын хәзерге шатлыклы тормыш белән чагыштырып җырлау, батыр чик сакчыларын олылау, колхоз һәм шәһәр хезмәт батырларын сурәтләү, туган илгә, партиягә бирелгәнлек.

Нур Баянның тавышы һәрвакыт көр, һәрвакыт ягымлы һәм горур. «Пост янында» (1928) шигырендә лирик герой ил чиген саклаучы исеменнән:

Мин бит монда илне саклар өчен
Тимер постчы итеп куелган, —

дип белдерсә, «Елак кызлар турында» (1929) дигән атаклы юмористик шигырендә:

Җиребезгә нинди орлык чәчсәк,
Киләчәктә шуны урырбыз, —

дип яшь буынны «коммун хисле» итеп тәрбияләргә чакыра.

Аның «Шагыйрь үлгәч» (1934) шигырен кем генә белми?! Һ. Такташ истәлегенә багышланган бу шигырь Н. Баян лирикасының тирән кичерешләр белән байый баруын күрсәтә.

«Шагыйрь үлгән!..» диләр,
Ай, бик авыр,
Авырттыра бу сүз күңелне,
Һәр тармакта җиңеп чыккан кебек,
Их, җиңәсе иде үлемне!..

Бу юлларны без гомерлеккә отып калдык.

«Мәликә», «Зөһрәгә хат», «Комбайнчы Гөлсем» кебек шигырьләрендә Н. Баян азатлыкка чыккан татар хатын-кызларының онтылмас образларын сурәтләде, кеше йөрәгенең иң нечкә тирбәлешләрен оста гәүдәләндерде.

Вулкан диләр,
Вулкан көчле,
Вулканны бар минем күргәнем.
Вулкан кайнар,
Вулканнан да
Кайнаррак минем йөрәгем, —

кебек популяр юллар күп иде ул шигырьләрдә.

Нур Баян туган якларының матурлыгын гомере буена шигырьгә салып килде.

Шомырт чәчәкләре җемелдәшә
Яшел яфрак күмгән урманда,
Кемнәр генә җырлап үтмәгәндер
Шул урманнар аша узганда.

Яки:

Чәчәкләргә чумган шул урманның
Бер суласаң исле һавасын,
Чәчләреңне ак чал капласа да,
Яшьлек хисе белән янасың, —

кебек строфаларда без аны нечкә хисле лирик художник итеп күрдек.

Ләкин Нур Баян лирик кына түгел, югары пафослы публицист та иде. «Ант» (1939) шигырендә ул, туган илгә мөрәҗәгать итеп:

Мин ант итәм сиңа, акылым көчен
Туры юлың өчен бирергә,
Коммунизм җирдә җиңсен өчен
Мин әзермен утка керергә, —

дип язды һәм үз сүзләренең хаклыгын Ватан сугышы фронтларында каны белән раслады.

Нур Баян — гаять эшчән һәм мул җимешле шагыйрь. Лирик һәм публицистик шигырьләр белән рәттән, ул үзе яшәгән чорны киң эпик полотноларда да уңышлы сурәтләде. «Клеверлы кырлар», «Яңгырлы төн», «Онытылмас яшьлек», «Җимерелгән дворец янында», «Гөләндәм» кебек поэмаларында Нур Баян замандашларының тулы канлы образларын бирде. «Яңгырлы төн» поэмасын гына искә төшерик. Сирай, Суфия образлары, аларның язмышлары безне бүген дә тирән дулкынландыра. Бу безгә шагыйрьнең елдан-ел ныгый барган эпик сурәтләү көче турында сөйли иде.

Нур Баян юмористик һәм сатирик әсәрләр дә күп язды. Аның «Карахмәт» поэмасы сатирик типлардан көлүнең уңышлы бер үрнәге булды.

Шагыйрь әсәрләрен яңадан кайтып укыган саен бер нәрсәгә ышанасың: Нур Баян үз чорының бөтен вакыйгаларын сизгер ишетүче, аны үз вакытында кәгазьгә күчерүче өлгер шагыйрь. Һәм ул безнең күңелебездә гомерлеккә әнә шул ягы белән кереп калды.

Нур Баянның бөтен иҗаты буйлап сузылучы үзәк тойгы — тормышны ярату, яшәргә, тулы тормыш белән яшәргә омтылу иде.

Их, яшисе килә җир күкрәтеп
Ал чәчәкле якты илемдә!
Без көрәшләр кичтек җир тетрәтеп,
Бирешмәбез тиген үлемгә! —

дип язды ул 1939 елда.

Бөек Ватан сугышында Нур Баян «ал чәчәкле илен» саклап, фашизм алып килгән үлемгә каршы чын мәгънәсендә батырларча көрәште.

Ярсып-ярсып атам һәр пулямны
Ватан өчен, туган ил өчен,
Балам өчен, атам-анам өчен,
Назлап сөйгән нечкә бил өчен, —

дигән зур кичерешле сүзләрдә без Нур Баянның, Муса Җәлил һәм Фатих Кәрим төсле үк, иле өчен гомерен дә җәлләмәүче көрәшче исеменнән сөйләвен бөтен йөрәк белән тоябыз. Һәм аның шигъри тавышы да М. Җәлил һәм Ф. Кәрим поэзиясе белән бик аваздаш.

Сугышның беренче көннәреннән алып фронтта, ут эчендә йөргән Нур Баян үзен батыр көрәшче итеп танытты һәм полк партия оешмасына җитәкчелек итүче өлкән офицер булып күтәрелде. «Беренче дәрәҗә Ватан сугышы», «Кызыл йолдыз» орденнары һәм күп санлы медальләр шул батырлыкның бизәге булды.

Иҗат өчен бик кыен шартларда яшәвенә карамастан, Нур Баян сугыш елларында байтак кына шигырьләр дә яза. Алар әле табылып та бетмәгәннәр. Ләкин безгә билгеле кадәресендә генә дә Нур Баян поэзиясенең яңа сыйфатлар белән баюын, тирәнәюен күрергә мөмкин. Аларда патриот шагыйрьнең ялкынлы хисләре һәм күңел түрендә сакланган изге фикерләре ачык чагылган:

Борчылмагыз, мине белгән дуслар,
Шат җырчыгыз сезне онытмас,
Бер кайтыр ул якты кояшсыман,
Дошманнарны җирдән корыткач.

*(1943 ел)*

Кая гына аяк бассам да,
Тик бер генә пуля атсам да:
Сөйгән халкым өчен барысы да,
Туры улың, халкым, мин сиңа.

*(1943 ел)*

Әйе, Нур Баянның бөтен иҗаты, тормышы шуны раслый, аның сугышның соңгы көннәренә кадәр батыр көрәшүе — шуның көзгесе. Шагыйрьнең тик бер генә сүзе дөрескә чыкмады — ул сугыштан кайта алмады, 1945 елның 23 апрелендә батырларча һәлак булды. Әмма шагыйрьнең иҗаты гына түгел, үлеме дә безнең исебездә!

*ЗӘЕТ МӘҖИТОВ*

*Ибраһим Гази*

# ИСТӘ КАЛГАННАРЫМ

— Кутуй үлде, — дигән хәбәрне алганда, без инде Берлинда идек. Сугыш беткән. Германия җиңелгән. Берлин каласы, кварталы-кварталы белән ташка һәм тузанга әйләнеп, җирдә егылып ята. Тротуардан йөрү куркыныч, чөнки аяк баскан тавышка стеналар гөрелдәп ишеләләр. Урам чатларында фанер такталарга зур-зур хәрефләр белән: «Житәкчеләр килә дә китә, халык кала, без немец халкын бетерергә җыенмыйбыз, фашизмны гына тамырыннан йолкабыз!»— дигән сүзләр язылган. Немецлар бу сүзләрне укып-укып китәләр. Трамвайларда, метроларда безгә, җиңүче гаскәр вәкилләренә, торып урын бирәләр...

Ул вакытта Берлин инде зоналарга бүленгән булса да, теләсәң кайсы зонага кереп йөрергә рөхсәт. Без французлар, инглизләр, америкалылар белән аралашабыз. Алар да, без дә сугыш беткәнгә шат, инде сугыш бервакытта да булмас кебек тоела, чөнки фашизм бетәчәк, аны тамыры-ние белән йолкып атарга һәр дүрт якның җитәкчеләре сүз биреп, әллә ничә төрле документларга куллар куеп, пичәтләр бастылар. Америка солдатлары белән урамда очрашканда, тегеләр баш бармакларын үрә катырып: «Корошо!» ягъни «Бик яхшы булды!» дип, безгә елмаешып карап узалар. Куанышабыз. Киләчәк буын сугышсыз яшәр, дип уйлыйбыз. Чынлап та, инглизләр, французлар, руслар дус булгач, аларга каршы корал күтәрергә кемнең кыюлыгы җитәр!

Кутуй да фашизмның бетүенә, сугышның тиз булмаячагына тәмам ышанып үлде. Майда ул исән иде әле. Апрель башларында ул безнең һөҗүм итүче гаскәрләребез белән бергә сугыш кырында булды, кызыл гаскәр белән Одер елгасына тикле барды. Одерда безнекеләр туктап (Одер аша чыгып, плацдарм тотып торучы частьлар да бар иде), Берлинны штурмлау өчен көч җыя башладылар. Шул арада Кутуй редакциягә кайтты.

Аның кайтып керүе бүгенге кебек күз алдымда. Безнең редакция ниндидер тимер юл станциясендәме дип әйтим, разъезддамы тора иде. Солдат шинеле төсле соры гына бер көн иде. Кичкә табарак күрәм: ниндидер бер кеше вагон асларына чума-чума миңа таба килә. Якыная төшкәч карасам — Кутуй! Аркасында йодрык хәтле генә вещмешок, үзе дә бик юка, бик суырылган, мине күргә елмая башлады.

Икәүләп редакция урнашкан вагонга кердек. Иптәшләрен, дусларын Кутуй бик сагынып кайткан икән. Барысы белән дә бер кат сөйләшеп алганнан соң, озаклап сөйләшүне кичкә калдырып, рус редакциясенә китте. Анда да иптәшләре, дуслары бар иде. Чөнки ул рус газетасына да яза, безнең кебек татар газетасы белән генә чикләнми иде.

Шул кичне барыбыз бергә редакциядә утыруыбыз хәтердә калган. Безнең редакция, типография, тора торган җир — барысы да бер кызыл вагонда иде. Кысан, тыгыз, караңгы... Метранпаж Сибгат абзый наборны битләргә сала башлаган. Ярулла Ярмәкиев, безнең редактор, бу эш белән үзе җитәкчелек итә. Менә бервакыт Сибгат абзый: «Буш урын кала, нәрсә тыгабыз?»— дип сорады бугай, Ярмәкиев, артына борылып:

— Кутуй, юкмы синдә яңа гына пешкән берәр кайнар хәбәр?— диде.

Кутуй, бик хәтеремдә, тактадан кораштырган өстәлгә терсәкләре белән таянып, бөкрәебрәк утырган. Мин инде аңа баядан бирле караштыргалыйм. Ул яман каты талчыккан булса кирәк, утырган җиреннән йоклап китә башлый, караңгы вагонда бите миңа кап-кара булып күренә, хәзер аңа егылып бер тәүлек йокларга иде, ә ул ятмый,

газета чыга торган көнне йокларга уңайсызланамы, әллә иптәшләрен бик тансыклап кайтканга безнең яннан китәсе килмиме, шинелен салмыйча гына өстәл кырында утырып тора. Алдында кечкенә генә блокнот. Барыбыз да эш белән бик мәшгуль булганга, күп сөйләшмибез. Кутуй да инде сөйләшеп туйган, сирәк-мирәк берәр сүз кыстырудан узмый. Йокымсырап киткән араларда учындагы ияге ычкынып китә дә башы чайкалып куя. Ярмәкиев дәшкәч, Кутуй:

— Нindirәk материал кирәк?— дип сорады.

— Артиллеристлар турында юкмы?— диде Ярмәкиев.

Кутуй, блокнотының битләрен ачкалап карагач, кирәкле материалны тапты ахры, иелеп язарга кереште. Хәбәрне ул бик тиз язып ташлады. Линотипта утыручы Равил Казаков дигән егет шундук җыеп та бирде.

— Кара әле, Гадел,— дидем мин Кутуйга,— син бик арыгансың, бар кайтып йокла...

Ул тагын бераз утырды да, алайса мин кайтыйм дип, Ярмәкиевтән рөхсәт алып, вагоннан чыгып китте.

Гаскәрләр һөҗүм иткәндә редакцияләр бик артта калучан булалар. Безне фронтка якынайтырга уйладылар бугай, күченү башланды: редакциянең алга таба күчеп китүе күңелемдә болайрак калган.

Машиналарга төялдек тә кузгалдык. Кутуй миңа машинада үзенә дип алган урынын бирде, чөнки ул, әйткәнемчә, рус редакциясе белән бик дус иде, алар янына күчеп утырды булса кирәк. Иртүк юл чыккан кешеләр, без, кич белән, инде караңгы төшкәч кенә, Познань шәһәренең типографиягә якын урамындагы бер йортка, поляк семьясына барып кердек.

Познань — зур шәһәр. Готика стилендә салынган йортлар күп. Немец князьләренең резиденцияләре кайчандыр шушы Познаньда булган, готика стилендәге зур сарайлар шул князьләрдән калган дип сөйләделәр. Шәһәр шактый тетелгән. Немецлар монда бик каты каршылык күрсәткәннәр иде, чөнки шәһәрдә крепость, икенче төрле әйтсәк, цитадель бар, сугыш үтеп киткәннән соң да шушы цитадельдә качып калган немец солдатлары һаман чыгалар иде.

Әйткәнемчә, бик соң килеп төштек. Кереп урнашкан квартираның хуҗалары безне, газета теле белән әйтсәк, бик җылы каршы алдылар. Кутуй диванга сузылып ятты. Хуҗаның хатыны, яшь кенә матур полячка, медицинадан төшеп үк калган кеше түгел икән. Кутуйга банка салды (чөнки Кутуй, танк өстендә, салкын тимердә ятып йөри-йөри миңа салкын тиде, дип сөйли иде, без дә шуңа ышана идек).

Хуҗалар кунакчыл булганга, безнең дә күңел хуш (хуҗа төнтек йөрсә, солдатка бик авыр була). Банкаларны алганда Кутуй, елмаеп, шаян сүзләр сөйләп ятты. Гомумән, йортта күңеллелек хөкем сөрә иде, чөнки хуҗалар да, без дә беләбез: сугыш озакламый бетәчәк, без җиңәчәкбез. Өстәвенә урамда яз...

Җиңәчәк дигәннән, безнең, ягъни редакция работникларының, җиңүгә теге үгез мөгезендәге чебеннең «Сукалап кайтып киләбез!» дип әйтүе кебегрәк булса да, без дә үзебезчә кирәкле, файдалы эш эшлибез дип, җиңүгә ярдәм итәбез дип уйлап йөрибез. Познаньдагы гаскәри частьларда булабыз, татар солдатларын эзлибез, очерклар, мәкаләләр язабыз. Кутуй шигырь яза. Ул күрер күзгә болай күңелле генә йөри, тик шулай да бөтенләй үк тернәкләнеп җитә алмый әле. Күбрәк ятып тора, кай көннәрне ашарга да бармый, алып кайтып ашатырга туры килә. Күпмедер вакыттан ул бөтенләй ашаудан калды, урыныннан тормый ук башлады. Мин әйтәм, Гаделне врачларга күрсәтергә кирәк иде дим. Яратмады. Юк, мин госпитальгә кермим, сезнең яннан бер яры да китмим, менә күрерсез, озакламый сәламәтләнермен, мин әле Берлинны алышырга барырмын!— дип, врачларга күренүдән баш тартты.

Кутуйның бер ягы бар иде: ул үзен бер дә аямый иде. Аның зарланганын, ансатрак эш бирегез дип әйткәнен мин белмим. Мин бүген шулай дип язам икән, бу үлгән кеше турында начар әйтергә ярамаганнан түгел, чынлап та ул шундый кеше иде. Аңа бит берәү дә, син гел фронтның алгы сызыгында йөр, дип әйтмәде, ул үзе йөри иде, һөҗүм башлануга ул фронтка китә, теләсә редакциядә дә кала алган булыр иде. Орденга куюлар башлангач, Кутуй: «Минем бер орденым бар, мине куймагыз, әнә фәлән иптәшне куегыз!» — дип үзе әйтте. Ул редакциягә килгәнгә хәтле, Волхов фронтындамы, Сталинград фронтындамы орден белән бүләкләнгән иде инде. Врачларга

күренергә теләмәүдә дә аның үзен кайгыртмавы, үзенә карата ваемсызлыгы сизелә иде. Инде хәле бик начарайгач кына, ул врачка күренәсе итте.

Познаньда бик әйбәт госпиталь бар иде. Комиссары үзебезнең Казан кешесе, медперсоналдан да Казан кешеләре, татарлар бар иде.

Кутуйны госпитальдә шушы иптәшләр кулына калдырып, редакция алгарак күчеп китте. (Чөнки хәлиткеч соңгы һөҗүм котелә иде.) Тагын урман эче, тагын ниндидер разъездмы, кыскасы, тимер юл, вагоннар... Йөзәр яшьлек наратлар... Һава бал урынына кабып чәй белән эчәрлек, шундый татлы... Сугыш та булмаса, җир оҗмахы инде. Ләкин сугыш әле бетмәгән. Бүген таңда һөҗүм башланырга тора. Урманга чыксаң, тынлык, тик каядыр еракта моторлар үкергәне ишетелә дә сирәк-сирәк төнге һаваны ракеталар ертып менеп китә...

Редакция күчте дигәч тә, аның әле күчеп бетмәгән койрыклары калган була. Шул уңай белән мин кире Познаньга бардым. Иске квартирага кердем. Керсәм, Кутуй госпитальдән чыккан, инде өйдә. Бик беткән. Габдулла Тукайның үләр алдыннан Клячкин шифаханәсендә төшкән соңгы рәсеменә охшап калган. Юка одеал астында беләк буе гына булып ята. Хуҗа хатыны авыруның алдына йомыркалар, пирожкилар куйган. Ләхин бу берсен дә ашамый икән.

— Нәрсә таптылар соң синдә? — дип сорадым.

Өзеп әйтмәде. Шулай да үпкәсеннән зарланды. Шушы хәлдә дә мин аны төзәлмәс авыру дип санамадым. Редакция урнашкан нарат урманын мактадым, андагы һаваны мактадым, аппетит ачар өчен кызыл аракы эчәрсең, дидем. Кыскасы, монда ятмаска, урманга күчәргә өндәдем. Тизрәк терелерсең, дидем. Ул риза булды. Иртәгә редакциянең койрыгын алып китәргә киләчәк машинага утырып, безнең янга килергә ниятләп калды. Мин шул көнне үк кире кайтып киттем.

Икенче көнне кичен Кутуй редакциягә килеп төште. Машинадан чыгуга, вагонга кереп ятты. Гази Кашшафтан аңа хат бар иде, шуны күргәч, кычкырып укырга кушты. Укыдым. Сөйләшеп утырдык. Газета чыга торган көн иде, мин редакциягә чаптым, Кутуй ятып калды.

Төн буе газета өстендә эшләп, иртә белән наборны басарга биргәч, мин Кутуй янына вагонга янадан кердем. Ул малахай бүрегенең колакчыннарын төшереп ияк астыннан бәйләгән, шинель якасын торгызган, линотип машинасының кургашын кайната торган, әле суынып өлгермәгән казанына сөенеп, ишеккә арты белән утырып тора иде.

— Әйдә, Гадел, ашап килик,— дидем.

Ул дәшмәде, әйләнеп карамады. Байтак шулай утырганнан соң гына, анда да ярты битен генә миңа таба борып:

— Күрмисеңмени хәлемне... — дип куйды.

Аның чырае көл төсле иде. Мин, ашарга җибәрермен дип, редакциянең ашханәсе урнашкан җиргә киттем. Кутуйга бераз кызыл аракы һәм ашарына җибәрергә куштым. Үзем ашадым да егылып йокыга талдым (төннең-төн буе йокламаган идем). Бервакыт дәшәләр, сине полковник чакыра, диләр. Полковникның миңа нинди йомышы төшсен икән? Аның беркайчан бер авыз сүз минем белән сөйләшкәне юк. Полковник белән редакторыбыз Ярулла Ярмәкиев кенә сөйләшә, ул да мәҗбүр булганда гына сөйләшә...

Йоклап яткан җирдән сикереп торып, шалаштан йөгереп чыктым. Чыксам, каршымда полковник үзе басып тора. Мин йокы исереклегеннән рәтләп айнып та җитмәгән хәлдә моның алдында үрә каттым.

— Син ут яктыңмы? Чәй кайнатып эчтеңме?— дип сорады кинәт бу миннән.

Юк, мин әйтәм, иптәш полковник, ут якмадым, чәй кайнатып эчмәдем. Газетаны тапшыруга ятып йокладым, сез чакыргач кына уяндым.

Ходаның хикмәте, артык бер сүз әйтмәде, китеп барды. Мин аптырап уйланып торам. Исемә төште: Гариф белән Кутуй бүтән урманнарда торганда урман эченә китеп чәй кайнаткалыйлар иде, ләкин бу урманга килгәч, Кутуйның, Гариф Галиевнең чәй кайнатып йөрер вакытлары булмады, Кутуйның хәле дә чәй кайнатып йөрерлек түгел. Аннары, кайнатсалар, чәй кайнатуның ни гаебе бар?

Соңыннан инде белдем: мин йоклаган арада урманга ут кабып, ялкын редакция хуҗалыгы урнашкан вагоннар өстенә сикерә башлаган икән. Көч-хәл белән генә сүндергәннәр. Полковникка кемдер, татарлар урманда чәй кайнатып эчәләр, ут шуннан чыккандыр, дип әйткән булган да, полковник мине утка бастырырга килгән икән. Ә минем чынлап та утякканым, чәй кайнатып эчкәнем юк иде.

Бераз тынычлангач, Кутуй янына кермәкче булып барсам, миңа әйтәләр: Кутуйны машинага утыртып, ашыгыч рәвештә госпитальгә озаттылар, диләр. Кайсы госпитальгә, адресы ничек? Белүче юк.

Ул арада фронт һөҗүмгә күчте. Иртә таңда башланган артиллерия әзерлеге редакциягә дә ишетелеп торды. Ә бит без фронттан шактый ерак. Туплар тавышы дөбер-дөбер-дөбер өзлексез дөберди... Самолетлар фронт ягына агылып кына тора... Бар иде безнең гаскәрнең бөтенләй самолетсыз сугышкан чаклары... Баш очыннан болыт кебек агылган үз самолетларыңны күреп торуның рәхәтен белсәгез иде сез... Башланды. Безнекеләр Берлинны, ул вакыт теле белән әйтсәк, фашист ерткычның оясын туздырырга дип кузгалдылар. Редакциядә дә кеше калмады диярлек. Калганнары өч кеше, дүрт кеше өчен эшлиләр. Эшне сайлап торган юк. Үзебез редактор, үзебез корректор, үзебез хикәяче, үзебез фельетончы, тәрҗемәче... Кыскасы, чәчүче дә, сукалаучы да үзебез. Сыбызгыны да үзебез сызгыртабыз. Гадел авырып ята, редакциядә бер кешегә ким...

Фронтта сугышлар бик каты. Безнең гаскәр, ниһаять, Берлинга бәреп керде. Урам сугышлары бара. Гитлерчылар үлем әчесе белән тартышалар. Эш күп. Кутуй янына атна-ун көн үтми барып булмады.

Гариф Галиев кемнәндер сорап, илтеп куючы шоферданмы, белмим, Кутуйның бездән әллә ни ерак түгел бер немец шәһәрендә ятуын белеп алган. Гариф белән икәү олы юлга чыктык та, кул күтәреп, машинага утырдык. Госпитальне барып таптык. Ак халатлы матур гына бер рус кызы (фронтта кызлар барысы да матур иде ) такта зурлыгы, балта түтәсе калынлыгы кенәгәсен ачты да бармагын йөртә-йөртә исемлектән Кутуйны эзләде. Без Гариф белән басып көтеп торабыз.

— Дәвалану өчен тылга озатылган,— диде матур кыз.

— Нинди авыру?

Бу әйтте.

— Нинди стадия?

— Ачык процесс,— диде.

Андый авыру белән кешеләр гомер буе яшиләр. Дәвалану өчен тылга да озатылгач, без әллә ни куркыр нәрсә тапмадык. Ул вакытта без күп нәрсәне искә алмаганбыз. Кутуй бик бетерешкән иде. Сталинград фронтында «Катюша»да хезмәт иткәндә ул бик каты туңган. Залп бирергә команда булганны көтеп, сәгатьләр буе карга күмелеп ятарга туры килгән чаклар булды, дип сөйли иде. Кыш ул елларны яман суык килде, ашау начар иде. Шуңа китереп Гаделнең ваемсызлыгын, үзен кайгырта белмәвен дә өстәсәк... Бөтенесе бергә аның болай да бик шәптән булмаган сәламәтлеген тәмам какшаткан. Ләкин госпитальдән шундый хәбәр алып чыгып киткәндә, без Кутуй терелмәс дигән уйны башыбызга да китермәдек. Кул күтәреп, машина туктатып, кире редакциягә кайтып киттек.

Хәтергә сеңеп калган тагын бер момент. Кич белән, инде бик соң, газетаның эшен бетереп, басарга тапшырасы гына калгач, кинәт автоматлардан шатыр-шотыр ата башладылар. Бу ни хәл? Атылышып вагоннан чыктык! Каян аталар? Кем ата? Һич ни аңлап булмый... Чатыр да чотыр... Ахырда аңлаштык. Сугыш беткән, Германия җиңелгән... Сөенечебезнең иге-чиге юк. Ләкин һәр яхшының бер начар ягы була дигәндәй, җиңү «вакытсызрак» булды: газетаның әзер битен сүтеп яңадан эшләргә туры килде.

Без инде Берлинда. Квартирабыз Шоссештрасседа, редакциябез бүтән урамда, типография янындарак... Көн саен трамвайга утырып эшкә барабыз. Төн утырып газета чыгарабыз да иртән яктырып килгәндә, буп-буш Берлин урамнарыннан җәяүләп өебезгә кайтабыз. Көтмәгәндә генә Кутуйдан открытка! Юлдан җибәргән. Поезд мине тылга алып китеп бара, ләкин мин әле кире борылып кайтырмын, Берлинны алуда катнашырмын, дип яза. Күптән язган булган, открытка кайдадыр адашып йөргән, шуннан соң гына безне эзләп тапкан. Шулай да Кутуйның үз кулы белән язган открытка булгач, без куандык: димәк, исән-сау, дәваланырга кайтып бара, дип уйладык. Инде Берлинны алышырга соңга калды, Казанны «алганда» очрашырбыз.

Тыныч кына эшләп йөргәндә, кинәт кенә тагын бер хат. «Кутуй госпитальдә үлде...»— диелгән. Без аптырадык та калдык. Беребез дә аны үләр дип уйламый идек бит. Гариф Галиев, тиз генә җыенып, Кутуй вафат булган госпитальне эзли китте. Госпиталь Польша җирендә, Лодзь шәһәрендә булып чыкты. Кайткач сөйләде, госпитальдәге татар кызлары: «Кутуй абый безнең кулда үлде», — дип әйткәннәр.

Күпмедер узгач, Гаделнең редакциядәге вещмешогын чишеп карадык: түгелми торган кара савыты, флягасы һәм трофей револьверы чыкты. Кутуй тоткан, Кутуй үзе белән йөрткән нәрсәләргә озак кына карап тордык. Гадел үзе инде юк, шушы әйберләре калды да «Берлинны алышырга мин әле кайтып житәрмен» дигән сүзләре калды.

Сугыш кырында ул гел алда булырга тырышты һәм гел алда булды да. Ә шәхси тормышында, иптәшләренә мөнәсәбәттә үз фигурасы белән бүтән язучыларны кулагаларга көчәнү аңарда бөтенләй юк иде. Исәннәргә үлгәннәрдән үрнәк алып, бераз тыйнаграк булу зыян итмәс иде дип әйтәсе килә...

## ГАЛИ ХАЛИТКА 50 ЯШЬ

# ТЫНГЫСЫЗ ИЛЛЕ ЕЛ

Торакның бу урынында һәрвакыт кеше була: керәләр, чыгалар, чәйнек тотып, кайберләре кайнар су алырга бара, кайберләре болай, эче пошканнан чуала. Очрашучылар бер-берсенә «Сәлам» дә «Сәлам» диешеп, ашыгып кына ике якка аерылып китәләр. Ә кайчакта кинәт кыска вакытлы гына бәхәс тә бәйләнеп ала.

Ике-өч студент нәрсәдер турында сөйләшә иделәр. Ахыры, әдәбият турындадыр. Әнә теге яктан берәү чыкты да, боларга һич игътибар бирмичә, бик кирәкле эшенә ашыккандай, үтә башлады. Болар туктаттылар. Бу—чандыр, озын гәүдәле, ак чырайлы, саргылт чәчле, күгелҗем күзле егет иде. Өстендә аксыл-зәңгәр күлмәк. Бер кулында китап иде микән, әллә чәйник иде микән... икенчесенең биш бармагын чәчләренә тирән батырып, артка таба сөреп куйды. «Я, әйтегез!» — дигән шикелле, тегеләргә, кырт кистереп кенә, карап алды. Тегеләр нидер әйттеләр. Мин әллә ишетмәдем, әллә ишетеп тә, хәтерем саклый алмаган. Әмма егетнең аерым сүзләре колак төбемдә гомергә яңгырар булып калды: «...Социаль характер... тирән психологизм... Менә нәрсә!.. Укыгыз... Лев Толстойны... Шолоховны...» Үз сүзләренең тегеләргә нинди тәэсир ясавы турында, ичмасам, һич кенә дә кызыксынмастан, ул шунда ук, алга карап, үз коридорына кереп югалды. Мин янымдагы студентлардан, кыюсызланып, шыпырт кына



сорадым: «Кем соң бу?» Чибәр генә бер кызый: «Әбәү! Бар икән тау тишегендә мүкләнеп яткан бәндәләр!» — дигән шикелле, гаҗәпләнеп, минем наданлыгым өчен үзе газап чигеп, йөземә ялт кына карап алды һәм, күкрәгендәге дулкынын басарга теләгәндәй, сүзләрен өзеп-өзеп кенә: «Шушы бит инде Халит... Гали Халит», — диде. Кызганычка каршы, минем бу егетне беренче күрүем, аның турында беренче ишетүем иде: ул дүртенче курс студенты икән...

Һай гомерләр! Шул көннән соң утыз елга якын вакыт үткән дә киткән! Халитка да бүген егерме яшь түгел, илле! Теге чибәр кыз да хәзер карчыктыр инде. Ләкин шунысы яхшы: дөнья кулыңнан берсен алса, икенчесен бирә. Еллар безнең Халитның да гомеренең зур бер кисәген алып китсәләр, алмашына җитди тәнкыйтьче һәм зур галим буларак танылу китерделәр, аңа карата кешеләрдә хөрмәт тудырдылар; аның социалистик культураны үстерү юлындагы хезмәтләрен тәкъдир итеп, хөкүмәт орденын бирде.

Истәлекләр дөньясына тагын бер әйләнеп карыйк әле... Ул заманнарда Тукай турында ниләр генә язылмады: ул динче дә, ул милләтче дә, ул вак буржуа да, ул фәлән дә, ул төгән... Утызынчы елларның ахырына таба шагыйрь турындагы хөкем акрын-акрын яхшы якка таба үзгәрә башлады. Ләкин шулай да хәлиткеч кыю аваз ишетелми иде әле. Һәм менә, ниһаять, 1938 елда егерме өч яшьлек бер егет: «Тукай — халык шагыйре!» — дип, мәйданга кыю һәм көчле аваз ташлады. Бу — Тукай турында әллә кайчан туып та, вульгаризаторлар басымы астында томаланып торган зур хакыйкатьне яңадан ачу, аны ачучы яшь егет Гали Халит иде. Егетнең тиздән «Халык

шагыйре Тукай» исемендә беренче зур китабы басылып чыкты. Егет танылган тәнкыйтьчеләр сафына басты. «Г. Халит» дигән имзаның шуннан соң, менә инде чирек гасырдан артыграк вакыт үтүенә карамастан, матбугат битләреннән төшкәне юк. Сугыш алдыннан гына ул безнең икенче зур шагыйребез М. Гафури турында матур китап бастырды, соңрак шунысы өчен аңа филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә бирелде. Сугыштан соң аның реализм мәсьәләләренә багышлаган махсус зур китабы чыкты. Аннары аның Тукай турында татар һәм рус телләрендә яңа зур-зур тикшеренүләре дөнья күрде. Шул ук вакытта ул Казан университетында лекцияләр укыды, урта мәктәп өчен татар теле һәм әдәбияты буенча программалар төзеде, дәреслекләр хәзерләште.

Ул күп еллардан бирле инде зур һәм җаваплы фәнни хезмәт башкаручы коллективның эшенә җитәкчелек итә. Ялгышмыйча әйтергә мөмкин, ул үз талант көченең 70—80 процентын шушы эшкә бирә. Мондый эш галимнән бик тирән эрудиция, талант, үткен каләм һәм аттай эшләрлек көч сорый. Уртак хезмәтләрнең аерым авторлар язган өлешләрен җитәкчегә кабат-кабат укырга, укырга гына түгел, төзәтергә, күп урыннарын авторлар өчен үзеннән язарга туры килә. «XX йөз башында татар әдәбияты», «Татар совет әдәбияты тарихы» — калын-калын китаплар. Ләкин теге яки бу бүлекне нинди генә автор язган булуына карамастан, мондагы һәрбер бит, һәрбер сүз, һәрбер өтер һәм нокта Халитның күзеннән үткән, мондагы һәр юлга аның каләме кереп чыккан...

Халит — карчыга күзле тәнкыйтьче. Ул кемнең дә булса язганын укыганда андагы көчле һәм зәгыйфь якларны шул хәтле өстенә туры төшеп эләктереп ала, аңа каршы әйтер сүзне табуы кыен. Ул гына да түгел, Халит үзе хакыйкать дип инанган нәрсәсен, боргаланып-сыргаланып тормыйча, туры һәм ачык итеп әйтә торган кеше. Мондый чакта аның телен кылычка охшаталар. Кайбер авторлар моның өчен рәнҗиләр. Минем үземә калса, аңардан рәнҗер урын юк. Беренчедән, мин аның телен кылыч түгел, хирург пычагы дияр идем. Икенчедән, Халитның тәнкыйть сүзен ишеткәндә күңел әрнеп ала икән, бу хирургның тәннән кирәкмәс нәрсәне кисеп алган чагындагы авырту кебек кенә. Соңыннан рәхмәт әйтәсең. Мин нәрсә дә булса язсам, басылганчы аны Халит укып чыгып фикер әйтүен үземә бәхет саныйм. Ул туры тәнкыйть ясый. Аның тәнкыйте яңа уй, яңа фикер, яңа идея тудыра. Аның тәнкыйтеннән соң эшләгәч, хезмәт, һичшиксез, яхшыра.

Ул үз җитәкчелегендәге коллектив белән дә шулай эшли. Аның җитәкчелегендә әзерләнгән һәм зур гына өлеше аның үзе тарафыннан язылган кырык табаклы зур хезмәт хәзер Мәскәүдә рус телендә чыгып ята. Татар совет әдәбиятының туу, үсү һәм чәчәк ату тарихы белән хәзер, шушы китаптан укып, бөтен дөнья таныша алачак.

Кайчакта телдән «Һай гомерләр!» дигән сүзләр ычкынып китсә дә, чынысын әйткәндә, бер дә алай үкенерлек түгел: кордашларның гомере юкка үтмәгән, алар авыравыр йөкләрне, кыенлыклар булганда да, «эһ» тә итмичә күтәреп чыга ала һәм халкыбызның мәңге югалмаслык хәзинәсенә кертеп урнаштыра белгәннәр. Шуларның берсе — Гали Халит, талантлы язучы, галим, тынгы белмәс эш кешесе, безнең каләмдәшебез һәм дустыбыз.

Кайчак илнең ерак почмагыннан берәр кунак килеп төшә. Аңа Казанны күрсәтәсең. Ләкин аны барыннан да бигрәк культураның танылган кешеләре: язучылар, композиторлар, җырчылар кызыксындыра. Ул аларны күрергә тели. Шулай берәр зур залга эләгәсең. Трибунада әлеге саргылт чәчле, күгелҗем күзле танышыбыз. Аның иң илһамланган минутлары. Зал бер тынын кысып утыра, бер яңгыратып көлеп җибәрә, бер, бүлдереп, кул чабып ала. Сокланган кунагым шыпырт кына сорый:

— Кем соң бу?

— Әнә шушы бит инде ул... Г. Халит!

Аның хезмәтләре, аның исеме татар совет культурасының дулкыны барып кагыла алган ерак чикләргә кадәр киң таралган.

Х. ГОСМАН.

Совет властенең 50 еллыгына

*Гариф Галиев*

# ЗЕМЛЕМЕР БАГАНАСЫ

Шулай элекке заманнар һәм революция көннәре турында сөйләшеп утырабыз. Патша заманында: «Бер түтәрәм тары чәчтем, ул да булса уңмады», — дип, ягъни таяк буе җир белән яшәгән ярлы крестьяннарны, революция елларында авылларда җир өчен барган көрәшләрне бер-бер артлы искә алабыз. Утырдашым миннән өлкәнрәк. Шулай да аның сөйләгәннәрен күз алдыма бик ачык итеп китереп бастыра алам. Чөнки яшь ягыннан беркадәр аермабыз булса да, асылда без революция алды елларын да һәм революция көннәрен дә бергә үткәргән, бергә кичергән һәм азмы-күпме шуңа көч куйган кешеләр. Шуның өстенә без берүк басуда җир сөргән, берүк тау башында бозау эзләп йөргән, ягарга утын булмаган чакларда, көзге салкыннарда берүк чокыр-чакырлардан корыган куралар, шайтан таяклары, әрем сабаклары җыеп һәм, ниһаять, этиләребез булмау аркасында, революция көннәрендә халык белән бергә җир өләшеп йөргән бер авыл малайлары. Тагы да дөресрәк итеп әйткәндә, ул елларда без аның белән җир өләшүнең башында торган, авылның «грамотный» малайлары идек. Чөнки без нииндидер «бәхет» аркасында авыл мулласының мал өендә «гыйлем» алган егетләрдән санала идек. Ул елларда без, авылдагы барлык ирләрне, барлык малайларны, бөтен хатыннарны, бөтен кызларны бергә туплап, җир кенәгәсенә терки идек. Аннары, инде шул кенәгәдәге исем, фамилияләрне кертеп, кечкенә кәгазьләрдән шобагалар бөтерә һәм шуларны алама бүрекләргә сала идек. Җир өләшергә басуга чыккан халык төркеме уртасыннан корт аналары кебек без атлый идек. Ул чакларда дисәтинәләргә аерылган җир башларына килеп туктау белән әлеге бүрекләрне селкеп шобага сикертү башлана иде. Менә шунда инде крестьяннар үзләренең бөтен гаилә членнарына, ягъни малайларына да, кызларына да, җир алып, «өлешеңә чыккан көмешең» дип, куаналар, шатлыкларыннан нишләргә белмиләр иде.

Совет властеның инде илле елга якын яшәвен уйлап, бүген күңелемнән шушы якын иптәшем Дәүләтша белән сөйләшеп утырганда, минем башыма бер фикер килде һәм хәзерге вакытта республикабызның зур гына хуҗалыкларыннан саналган Вахитов исемендәге совхоз (Азнакай районы) территориясен әйләнеп кайтырга булдым. Башта таныш-белешләр белән хәбәрләшеп, кемнең кайда икәнлеген аныклагач, юлга чыктым.

Менә хәзер мин җиде-сигез мең гектар мәйданнан торган элекке Урманай авылы җирендәге болыннарны, әрәмәләрне, урманнарны, тауларны, эреле-ваклы елгаларны, һәртөрле сызаларны, киң көтүлекләрне,

тирән чокырларны карап йөрим. Минем хәтеремә әлеге якын иптәшем Дәүләтшалар белән бергә шушы җирләрне җан башыннан өләшеп йөргән чаклар килеп төшә. Һәм, бөтенесеннән элек, күз алдыма бу кырларны әле аркылыга, әле буйга ергалаган, һәркайсының төбе яшел кәсләр белән капланган бик күп баганалар калкып чыга. Әйе, алар күп. Тауга менсәң дә, таудан төшсәң дә, көтүлекләргә килеп җитсәң дә, көтүлекләрне үтеп китсәң дә, елгаларның бирге ягында торсаң да, аргы ягына чыксаң да, кыскасы, кая гына барсаң да, кайда гына атласаң да — шушы баганаларга очрыйсың. Шушы баганалар алдында: «Мин кем җирендә?» дип, аптырап басып торасың. Хәтта җиләклекләргә барсаң да, шушы баганаларны күргәч, синең кулыңнан савытлар төшеп китә, урманнарга кереп чыбыркы сабы сындырып ала башласаң да, шушы баганаларны күргәч, синең кулларың елгысызлана. Никадәр күп, никадәр ишле иде ул чакларда бу баганалар. Ләкин алар үзләре шулай күп булсалар да, исемнәре бер генә иде:

Землемер баганасы!

Хәзер безгә бу исемне бик сирәк, тик элекке авылларны, элекке заманнарны искә алганда яки революция чорларын хәтергә төшереп, үзара сөйләшеп утырганда гына ишетергә туры килә. Чөнки землемер дигән исем үзе дә һәм шуннан килеп чыккан «землемер баганасы» дигән төшенчә дә хәзер инде халык телендә дә һәм матбугатта да бөтенләй диярлек кулланылмый. Ул инде киңрәк мәгънәне эченә алган «җир төзүче» дигән яңа исем белән алышынды. Элекке землемер баганалары алпавытлар тарафыннан крестьяннар кулыннан тартып алынган җирләрнең межаларын саклап торган җансыз сакчылар булып хезмәт иткән булсалар, хәзерге җир төзүчеләр утырта торган баганалар җирне крестьяннарга мәңгегә файдалануга беркетүнең какшамас терәкләре булып торалар.

Землемер баганасы!

Бу бит гомер буе авыл халкының йөрәкләрен телгәләгән, аңа рәхәтләнеп җиргә басарга ирек бирмәгән багана! Әллә кайлардан әллә кайларга кадәр җәелгән киң басулардан крестьяннарны шушы баганалар мәхрүм иткән бит.

Беркайчан да черемәсен өчен сумалалар белән буяп, беркайчан да аумасын өчен җир астында кала торган башларына эвернәләр кигереп утыртылган менә шушы баганаларны Бөек Октябрь социалистик революциясе төбе-тамыры белән куптарып ыргытты.

Авылның бөтен басулары, хәтта басулары гына да түгел, барлык көтүлекләре, бөтен ындыр артлары шушы баганалар белән чикләнгән, шушы баганалар белән аркылы-торкылы ергаланган иде. Чөнки крепостнойлык алышынганнан соң, бу җирләргә боярлар, мирзалар, хаҗилар ия булып, хуторлар корып тамыр җәйгәннәр иде. Болар кадерле җиребезне баскан билчәннәр иде. Икенче төрле итеп әйткәндә, төпләренә туфрак өелеп, кәсләр белән капланган бу баганалар җир өстенә чыккан әшәке чуаннар, һәм аларны сытарга, ә инде сытканнан соң уыны билгеле булмаслык итеп, тәмам корытырга кирәк иде. Моның шулай булырга тиешлеген бер безнең авыл халкы гына түгел, Россиянең барлык игенчеләре дә аңлыйлар. Шуны аңлаганга күрә дә, безнең авылда да ел аралаш диярлек җир турында кузгалып-кузгалып куялар, ул замандагы Земская управа дигән учреждениегә ходатайлар җибәрәләр, җир планнарын актарып чыгаралар, межаларны яңадан сызуны таләп итәләр һәм югарыдан күңелгә ятышлы хәбәрләр алынмагач, язгы сабан өсләрендә бер-ике сажин гына булса да бояр җиренә керәләр. Боярлар, байлар исә, нәкъ менә шундый вакытларда землемер баганаларына аеруча нык таяналар һәм, үзләре трантаска утырган килеш, җәяүле крестьяннар төркемен ияртеп, аларны бер баганадан икенче баганага таба әйдиләр иде.

Менә шундый дәгъваларның, шундый чуалышларның кайберләре минем хәтеремә бигрәк тә нык сеңеп калган. Иң элек шуны әйтим, белмим, яшьтән үк атасыз һәм бу авылга икенче бер җирдән күчеп килүебез аркасында бөтенләй җирсез үскәнгәмедер, белмим, ир бала булгангамыдыр, мин әллә нишләп пожар лапасы каршында җыела торган сходларны читтәнрәк булса да карап тора идем. Хәер, ир балалар бөтенесе дә диярлек шулай олыларның нәрсә турында сөйләшүләре белән кызыксынучан, аларга ияррергә тырышучан, авылда барган бөтен вакыйгаларның эчендә кайнаучан һәм, ниһаять, барлык хәбәрләрне алдан ишетүчән булалар бит.

Шунлыктандыр инде, без, бер төркем дус малайлар, ул көнне авыл читендә башланып киткән гауганы бик тиз ишетеп алдык, һәм бөтенебез берьюлы шул гауга барган урынга йөгердек.

Бу юка гына кырпак төшкән көз көне иде. Әлеге вакыйга җир-суы булмау аркасында чабата ясап, итеккә олтан салып көн күрүче Хөснетдин абзыйлар тирәсендә, ярым кычыткан баскан бер чокыр буенда бара иде. Авылның җирле байлары тамаклары карлыкканчы халыкка карап акыралар:

— Алтынчы землемер баганасы шушы чокыр буенда иде. Кайда ул?

Аларга каршы халык кычкыра:

— Без каян белик аны! Межа монда түгел, әнә тегендәрәк, сезнең күзләрегез тонган!..

Ике катлау арасындагы бәхәс куерганнан-куера бара. Байлар, халыкка карап, һаман акыралар:

— Сез землемер баганасын казып алып, каядыр ыргыткансыз!

Халык аларга килеп ябырыла:

— Казып алган булсак, багананың урыны калыр иде!

Байлар һәм алар ягындагы ялчы староссталар, урядниклар багананың урынын эзләргә тотыналар. Ләкин ничаклы гына тырышып эзләмәсеннәр, багананың урынын таба алмыйлар. Яңадан акыра башлыйлар:

— Безгә багананың урынын табу гына кирәк. Урынын тапсак, аның төбендә кара күмер ята. Межаны ачыклау өчен безгә шул кара күмер җитә!

— Җитсә, табыгыз багананың урынын! — дип, шау-гөж килә халык.

Без малайлар өчен шунысы гаҗәп, халык арасында тик Хөснетдин абзый гына үзен үзе ничектер тынычрак тота шикелле. Хәер, аның үзүзен тотуын аңлау да кыен: ул әллә ничек, бер караганда, нәрсәдәндер сагайган кебек, икенче караганда, утны-суны кичәргә әзер торган кеше кебек тоела. Итекләребезгә олтан салганда, без аңа еш кына җеп сумалалап, аңа ничек кенә булса да ярарга тырыша идек. Бу сумала йомарлакларын кулга тоту безнең өчен ничектер рәхәт, бу җепләрне сузып утыру безнең өчен ничектер кызык, күңелле иде. Һәм сары, калын кашлы, аз гына салынкырак битле, һәркайчан нәрсә булса да сөйләп гел көлдерә торган Хөснетдин абзыйның бүген чокыр буендагы халык арасында үзен болай тотуы безгә бөтенләй аңлашылмый, хәтта башыбызга сыймый иде.

Дәүләтша дустым кинәт колагыма пышылдады:

— Әллә чирле микән ул Хөснетдин абзый?

— Белмим шул, — дидем мин аптырап.

Дәүләтша үзенең әле генә биргән соравына шунда ук җавап бирде:

— Нишләп чирле булсын инде. Чирләсә өендә ятыр иде, — диде ул.

Җир биләүче байларның землемер баганасының урынын эзләүләре дәвам итте. Ләкин багана һаман табылмады. Халык та бу мәсьәләдә аптыраштта калды.

— Чынлап та, кем суырып ыргытты икән аны?

— Суырып ыргыткан булсалар, урыны кала ич аның. Урынын да таба алмыйлар лабаса!

— Җир йоткандыр!

— Нәрсәне?

— Әлеге шул каһәр суккан багананы.

Күк йөзе болай да болытлы иде. Кояш тау артына кереп баткач, көн тагы да караңгыланып китте.

— Ул болай да чери башлаган иде. Үзеннән-үзе ауган дыр да, язгы ташкын белән агып киткәндер, ә инде урынын су юып үткәндер... Шулайдыр... Шулай булмаса, кая китсен ул, — диде бер картрак кеше.

— Без аны бүген барыбер аудара идек, урынын җир белән тигезли идек, — дип куйды кемдер.

Җир биләүче байларның эзләүләре икенче көнне дә, өченче көнне дә һәм аннан соң да бернинди нәтиҗә бирмәде.

Авыл буйларыннан яки ындыр араларыннан үткән куян, бүре эзләрен көннәр буе эзәрлекләп йөрү безнең өчен никадәр кызык булса, бу югалган землемер баганасының урынын эзләп табу аннан да кызыграк, аннан да мавыктыргычрак иде. Билгеле инде, без аны байлар өчен түгел, ә үзебез өчен эзли идек һәм без аны тапсак та җир биләүче байларга беркайчан да әйтмәячәк, ә бу турыда Хөснетдин абзый кебек үзебез якын күргән кешеләргә генә әйтәчәк идек.

Без ул баганының урынын әнә шундый яхшы теләк белән эзләдек. Чокыр буенда без тимер көрәк белән казып, лом белән төртеп карамаган кулъяулыгы кадәр дә урын калмагандыр. Без ул чокырның яр асларын, яр өсләрен актардык. Мәгәр никадәр генә тырышып эзләсәк тә, землемер баганасы менә шушында утыртылган булган, дип әйтерлек кара күмерле урын таба алмадык. Ул елларда без, малайлар, йөнтәс этләр белән дә йөгерек куяннар тота ала идек, юкәдән үрелгән тозаклар белән дә бик сизгер йомраннарны кулга төшерә ала идек, үзара уйнау тәртибендә елга төбенә ыргытылган бакыр акчаларны да, көмеш тәнкәләрне дә суга бер чумуда табып чыга ала идек. Ә менә ул көзне көннәр буе казынып та шул землемер баганасының үзен түгел, хәтта урынын да таба алмадык. Бу хәл, гәрчә кечкенә булсак та, безнең өчен йөз кызыллыгы иде. Без бу булдыксызлыгыбызны озак вакытлар оныта алмыйча йөрдек.

Озакламый кырпак өстенә кар төште. Җир ап-ак юрган ябынып кышкы йокыга талды. Багана турындагы бәхәс тә, ничектер, беркадәр вакытка сүрелгәндәй булды.

Инде салкын кыш айлары үтеп, язлар житте. Әлеге авыл читендәге чокырның ярларыннан чыгып ташкын суы акты. Бу исә тагы яр буйларын юып үтте. Һәрберсе икешәр-өчәр йөз дисәтинә җир биләүче байлар бу язда инде землемер баганасының урынын табудан бөтенләй өметләрен өзделәр. Кайбер үткенрәк һәм тәвәккәлрәк кешеләр аларга каршы сүз тараттылар:

— Багана чокырның бу ягында түгел, ә теге ягына утыртылган булган. Еллар үткән саен су юлы алышына барган. Сез шуны да белмисез, — диделәр. Һәм шундый сүзләр йөрткән арада дисәтинә киңлегендә чокыр буйлап авылның җирен кинәйтеп тә өлгерделәр.

Шул елны күп җир биләүче байлар әлеге югалган землемер баганасын янадан торгызу, ягъни аның урынын аныклап яңа багана утырту өчен өяздән землемер чакырдылар. Ләкин дөньялар кинәт алышынып китте, патша турында төрле-төрле хәбәрләр таралды, боярларның берсе — Дукшин фамилиялесе — бер төнне бөтен имениесен ташлап каядыр качып китте. Землемер дә килмәде. Мәгәр әлеге чокыр буендагы, Хөснетдин абзыйлар янындагы землемер баганасының югалуы җирле байлар өчен дә, җирсез крестьяннар өчен дә бик тирән бер сер булып калды. Бу турыда авылда һәртөрле юраулар таралды. Берәүләр:

— Аны аждаһа күтәреп алып китеп, Каф тавы артына илтеп ташлагандыр, — диделәр. Икенчеләр:

— Көчле өермәләр тамырлары бик тирәнгә киткән юан агачларны да туфраклары белән кубарып ала бит. Бу баганаңы да шундый өермә һавага күтәргәндер, без күрми калганбыздыр, — диделәр. Өченчеләре исә алар фикеренә кушылмадылар, үзләренең сүзләрен әйттеләр:

— Кеше кулы эшләгәндер, ул үзебезнең арабыздадыр һәм үз кешебездер. Мәгәр әйтми торгандыр, дус бар, дошман бар дигәндәй, саклана торгандыр, — диделәр. Сер һаман ачылмады, ул катлы-катлы тимер ишекләр белән бикләнгән сейфта сакланган яшерен әйбер кебек яшерен килеш калды.

Бүген Вахитов исемендәге совхоз җирендә, сузылып киткән тау башларында утырганда, күз алдымнан менә шушы күренешләр үтеп китте. Һәм хәзер укучыларны әлеге бик серле землемер баганасының тарихы белән ахырына кадәр таныштыру өчен бу чын хикәямне дәвам итим.

Революциягә кадәр Урманайны төрле яклап урап алган, аны төрле яктан кысып торган Д. Тручанин, Г. Дукшин, Б. Сафонов кебек боярлар, һәрберсе кимендә ике йөз дисәтинә җир биләп торган авылның үз карун байлары пыран-заран китерелгәч, басулар киңәеп, елгалар тирәнәеп, урманнар куерып китте. Болыннарны, көтүлекләрне үлән басты, тауларның башлары күкләргә ашты.

Ул елларда, ул көннәрдә илебез өстендә торган кара болытлар әле таралып бетмәгән, үзенең әчкелтем исе белән һаваны бозып торган дары исләре дә бетеп җитмәгән, ябырылып килгән дошман яулары әле сугыш кырларыннан бөтенләйгә китмәгән, Ватаныбызның әле бер, әле икенче почмагында вакыт-вакыт бомбалар ярыла, туплар шартлый, пулеметлар ютәлли иде.

Шушындый авыр вакытларда, чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, 1921 елның язында Идел буйлап коры, кайнар җилләр исә башлады. Бу афәтле җилләр көннән-көн көчәйде һәм күкрәп үсәргә тиешле игеннәрне, җимеш бирү өчен шытып чыккан яшелчәләрне дымга сусатты. Аларны яңа гына тишелеп чыгып та бик тиз башын игән умырзаялар шикелле хәлсезлеккә дучар итте. Җирләр янды, үләннәр кипте, агачлар корыды. Күзләрен гадәттә икмәк белән тула торган бураларга бер подаука арыш, бер тубал бодай, бер соскы солы, бер уч тары салынмады. Абзарларда атлар, тайлар, сыерлар, сарыклар, кетәкләрдә тавыклар калмады. Кешеләр алты кадак он бәрабәренә кулакларга өйләрен сатып, икешәр-өчәр хуҗалык бергә кушылып яши башладылар.

Ул чакларда ике йөз сиксән сигез хуҗалыктан торган әлеге Урманай авылының халкы шушы дәһшәтле бер ел эчендә өйдәш була-була йөз алтмыш ике хуҗалыкка калды. Андагы җан исәбе мең өч йөз егерме ике кешедән сигез йөз кырык дүрт кешегә кимеде.

Яшь Совет власте, әлбәттә, авылга ярдәм итүдә кулыннан килгәнен бөтенесен дә эшләде. Ерак Украина далаларыннан кукурузлар кайтартты, салкын Себер якларыннан атлар китертте, илнең кайнар җилләр исмәгән почмакларыннан икмәкләр ташытты. Ләкин бөлгенлек белән тәмам йончыган авылны ике аягына да бастыру бик авыр иде. Бу дошманнарның җиңүе түгел, ә илнең стихия алдында калуы, шуның аркасында ачлык-ялангачлыкка дучар булуы иде.

Инде 1921 елгы ачлык үтеп, авыл икмәккә туя башлаган, чыгырыннан чыккан хуҗалыклар яңадан торгызылган, халыкның көнкүреше яхшырган: ачлык вакытында бушап калган ындырларда кибәннәр утыра, абзарларда көр терлекләр сөзешә, өйләрдә бәрәңгегә чокып салынган кыска филтәле түң май урынына җиделе лампаларда карасу-зәңгәр керосиннар яна, тәрәзә башларына эре парчалы ситсалардан тегелгән кашагалар эленгән, сандык өсләренә яңа тышланган түшәк-ястыклар өелгән, моржалардан төтеннәр чыга, кыскасы, авыл үз төсенә кергән,

бөтенесеннән битәр, җир-суга баеган. Ләкин җирдән тулысынча файдалану өчен көч аз иде әле.

Бу НЭП ның соңгы еллары иде булса кирәк. Ул җәйне мин, гәрчә рәсми яктан сайланып куелмаган булсам да, нишләптер, авыл Советында эшли идем. Аның рәсми секретаре да бар иде, югыйсә. Ләкин, шулай булуга да карамастан, мин дә эшлим: һәртөрле протоколлар күчерә идем, озын-озын исемлекләр төзи идем. Кайчакларда авыл хуҗалыгы налогы бланкларын тутыра-тутыра кулларым тала иде. Мәгәр, төптән уйлап караганда, мин авыл Советы председателе Габдулла абзый Гәрәевнең шәхси секретаре идем бугай. Бу юлларны укучы, авыл Советы председателенең нинди шәхси секретаре булсын, дип автор белән бәхәскә керергә ашыкмасын, бу мәсьәлә хәзер аңлашылыр. Эш болай иде: председатель Габдулла абзый әлифне таяк дип тә белми торган, гомер буе көтү көткән, күп еллар солдатта йөргән, гаҗәп йомшак күңелле, әмма бик каты куллы һәм бер нәрсәдән дә курыкмый торган, ир уртасы булуына карамастан, белемгә сусаган кеше иде. Ул волостьтан бик күп газеталар алып кайта иде дә шуларны миннән кычкырып укыта, вакыт-вакыт мине газета укудан туктатып, анда язылганнарны үзе миңа кинрәк итеп аңлатып бирә иде. Хәтта кайбер көннәрне ул мине үзе белән бергә өйләренә кичке ашка алып кайта, аштан соң газеталар укытып утыра. Сүз арасында: «Син, туган, мин печать баса торган кәгазьләрне бик игътибар белән укы. Бөтен ышанычым синдә. Бу елларда читтән кайтып төрле-төрле справкалар сораучылар күбәеп китте. Кемнең кем нәселеннән икәнлеген яхшы белсәм дә, каләмем юк бит, туган. Ә теге ул (сүз каяндыр килеп эшли торган тотанаксыз рәсми секретарь турында бара) аумакай кеше. Аңа самогон гына булсын, самогон иснәтсәләр, ул теләсә нинди справка язар. Кабат әйтәм, бөтен ышанычым синдә», — ди торган иде.

Шул җәйнең урталарында нәкъ төш вакытында авыл Советына өстенә кызыл һәм кара мамык белән чигелгән ак кофта, яшел шакмаклы юбка кигән таза гына гәүдәле, чибәр генә йөзле, егерме яшьләр чамасындагы бер рус кызы килеп керде. Без Габдулла абзый белән икәү генә утыра идек. Яшь кыз туп-туры өстәл янына узмады, әдәп белән генә безнең белән рус телендә исәнләште. Йөзе чибәр, гәүдәсе дә бик сылу. Аның арганлыгы сизелә, үзен үзе беркадәр таркаурак та тота кебек күренә иде.

Ул шулай кыяр-кыймас кына басып торганда, Габдулла абзый аңа русча дәште:

— Ни йомыш, акыллым? — диде.

Рус кызы кинәт үкси-үкси елый башлады.

Габдулла абзый да, мин дә, бер-беребезгә карашып, берничә минут сүзсез калдык. Аннары кыз тынычлангандай булды һәм сөйләргә җыенды:

— Мин, мин... шушы авылда туганмын булса кирәк...

Ул яңадан еларга тотынды.

Мин эчемнән генә уйлап алдым: «Димәк, бу кыз да Габдулла абзый әйткәнчә, справка сорап авылга кайтучыларның берсе була. Ләкин бит... бу рус кызы. Ә безнең авылда руслар юк ич... Ә нигә елый соң бу? Юри генә елый дияр идең, юри елаган кеше болай елый алмый... Чынлап елау белән юри елауны аерып була бит... Кем икән соң бу?..»

Габдулла абзый, күп еллар солдат хезмәтендә булганлыктан, русчага шактый оста иде. Ул аны каршысына утыртып, иплән кенә исем, фамилиясен, кайдан килүен сораша башлады.

Алар сөйләшкәндә мин бу кызга берничә тапкыр карап куйдым һәм, ничектер, ул миңа таныш шикелле тоелды. Ләкин, әле генә Габдулла абзыйга әйтүенчә, аның исеме Зоя, фамилиясе Харитонова. Мин андый исемле кызны белмим...

Утыра торгач, ул татарча сүзләр дә кыстырып сөйли башлады. Ләкин болар тулы җөмләләр түгел, ә аерым-аерым сүзләр генә иде.

Ул яңадан бөтенләй русча гына сөйләүгә күчте. Дөресен әйткәндә, аның теле безнең бу тирәләрдәге рус теленнән, ничектер, аерымрак кебек иде. Сүз арасында кинәт тагы татарча әйтеп куйды:

— Атам — Хуснутдин!.. Анам — Марьям!..

Һәм үкерә-үкерә тагы еларга тотынды...

Без аны кызганып, тагы тынып калдык. Габдулла абзый миңа карап әкрен генә болай дип куйды:

— Төсе-бите белән Хөснетдин абзыйга охшый. Күрәсең, сугыш елларында балалар йортына озатылган булгандыр.

Сүз барышында аның, чынлап та, балалар йортына бирелгәнлеге, тора-бара бу балалар йортының Украина якларына китүе, кызның үз телен әкренләп онытуы, үсә төшкәч, кайбер нәрсәләрнең исенә төшүе аңлашылды.

Озак кына сөйләшкәннән соң:

— Сезгә метрическая справка кирәктер инде, шуның өчен кайткансыздыр? — диде аңа Габдулла абзый.

— Юк, аның өчен генә түгел... — диде кыз көч-хәл белән генә һәм, инде ничәнче тапкырдыр үзен-үзе тыя алмыйча, күз яшьләрен коярга тотынды.

Мин инде аны төсмерләп, тәмам танып өлгергән идем. Бу кыз — без землемер баганасының урынын эзләп йөргән көзне Хөснетдин абзыйның чәчәк чыгып авырган иң кече кызы Зәйтүнә иде.

Габдулла абзый Зәйтүнәнең тирән кичерешләрен тиз аңлап алды бугай, ул аны юатырга тырышмады, берничә минутка тынып калды. Аннары моңсу күзләре белән миңа карап:

— Шулай инде, туган, борынгылар: «Тулган түгелми калмый», — дип, тиккә генә әйтмәгәннәр. Моның да йөрәге тулып ашкан, җирсәп, сагынып кайткан бу, — диде.

Зәйтүнә тынычлана төште. Чигүле кулъяулыгы белән күз яшьләрен сөртте. Ул бөтенесеннән битәр, туган авылын, үзе бишектә яткан өйләренең нигезен генә булса да күреп китәргә кайтканлыгын сөйләде. Габдулла абзый бер-бер артлы сораулар бирде. Аның сорауларына җавап тәртибендә ул, югарыда әйтелгәнчә, балалар йорты белән Курск якларына барып чыкканлыгын, үсә төшкәч, аны бер агрономның балалыкка алганлыгын, хәзер инде үзенең җир төзүчеләр техникумын тәмам иткәнлеген сөйләде. Сөйләде-сөйләде дә әйтеп куйды:

— Миңа бернинди справка да кирәк түгел, мин туган җиремне күрү өчен генә кайттым, — диде.

Байтак вакыт сөйләшеп утырганнан соң, Габдулла абзый аны көндезге ашка үзләренә алып китте.

Зәйтүнә турындагы хәбәр бик тиз бөтен авылга таралды. Ләкин, мәрхәмәтсез сугыш, бөлгенлек аркасында ата-анасыннан мәхрүм калып, үз авылыннан аерылган бу кызның язмышы һич кенә дә үкенерлек түгел иде. Һәркем аңа сокланып карады:

— Менә бит, дөнья ничек ул! Ил аны ятим итмәгән.

Кичкырын без Зәйтүнәләрнең өй урынын ничаклы гына тырышып эзләсәк тә, шактый еллар үткәнлектәндер инде, таба алмадык. Ул вакытлардан бирле өйнең нигезе ничек сакланып торсын. Ул вакыт үтү белән үзеннән-үзе күмелеп беткән иде.

Бу хәл теге елларда землемер баганасының урынын эзләп йөргән чакларны хәтергә төшерде һәм мин шул хакта Зәйтүнәгә сөйләп бирдем. Ул кинәт нәрсәнедер исенә төшергән кеше шикелле:

— Землемер баганасы дисезме? — дип сорап куйды.

Габдулла абзый да, мин дә икебез берьюлы:

— Әйе, ул чакта сезнең өй янындагы, чокыр буендагы землемер баганасы кинәт югалган иде.

Зәйтүнәнең йөзенә елмаю йөгерде:

— Ул безнең өй базының уртасында калдырылган иде бит... Әткәй ком кирпечтән яңа өй салганда... Без аны базга төшкән саен күрә идек... Әтием аны төбеннән үк кискән иде. Ул бу турыда безгә: «Берәүгә дә сүз чыгармагыз», — ди торган иде.

Теге вакытта югалган землемер баганасы, күп еллар үткәч, әнә шулай табылды. Моны мин, әлбәттә, авыл халкының җир өчен элек-электә үк ничек көрәшеп килгәнлеген күрсәтә торган кечкенә бер эпизод кына дияр идем. Хөснетдин абзый салам катнаштырылган комнан кирпеч сугып авыл башындагы чокыр буена үзенә өй салган чакта аны баз уртасында калдырган. Ул үзен һәм үзе кебек бик күпләрне җиргә тилмерткән бу багананы яшереп, алпавытлар, купецлар һәм хаҗда йөреп кайткан байлар җире белән крестьяннар җире арасында сызылган межаны, азмы-күпме булса да, халык файдасына читкәрәк этәргә тырышкан.

Көтмәгәндә югалган землемер баганасының Хөснетдин абзыйның өй базында икәнлеген, әлбәттә, белүчеләр булгандыр. Ләкин алар сер чыгармый торган, халык әйтмешли, «йөрәкләрендә йөгәнле атлар саклый ала торган» булганнар, күрәсең. Аннары, кеше дигәнең, бердән, табигый рәвештә үлеп-туып тора, икенчедән, афәтле ачлыклар, дәһшәтле сугышлар миллионнарча җаннарны алып китәләр бит. Югарыда без ачлык вакытында бу авылның халкы күпмегә кимегәнлеген әйтеп үткән идек инде. Шуның өстенә 1914 елда башланган сугышта гына да шушы ук авылның йөздән артык корбан биргәнлеген искә алсак, бик күп ирләрнең бу якты дөньядан вакытсыз киткәнлеген күрербез. Югалган землемер баганасының кайда икәнлеген ачык белгән һәм калган барлык баганаларны да аудару өчен көрәшкән кешеләр дә, безнеңчә, шул саннар эчендәдер.

Әле мин һаман тау башында әнә шул еракта калган авыр көннәрне, җир өчен барган кызу көрәшләрне, шул көрәшләрнең башында барган, олылар әйтмешли, куш йөрәкле ирләрне уйлап утырам. Җир турында уйлый башладыммы, мин революциянең беренче көннәрендә үк солдатлар белән авылга кайтып кергән бер бит сары кәгазьне искә төшерәм. Аны, башкалар белән бергә, югарыда телгә алынган Габдулла абзый алып кайткан иде. Һәм ул анда бер генә нөсхә түгел иде шикелле. Чөнки мин аның эре хәрефләр белән нәрсә турындадыр басылган бу кәгазьне Шәймәрдән хаҗиларның, Җамалетдин муллаларның капкаларына, мәчет коймаларына, сәүдәгәрләрнең кибет ишекләренә арыш аparaсы белән ябыштырып йөргәнлеген бүгенгедәй хәтерлим. Бу — Ленин кул куйган мәшһүр «Җир турында Декрет» иде. Шунысы да исемдә калган: бу кәгазь ябыштырылган урынга халык бик күп җыела, ләкин аларның берсе дә укый белми, шул исәптән Габдулла абзый да укый алмый. Ул анда басылганнарны телдән сөйләп бирә белә һәм көннәр буе әлеге сары кәгазь алдына җыелган халык арасында басып тора иде.

Без, дустым Дәүләтша белән, «грамотный» малайлар, югыйсә. Ләкин без «ике каләмле» түгел шул, ягъни русча укый-яза белмибез. Габдулла абзый безгә бик таяныр иде дә, ләкин аптырап кала һәм бик мөлаем тавыш белән:

— Әй, үскәннәрем, — ди дә авылыбызның вак товарчысы, шул заманның инвалиды, аксак Василийны чакыртып китертә. Аңа Декретны кычкырып укып бирергә куша.

Василий агай (без аны шулай дип йөртә идек) агач аягы белән титаклап баса-баса сары кәгазь алдына килә дә аны укый башлый.

Сирәк кенә тешләре арасыннан өзек-өзек, аермачык булып чыккан сүзләре белән халыкны үзенең авызына каратып тота.

Ул, күрәсең, үзе дә Габдулла абзый кебегрәк кеше булгандыр, аның безнең авылыбызга вак товарчы булып килүе дә очраклы хәл булмагандыр... Каян беләсең, бәлки ул революциянең авылга җибәргән шинельсез солдаты, ышанычлы улы булгандыр... Чөнки Декретны укыганда аның тавышы көчәйгәннән көчәя бара, хәтта укып чыкканнан соң ул тавышын тагы да көчәйтебрәк, тагы да күтәребрәк:

— В. И. Ленин! — дип, бөтен халыкка берьюлы карап ала иде.

Аның артыннан ниндидер эчке якынлык, кайгы-хәсрәтләрне дә, шатлыкларны да эченә алган йомшак тавыш белән халык кабатлый иде:

— Ленин!

— Әйе, Ленин кул куйган.

Мин бу тавышны менә шушында, совхоз җирендә, тау башларында хәзер дә ишетәм. Ул минем колагымда һаман да яңгырап тора:

— Ленин!

Мин әле бу таулардан төшәргә ашыкмыйм һәм янымда, аксыляшел үлән өстендә ята торган кечкенә генә кул саквояжымны ачып, андагы «В. И. Ленин в Петрограде (1917—1920 гг.)» дигән китапны актара башлыйм. Бу китапны минем берничә тапкырлар укыганым бар. Ә менә бүген тау башында, җир турында уйланып утырганда, Ленинга багышланып язылган бу китапны яңадан укып чыгасым килде. Чөнки җир турында уйланасың икән инде, ул Ленин турында уйлыйсың дигән сүз, ягъни җир ул — Ленин.

Бу китапның авторы В. Д. Бонч-Бруевич 1920 елга кадәр СССР Халык Комиссарлары Советының эшләр башкаручысы булып хезмәт иткән, ягъни Ленинны көн саен күргән, аның белән көн саен сөйләшкән, крестьянча әйткәндә, аның белән бергә чәй эчеп утырган кеше.

Ул үзенең бик җылы хисләр белән сугарылган бу китабында Ленинның җир турындагы тарихи Декретны ничек язганлыгын сурәтли. Менә Бөек Октябрь социалистик революциясенең бишеге — Петроград шәһәре, Смольный. Иртәнге сәгать дүртләр тирәсендә, эшләп тәмам арыгач, В. И. Ленин һәм башкалар Смольныйдан тарала башлыйлар. В. Д. Бонч-Бруевич башта Рождественский районының бөтен дружиналарына телефоннан шалтыратып, аларга бик уяу булырга, урамнарга ныклап разведка ясарга куша. Шуннан соң инде Владимир Ильичка Бонч-Бруевич үз квартирасына йокларга кайтырга тәкъдим итә. Петроград урамнары дөм караңгы була. Алар алдан сөйләшеп куелган урынга килеп, автомобильгә утыралар һәм квартирага китәләр.

В. Д. Бонч-Бруевич Владимир Ильичны аерым кечкенә бүлмәдәге үз кроватена ятарга тәкъдим итә. Бу бүлмәдә язу өстәле, кәгазь, кара һәм китапханә була. Бонч-Бруевич үзе күрше бүлмәдәге диванга ята һәм Ленинның йокыга талганлыгына тәмам ышангач кына йокларга карар бирә. Ишекләрне ныклап бикли, револьверларны кора. Ниһаять, Ленин бүлмәсендә ут сүнә. Ләкин Бонч-Бруевич йокыга киттем дигәндә генә Владимир Ильич бүлмәсендә кинәт ут яктысы күренә. Бонч-Бруевич сикереп урыныннан тора һәм Ильичны күзәтә. Ул, әкрен генә, тавышсыз-тынсыз гына урыныннан кузгалып, өстәл янына килеп утыра һәм яза башлый. Бер яза, бер сыза, тагы яза һәм язганнарын акка күчерә. Иртәнгә таба инде, ягъни караңгылы-яктылы вакытта ул утны сүндерә һәм йокларга ята.

Җир турындагы тарихи Декретны Владимир Ильич менә шушы төнне яза. Бу Декрет Советлар съездында кабул ителгәннән соң, бөтен газета редакцияләренә басарга җибәрелә. Аннары ул аерым кәгазьгә басылып, солдатлар һәм крестьяннар арасында таратыла. Аны губерна, өяз шәһәрләренә генә түгел, Россиянең барлык волостьларына җибәрәләр. Владимир Ильич аңа шулчаклы зур әһәмият бирә ки: «...бер

генә башка закон да җир турындагы закон кебек шул кадәр күп таралмагандыр», дип яза бу хакта Бонч-Бруевич.

Мин тау өстендә утырган урынымнан торып, аягүрә бастым. Һәм күз күреме кадәр киңлектәге бу җирләргә карап туя алмадым. Мин анда тракторлар үрмәләгәнне, озын елгалар буйлап көймәләр йөзеп барганны, канатсыз атларга менеп, тау биеклекләренә күтәрелүче кешеләрне, җимеш бакчалары өчен мәйдан яручы землемерларны күрдем. Чәчүне дә, тырмалауны да бер үк вакытта башкарып, җирне иңләп бара торган машиналарга, машиналар таккан тракторчыларга, көймәләргә утырып йөрүче балыкчыларга, таза атларга атланып көтү әйдәүчеләргә, корыч ленталар сузучы землемерларга карап күңелемнән үземнең фикерләремне әйттем:

Әгәр мин тракторчы булсам, шушы Декретны кызыл комачларга күчереп язып, аны радиатор трубаларына эләр идем.

Әгәр мин көймәче булсам, шушы Декретны ак җәймәләргә күчереп язып, аны җилкән итеп корыр идем.

Әгәр мин чапкын атлар өстендә барсам, шушы Декретны чуклы бәрхетләргә күчереп язып, аны колгаларга беркетеп, һаваларга күтәреп очар идем.

Әгәр мин бүгенге землемер булсам, шушы Декрет белән безнең кулыбызга мәңгегә бирелгән бу изге җирләрне укалы тасмалар белән каер идем.

Тагы берничә авыз сүз белән сезгә дәшәм.

Хәзер ничәмә мең тонна ашлык бирә торган бу җирләр, ничәмә мең терлекләр йөри торган бу көтүлекләр, ничәмә эскерт печәннәр чабып алына торган бу болыннар, биек-биек йортлар, хисапсыз күп балыклар үрчи торган бу елгалар, саннарына чыга алмаслык бал кортлары оча торган бу чәчәкле киң далалар өчен барган көрәш тарихларын сез беләсезме? Әгәр белмәсәгез, авылдашларыгыздан сорашыгыз, китаплардан өйрәнегез. Шушы байлыкларның чыганагы булган Җир турындагы олы Декретны сезнең укыганыгыз бармы? Әгәр булмаса, аны кат-кат укып карагыз! Сез Җир өчен барган көрәш тарихларын һәм аның турындагы бик зур ул документны укысагыз, бу сезне шушы зур байлыкларның, шушы иркен хокукларның кадерен белергә өйрәтер, аларны саклау өчен сезне һәркайчан әзер торырга чакырыр. Гасырлар буе көтеп алынган бу көннәрдә яшәүнең мәгънәсе дә шунда!..

———◆———

*Рөстәм Надиев*

# БОРЫНГЫ ШӘҺӘРНЕҢ ИКЕНЧЕ ЯШЬЛЕГЕ

Әкият булып
Күтәрелә Казан —
Кызыл Татарстан башкаласы.
*В. Маяковский.*

## 1

Борынгы архитектураның гүзәл үрнәге — Сөембикә манарасына менеп карасаң, Казан шәһәренең искиткеч матур панорамасы күз алдына килеп баса. Зур Идел һәм мул сулы Казан елгасы буйлап дистәләрчә километрларга шәһәребезнең торак йортлар кварталлары, культура-көнкүреш бипалары, яшеллеккә күмелеп утырган бакчалар, парклар, скверлар сузылган. Зур һәм данлыклы ул Казан каласы. Алты гасыр буена төзегәннәр аны. Аның бөтен тарихы халык язмышы, Ватаныбызның тарихы белән нык бәйләнгән.

Монда 1887 елда бөек Ленин үзенең революцион эшчәнлеген башлап җибәрде. С. М. Киров, Я. М. Свердлов, Э. Н. Бауман, М. Вахитов, Н. И. Лобачевский, Л. Н. Толстой, А. М. Горький, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Муса Җәлил һәм башка бик күп атаклы кешеләрнең исемнәре Казан белән бәйле.

Казан — тарих һәм архитектура истәлекләренә бик бай шәһәр. Аның үткәне киләчәге белән нык бәйләнгән. Без үткән гасырлардагы осталарның гүзәл иҗат җимешләренә хәзер дә сокланабыз. Борынгы осталарның Кремль, Сөембикә манарасы, Петропавел соборы һ. б. кебек бөтендөнья культура хәзинәсенә кереп калган әсәрләрендә халыкның милли даһилыгы гәүдәләнә. Ләкин башкалабызның бүгенгесе һәм киләчәге тагы да матуррак, тагы да гүзәлрәк.

Шәһәр — ул үзенә күрә бер организм. Ул туа, үсә, чәчәк ата, картая, ә кайчакта хәтта үлә дә. Аның авыруы да, озак һәм каты авыруы да мөмкин. Казан да революциягә кадәр шундый авыру кичерде. Аны Идел буендагы иң матур калаларның берсе итеп әверелдерү өчен Совет власте елларында республикабызның хезмәт ияләренә күп көч куярга туры килде.

Бишьеллыклар чорында һәм җидееллыкта Казанда машина төзү, химия, азык промышленносте, төзү материаллары предприятиеләре барлыкка килде. Промышленность үсеше нәтиҗәсендә шәһәрнең халкы да шактый үсте. 1926 елны Казанда 179 мең кеше булса, хәзер анда 800 меңгә якын кеше яши. Халык саны буенча Казан Россия Федерациясендә 8 нче урында, илебез буенча 15 нче урында тора. Берничә ел үтәр: башкалабыз миллион кеше яши торган шәһәр булып үсәр.



Куйбышев мәйданында салыначак «Үзәк» гостиница проекты.
*В. Запорожченко* фотосы.

Казан шәһәренең үсеше һәр яктан уйлап эшкәртелгән, фәнни нигезләнгән генеральный план нигезендә алып барыла. Бу план шәһәрләрне проектлау буенча Ленинград институтының («Ленгипрогор») талантлы иҗади коллективы тарафыннан төзелде. Шәһәрнең гомуми генеральный планы башкалабызның спецификасын, аның тарихи формалашкан үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелгән. Анда хәзерге архитектура, шулай ук төзелеш фәненең һәм техникасының казанышлары, ысуллары белән шәһәрне яңарту да күз алдында тотыла.

Шәһәребезнең төзүчеләре проектны тормышка ашыру өчен күп эш башкардылар. 1957 елда Зур Идел борынгы Кремль стеналары янына ук килеп җитте. Моның өчен уннарча километр яр буйлары ныгытылды, Иделдә иң зур механикалаштырылган елга портларыннан берсе булган Казан порты, елга вокзалының гүзәл бинасы (авторы безнең якташыбыз — ТАССРның һәм Төньяк Осетия АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Исмәгыйль Гайнетдинов) салынды.

Казан шәһәренең читләре дә танымаслык булып үзгәрде. Моннан 25—30 ел элек бушлык булган урында яңа социалистик шәһәр — башкалабызның Ленин районы үсеп чыкты. Аның күп катлы йортлары, киң һәм төз проспектлары — шәһәребезнең мактанычы.

Бик күп азатлык сөючеләрнең богау тавышларын ишеткән, Радищев, Чернышевский, декабристлар һәм патша самодержавиесенә каршы башка бик күп көрәшчеләрнең каторгага куылу юлы булган борынгы Себер тракты буйлап яңа торак корпуслары, Культура сарайлары, промышленность предприятиеләре биналары күтәрелде. Республикабыз башкаласының яңа зур районы — Совет районы барлыкка килде. Шулай ук Идел буе, Киров һәм Бауман районнарында да зур үзгәрешләр булды. Казандагы төзелеш фронтының киңлеген түбәндәге саннар бик ачык күрсәтә: соңгы 6 ел эчендә шәһәребездә торак мәйданы бер миллион 400 мең квадрат метр булган бер меңгә якын күп катлы йорт,

40 мәктәп, 70 балалар учреждениесе һәм шактый культура-көнкүреш биналары салынды.

В. И. Ульянов-Ленин исемендәге 25 мең кеше сыярлык үзәк стадион, Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры бинасы, Ирек мәйданында партиянең өлкә комитеты бинасы, Куйбышев мәйданында үзәк универмаг бинасы һ. б. лар башкалабызның горурлыгы булып торалар.

Шәһәр төзү эше кеше эшчәнлегендәге шундый өлкә ул: анда инженер-техник һәм эстетик мәсьәләләр генә хәл ителми, ә, беренче чиратта, социаль мәсьәләләр күз алдында тотыла. Бу мәсьәләнең тормышка ашырылуы кешеләрнең хезмәтендә дә, көнкүрешендә дә, ялында да шартларның яхшыртылуы нигезендә бара. Партия һәм хөкүмәтебез шәһәр төзүчеләр алдына нәкъ әнә шундый бурычларны куя. Шәһәребезнең социаль структурасы, аны архитектура ягыннан планлаштыру промышленность предприятиеләре белән торак районнарның үзара уңай урнашуын күз алдында тотарга тиеш; анда халыкка культура-көнкүреш хезмәте күрсәтү тормышның коммунистик уклады үсешенә яраклы булырга тиеш.

Хәзерге шәһәр төзү эшендәге шушы төп принциплар нигезендә соңгы елларда аерым торак массивларын проектлаштыруда шактый мөһим үзгәрешләр барлыкка килде. Зур торак массивларын планлаштыруда һәм төзүдә түбәндәгеләр күз алдында тотыла:

а) микрорайоннар салу, аларда торак йортлар һәм даими хезмәт күрсәтү учреждениеләре булдыру;


б) торак йортларны тавыштан һәм зур хәрәкәтле магистраль урамнардан изоляцияләү;

в) биналарны көн ягына уңай итеп урнаштыру;

г) микрорайоннарда бакчалар һәм спорт-физкультура мәйданчыклары булдыру;

д) коммуналь-хуҗалык биналары өчен (шәхси гаражлар, кер юу урыннары һ. б.) махсус җир бүлеп бирү һ. б. лар.

Мондый тәртиптә эш алып бару, бер яктан, төзелеш эшләрен индустрияләштерүне яхшырту мөмкинлеген бирсә, икенчедән, сыйфатны яхшырту, үзкыйммәтне киметү, эстетик яктан тулы канлы ансамбльләр тудыру өчен нигез булып тора. Мондый зур массивлар Казан шәһәрендә



Идел буе районында корыла торган яңа микрорайон менә шундый булачак.
*В. Запорожченко* фотосы.

инде шактый. (Ленин районының 42-кварталы, Совет районының 28 һәм 29 кварталлары, Идел буе районының Татарстан урамындагы микрорайон, Киров районының Болотников, Краснококшайский, Горький тракты урамнары һ. б. лар). Озакламый шәһәрнең көньяк-көнчыгышында Казанда иң зур торак массивларының берсе салыначак. Бу микрорайон республика Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсе янында 100 гектар мәйданны биләячәк. Анда уннарча күп катлы торак йортлар, мәктәпләр, балалар учреждениеләре, магазиннар, көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинатлары, стадион салыначак, бакчалар утыртылачак.

Төзүчеләр һәм архитекторлар коммунизм төзүче совет кешеләре өчен уңай, аларның барлык көнкүреш һәм культура таләпләренә җавап бирерлек шартлар тудыру өстендә киң колачлы эш алып баралар. Моның өчен алар планировканың һәм төзелешнең яңа, прогрессив методларын кулланалар.

Сугыштан соңгы елларда эре панельле йортлар салуның киң колач белән кулланыла башлавы бик әһәмиятле. Хәзер йортларның детальләре махсус предприятиеләрдә ясала, төзелеш мәйданнарында аларны җыялар гына. Үзләренең җылылык саклаулары һәм башка сыйфатлары белән мондый йортлар кирпеч йортлардан калышмыйлар, киресенчә, алар кирпеч йортларга караганда арзанракка төшәләр һәм озаккарак чыдамлы булалар. Эре панельле йортлар салу күләме елдан-ел үсә бара. 1960 елда Казанда бары 3 кенә эре панельле йорт салынган булса, 1964 елда 36 күп катлы панельле йорт салынды.

Казан шәһәренең үзәк урамнары хәзерге көндә, кызганычка каршы, бик үк әйбәт тәэсир калдырмый. Шәһәребезнең бу өлеше электәге купецлар шәһәрен хәтерләтә.

Бу урамнарны хәзерге чорга ятышлы итеп үзгәртеп кору мәсьәләсе күптәннән инде архитекторлар җәмәгатьчелеген борчып килә. Бу мәсьәлә Татарстан АССР Министрлар Советының төзелеш һәм архитектура эшләре идарәсе, Казан шәһәр советының башкарма комитеты һәм Архитекторлар союзының Татарстан бүлегенең берләштерелгән архитектура-техника советында каралды. Узган ел, ниһаять, Татарстан Министрлар Советында шәһәребезнең үзәк өлешен реконструкцияләү проекты расланды.

Хәзер Казан шәһәре — зур бер төзелеш мәйданы. Кая гына карама — зур, куәтле краннар үзләренең укларын күккә сузганнар. Кечкене бушлыклар урынында матур-матур биналар күтәрелә. Борынгы шәһәрнең чикләре көннән-көн киңәя. Казан көннән-көн яшәрә бара.

Шулай да әле аны Идел буендагы иң матур шәһәр итәр өчен күп тырышырга кирәк. Бигрәк тә электән калган тар урамнар һәм тыкрыклар эчне пошыра. Киләчәктә аларның берсе дә булмаска тиеш.

Әлбәттә, гасырлар буена салынып килгән иске йортларны сүтү, алар урынына яңаларын торгызу җиңел эш түгел. Бу катлаулы проблеманы чишү өчен безнең архитекторлар күп еллар буена зур иҗади эзләнүләр алып бардылар. Ниһаять, узган ел бу эш уңай хәл ителде. Шәһәрләрне проектлау буенча Ленинград институтының һәм «Татаргражданпроект» институтының авторлар коллективы башкалабызның үзәк өлешен һәрьяклап планлаштыру буенча хәзерге шәһәр салу һәм архитектура таләпләренә җавап бирә алырлык кызыклы проект төзеделәр.

Үзгәртеп корылачак шәһәрнең үзәк өлеше бик зур мәйданны (600 гектардан артык) били: Кремль — тимер юл вокзалы — елга порты — Татарстан, Куйбышев урамнары һәм Ирек мәйданы.

Дөрес, әлегә моны макетта һәм ватманда гына күз алдына китерә алабыз.

Менә безнең алда Кремль тирәсе районы. Кайсы яктан гына карасаң да, борынгы архитектураның гүзәл үрнәге булган Кремль корылмалары иң беренче булып күзгә ташлана. Казанны Кремльдән башка күз

алдына да китерү кыен. Проект төзүчеләр шәһәрнең үзәк мәйданын Кремль янында планлаштырып бик дөрес эшләгәннәр. Бу мәйдан хәзерге Беренче май мәйданына ялганып, кайбер архитектура алымнары ярдәмендә Бауман урамына кадәр дәвам итәчәк. Матур итеп бизәлгән бу зур мәйдан Кремль ансамблен тагы да матуррак итеп күрсәтәчәк. Мәйданнан Идел ярына кадәр 90 метр киңлектәге аллея-проспект сузылачак. Бу чын-чынлап башкалабызның парад проспекты булачак. Яшеллеккә күмелгән, фонтан каскадлары белән бизәлгән, су бассейннары буйлап сузылган бу олы проспект шәһәребез архитектура ансамбленең иң гүзәл элементларыннан берсе булачак.

Хыялыбызда гына булса да бу эспаланда [1] буйлап сәяхәт итик. Анын сул ягында, Бауман урамында — КПСС өлкә комитетының политик мәгариф йорты бинасы. Ул хәзерге ярым җимерек чиркәү һәм әллә кайчангы ямьсез йортлар урынына салынган. Ә аннан соң электәге искереп беткән бер-ике катлы йортлар урынында монументаль җәмәгать һәм культура биналары тезелеп киткән. Киров урамы почмагыннан олы проспект буйлап Хезмәт сарае сузылган. Бу бина — шәһәрдәге иң зур йортларның берсе, аның тамаша залына гына да 800 кеше сыя. Ә проспектның уң ягында, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге үзәк стадион белән рәттән, өч мең тамашачы сыйдырышлы җәйге ябык каток һәм башка спорт корылмалары комплексы тезелгән. Пыяладан һәм тимер-бетоннан коелган уналты метр биеклегендәге гаять зур бу каток бинасы — Кремль тирәсе районын матурлап торган биналарның берсе. Катокның ясалма боз өсте мәйданы 1800 квадрат метр. Монда тамашачылар боз өсте балеты, фигуралы шуу, хоккей ярышларын гына түгел, зур концертлар, спектакльләр һәм цирк тамашалары да карый алалар. Чөнки, кирәк икән, боз өсте мәйданын өстәмә 2000 тамашачы сыешлы тамаша залына әверелдерү — бик җиңел эш.

Стадионның төньяк-көнчыгыш ягында 2000 урынлы цирк бинасы калкып тора. Бу бинада хәзерге заман архитектура сәнгатенең һәм төзелеш техникасының яңа казанышлары гәүдәләнгән.

Олы проспект тирәсендә, болардан тыш, яңа театр, шәһәр китапханәсе, гостиница, зур кафе-ресторан һ. б. биналар да күз явын алып тора.

Хәзерге заман архитектура сәнгате һәм төзелеш техникасы ысуллары белән салынган бу биналар һәм Кремльнең, Спасс манарасының борынгы үзенчәлекле архитектурасы үзара аралашуы нәтиҗәсендә менә дигән ансамбль барлыкка килгән. Бу күренеш ирексездән соклану, горурлану хисе тудыра.

Кремльнең үз ансамбле хәзер заповедникка — тарихи-революцион зонага әверелдерелгән. Электәге төрле учреждениеләр аннан алынган. Ул хәзер, кайбер реконструкциядән соң, музей-күргәзмә бинасы ролен үти. Анда зур күргәзмә заллары булган тарих институтлары урнашкан.

Казан елгасы ярыннан Куйбышев мәйданына кадәр сузылган Бауман урамы да бик нык үзгәргән. Электәге буталчык, берсе-берсенә терәп салынган иске йортлар хәзер инде борынгы шәһәр күренешен хәтерләтмиләр. Беренче бишьеллыклар чорында салынган Матбугат йорты, «Родина» кино-театры, «Балалар дөньясы» магазины тагын да матурайган, Зур драма театры стеналары төсле тимер-бетон плиталар белән тышланган. Яңа кафелар, төрле магазиннар һ. б. биналар урамның йөзен бик нык үзгәрткәннәр. Ләкин киңлеге бары 20 метр гына булган бу тар урамны тамырдан үзгәртеп кору өчен уннарча еллар вакыт кирәк әле. Дөрес, хәзер үк инде бу урамнан транспорт йөрми, транспорт юлы күршедәге Профсоюз, Островский, Университет, Чернышевский урамнарына күчерелгән. Урам уртасыннан өч метр киңлектәге яшел

[1] Эспаланда — уртасыннан аллея сузылган киң урам.

тасма сузылган. Зур җәмәгать бчналары (Банк, «Балалар дөньясы» универмагы) янында ачык яшел мәйданчыклар барлыкка килгән. Чәчәкләргә фонтаннардан су бөркелә, тирә-юньдәге эскәмияләрдә кешеләр ял итеп утыралар. Бауман урамы хәзер җәяү йөри торган аллеяга әверелгән. Электәге Бауман һәм Университет урамнары чатындагы ипи, хуҗалык товарлары кибетләре урынында тирәсендә яшел декоратив үләннәр үсеп утырган су бассейны җәелеп ята.

Бауман урамы — элек-электән шәһәрнең сәүдә үзәге, кибетләр, сәүдә учреждениеләре урамы. Шуңа күрә бу урам төрле төстәге реклама утлары белән матур итеп бизәлгән. Магазиннарның зур пыяла витриналарына һәртөрле көнкүреш товарлары куелган...

Хәзер югарыга — Ленин урамына күтәрелик. Бу — шәһәребезнең иң төз, иң матур урамнарыннан берсе. Архитектура-тарих истәлеге — В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты бинасы, аның факультетлары урнашкан биналар, СССР Фәннәр Академиясенең Казандагы институтлары бинасы, В. И. Ленин исемендәге республика Үзәк китапханәсе бинасы — һ. б. лар бу урамның гына түгел, бөтен Казан шәһәребезнең горурлыгы булып торалар. Ленин урамы — башкалабызның фәнни үзәкләреннән берсе.

Менә Астрономический урамы. Бу урам да җәяү йөри торган олы урам-аллея булып әверелгән. Ул Лобачевский урамының дәвамы булып сузыла.

Куйбышев мәйданы. Ул һәрвакыт халык белән тулы. Моннан бернича дистә ел элек бу урын шәһәрнең күңелсез, пычрак урыннарыннан берсе иде бит. Аңа аннан-моннан гына кытыршы, тигезле-тигезсез таш җәелгән иде. Аны «Балык базары» дип йөртәләр иде. Моны инде картлар гына хәтерли торганнардыр.

Ә хәзер... Хәзер уң якта биш катлы зур торак йорт. Аның аскы катында кибетләр, «Чайка» исемле автомат кафе. Каршыда пыяладан һәм бетоннан салынган зур, якты универмаг бинасы. Аның белән рәттән, электәге мәйданның ямен җибәреп торган ике катлы иске йортлар урынында, башкалабызның 12 катлы Үзәк гостиница бинасы болытларга тия язып тора. Талантлы яшь архитекторлар Мөнир Агишев белән Мөнир Яваев проекты нигезендә салынган бу монументаль бина мәйданны тагы да матурлаган, ямьләндергән.

Электәге «Вузовец» кино-театры урынында тагы бер күп катлы бина мәйдан ансамбленә ямь өсти. Ә революциягә кадәрге «Музуров номерлары» дип йөртелгән йортның фасадлары бөтенләй үзгәргән. Архитекторлар аңа яңа, хәзерге заман төсе биргәннәр.

Мәйданның дәвамы булып Куйбышев урамы сузыла. Бу урам элек башлыча төрле характерлы бер-ике катлы йортлардан гыйбарәт иде, аның архитектура йөзе бөтенләй юк иде. Шәһәр кешеләре сизми дә калдылар: бу урам тамырдан үзгәрде, киңәйде; анда архитектура сәнгатенең соңгы казанышлары рухында өр-яңа биналар, сул яктагы ярым җимерек иске йортлар урынында яшеллеккә күмелеп утырган бакчада җиңел, хәзерге заман корылмалары — кафе, көнкүреш хезмәте күрсәтү павильоннары барлыкка килде. Бу яшел зона, университет мәйданы белән тоташып, шәһәр үзәгенең иң матур урынына әверелгән. Урамның уң ягында — күп катлы торак йортлары.

Ирек мәйданы күптән инде башкалабызның иң матур урыннарыннан берсе булып әверелде, һәм анда В. И. Ленин монументы, Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры бинасы, КПССның Татарстан өлкә комитеты бинасы, Офицерлар йорты, Казан авиация институты корпусы һ. б. биналар төгәл архитектура ансамблен барлыкка китерәләр. В. И. Ленин монументы яныннан башланып киткән сквер мәйданга ямь биреп тора.

Боларга күптән түгел Офицерлар йорты белән рәттән салынган консерваториянең концерт залы өстәлде. Бу бина да шулай ук хәзерге архитектура сәнгате стилендә пыяла һәм бетоннан салынды.

Ирек мәйданы аша үтә торган Зур Кызыл урам буйлап Кремльнең төньяк-көнчыгыш ягына таба атлыйк. Элек авиация институты һәм тәмәке фабрикасы булган урында хәзер — фәнни учреждениеләр, профсоюз клублары, китапханәләр һәм башка җәмәгать биналары... Красин урамыннан көнчыгышка таба, элеккеге агач йортлар урынында, яңа торак микрорайон башланып китә. Бу микрорайондагы йортлар биш, тугыз һәм унике катлылар. Биек йортлардан гыйбарәт булган бу микрорайон, Казан елгасы аръягыннан караганда, шәһәрнең үзәк өлешендә калку силуэт булып күренеп тора. Шулай ук биредән Казан елгасының аръягы да күренеп тора: анда зур төзелеш һаман да туктаусыз дәвам итә.

Сәяхәтебезне дәвам итик. Хәзер шәһәрнең үзәген калдырып, Яңа бистә ягына, Иделгә таба юнәлик. Казан кешеләренә бу тирәләрдә элек бушлык булганы яхшы билгеле. 1962 елда Идел ярында елга вокзалының яңа бинасы калкып чыкты. Бу вокзал чын-чынлап Казан шәһәренең горурлыгы. Ул композициясе белән генә түгел, үзенең заманча эшләнеше, милли формасы һәм архитектура элементлары белән дә игътибарны җәлеп итә.

Вокзалның әйләнә-тирәсендә дә шәһәр танымаслык булып үзгәргән. Татарстан һәм Кәрим Тинчурин урамнарындагы биек йортлар урынында әле кайчан гына пычрак күлләрдә бакалар кычкырыша иде. Аларның хәзер эзе дә юк. Бу урамнарда күз алдында уннарча күп катлы йортлар үсеп чыкты. Татарстан урамындагы элеккеге кыйшаеп беткән агач йортлар сүтелеп, алар урынына тугызар катлы йортлар салынды. Татарстан урамы Иделгә чыга торган олы магистраль урамга әверелде. Ике микрорайоннан торган торак массив 31 гектар мәйданны били. Биредә мәктәп, балалар учреждениеләре, кино-театр, стадион, гостиница, көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинаты салынды.

Урамның Кабан күле белән тоташкан урынында да үзгәрешләр зур. Монда тагын 9—12 катлы өч зур бина калкып чыкты. Алар органик рәвештә шәһәр ансамблен тутырып торалар һәм саф зәңгәр күк фонында заманыбызның бөеклеген гәүдәләндерәләр...

...Әйе, без бу кыска сәяхәтне хыялыбызда гына ясадык һәм югарыда әйтелгәннәрнең күбесе әлегә проектта гына. Ләкин бу проект һичшиксез якын арада тормышка ашырылыр. Моны тормышка ашыру эшләре көннән-көн киңрәк канат җәя. Безнең илебездә хыял нинди генә катлаулы булмасын, аның тормышка ашырылмый калганы юк. Тагын берничә ел үтәр, шәһәребезне нәкъ шундый итеп, хәтта матуррак, гүзәлрәк итеп күрербез. Чөнки безнең заманда чынбарлык гадәттә күзаллауга караганда киңрәк тә, гүзәлрәк тә була. Совет Татарстанының башкаласы — борынгы Казан шәһәре көннән-көн үзгәрә, яшәрә.

*Касыйм Гыйрфанов*

# СӘГЫЙТЬ РӘМИЕВ ТУРЫНДА КАЙБЕР ИСТӘЛЕКЛӘР

**Сәгыйть Рәмиев!.. Бу исемне ишетү белән күз алдыма нык гәүдәле, кара бөдрә чәчле, әчкерсез дуслык очкыннары чәчеп карый торган зур кара күзле, мөлаем йөзле кеше килеп баскандай була. Татар поэзиясе күгендә ялкынлы дәрт, гаҗәеп зур поэтик көч белән авылның айлы-йолдызлы, энҗеле-бриллиантлы, ләкин «тын һәм буш» табигатен җырлаган, югары пафослы, нечкә музыкаль аһәңле, образларга бик бай булган күп шигъри әсәрләр иҗат иткән хөрмәтле шагыйрь бу!..**

## СӘГЫЙТЬ РӘМИЕВ БЕЛӘН БЕРЕНЧЕ ТАНЫШУ

**Мин Сәгыйть Рәмиевнең «Таң вакыты» шигыре матбугатка чыккан көннәрдән башлап, шул чор яшьләренең күпчелеге кебек, аның лирик шигырьләре белән бик нык мавыгып, аларны укып, ятлап үскән яшьләрнең берсе идем. Ә Сәгыйтьнең үзе белән күрешеп танышуым тик 1914 елның җәендә генә булды. Мин аның белән Уфада, «Авыл көнкүреше» журналы редакциясендә күреп сөйләштем. Рәмиев мине бик ачык йөз белән мөлаем елмаеп каршы алды. Урыныннан торып күреште дә, миңа урын күрсәтеп:**

**— Хуш, сез кайдан? Ни йомыш? — дип миңа сораулар биреп, тагын урынына утырды.**

**Мин исем-фамилиямне әйтеп, курсларда укучы икәнемне белдереп, йомышны сөйләп бирдем. Ул, минем сүзләремне бөтенләй тыңламагансыман, һәм үз-үзе белән сөйләшкәндәй итеп, «Гыйрфани... Гыйрфани...» дип торды да:**

**— Фамилиягез миңа бик таныш кебек күренә, сезнең шигырьләр язганыгыз бармы? — диде.**

**— Бар. Сез «Идел»дә эшләгән вакытта бер-ике шигыремне газетагызда басып чыгарган идегез, — дидем. Ул тагын да яктырыбрак киткәндәй булды:**

**— Шул шул!.. Таныш фамилия... — диде. Мин:**

**— Ләкин сез минем шигыремнең берсендәге:**

**«Син генәсең минем аллам...**
**Син генә, тик син генә!.. —**

**дигән юллардагы «аллам» сүзен «вөҗүдем» сүзе белән алмаштырып:**

**«Син генәсең бар вөҗүдем,**
**Син генә, тик син генә!..» —**

**рәвешендә биргән идегез, — дидем. Ул:**

**— Әллә охшамадымы сезгә? — диде.**

**— Әйе, охшап ук бетмәде шул. Сез бит, үзегез «Кайвакытта уйлыймын мин...» дигән шигырегездә: «Син генә рух биргән аллам...» дип җырлыйсыз, — дигәч, бераз карап, уйланып торды да:**

**— Әйе, бу дөрес, Касыйм әфәнде. 1908 еллар иде. Заманнар алышына, карашлар да үзгәрә. Ләкин мөхәррире чалмалы мулла булган бер газетада андый карашларны**

үткәрмиләр иде шул, — дип, уфтануга охшагандай итеп, җавап бирде. Аннан соң, хәзер язу-язмавымны сорашып: — Сезнең каләмегез шома гына иде, язарга, эшләргә кирәк, — дигән киңәшне бирде дә, ишеккә якын гына җирдә утырган бер егетне күрсәтеп: — Йомышыгызны әнә шул егет башкарыр,— диде. Өстәлендә тузылып яткан язмаларның күплеге аның эше тыгыз икәнлеген күрсәтеп тора иде.

Бик эредер, башкаларга бик өстән карый торгандыр дип уйлаган шагыйрьнең шундый ачык күңелле, түбәнчелекле һәм башкаларга бик илтифат итүчән, яхшы киңәшләр бирүчән бер кеше булып чыгуы миндә бик тирән тәэсир калдырды һәм күңелемдә аңарга карата мәхәббәт тудырды.

Моннан соңгы вакыйгалар: сугыш, армия, Февраль, Октябрь революцияләре, гражданнар сугышы һәм башкалар күпләрне өермә кебек бөтереп алып, үзенең утлыдавыллы казанында кайнатты. Мин моннан соң Сәгыйть Рәмиев белән тик 1920 елның җәендә генә яңадан очраша алдым. Бу очрашу Чиләбе шәһәрендә булып, без инде аның белән күптәнге танышлар, эшнәләр булып күрештек. Шул вакыттан алып, гомеренең иң ахыргы көненә хәтле мин шагыйрь белән якын бәйләнеш тотучыларның берсе булып калдым. Баштарак Чиләбедә, аннан соң Уфада аның шигырьләре, прозаик әсәрләре һәм күп санлы тәрҗемәләре белән; шәхси омтылышлары, интереслары белән; һәм, ниһаять, аның гаять кешелекле һәм кечелекле табигате-характеры белән якыннан таныштым. Ул, Алексей Максимович Горький кебек үк, кешегә, аеруча хезмәт иясе кешесенә, күңелендә чиксез зур ихтирам саклый һәм, гомумән, кеше рухының изгелегенә тирән ышана иде.

Сәгыйть Рәмиев әдәбият-сәнгатьнең төп бурычы турындагы М. Горький тарафыннан бирелгән билгеләмәләрне тулысы белән кабул итә. Горький әсәрләрен кабат-кабат укый; аның «Изергил карчык», «Кеше», «Давыл хәбәрчесе» һ. б. кебек кечерәк күләмле әсәрләрен яттан белә иде. Ул Толстой, Пушкин, Лермонтов, Кольцов, Некрасов, Короленко һәм башкалардан тыш, Шекспир, Гете, Шиллер, Гейне, Гюго, Джованьоли, Верхарн һәм башкаларның әсәрләрен яратып укый; көнчыгыш классикларыннан Шәйхе Сәгъдинең «Гөлстан»ын, Хафиз Ширази газәлләрен, Гомәр Хәйям шигырьләрен бик җентекләп өйрәнә, тикшерә иде.

Сәгыйть Рәмиев турында сөйләгәндә кайберәүләр, ул Октябрьдан соң эшләмәде, яки бик аз эшләде, диләр. Мондый сүзләр ялгыш. Ул Октябрь революциясе чорында бик борчулы бер дәверне үткәрә. Ләкин бу дәвернең бөтен кыенлыкларына, бөтен кимсетүләренә дә карамастан, ул шушы мәсьәләгә ачыклык кертү теләге белән «Мәсихы хөррият» яки «Хәсет корбаны» дигән әсәрен яза. Хаксыз ташланган бу пычракны фаш итү уңае белән, каты авыру булуына карамастан, С. Рәмиев бик күп эшләргә мәҗбүр була: «Мәсихы хөррият»не язу белән беррәттән «Спартак»ны, «Жрец Тарквини»ны тәрҗемә итә. «Саботаж» исемле хикәя өстендә эшли, «Кызыл Урал» газетасына языша, Чиләбе кызлар техникумында әдәбият дәресләре алып бара, үзлегеннән француз телен өйрәнә башлый. Татар теленә кергән гарәп, рус, төрек, фарсы сүзләренең кыскача сүзлеген төзи, «Чиләбе губерна азчылык милләтләр» комиссариатында штатлы эшче булып та хезмәт итә. Шуның нәтиҗәсендә, гадәттә «кырык яшемә хәтле бер генә төрле авыру белән дә чирләгәнемне белмим» дип сөйли торган шагыйрь үпкә чире белән авырый башлый.

Сәгыйть Рәмиев үзе белән мөнәсәбәткә кергән кешеләргә бик тиз ышанучан иде. Моның аңа күңелсез хәлләр китергән чаклары да була иде. Шулардан берсе итеп, аның кулъязмаларын укырга дип сораган кешеләргә ышанып, биреп җибәрү гадәтен әйтергә кирәк. Кайчакта бу ышаныч зур борчуларга сәбәпче була. Мәсәлән, «Мәсихы хөррият»нең II нче кисәге, «Кабакта мәхәббәт» әсәре һәм «Интернационал» тәрҗемәсе белән булган хәлләр бик гыйбрәтле.

С. Рәмиевнең үзе сөйләве һәм Г. Ибраһимов истәлеге буенча, аның 2 бүлектән торган «Мәсихы хөррият»е язылып беткән булган. Бу әсәр «охранка» мәсьәләсен фаш итүгә багышланган булып, I нче бүлекнең сюжет үсешендә гомуми ситуация: тентүләр, кулга алулар... Икенче бүлектә охранкада агент булып эшләгән кайбер кешеләрнең эшләре турында сөйләнә. Чынлыкта да нәкъ менә шундый кешеләрнең берсе [1] шагыйрь белән мөгамәләгә кереп, «Мәсихы хөррият»нең II нче дәфтәрен укырга дип сорап ала

[1] Бу кеше Гыйлемдар Баембитов була.

да яңадан кайтарып бирми (соңыннан аны яндырганлыгы билгеле була). Чиләбегә килгәч С. Рәмиев бу икенче бүлекне яңадан язарга уйлый. Ләкин каты авыру булу сәбәплеме, әллә эш күплектәнме, ул аны язып бетерә алмый.

1920 елда Чиләбе губерна мәгариф бүлегенә дәреслекләр һәм китапханәләргә әдәбият алу өчен Мәскәүгә һәм Казанга барачагымны белгәч, Сәгыйть Рәмиев Казанда Галимҗан Ибраһимовны күреп, «Спартак»ны[1] бастырып чыгару турында сөйләшүемне үтенгән иде. Мәскәүдән Казанга килгәч, мин Галимҗан Ибраһимовны күрдем. Сәгыйть Рәмиевнең үтенечен сөйләп, бу турыда аның фикерен сорагач, ул: «Спартак»ны бастыра алмыйбыз, башка кешенең тәрҗемәсе басылып бетеп бара. Ул безгә «Мәсихы хөррият»ен бирсен, аны чыгарабыз. Ул аның югалган өлешен яңадан эшләргә булган иде. Эшләп бетергәндер инде», — диде. Г. Ибраһимовның бу сүзләре «Мәсихы хөррият» әсәре белән таныш булуын һәм аның белән бик кызыксынганлыгы турында сөйли.

Бу вакытта «Безнең көннәр» романының беренче басмасы басылып беткән булса да, әле ул төпләнеп, китап хәленә китерелмәгән иде. Мин Галимҗан Ибраһимов өстәленнән яңа гына типографиядән чыккан бер нөсхәсен алып, аны караштыра башладым. Галимҗан минем кызыксынуымны күреп: «Ә!.. Ул басылып бетте. Ләкин төпләнмәгән әле», — диде. Минем күзләр ни теләгәнемне белдерткәндер булса кирәк, ул минем кайчан китәчәгемне сорап алды да:

— Бусын үзем өчен кирәк булгач алган идем, сызгаланган. Типографиядән алып, мин сезгә бер нөсхәсен бирермен. Иртәгә кереп алырсыз! — диде.

Икенче көнне эшләремне бетереп, хушлашып чыгыйм дип, аңа кергәндә, ул «Безнең көннәр»нең бер нөсхәсен китап хәленә китереп, өстенә «Автордан Касыйм Гыйрфанов иптәшкә истәлек өчен» дип язып, имзасын куеп, әзерләп куйган иде инде. Бөек әдибебезнең шундый кыйммәтле истәлеге өчен мин аңа зур рәхмәтләр әйттем. Саубуллашканда ул тагы бер мәртәбә:

— Сәгыйтькә миннән сәлам әйт! «Спартак»ның башка берәү тарафыннан ясалган тәрҗемәсе басылып ята. Ул безгә «Мәсихы хөррият»ен бирсен. Аны чыгарырбыз!.. — дип, кичәге сүзен тагын бер мәртәбә кабатлап, озатып калды.

Чиләбегә кайткач, мин Сәгыйть Рәмиевкә Галимҗан Ибраһимовның сәламен ирештердем, аның сүзләрен сөйләм бирдем. Ул бик әсәрләнде һәм тирән уфтангандай итеп: «Мәсихы хөррият»нең икенче бүлеген яңадан эшләп бетерә алмадым шул...» — диде.

Сәгыйть Рәмиев үлгәннән соң, 1929 елда, без язучы Имай Насыйри белән әдипнең бөтен әсәрләрен өч томга җыеп Татарстан нәшриятына тапшырган идек. Бу әсәрләрнең I нче томына аның шигырьләре, «Мәсихы хөррият»нең I нче бүлеге; II нче томына нәсерләре, III нче томына тәрҗемәләре кертелгән иде. Әсәрләрнең беренче томына шагыйрьнең биографиясе һәм минем тарафтан язылган «Сәгыйть Рәмиев иҗаты турында кайбер фикерләр» дигән кереш сүз бирелгән иде. Бу әсәрләрне бастырып чыгару турында рөхсәт тә алынган иде. Ләкин нинди сәбәпләр аркасындадыр ул хезмәт басылмый калды һәм югалды.

Сәгыйть Рәмиевнең Чиләбегә эшкә килгән чоры гражданнар сугышының иң кызган вакытына туры килә. Бу чорда революциянең эчке дошманнары Советлар властена каршы саботаж оештыралар иде. Саботажлар бөтен Россия күләмендә җәелеп, аның башында «Викжел»[2] дигән оешма тора иде.

В. И. Ленин 1917 елның 7 (20) декабрендә ук Ф. Э. Дзержинскийга язган «Записка»сында бу саботажның бик куркынычлы булуын әйткән иде.

Нәкъ шул чорларда Чиләбе «Балалар йортын» утын белән тәэмин итү С. Рәмиев өстенә төште. Ул утын алу өчен урман эшен башкаручы оешмаларга барып йөреп, мең төрле җәфалар, кимсетүләр күрә; балаларның салкын өйдә туңып, елашып утыруларын күреп, вөҗдан газаплары кичерә иде.

Менә шушы мәгънәсезгә йөрүләрне, балаларның суыктан интегүләрен тасвирлап, Сәгыйть Рәмиев «Саботаж» дигән хикәя яза һәм саботажникларны ачы тәнкыйть белән

---

[1] «Спартак» — тарихи роман. Италия язучысы Рафаэлло Джованьоли әсәре. Сәгыйть Рәмиев тәрҗемәсе. 1923 елда Уфада чыгарыла башлаган «Яңа юл» журналының 1—6 саннарында берничә бүлеге чыгарылса да, журналның тукталуы сәбәпле калган бүлекләре чыгарылмыйча бүленеп калды.

[2] Викжел — «Всероссийский Исполнительный Комитет железнодорожников» дигән сүзләрдән кыскартылган.

фаш итә. Хикәянең берничә бүлеге Чиләбенең «Кызыл Урал» газетасында басылса да, әсәр бөтенләе белән басылып бетмичә калды.

1921 ел ачлыгын шул чор кешеләреннән кемнәр генә хәтерләми! Ачлык аркасында акылыннан язган ата-аналарның үз баласын суеп ашау кебек тетрәткеч трагедияләрне тасвирлаган «Ачлык тырнагында» (Мәҗит Гафури), «Адәмнәр» (Галимҗан Ибраһимов) һәм башка әсәрләрне укып кемнәр генә куркыныч тойгылар дулкынында чайкалмады?!.

Менә шундый авыр елның суык кыш айларында Чиләбедә, ачлыктан үлеп, карга күмелеп калган үлекләрне җыйнау өчен отрядлар оештырылды. Без Сәгыйть Рәмиев белән икебез бер отрядта идек. Һәр көн иртә үк торып, урамга чыгабыз. Кар астыннан күренеп яткан мәетләрне җыйнап, чаналарга салып, үлекләр сараена (баракка) илтеп тапшыра идек. Кайбер карлы-буранлы көннәрдә егермешәр, хәтта утызар үлек илтеп тапшырган чаклар була иде. Бу гражданлык бурычын үтәү ягыннан хөрмәтле эш булса да, мораль яктан чиксез кыен тоела иде.

Нәкъ менә шушы авыр тойгылар астында Сәгыйть үзенең «Иблис тә дердерәде» дигән, көләме ягыннан кечерәк кенә булса да, әһәмияте гаять зур булган атеистик-фәлсәфи әсәрен язды. Ул «Кызыл Урал» газетасында басылып та чыкты.

Монда шагыйрь 1907—1908 елларда «Таң вакыты» шигырендә бирелгән «алладан өмет итеп яту»ның трагик нәтиҗәләргә китерүе мөмкинлеген 1921 елдагы ачлык уңае белән тагын бер тапкыр атеистик планда искә алып китә.

Бу урында тагы бер кызыклы һәм Сәгыйть Рәмиев өчен бик характерлы булган бер вакыйганы әйтәсе килә. 1922 елда Чиләбе татар буржуазиясе, шәһәрнең яңа мулласы — элекке казый Салихҗан Урманов инициативасы белән, борынгы Идел буе болгарларының ислам динен кабул итүләренә мең ел тулу уңае белән бәйрәм үткәрергә уйлап, шәһәр байларын, җәмәгать хезмәтчеләрен җыеп, шул эшне оештыру турында киңәш җыелышы үткәрде. Күп сүзләр булды: исламны мактадылар, мактандылар. Шушы мәҗлескә чакырылган Сәгыйть Рәмиев сүз алып:

«Җәмәгать! Монда бик күп сүзләр булды. Ләкин боларның күбесе буш сүз, хакыйкатькә каршы күз йомып сөйләнгән сүзләр. Болгарларның ислам динен кабул итү көнен бәйрәм көне итеп түгел, бәлки матәм (траур) көне итеп үткәрергә кирәк. Чөнки ислам дине Идел буе татарларын бөтен мәдәнияттән аерды; аларның табигатен коллыкка, дини идеологиягә бәйләп куеп, аларны түбәнәйтте. Артта калуларына сәбәп булды. Аларны башка халыкларга каршы куеп, алар арасында дошманлык уты кабызды. Минем этием мулла иде. Нинди дә булса берәр җинаять эшләсә, тәүбә итә дә, гөнаһым бетте инде, дип ышана һәм вөҗданы һич тә икеләнмәстән, яңадан җинаять эшләргә керешә иде. Чөнки ул тәүбә итсә, барысы да кичерелә дип ышана иде. Ул бөтен гомере буенча хаҗга барырга уйлап йөрде. Бәхеткә каршы, ул хаҗга бара алмыйча үлеп китте...» — дигән сүзләр белән чыгыш ясаган иде. Билгеле, бу сүзләр өчен аны тиргәделәр, сүктеләр. Аның бу чыгышы татар байлары өчен көтелмәгән хәл булды. Алар бик ачуландылар. Шулай итеп, ул бу чыгышы белән атеистик караштa торганлыгы турында дошманнары алдында кыю рәвештә үзенең фикерен ишеттерә алды.

С. Рәмиевне искә алганда, аның 1921 елның көзендә Чиләбедә үткәрелгән «Шәрык кичәсе»ндә ясаган чыгышы да хәтергә килә. Ул елны ил өстендә мәрхәмәтсез ачлык хөкем сөрә иде. Ачлык бәласен аз гына булса да җиңеләйтү өчен һәр җирдә диярлек ачларга ярдәм комитетлары оештырыла, зуррак шәһәрләрдә, ачларга ярдәм фонды файдасына, «Шәрык кичәләре», әдәби ахшамнар үткәрелә иде.

Зур шәһәрләрдән үрнәк алып, Чиләбе җәмәгатьчелеге дә ачларга ярдәм фонды файдасына «Шәрык кичәсе» үткәрергә булды. Моны оештыруда ирләрдән: Сәгыйть Рәмиев, Исмәгыйль Сабитов, Салихҗан Урманов, Барый Габбасов, Әхмәтша Җәләлетдинов, Ризван Ибраһимов һәм башкалар, ә хатын-кызлардан: Фәрханә Ибраһимова, Хәдичә Хөсәенова, Зәйнәп Тумашева, Галия Мусина, Мәрьям һәм Хәдичә Исхаковалар һәм башка укытучы-укучы кызлар һәм бик күп кенә хатыннар катнашты. Бай гаиләләрнең хатыннары буфетлар оештырдылар. Китаплар, открыткалар, чәчәкләр сату өчен киосклар ачылды. Халык йортының зур залы, сәхнәсе һәр төрле келәмнәр, паласлар, чаршаулар белән бизәлде. Кичәдә музыка номерлары, җырлар, декламацияләр, танцылар үткәрү планлаштырылды. Ярдәм җыю һәм җыелган ярдәм фонды өчен җаваплы

бер комиссия дә төзелде. Кичәдә катнашучылар фонд хисабына үзләренең шәхси әйберләрен бүләк иттеләр, акчалар бирделәр. Без сәгатьләребезне бүләк иттек.

Шуннан соң кичәнең әдәби бүлеге ачылды. Бер пәрдәлек инсценировка куелганнан соң, музыка, җыр, декламация, биюләр башланды.

Декламация бүлегендә мин дә катнашырга тиеш идем. Чөнки шул кичәдә укыр өчен ачлык турында үземчә бик шәп бер шигырь язган идем. Ләкин шул көннәрдә генә салкын тидердем. Температурам күтәрелде, баш әйләнә, укырга түгел, сөйләшергә дә тавыш юк.

— Сәгыйть агай, мин теге шигырьне укый алмам, ахры,— дидем. Ул:

— Ярый, алайса мин укырмын. Син борчылма! — диде. Программа буенча укырга нәүбәт миңа җиткәч, конферансье минем исемне әйтеп, сәхнәдән кычкыргач, Сәгыйть Рәмиев чыгып, халыкка мәсьәләне төшендерде. Миңа караганда Сәгыйть Рәмиевнең яхшырак укыячагын белеп булса кирәк, халык аны шаулатып кул чабып алкышлады...

Сәгыйть Рәмиев иҗаты турында сөйләгәндә аның «Кабакта мәхәббәт» дигән әсәренә тукталмый китү хаксызлык булыр иде. Аның бу әсәре сәхнә өчен эшләнгән. Әсәр 1909—1910 елларда, Сәгыйтьнең Астраханьда эшләгән вакытында ук язылган булса да, ул чорда аны бастырып чыгаручы табылмаган. Чөнки ул бу әсәрен реакция чорының иң караңгы, иң авыр еллары тормышын реалистик алымнар белән яктыртуга багышлаган.

Шагыйрь ул чорның кара, пычрак тормышын кабак тормышы итеп сурәтли. Драмада төрле милләт, төрле сыйныф вәкилләре катнаша. Мәсәлән, Мәскәү фабриканты Петр — бозык, ерткыч капиталист. Кабак тотучы Фекла карчык — акчага алла итеп карауччы мещанка; кабакта шаулашып эчеп утыручы динче Хәйретдин, Гайнетдин, алар тирәсенә сырышып утырган төрле кыяфәттәге татар байлары малайлары... Капиталист Петр тарафыннан әйтелгән: «Акча белән аракы берләшкән җирдә, аларга каршы тора алган көч әлегә хәтле дөньяда күренгәне юк!..» — дигән караш алар өчен иң «изге» девиз булып тора.

Менә шушы кабак тормышы эчендә журналист-шагыйрь Хәмит белән эшче кыз Татук (Татьяна) бер-берсен саф мәхәббәт белән сөюче пакь күңелле, төзек фикерле шәхесләр итеп бирелгәннәр. Көрәш объекты — Татук. Бу көрәштә фабрикант Петр белән Фекла карчык Татукны Хәмиттән аерып алып, аны үзләренең корбаны итү өчен берләшәләр. Акчага сатылган Фекла карчык төрле алдаулар, куркытулар белән үз кызы Татьянаны бернечә сәгатькә капиталистка сата.

Әсәрнең чишелү моменты болай күрсәтелә: Татукның трагик хәлен күз алдына китергән Хәмит, саф мәхәббәтендә алданганын күреп, зал уртасына чыгып, үзен револьвердан атып үтерә. Бу тавышны ишеткән Татук: «Ах! Нишләдем мин?!» — дип бүлмәдән атылып чыга да Хәмитнең үле гәүдәсе өстенә барып егыла. Вакытлы рәвештә капитал үзенең максатына ирешсә дә, мәхәббәт соңгы моментта үз вәкиле ягында кала. Димәк, мәхәббәт өчен, дуслык, туганлык өчен көрәш киләчәктә дәвам итәргә тиеш булып чыга!

1929 елда С. Рәмиев әсәрләрен басарга әзерләгәндә «Кабакта мәхәббәт» табылмаган иде. Шунлыктан ул вакытта бу драма Сәгыйть әсәрләре составына кертелмәде. Тик ике ел чамасы вакыт үткәннән соң гына «Кабакта мәхәббәт»не Шәриф Сөнчәләй (Сәгыйть Сөнчәләйнең бертуган кардәше) Мәскәүдән Уфага, язучы Имай Насыйри адресына җибәргән һәм аны Сәгыйть Сөнчәләй язмалары арасыннан тапканлыгын хәбәр иткән иде.

«Кабакта мәхәббәт»нең бу нөсхәсе 70 битләр чамасындагы 20 $\times$ 28 сантиметр форматтагы кәгазьгә гарәп шрифты белән язылган иде.

## СӘГЫЙТЬ РӘМИЕВ АСТРАХАНЬДА

Сәгыйть Рәмиев Астраханьга 1910 елда килә һәм «Идел» газетасында эшли башлый. Ул, формаль яктан редакциянең җаваплы секретаре булып хисапланса да, фактта редакторлык эшен алып бара.

1905—1907 елгы революциядән соң Астрахань татар җәмәгатьчелеге арасында да культура-мәгариф эшләре киң колач ала: мәктәпләр, китапханәләр, уку йортлары ачы-

ла, газета-журналлар чыгарыла, әдәби кичәләр үткәрелә, спектакльләр куела башлый. Бу эшләрнең башында Астрахань Россия социал-демократлар партиясе янындагы татар эшчеләре группасы тора. Алар арасында Ибраһим Моратов, Гафур Коләхметов, Борһан Мансуров, Заһир Шәрәфетдинов, Шәһит Гайфи кебек революциядә катнашкан кешеләр, типография эшчеләре һәм башкалар була. 1909 елда боларга атаклы революционер, публицист һәм драматург, доктор Нариман Нариманов килеп өстәлә. Ул биш елга сөргенгә җибәрелгән була. Сагыйть Рәмиев әнә шундый мохиткә килеп керә.

Сагыйть Рәмиев монда бик зур активлык белән эшкә керешә. «Идел»дә эшләү белән генә канәгатьләнми, тиз арада җәмәгатьчелек белән дә таныша, аралаша. Әдәби ахшамнарны тәртипле рәвештә үткәрү, театр уеннарын юлга салу, яшьләрне оештырып, аларны театр сәнгатенә өйрәтүдә активлык күрсәтә. Реакция хөкем сөргән еллар булуга карамастан, С. Рәмиев, Астраханьга сөргенгә җибәрелгән революционерлар белән бер сафта, халыкны политик агарту эшләрендә катнаша. Нариман Наримановның докторлыгыннан файдаланып, «эчкелеккә һәм туберкулезга каршы көрәш», «Ак чәчәк бәйрәме» һ. б. кичәләр үткәрү сылтавы астында халыкка политик белем бирү эшләре үткәрелә. 1911 елда, мәсәлән, Сагыйтькә таныш булган укытучы Габдерәхим Сәмәки катнашы белән, Сәмәк авылында крестьян Латыйп Гомәров бакчасында Беренче май бәйрәме — маевка үткәрелә. Доктор Нариманов Беренче май бәйрәме тарихына тукталып зур чыгыш ясый.

Ул вакытта магазин эшчесе Вәли Садыйков бу кичәләр турында болай сөйли:

«Мин әдәби ахшамнарга еш йөри идем. Гадәттә Сагыйть Рәмиев кичәне ача да доктор Наримановка сүз бирә. Ул алкогольнең зарары турында сөйли. Бер читтәрәк, кылычына таянып, жандарм утыра. Ул булгач, янәсе, беркем дә яман сүз ычкындыра алмый. Нариманов эчкелекнең социаль тамырларына тукталып, тормышның авыр булуы, аны җиңеләйтергә, яхшыртырга кирәклек турында сөйли. Ә аңа ничек ирешергә? Тормыш шартларын үзгәртергә кирәк. Ничек үзгәртергә? Анысын инде лектор ачык әйтә алмаса да, тыңлаучылар яхшы аңлыйлар...»

«Бервакыт без Сагыйть Рәмиев белән бергә бер җыелышта (Гыйрфан Гыйсмәтуллин өендә) булдык, — дип исенә төшерә (ул вакытта тел-әдәбият укытучысы, ә хәзер пенционер) Кәрим Каниев. — Күрәсең, бу турыда жандармнарга хәбәр иткәннәр. Капылт кына без утырган өйне жандармнар камап алалар. Сагыйть аптырап кала. Чыгып качу юлын эзли башлый. Ләкин җыелышта булган Әбүбәкер Дашкин аны тынычландыра: «Утырыгыз, утыр, кузгалмагыз!..» — ди дә барып ишекне ача. Ул шәһәр думасының гласные иде. Жандармнарга үзенең кем икәнен танытып: «Мин каз мәҗлесе үткәрәм», — ди. Тегеләр: «Ялгышканбыз, гафу итегез!..» — дип уңайсызланып кайтып китәләр».

Бу чорда Астраханьда Сагыйтьнең дошманнары бик күбәя. Мәчет әһелләре, муллалар Сагыйть Рәмиевне озын чәч йөртеп, халыкны «юлдан аздырганы» өчен күрә алмыйлар, аңа бәддога укыйлар. Карагруһлар аны берничә тапкыр кыйнатырга да маташып карыйлар. Ләкин шуларга да карамастан, Сагыйть Рәмиев үзенең халыкка хезмәт итү эшен дәвам итә. Нариманов оештырган лекцияләрдә, маевкаларда катнаша, ачык һәм яшерен үткәрелә торган җыелышларга бара.

Ләкин Сагыйть Рәмиевнең бу эшләре һәммәсе дә диярлек җәмәгатьчелек хезмәте булып, аның төп эше «Идел» газетасын тәртипле һәм политик яктан шул чорның таләпләренә җавап бирә алырлык итеп чыгару иде. Ул иң әлек «Идел»нең телен татар әдәби теленә якынлаштыра. Яңалыклар кертү уе белән «Идел»дә революционер Блюментальның мәкаләсен басып чыгара. Ләкин полиция шунда ук аның «тезгенен» тарта: «Идел»нең бу номеры конфискацияләнә, һәм Сагыйтьнең үзен штраф түләргә мәҗбүр итәләр.

Сагыйть бу чорда бик күп эш алып бара: «Кабакта мәхәббәт»не язып бетерә, Л. Н. Толстойның «Живой труп» дигән әсәрен татарчага тәрҗемә итеп «Идел» газетасында бастырып чыгара, шигырьләр яза.

Шулар белән берәттән, ул күп санлы яшь шагыйрьләр, язучылар, артистлар белән бәйләнеш тота һәм аларның иҗатлары турында «Идел» газетасы битләрендә тәнкыйть, рецензияләр белән чыга. Аның тәнкыйть һәм рецензияләре, фикри яктан ачык һәм туры була, хәтер саклап борғаланулар аңарга бөтенләй чит иде.

1914 елны Уфада чыга торган «Тормыш» газетасының 123 нче санында С. Рәмиевнең «Әдәбият, музыка һәм жыр кичәсе» дигән тәнкыйть мәкаләсе басылды. Ул үзенең бу мәкаләсендә кичәдә катнашучы әдипләрнең чыгышларын анализлый һәм, сүз уңаенда, гомумән татар сәнгатенең аерым төрләре турында кыйммәтле фикерләр әйтә. «...Бу көнгә кадәр бездә төрле-төрле көйләр булса да һәм һәркайсылары телләрдә жырланып, музыка коралларында уйналып килсәләр дә, әмма аларның берсенең дә чын иҗат итүчеләре билгеле булмаганга, һәммә матур һәм рухны сөйләп бирә торган көйләрне дә без бары матур көй дип кенә жырлый килә идек. Аның гажәеп бер сәнгать булу ягына һәм бу сәнгатьченең көченә, аның сәләте ягына һич бер төрле зиһен жибәрми идек. Бүгенге кичәнең программасында яшьләребездән Габәши әфәнденең музыкадан үз иҗатының күренүе, бездә ул көйләрнең бер-берләренә карата (чагыштырма) матурлыгы вә тыңлаучыга тәэсире ни дәрәҗәдә икәнлеген тикшерү дәртен уйгатты. Габәши әфәнденең иҗат иткән көйләрен аерым бер дикъкать белән тыңладык. «Сагыш», «Яшь вакыт», «Кайгы соңында шатлык» дигән көйләрен үзе рояльдә уйнады. «Пикник» дигән көен рояль, скрипка, мандолина һәм гитара кебек музыка коралларыннан гыйбарәт оркестр башкарды.

...Ләкин безнең оркестрларыбыз көйләребездәге сәктә [1], вакыф [2] һәм паузаларга бер дә игътибар итмиләр. Бер көйнең кай жирдән башланып, кайда беткәнлеге аерылмый: башы ахырына, ахыры башына тоташып китә... Бу хәл зур кимчелекле хәл булып, моның төзәтелеше бик житди сурәттә теләнеләдер. Оркестрыбызны оркестр хәленә куярга бик вакыт...

Сүзебезне тагын Габәши әфәндегә борып, аңарга үз иҗатларын яхшылап эшләп, музыка галәменә чыгару юлында муаффәкыять [3] телибез һәм Габәши әфәнде әсәрләрендә композиция эшенең бездә дә баш күтәрүе белән вә Габәши әфәнде шәхсендә бер композиторыбызның безнең арабызда да башлап вөҗүды (барлыкка килүе) белән милләтебезне тәбрик итәбез!»

Сәгыйть Рәмиев жырларның һәм әдәби декламацияләрнең башкарылу осталыгына тукталып, уңышлы һәм кимчелекле моментларны күрсәтә. Монда инде ул чарасыз рәвештә Шәехзадә Бабич турында берничә сүз әйтергә мәҗбүр була. Ул болай ди:

«Программаның башка номерлары турында сөйләгәндә комик Шәехзадә Бабич әфәнденең дә рольләре һәм аңарга халыкның карашы хакында да бер сүз әйтеп китү урынсыз булмаячактыр. Шәехзадә әфәнде бөтен торышы белән комик бер адәмдер. Программада бу номерның булуы программа өчен бик тулылык булды һәм ул номерны халык бик яратты. Халыкның үз тәгъбире белән әйткәндә, бу номерда ул «эче катып көлде».

Кыскартылып алынган бу мәкаләдән дә Сәгыйть Рәмиевнең ул вакытта нинди мәсьәләләр белән мавыгуын ачык күрергә мөмкин.

Сәгыйть Рәмиев белән Габдулла Тукайның бер-берсенә карашлары мәсьәләсе — татар әдәбиятында киң рәвештә яктыртылган нәрсә. Ләкин бу ике шагыйрь баштарак очрашуларында бер-берсенә зур хөрмәт күрсәтәләр иде.

Сәгыйть Рәмиев Астраханьда эшләгән вакытында Габдулла Тукайның бик каты чирләп китү хәбәрен ишеткәч, нык борчыла һәм аны кымыз белән дәваларга дигән фикергә килә. Шул эш турында доктор Нариманов белән киңәшләшеп, кымыз белән тәэмин итү һәм торак мәсьәләсендә яхшы шартлар тудыру турында Астраханьның алдынгы жәмәгать эшчәннәре белән сөйләшеп, бер фикергә килгәч, Тукайны Астраханьга кунакка чакыра.

1911 елның апрель аенда Тукай Астраханьга килә. Башта ул Сәгыйть Рәмиев белән бергә тора. Аннан соң аны шәһәр читендәге Калмык базары дигән авылга укытучы һәм художник Шәһит Гайфи өенә урнаштыралар. С. Рәмиев һәркөн диярлек аның янына барып, хәлен белә, аны яңа газета-журналлар белән тәэмин итеп тора. Әгәр дә берәр сәбәп белән С. Рәмиев килми калса, Тукай Шәһит Гайфи белән икәүләп аның янына барып житә торган була.

Сәгыйть Рәмиев, Шәһит Гайфи, артист Зәйни Солтанов һәм башкалар шәһәрнең зур драма театры бинасында Г. Тукай хөрмәтенә кичә оештыралар. Тияк районындагы

[1] Сәктә — тын алмастан аз гына вакытта тавышны өзеп тору.
[2] Вакыф — тукталып тору.
[3] Муаффәкыйть — уңышлык.

эшчеләр бистәсендәге «Сары агач» дип йөртелгән сыраханәнең өске катында ярым яшерен әдәби ахшам үткәрелә. Монда Г. Тукай «Халык әдәбияты» темасына лекция укый. Ә «Идел» эшчеләреннән Барый Әминов, Әждар Моратов, Зәйни Солтанов һәм башкалар Г. Тукай шигырьләрен сөйлиләр.

Тукай Астраханьнан киткәндә С. Рәмиев аны хөрмәтләп, олылап озатуны оештыра.

1913 елда Габдулла Тукайның үлү хәбәрен ишеткәч, «Аң» журналының 8 нче санында басылган телеграммасында С. Рәмиев үзенең тирән кайгысын белдереп болай яза:

«Астрахань. Шагыйрь Тукайҗанның үлүеннән килгән кайгымны тел белән әйтеп бетерә алмыйм. Фәкать бүген суынган даһи маңгаеннан үбү белән иктифа [1] итәм.

Хуш кыйммәтле шагыйрь, гафу ит, син безнең тереклегебезнең корбанысың.

Рухың тыныч булсын, Тукайҗан!..

Сәгыйть Рәмиев».

* * *

С. Рәмиев Казанда «Таң йолдызы» газетасының редакторы булып эшләгән чорында газетаның аерым номерлары конфискацияләнеп, үзе судка бирелгән иде. Шундый «гөнаһлары» булган Сәгыйть Рәмиев Астраханьга килгәч, полиция һәм охранка агентлары аны нык күзәтәләр.

Революциядән соң Астрахань дәүләт архивында Сәгыйть Рәмиев һәм Габдрахман Гомәровка караган байтак кына документлар, доносلар табылган. Бу материалларда полиция Сәгыйть Рәмиевне «җәмәгать эшлеклесе, патша самодержавиясенә каршы халыкны агитацияләүче, аны культурага якынайту өчен көрәшүче» дип гаепли.

Полициягә күп доносلар килгәч, полиция чаралар күрә башлый. «Идел» газетасының нәшире һәм элекке редакторы Габдрахман Гомәров 1914 елда сөргенгә озатыла, ә Сәгыйть Рәмиевкә генерал-губернатор Соколовский тарафыннан 40 сәгать эчендә Астраханьнан чыгып китәргә боерык бирелә. Сәгыйть Рәмиев 1914 елда Уфага күчеп килә.

Дөрес, С. Рәмиев иҗатында аның гомуми музыкасыннан башкарак моңнар да яңгырап киткән очраклар булгалады:

«Очырыймсың бәлаләргә, башым, очра!..»

Яки:

«...Алдагы бәйрәм көнен бер шат күрергә ит насыйп...»

Бу мисаллар шагыйрьнең йөрәге авыр кичерешләр белән изелгәнен, авыр тойгылар астында йончылган чакларын күрсәтәләр. Беренчедән, охранка агентларының тенкәсенә тиюләре; икенчедән, татар буржуазиясе һәм аның Гаяз Исхаков, Гомәр Терегулов кебек сатлык бәндәләренең аңа яла ягарга тырышулары һ. б. бергә җыелып, аның өстенә төшәләр дә тинтерәтеп калдыргандай булалар. Ләкин ул мондый авыр моментларда да югалып калмый, үз-үзен тиз барлап ала; үзенең поэзия көчен эшкә җигеп, әдәби иҗат эшен дәвам иттерә, җәмәгатьчелек эшенә чума, совет дәүләте учреждениеләрендә баш алмастан гражданлык бурычларын үтәргә керешә. Шул вакытта, әле ул тормыштан өмет өзмәгәнен дә игълан итеп:

«Сәгадәттән бер дә өмет кискәнем юк,
Хәят белән арам төенен чишкәнем юк,
Кесәсеннән хәятның, раст, авыз итсәм дә,
Ләкин әле төбенә хәтле эчкәнем юк», —

дип яза.

Ул әле дошманнарын аптырашта калдырырлык итеп җырлаячагын вәгъдә итә:

«Күрерсез сез хөсумемнең [2] аптырашын,
Хак алдында батыйлның [3] дер калтырашын, —

---

[1] Иктифа итәм — канәгатьләнәм.
[2] Хөсум — дошман. Политик карашы белән каршы кеше.
[3] Батыйл — хаклыкның киресе. Бозык әшәкелек.

Әгәр Зәмин[1] әзер булып, тоталсагыз,
Сез һавадан аның яшен ялтырашып...»,

— ди ул.

Ләкин көчәеп киткән каты чир аңа күп җырларга ирек бирми...

Сәгыйть Рәмиев эшчәнлеге турында сүз барганда аның татар теле һәм татар орфографиясе мәсьәләсе буенча да күп кенә эшләр башкарганлыгы турында бер-ике сүз әйтеп китәргә кирәк. Ул бу мәсьәләдә, күп кенә телчеләрдән аермалы буларак, татарлар кулланып килгән гарәп хәрефләрен бераз үзгәртү, сипләү кебек эшләрне бөтенләй файдасыз дип саный һәм башка принципиаль позициядә торып, гарәп хәрефләрен ташлап, латин хәрефләрен алуны тәкъдим итә. Ул бу турыда зур көч куеп, латин хәрефләрен татар телендә куллану проектын төзи һәм аның үрнәкләрен «Идел» газетасында бастырып чыгара, проектны тикшерү өчен җәмәгатьчелек дикъкатенә тәкъдим итә.

Ләкин орфография алыштыру, бер шрифттан бүтән шрифтка күчү кисәк кенә мөмкин түгел иде. Җәмәгатьчелек бу реформаның прогрессив икәнлеген таныр өчен еллар кирәк булды. Тик 1927 елны Баку съезды булып үткәч кенә моны тормышка ашыру мөмкин булды.

Тюркологларның Баку съезды латин хәрефләрен кабул иткән көннәрдә Сәгыйть Рәмиев бик каты чирләп Уфа больницасында ята иде. Мин, съезддагы фикер алышулар һәм карарлар язылган газеталарны алып, аның янына больницага бардым. Съездда латин хәрефләре кабул ителгәнлеген телдән дә, укып та аңлаттым. Ул сабыйларча куанды, нурланып киткәндәй булды.

Мин сәламәтлеге, кәефе ничеклеге турында сораша башладым.

— Хәлем яман түгел. Ләкин кичкә табан, бигрәк тә кояш баегач, авыраям. Һава җитмәгәндәй була. Әмма кояш чыгар алдыннан хәлем яхшылана... — дип сөйләгәч, мин аңарга көлебрәк кенә Бальмонтның:

«Я в этот мир пришел,
Для того, чтобы видеть солнце!..», —

дигән шигыреннән бер-ике куплет укыдым. Ул тагын да җанланып киткәндәй булды:

— Төн таңга таба авыша башлагач та, тән җиңеләйгәндәй була башлый. Бу, әлбәттә, кояш тәэсире инде. Мин «кояш культы» төзегән кешеләрне бик акыллы һәм реалист булганнар дип уйлап ятам, — диде.

Мин аның «кояш культы» турындагы фикерләрен бик кызыксынып тыңладым. Бу 1926 елның 16 марты иде.

Көн кичкә таба авышты. Мин күп сөйләтеп арытмыйм дип, рөхсәт сорап, иртәгә тагын килермен, дип кулын кысып күрештем.

— Кил, кил! Син килгәч, рәхәт булып китте әле!.. — дип мине күзләре белән озатып калды...

Ләкин икенче көнне ул юк иде инде...

Бөтен гомере буенча матурлыкка, шигырьгә табынган, кешеләр арасында «мәхәббәт орлыгы чәчү» юлында ялкынланып, дөрләп янган шагыйрь йөрәге мәңгегә сүнгән иде!

Олы талантлы шагыйрь Сәгыйть Рәмиев исемә төшкән саен минем күңелгә аның:

«Кешеләргә күренгәннән мин яхшырак,
Тышымдан эчем минем күп яктырак,
Ант итәм — тәхкыйрь, ачу, кинә түгел —
Күңелемдә илгә каршы янган чырагъ!..» —

дигән шигыре килеп төшә.

— Әйе, шагыйрь, син шундый идең!

---

[1] Зәмин — җирлек.

# Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары

## В. И. ЛЕНИН ТУГАН КӨНГӘ БАГЫШЛАНГАН МУЗЫКАЛЬ ФЕСТИВАЛЬ

Казанда кешелек дөньясының даһи юлбашчысы Владимир Ильич Ленин туган көнгә багышлап музыкаль фестиваль үткәрү инде традициягә әверелде.

Быелгы фестиваль 19 апрельдә Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында А. Холминовның «Ленин турында җыр»ы белән ачылды. Фестивальгә илебезнең башкаласыннан танылган артистлар, композиторлар һәм СССРның дәүләт симфоник оркестры килде.

Казан тамашачылары СССР халык артисты профессор Л. Оборин башкаруында Бетховенның оркестр белән фортепьяно өчен язылган V концертын һәм аның Шиллерның «Шатлыкка» одасына язылган IX симфониясен һ. б.ларны кызыксынып тыңладылар. Фестивальгә шулай ук РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе А. Юрлов җитәкчелегендәге республика рус хоры капелласы, солистлардан А. Пазовская, В. Суховицина, РСФСРның халык артисты В. Ивановский, халыкара конкурс лауреаты В. Грамадский һ. б. лар катнашты. Фестиваль республикабыз башкаласының театрларында, клубларында, Культура йортларында апрель ахырына кадәр дәвам итте.

Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе артистлары фестиваль уңае белән предприятиеләрдә, югары уку йортларында, концерт залларында Ленин турындагы һәм Ильич яраткан әсәрләрне башкардылар. Фестиваль барышында «Ленин безнең белән», «Бөек тормыш» дигән әдәби концертлар оештырылды.

## КОМПОЗИТОР А. Г. НОВИКОВ КАЗАНДА

В. И. Ленинның тууына 95 ел тулуга багышланган фестивальгә танылган җырчы-композитор Анатолий Григорьевич Новиков та килгән иде. Бу көннәрдә ул Казан дәүләт университеты студентлары янында кунакта булды, Казан музыка сөючеләренә берничә концерт бирде.

## ТАМАШАЧЫЛАР БЕЛӘН ОЧРАШУ

20 апрельдә «Татарстан» кинотеатрында В. И. Ленинның тууына 95 ел тулу уңае белән үткәрелгән тамашачылар белән очрашуда шагыйрьләрдән Ш. Галиев белән М. Фәйзуллина бөек юлбашчыга багышланган әсәрләрен укыдылар.

## КИНЕМАТОГРАФИСТЛАР КИҢӘШМӘСЕ

Апрель башында Казанда кинофикация һәм кинопрокат работниклары киңәшмәсе булды. Киңәшмәгә унике автономияле республика һәм өлкә кинематографистлары катнашты.

Киңәшмәгә катнашучылар РСФСР Министрлар Советының Кинематография буенча Дәүләт комитеты председателе докладын тыңладылар, доклад буенча фикер алышуларга катнаштылар.

Киңәшмәгә Төньяк Кавказ һәм Идел буе шәһәрләрендәге биш киностудия чыгарган фильмнарга смотр үткәрелде.

## КИТАП БӘЙРӘМЕ

Бөек юлбашчыбыз Владимир Ильич Ленин тууына 95 ел тулу алдыннан, КПСС райкомы бюросының карары нигезендә, Мөслим районында китап сату ике айлыгы булды. Башлангыч партия оешмалары, комсомол оешмалары, укучылар һәм укытучылар колхозчылар арасында китап пропагандалауны һәм сатуны киң җәелдереп җибәрделәр.

Мөслим унберьеллык мәктәбе укучылары һәм укытучылар 785 сумлык китап саттылар.

## КАЗАНДА ЯҢА ОРКЕСТР

Татар музыка культурасының казанышлары шактый зур. Татар композиторларының симфоник әсәрләре, алар иҗат иткән опера һәм балетлар, җырлар республикабыз чикләреннән еракларда да яратып тыңлана. Шуңа карамастан, моңа кадәр симфоник әсәрләр башкару өчен махсус оркестр юк иде. Апрель аенда Казан музыка сөючеләре, ниһаять, шәһәребезнең үз оркестрын тыңладылар. Бу оркестрны оештыручы һәм аның дирижеры РСФСРның атказанган артисты, Карелия АССРның халык артисты профессор И. Э. Шерман. Оркестр составында Казан консерваториясе педагоглары һәм студентлары чыгыш ясый. Оркестрның беренче концертлары тыңлаучыларда җылы тәэсир калдырды.

## МУЗЫКА СӘНГАТЕ ФЕСТИВАЛЕ

Горький шәһәрендә апрель аенда Идел буе халыкларының музыка сәнгате фестивале булып үтте. Фестиваль Татарстан композиторы Альберт Леманның «Ленин» ораториясе белән ачылды.

Фестивальдә анардан тыш татар композиторларыннан Н. Җиһанов, Р. Яхин, А. Монасыйпов, Р. Еникеев, Ф. Әхметов һәм И. Хисамов катнашты.

## А. АЛИШ ИСЕМЕНДӘГЕ ПИОНЕРЛАР САРАЕ

ТАССР Министрлар Советы тәкъдиме белән РСФСР Министрлар Советы Казандагы Пионерлар сараена Абдулла Алиш исемен бирде.

## БӨТЕНСОЮЗ КИТАП ЯРМИНКӘСЕ

Кыргызстан ССРның башкаласы Фрунзеда апрель аенда Бөтенсоюз китап ярминкәсе үткәрелде. Анда барлык союздаш республикаларның китап сәүдәсе оешмаларыннан, РСФСРның Автономияле республикалары, крайлары һәм өлкәләрендәге шундый ук 103 оешмадан вәкилләр катнашты. Татарстаннан күп санлы китап үрнәкләре куелган иде. Аларның күбесен бүтән республика һәм өлкәләрнең сәүдә оешмалары договор төзү һәм заказлар бирү тәртибендә сатып алдылар. Китап пропагандалауда актив катнашырга тиешле иҗат оешмасы булган Татарстан Язучылары союзыннан ярминкәдә З. Нури, Татарстан китап нәшриятының баш редакторы Х. Гобәйдуллин, яшь композитор А. Батыршин, Таткниготорг, Татсоюз, өлкәара китап сәүдәсе базасы вәкилләре катнаштылар.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Татарстан Язучылары союзының Әлмәт бүлегендә отчет-сайлау җыелышы булып үтте. Бюро составына Р. Төхфәтуллин, Ә. Маликов, Ш. Бикчурин иптәшләр кертелде. Бүлекнең җаваплы секретаре итеп Ә. Маликов сайланды.

Әлмәт Татар дәүләт театры Гариф Ахуновның «Утлар яна учакта» дигән пьесасын тамашачыларга күрсәтте. Бу әсәр республикабызның нефтьчеләр тормышына багышланган.

Әлмәт районы буенча семинарга җыелган клуб мөдирләре, китапханә работниклары алдында шагыйрь Әдип Маликов һәм прозаик Герман Крылов чыгыш ясадылар. Алар үзләренең әсәрләрен укыдылар, күп санлы сорауларга җаваплар бирделәр.

## КОНФЕРЕНЦИЯЛӘР, ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Мамадыш районының Югары Ошма авылы клубында булып үткән культура-агарту работникларының районара семинарына катнашучылар шагыйрь Г. Латыйп, балалар язучысы Г. Бакиров белән очраштылар, аларның яңа әсәрләре белән таныштылар.

Апрель аенда Татарстан дәүләт музеенда казанлылар язучы Ю. М. Корольков белән очраштылар. Патриот шагыйрь Муса Җәлил, куркусыз разведчик Рихард Зорге турында повестьлар авторы Юрий Михайлович Корольков Бөек Ватан сугышы еллары һәм повестьларны ничек язуы турында сөйләде.

Март аенда В. И. Ленин исемендәге республика китапханәсендә Э. Касыймовның «Гомер ике килми» романы буенча укучылар конференциясе үткәрелде. Фикер алышуга эшчеләр, студентлар, укытучылар катнашты. Слесарь Зарипов, токарь Хәйретдинов, аппаратчик Айзетдинов, укытучы Яруллина, пенсионер-укытучы Гайнуллин, инженер Зәйнуллин һ. б. чыгыш ясаучылар романны яратып укуларын сөйләделәр, авторга яңа иҗат уңышлары теләделәр.

Шул ук романга карата укучылар конференциясе Алабуга педагогия институтында да булып үтте. Студентлардан Якупова, Нуриева, Рәхимова, Гафаров, Кәримуллина, Фәсхиева, Дәүләтова, Гиззатова һ. б. лар роман буенча фикерләрен әйтеп чыгыш ясадылар.

Габдрахман Минский, Казан дәүләт Консерваториясе студентлары белән очрашып, үзенең яңа әсәрләреннән өзекләр, иҗат планнары белән таныштырды.

Галимнәр йортында Бөек Ватан сугышында җиңүгә 20 ел тулуга багышлап «Ул көннәрнең даны онытылмас» дигән темага үткәрелгән кичәдә шагыйрь Зәки Нури катнашты. Ул совет кешеләренең сугышта күрсәткән батырлыклары турындагы әсәрләрен укыды.

Шагыйрь Нәби Дәүли Удмуртия АССРда булып кайтты. Шул көннәрдә ул Болезино эшчеләр поселогының беренче номерлы тимер юл мәктәбе укучылары белән очрашты һәм тимер юлчылар клубына җыелган эшчеләргә «Яшәү белән үлем арасында» исемле повесте турында сөйләде һәм яңа әсәрләрен укыды.

Әгерҗе районы Культура йортында Н. Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» исемле китабына карата укучылар конференциясе үткәрелде. Конференциягә автор үзе дә катнашты.

Казан дәүләт педагогия институтында Х. Туфан, Г. Әпсәләмов, Ә. Исхак иҗатларына багышланган әдәби кичә булып үтте. Студентлар яраткан язучыларының чыгышларын зур кызыксыну белән тыңладылар.

Казан шәһәренең 10 номерлы интернат мәктәбе укучылары белән очрашуга Гариф Гобәй, Зәки Нури, А. Сәләхетдинов, К. Фәсахов һәм Х. Сарьян катнашты. Укучылар язучы абыйларының яңа әсәрләрен яратып тыңладылар.

Казан дәүләт университеты каршындагы әдәби-иҗат түгәрәгенең чираттагы утырышында Ф. Хәсни студентларны РСФСР язучыларының II съезды йомгаклары белән таныштырды.

Г. Әпсәләмов Казан шәһәренең 122 мәктәп укучыларында кунакта булды, аларны әсәрләренең язылу тарихы белән таныштырды, иҗат планнары турында сөйләде.

12 апрельдә Казан шәһәренең 35 мәктәбендә укучылар һәм укытучылар язучылардан Госман Бакиров, Әминә Бикчәнтәева, Мөнир Мазунов һәм Самат Шакир белән очраштылар.

Соңыннан укучылар тарафыннан концерт бирелде. Укучылар язучы абыйларына һәм апаларына бүләкләр тапшырдылар.

Залда китап сату оештырылган иде. Язучылар автографлар белән китапларын бирделәр.

Арча районы Олы Әтнә авылындагы китапханә укучылары белән Самат Шакир очрашу үткәрде. Ул укучыларга үзенең шигырьләрен укыды һәм Сталинград геройлары испанлы Рубен Ибаррури Руис, рус егете Владимир Каменщиков һәм татар егете Хафиз Фәттәхетдиновлар турында «Легенда егетләре» дигән повесте өстендә ничек эшләвен сөйләде.

7 апрельдә Алабугада «Яңа Кама» газетасы редакциясе янында оештырылган әдәбият түгәрәгенең чираттагы утырышында Э. Касыймов РСФСР язучылары съезды йомгаклары турында сөйләде. Соңыннан яшь шагыйрьләр Е. Уткин белән Ф. Шәйхиевнең яңа шигырьләре укып тикшерелде.

## ТУКАЙ КӨННӘРЕНДӘ

Республикабыз хезмәт ияләре апрель аенда халкыбызның бөек шагыйре Г. Тукайның тууына 79 ел тулу көнен билгеләп үттеләр. Шагыйрь иҗатына карата китапханәләрдә, мәктәпләрдә, югары уку йортларында китап күргәзмәләре оештырылды, әдәби кичәләр үткәрелде.

Казанда Тукай һәйкәле янында 25 апрельдә шул уңай белән традицион шигырь бәйрәме үткәрелде.

Бәйрәмне Г. Тукай иҗатына багышланган кереш сүз белән Г. Тукай премиясе лауреаты Г. Әпсәләмов ачты. Аннары Х. Туфан, С. Хәким, Г. Хуҗиев, М. Садри, З. Нури, Ә. Давыдов, И. Юзиев, Ш. Галиев, Ә. Баянов, М. Фәйзуллина, Ә. Бикчәнтәева, С. Шакир, Н. Гайсин, яшь шагыйрьләрдән Ә. Гайнуллин, Л. Шакирҗанова үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар. Артистлардан Ә. Һһүдин, А. Шамуков, 35 мәктәп укучылары Л. Галиева, Т. Галиева, И. Сибгатуллина, Н. Локманова, 126 мәктәп укучылары Г. Мусина һәм С. Хисмәтуллина Г. Тукай әсәрләрен яттан сөйләделәр.

Бәйрәмгә катнашучылар Г. Тукай һәйкәленә чәчәкләр куйдылар.

21 апрельдә Совет районы Культура сараенда (Дербышка поселогы) Г. Тукай иҗатына багышланган әдәби кичә булды. Г. Тукай иҗаты һәм хәзерге заман турында доклад белән Гали Халит чыкты. Инженер-конструктор Эрнест Зәйнуллин Тукайның халыкчанлыгы, контролер Гафиятуллин Тукай лирикасы, партия эшчесе А. Исхаков Г. Тукай һәм балалар әдәбияты турында сөйләделәр.

Кичәдә Хәсән Туфан, Нури Арсланов, Галимҗан Латыйп, Мөхәммәт Садри Г. Тукайга багышланган әсәрләрен һәм шигырьләрен укыдылар. Филология фәннәре кандидаты, доцент Якуб Агишевның Тукай әсәрләрен художестволы итеп укуын кичәгә катнашучылар бик яратып тыңладылар.

Соңыннан 106 мәктәп укучылары Г. Тукай әсәрләреннән зур концерт бирде.

## ГЕРОЙ ШАГЫЙРЬ Х. МӨҖӘЙНЕ ИСКӘ АЛУ КИЧӘЛӘРЕ

Күптән түгел Башкортстан АССРның Октябрьск шәһәрендә Бөек Ватан сугышы герое, патриот шагыйрь Х. Мөҗәйгә музей ачылу уңае белән искә алу кичәсе булды. Кичәне КПССның Октябрьск шәһәр комитетының беренче секретаре Мидхәт Афридонов ачып, болай диде:

— Без бүген ялкынлы көрәшче һәм шагыйрь Мөҗәһит Хәйретдиновны хөрмәт белән искә алырга килдек. Х. Мөҗәй — безнең якташ. Ул Октябрьск шәһәренең Төрекмән эшчеләр поселогында туган, шуннан армиягә киткән һәм каты сугышларда катнашкан. Ул искиткеч батырлыклар күрсәтеп һәлак булды. Фашизм оясында — Мюнхен һәм Дахау үлем лагерьларында да ул коммунистлар партиясенә, Ватанга турылыклы булды. Патриот шагыйрь безнең йөрәкләребездә мәңге сакланыр...

Аннан соң сүз Татарстаннан килгән шагыйрь Самат Шакирга бирелде. Ул Х. Мөҗәйнең тормышы һәм иҗаты, фашизмга каршы көрәшкән ышанычлы оешмада алып барган эше, көрәше турында сөйләде. Башкорт шагыйрьләре Мөхетдин Таҗи, Тимер Арслан, Габдулла Байбурин Х. Мөҗәйнең батырлыклары турында чыгыш ясадылар. Шагыйрьнең апасы Хәйретдинова Хаҗувафа Мөҗәй турында истәлекләр сөйләде. Социалистик Хезмәт Герое Ләйлә Мәрдәншина патриот шагыйрьнең исемен мәңгеләштерү кирәклеген әйтте.

Кичәдә Х. Мөҗәйнең шигырьләре укылды.

23 апрельдә Казан Мәгариф хезмәткәрләре йортында Х. Мөҗәйгә багышланган әдәби кичә булды. Кичәне кыскача кереш сүз белән Г. Әпсәләмов ачты. Самат Шакир шагыйрьнең тормышы, иҗаты, фашист тоткынлыгында күрсәткән батырлыгы турында сөйләде. Илдар Юзеев Х. Мөҗәйгә багышлап язылган поэмасын укыды. Соңыннан Идел буе районы Киров исемендәге Культура сарае каршындагы үзешчән сәнгать түгәрәге көче белән Х. Мөҗәй иҗатына багышланган зур концерт булды.

## Алдагы саннарда:

Ш. Маннур. **Муса.** Роман.
Ш. Бикчурин. **Кайту.** Хикәя.
Ф. Хөсни. **Ике агроном, бер овчарка.** Хикәя.
Г. Хуҗиев шигырьләре.
Юстас Палецкис (Литва шагыйре) шигырьләре.
Х. Вахит. **Карлыгач канат кага.** Комедия.
Р. Сверигин. Ф. Хөснинең иҗат портреты.
Г. Халит. **Яңа герой ничек туды.** Тәнкыйть мәкаләсе.
Х. Хисмәтуллин. **Гаделлек һәм мәхәббәт** поэзиясе. «Дастан Бабахан» әсәре турында мәкалә.
И. Нуруллин. Ф. Әмирханның пьесалары турында тәнкыйть мәкаләсе.
Яңа басылып чыккан китапларга рецензияләр.
Латыш халык мәзәкләре.

Җаваплы редакторы **Сибгат Хәким**
Редколлегия: **Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский, Нил Юзиев**

Наборга бирелде 10/IV-65 ел. Басарга кул куелды 18/V-65 ел. ПФ 08111. Кәгазь форматы $70\times108^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Заказ № Л-532. Тираж 20228 экз. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, 19. 1965 ел.

# ХӨРМӘТЛЕ ИПТӘШЛӘР!

«Казан утлары» журналына елның теләсә кайсы аенда язылырга мөмкин. Журналга язылу бәясе:

6 айга — 2 сум 40 тиен;

3 айга — 1 сум 20 тиен.

«Казан утлары» —Бөтенсоюз каталогына кертелгән журнал. Аңа Советлар Союзының барлык элемтә бүлекләрендә, «Союзпечать»-ның барлык бүлекләрендә чикләүсез язылырга мөмкин һәм түбәндәге адрес белән дә язылып була:

*Казань, ул. Куйбышева, 17|25, областной отдел „Союзпечати“.*

Урыннарда нинди дә булса сылтау белән журналга язмасалар, турыдан-туры редакциягә хәбәр итүегезне үтенәбез.

Безнең адрес:

*Казань, Баумана, 19, Дом печати, редакция журнала „Казан утлары“.*

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

Индекс
73367

*Ежемесячный литературно-художественный*
*и общественно-политический журнал*

**КАЗАН УТЛАРЫ**

*(Огни Казани)*

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ